www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ренат ХАРИС. Аһ, үзгәрә дөнья!.. *Шигырьләр.* ....3
Фоат САДРИЕВ. Тургай. *Бәян.* ....9
ИДЕЛБИКӘ. Кан тамыры кебек елгалар. *Шигырьләр.* ....49
Вакыйф НУРИЕВ. Ни хәлең бар, балам?.. *Бәян.* ....52
Мөхәммәт САДЫЙКОВ. Тамыр җәйдек туган туфракка. *Шигырьләр.* ....78
Рашат НИЗАМИ. Блокада хатирәсе. *Хикәя.* ....81
Гөлүсә БАТТАЛОВА. Ихласлыкка сусаган җан. *Шигырьләр.* ....89
*100нче бит:* Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Рухи мирасыбыз һәрчак юлдаш булсын! ....100

ЮБИЛЕЙЛАР

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Сугышчы әдип — сафта. ....94
Ленар ШӘЕХ.«Мин — мәңге тутыкмас алтын төрән! ....102
Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Учларында утлы күмер… ....106
Мөхәммәт МИРЗА. Гомерләр кичкәндә. ....110
Гамил АФЗАЛ. Мәңгелек гамь. *Шигырьләр.* ....119
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. «Кыр казлары очып узарга…». ....122
Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ. Татар теле. *Шигырьләр.* ....125
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН, Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Язмыш йөртә кешене. ....128

*Әдәби тәнкыйть:* Фәрит ХАТИПОВ. Ясалма трагедия. ....134

ПУБЛИЦИСТИКА

Гомәр ДАУТОВ. Олуг максатка мәгариф аша килик. ....135

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Рафис КОРБАНОВ. Үткәннәргә хисап тотканда. ....140

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Тукай очырган карлыгачлар: Гыйффәт туташ. ....148

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән:* Афзал ШАМОВ. Дустым кабере янында. *Хикәя.* ....152

СӘНГАТЬ

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Яратып китү. ....159

МИЛЛИЯТ

Индус ТАҺИРОВ. Изге сөткә ни җитәр? ....163

*Юбилейга барышлый:* Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ. Көндәлек дәфтәремнән. ....172

АК ҖИЛКӘН

Зөлфәт ХӘКИМ. Бәләкәй Зөлфәт. ....177
Хикәя яза аласызмы? *(Алёна Фәхретдинова, Ильяс Рәхмәтов хикәяләре; Роза Кәлимуллина әкияте).* ....183

*Шаян сәхифә.* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....186

«Казан утлары» архивыннан. ....92
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....189

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).


✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.04.2016, график буенча 29.04.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-1148. Тираж 4005.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе иркле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2
© «Казан утлары», 2016 ел



Ренат Харис

# Аһ, үзгәрә дөнья!..

## Бүгенем сонеты

Килдем сиңа нинди көннәр аша,
нинди төннәр аша, бүгенем?!
Хәтеремдә хәзер чиратлаша
татлы шатлык, ачы үкенү,

хурлану һәм канәгатьлек хисе,
горурлану белән оялу...
Чәчләремдә шулар буявы,
болын исе җанда, янгын исе...

Барысы да үтә икән, сизәм...
Бетми икән ләкин берсе дә,
бигрәкләр дә – күңел ярасы...

Син, бүгенем, матур итеп бизә
гомерлеккә күзне ачу белән
мәңгелеккә йому арасын...

## Бәхет төшенчәсе сонеты

Сөйләшмик әле кайгы турында!..
Бәхет турында ешрак сөйләшик!
Бәхетнең җылы, якты нурында
яна, югала, эри бөтен шик.

Сүзләр күңелгә аллы һәм гөлле
матур, илаһи тынычлык кертә,
һәм кызыл башлы җитен ак сөлге
куанган җанның яшьләрен сөртә...

---

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт премиясе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Нарасый бала кебек гөнаһсыз,
фәрештә кебек аһсыз һәм ваһсыз
яшәп карыйсы килә кешечә…

Ләкин нигәдер дөньясы шундый –
безгә һаман да һич аңлашылмый
бәхет-сәгадәт дигән  төшенчә…

## Алманың хушлашу сонеты

Мин иртәгә синнән китәрмендер –
үзәгемне нидер кимерә…
Ләкин белмим – кая төшәрмендер,
Җиргә төшсәм, аны җимерәм.

Шундый авыр бит мин! Белми кем дә:
кайчан, кайда, ничек җыйганмын,
ботагыңда  торып көн дә, төн дә,
авырлыгын бөтен җиһанның!

Ничек сынмыйсың син? Аңлап китим!..
Нинди максат белән яшисең –
шул сереңне кабат җиргә илтим…

Миндәй алма синдә меңләгән…
Җир һәм кояш арасына бит мин
зерә үләр  өчен менмәгән!

## Эндәшмәү сонеты

Мин эндәшмим – мине Аллаһ тыңлый!..
Аның белән шулай аңлашам…
Җанымдагы фани давыл тыны
бакый тынлык белән алмаша.

Һәрбер күзәнәккә тынлык тула,
су сеңгәндәй коры мамыкка…
Мин Аллаһны аңлагандай булам…
Сөйли генә белмим халыкка…

Аңлаганны сөйли алсам әгәр,
куанычтан үләр идем мин…
Аллаһ сүзен Җиргә тик пәйгамбәр
җиткергәнен әллә белмимме?!

Аллаһ тыңлый мине тын торганда –
фани аңым бакыйлыкка орынганда…

## Үлмәс зынҗыр сонеты

Йөрәгемне синең йөрәккә
җырым белән куйдым чылбырлап.
Боҗралары, һәрчак чылтырап,
шат яшәргә мине өйрәтә.

Ә җырларым шундый нәрсәдән –
алмазлар да кисә алмаслар!
Кисәргә дә аны юк сәбәп…
Үлем генә аяк чалмаса…

Боҗраларга боҗра кидерәм –
дәвам итәм җырлы чылбырны!
Йөрәгемә һәркөн тидерәм
җан җылысы булган зынҗырны.

Сөйгән ике йөрәк арасы –
үлмәс зынҗыр кою чарасы.

## ТӘРӘЗ КАРШЫНДАГЫ ЮКӘЛӘР

ЦИКЛ

### Баллы яңгыр

Тәрәз каршындагы юкәләрдән
бал тамчылар тамып торалар…
Ник яшәми икән калаларда
бал кортлары, төклетуралар?!

Яңгыр юа юкә чәчәкләрен –
әрәм була инде баллы су…
Баллы яңгыр! Баллы яңгыр, сине
ничек кенә җыеп калыйм соң?!.

Агып китә баллы юкәләрнең
җир сихәтен җыйган серкәсе –
үткәннәрдән калган яраларга
дәва итеп кенә сөртәсе!

Искә төшә юкә аллеясы:
аягыбыз балга ябышты;
балга басып, баллы һава сулап,
балдай татлы итеп кавыштык…

Шул көннән соң күпме яңгыр койды,
яфрак очты, карлар яудылар.
баллы эзләр безнең сөртелмәде,
балның татын саклап калдылар.

Юкәләрне юып яңгыр ява…
Ышыгында – бер кыз… Ялгызы…
Әрәм була инде, әрәм була,
әрәм була инде баллы су…

### Яшел яфрак аша

Тәрәз каршындагы юкәләрдән
әле генә сары бал тамды…
Бүген – сары яфрак!..
Гомер оча!..
Тизлегенә аның таң калдым…

Сары яфрак булып оча гомер,
дип уйлыйсы килми –
яралый…
Яшел яфрак аша
күк күренә…
Яфрак яткан җиргә
карамыйм…
Яшел яфрак аша күк күренә –
кайчак зәңгәр,
кайчак ак булып.
Җанга җәйне алып керә кебек
яфрак аша узган яктылык.

## Мин курыкмыйм

Тәрәз каршындагы юкәләргә
кошлар түгел,
сары көз кунган.
Кичә генә дүрт-биш яфрак иде,
бүген инде алар йөз булган.

Саныйм… Саныйм…
Эшем юктан түгел…
Яфракны да түгел санавым…
Тоям –
Көзнең, күзләремә карап,
саргайтулар белән
янавын…

Мин курыкмыйм…
Көз
җилләрен айкый –
сары давыл анда котыра…
Мин курыкмыйм…
Башны учка салып,
кыш турында уйлап утырам.

## Көзге яшел яфрак

Юкәләрнең яшел яфракларын
таптап йөрдем бүген ачынып…
Аһ, үзгәрә дөнья!..
Аңлашылмый…
Шул кузгата җанда ачуны.

Алтын көзнең ямен
салкын җиргә
яткан яшел яфрак киметә…
Искә төшә иртә киткән дуслар,
җимеш булмый калган өметләр…

Искә төшә үткән яшел көннәр,
баллы яфракларның хуш исе…
Сагындыра…
Нидер сагындыра…
Сагынасың – димәк, яшисең!

## Табигатьнең Морзе әлифбасы

Каршыбызда үскән карт юкәнең,
тәрәзәгә чиртеп, ботагы
хыял дөньясында рәхәт чиккән
уйларымны минем бутады...

Ни йомышың төште миңа, юкә?
Әллә инде бераз туңгансың?
Мин өемә алып керер идем,
тамчы гөлдәй генә булсаң син...

Табигатьнең Морзе әлифбасын
укый белмим – шундый надан мин!
Таный алмаганны аңладым дип,
ничә тапкыр инде алдандым.

Ни әйтергә телисең син, юкәм,
нинди хәсрәт синең башыңда –
матурлыгың, сары яфрак булып,
тапталумы урам ташында?..

Борчылудан төсең качкан кебек –
ботакларың бәскә төренгән...
Син дә куркасыңдыр кара көздән
ап-ак кышка барып керүдән...

## Карт бер ала карга

Карт бер ала карга биләп алды
тәрәз каршындагы юкәне.
Бер кошны да якын җибәрмәде
әллә җыры, әллә ютәле...

Һәм бүген дә биләмәсенең ул
барлап чыкты һәрбер ботагын,
канатларын ярсып шапылдатты –
зәһәрләнгән иде мотлак ул!..

Ә аннары балкон кыршавына
хуҗаларча килеп кунды да,
миңа карап, шундый каркылдады –
тетрәп куйды каләм кулымда.

Әйтерсең лә юкә яфракларын
мин койганмын, урлап кергәнмен,
һәр яфракка язып барган икән
шигырьләрен, йөрәк серләрен...

Әйе, шулай каркылдады карга!..
Ни гаҗәеп – аны аңладым!..
Карга халкының да шагыйре бар! –
моңа минем шигем калмады...

Өзелде дә очты соңгы яфрак
кара көзнең салкын җилендә...
Аны эзләп, карга очып китте...
Иярәсем килде минем дә...

## Әллә нишләде дөньялар

Тынычсызланып, боегып,
ни буласын белмичә,
тәрәз каршымдагы юкәм
күзләрдән кышка күчә.

Яфракларын кыштырдатып,
килер язын күзаллый…
Яңа бөрегә юл ябык –
иске яфрак кузгалмый,

җыерылып бөрешкән дә
тора бирә ябышып –
Җирнең нинди җимен җыеп,
суын эчеп ялгышты?

Кояшның нинди нурлары
тәнен тишеп узганда,
күзәнәк үзәгендәге
тәртипләрне бозганнар?..

Тамырын җирдән йолкырга
теләде бугай юкә…
Каурыйсыз калган канатлар
күтәрә алмый күккә…

Әллә нишләде дөньялар…
Үзем дә элеккечә
алмаштырмыйм фасылларны –
тынычсызланып күчәм…

## Ятьмә кебек ботаклар

Кара җептән үргән ятьмә кебек
ботакларын җәеп, юкәләр,
тәрәзәмә карап, нәрсәнедер
эләктермәк булып көтәләр…

Тәрәзләрем аквариум түгел,
тотмыйм өйдә читлек кошы да,
ә юкәгә карап, тозак күрәм…
Менә шуңа җаным пошына…

Минем өйдә оча торган нәрсә
таба алмас беркем һич кенә…
Оча алган нәрсә – җаным гына,
ул әлегә тәнем эчендә…

Җылы якка хат җибәргән идем
яз кошларын монда чакырып…
Кара ботакларга бер кош кунды, –
сыерчыклар кайтты, ахрысы…

Фоат
Садриев

# ТУРГАЙ

БӘЯН

## Сөмбел

Иртән тәмләп кенә чәй эчеп уянганда, әбисе сикереп торып календарьга карады да:

– Бүген Шәмседохаттига иксән яшь! – диде.

Шау-гөр килеп бу хәбәрне тикшергәч, аны котларга әбисе белән Тургай барырга тиеш булды. Әтисе белән әнисе эшкә китте, бабасының гадәттәгечә башы белән йөрәге авырта. Мондый эшкә шортыдан барырга ярамый дигәч, Тургай яңа күлмәк-чалбарын киде. Күчтәнәчкә гөбәдия, чәй, җимешләр, тагын әллә ниләр төреп алдылар.

Ындыр артлап кына бик тиз барып җиттеләр. И, сөенеп тә куйды инде Шәмседоха әби алар килгәнгә! Кендек әбисе Тургайны туйганчы сөйгәннән соң:

– Сиңа ничә яшь инде, улым? – дип сорады.

Тургай юри бер сүз дә дәшмичә, биш бармагын тырпайтып күрсәтте.

– Биш яшең тулгач, син егет кеше булгансың инде, улым, – диде Шәмседоха әби. – Ә менә миңа бүген сиксән яшь.

Тургай аларны ничек көлдерергә микән, дип уйлап кына тора иде, теленә килгән беренче сүзләрен әйтте дә салды:

– Беркая да бара алмыйсың инде, Шәмседоха әби, картаябыз!

Бу сүзләрне ишетүгә, әбиләр, кигәвен куарга теләгәндәй, кулларын селти-селти көләргә тотындылар, диванга барып чүмәштеләр, әлеге сүзләрне туктаусыз кабатлаттылар, Тургай үзе алардан да ныграк көлде.

Шәмседоха әби чәй әзерли башлауга, ишегалдыннан кереп килүче таза гына апа күренде. Ул бер кыз җитәкләгән иде.

– Карамалыдан Хәнифә бу, – диде Шәмседоха әби, тәрәзәдән карап.

Ул арада алар өйгә дә килеп керделәр. Кызның күлмәге Тургайларның ишегалдындагы әнисе утырткан чәчәкләр төсле ал иде. Хәнифә исәнләшкәч, алар өчесе дә, ачыгып кайткан казлар кебек, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләшергә тотындылар. Кыз бер кулы белән әнисенең итәгенә ябышкан килеш Тургайдан күзен алмады. Тургай аңа якынрак килде. Кызның күзләре зур, зәп-зәңгәр, бераз куркыбрак карыйлар иде. Ул курыкмасын өчен, Тургай, елмаеп, кызның битен йомшак кына сыпырып алды. Аның бите йомшак, җылы , күлмәге төсле алсу иде. Аның бераз ачылыбрак торган кызыл иреннәре сөт имүдән әле генә туктаганнар, шуңа сөт исе киләдер кебек тоелды. Битенә кагылгач, кыз, башын читкә борып,

*Дәвамы. Башы 3нче санда.*

әнисенә ныграк елышты. Тургайның нишләптер шул мизгелдә аны күтәреп алып йөгерәсе килде. Ул елый башлар, әнисе артыннан куар, ә Тургай юри туктамас, үзләренә кадәр йөгереп кайткач кына, ишегалды чирәменә «тып» итеп бастырыр да: «Менә безнең ихата!» дияр, өйне, әти-әниләрен, әби-бабасын күрсәтер, песи, Акбай, бәбкәләр янына алып чыгар, агачлар, чәчәкләр белән сөйләшергә өйрәтер... Шунда әнисе кызга иелеп:

– Сөмбел кызым, әнә Тургай белән уйнагыз, – диде, кызның кулын итәгеннән ычкындырды һәм алар өчесе, өстәл янына утырып, күгәрченнәр кебек гөрләшергә тотындылар.

Сөмбел зәңгәр күзләрен түгәрәкләндереп аңа карап тора бирде. Шунда ул аның беләгенең кабарынкылыгын, беләзек турыннан җеп белән кысып куйган шикелле батып торуын күрде. Нишләптер кызның шул күперенке беләген чеметеп аласы, алсу битеннән кысып тотасы килде. Тик болай эшләргә ярамый. Аны көлдерергә кирәк, аның шикләнүе йөзенә чыккан. Ул кесәсеннән иң элек теге йолдыз кыйпылчыгын чыгарып аңа сузды. Әмма Сөмбел ташка кагылып та карамады. Тургай кесәсендәге шоколадлы ике конфетның берсен бирергә теләде, Сөмбел аны алмады, әмма ымсынган төсле карап торды. Тургай аңа якын ук килде, кыз чигенмәде. Кызның маңгае тирләгән, кара бөдрә чәчләренең бер учмасы тир белән маңгаена ябышкан. Тургай шул ябышкан чәчтән күзен ала алмады. Ул Сөмбелне кызганып куйды. Әнисе аны әнә шул матур кулларыннан җитәкләп, кызу-кызу атлагандыр, ә ул җитешәм дип терек-терек йөгергәндер, шуңа тирләп чыккандыр. Тургай нишләптер курка-курка гына аның кулын тотты. Сөмбелнең кулы үзе кайнар, үзе тирләгән иде.

– Әйдә чыгабыз, – диде Тургай, аңа якын ук килеп.

Ул Сөмбелнең озын керфекләрен аермачык күрде, тын алганын ишетте. Сөмбелнең моңа кадәр зур булып ачылган күзләре кысыла төште, иреннәрендә елмаю күренде. Ул, телен чыгарып, өске иренenең бер читен каплады. Аның тел асты әллә ничә тамырлы, бик кызык иде. Тургай да көлә-көлә аңа охшатып телен чыгарды һәм нишләптер тел очын аның битенә тидерде. Шулчак:

– Сезнең егет минем кызымны үбә түгелме соң?! – дип көлеп җибәрде Сөмбелнең әнисе.

Тургай шундук йөгереп китте дә, әбисенең тезенә аркасы белән терәлде.

– Хәзерге балалардан барысын да көтеп була, – диештеләр өстәл янындагылар.

Тургай тагын кыз янына килеп, конфетын сузды. Ләкин Сөмбел күзләрен ике кулы белән каплап өлгерде.

– Ояла ул, аңа өч яшь кенә бит әле, – диде әнисе аклангандай.

Тургай Сөмбелнең ике бармак арасыннан бер күзенең елтыр-елтыр килүен күреп торды. Ахырда ул конфетны алды. Тургай аны җитәкләде, Сөмбел карышмады, алар ишеккә атладылар.

– Син сөйләшә беләсеңме? – дип сорады Тургай, ишегалдына чыккач.

– Тук, – диде кыз.

Тургайның аны уйнатасы, көлдерәсе килде. Их, өч тәгәрмәчле велосипедын алып килгән булса! Йөреп тә күрсәтер, аны да өйрәтер иде.

– Конфетыңны аша, – диде Тургай.

Ләкин ул басып тора бирде. Тургай кесәсеннән калган конфетын алып, кәгазен сүтте дә Сөмбелнең авызына китерде. Ул аны борчак кадәр генә тешләп алды. Тургай да аның кебек итте. Шулай әле берсе, әле икенчесе вак-вак тешләп, конфетны ашап та бетерделәр. Сөмбелнең иягенә көрән булып конфет буялып калган иде.

– Битеңә конфет тигән, – дип Тургай аның ияген кулы белән сөртте.

Аннары нишләптер битен дә сыпырып аласы итте. Бу вакытта Сөмбел гел елмаеп торды. Тургай тагын аның кулын тотты. Хәзер аның кулы май кебек йомшак, әллә ничек аңа тартылып тора иде. Тургай аны җитәкләп абзар ягына

алып китте. Сирәкләп коелган койма артыннан Шәмседоха әбинең Ристан исемле ак кәҗәсе күренә иде. Тургай конфетларны Ристанны сыйларга дип алган иде. Сыйлый алмады инде. Кәҗә аның буш кул белән килмәвенә күнегеп беткән. Бүген дә, койма ярыгыннан борынын тыгып, телләрен сузып-сузып алды. Сөмбел чырык-чырык көлеп куйды һәм Тургайны шаккатырып:

– Кәзә! – диде.

– Сөйләшә беләсең икән бит, – диде Тургай.

– Тук, – диде кыз өметсез тавыш белән.

Тургай: «Әйдә синең конфетыңны аңа бирик», — димәкче булды да, тыелып калды.

– Мин синең янга яңадан килермен әле, – диде ул, Ристанның борын өстен сыпырып. Аннары: – Әнә сакалын күрәсеңме? – дип сорап куйды.

Кыз берни дә әйтмәде, кәҗәгә төбәлгән килеш тора бирде.

– «Сакал» диген әле, – диде Тургай.

– Такал, – диде кыз.

– Сезнең сыерыгыз бармы?

Сөмбел «әйе» дип баш селкеде.

– Сыер белән кәҗә икесе дә бозау булган, – дип аның игътибарын яуламакчы булды Тургай. – Берсе әйбәтләп ашаган, икенчесе киреләнгән, юньләп ашамаган. Шуннан ул менә шулай бәләкәй булып калган. Әнә бит койрыгы да бәләкәй, өскә күтәрелеп тора. Сыерның койрыгы җиргә тия язып йөри.

Сөмбел чыркылдап көлеп куйды. Ышанмый, шуңа көлә, дип уйлады Тургай. Үзе биргән конфетны бик тә ашатасы килә иде аның.

– Әгәр ашамасаң, синең дә кулларың, аякларың үсмичә бәләкәй калачак.

Сөмбел тагын көлеп куйды да:

– Минем койрык тук, – диде ике кулы белән арка яклап билен тотып.

– Койрыгың булмаса, менә бу төшеңә сакал чыга, – диде Тургай, бармагы белән аның ияк астын кытыклап.

Сөмбелнең ияк асты шундый йомшак, җылы иде.

Тургай аны җитәкләп, Шәмседоха әбинең ишегалдын күрсәтеп йөрде. Аннары чиләкләр, чүлмәк, савыт-саба каплап куелган киң эскәмия янына килделәр. Шунда Сөмбел кесәсеннән нидер алды да, бер чиләккә чыкы-чыкы суга башлады.

– Ни ул? – дип кызыксынды Тургай.

Сөмбел учын ачты. Бу тимер акчадан шактый зур бер түгәрәк нәрсә иде. Аңа чабып барган канатлы ат төшерелгән, үзе күзләрне чагылдырырлык ялык-йолык килә. Тургайның аны тотып карыйсы килде, әмма Сөмбел учын йомды. Ул аны йомып бетерә алмады, теге әйбер елтырап күренеп тора иде. Тургай ике кулы белән Сөмбелнең учын ачты да әйберне кулына алды. Сөмбел аның алуына ачуланмады, «Ярар, сиңа булсын», дигәндәй көлеп куйды.

Ул арада әбиләр дә килеп чыктылар. Сөмбел әнисе белән бер якка, Тургай белән әбисе икенче якка киттеләр. Тургай шактый вакыт кулын теге түгәрәк әйберне салган кесәсеннән чыгармыйча барды, артына да караштырып алды. Көмеш ат сурәте аның күз алдыннан китмәде, ул аның өчен бик тә кадерле әйбергә әверелде. Әнисе арттан килеп, ул әйберне алып китәр кебек тоелды. Әллә шуңа, әллә башка сәбәптән, аңа әбисе белән атлау бик акрын тоелды. Һәм ул: «Мин кайта торам», — диде дә өйләренә очты гына…

## Шәһәрдән кайткач

Кичә ашыга-кабалана шәһәргә барырга әзерләнергә тотындылар. Тургай моңа куанып туймады. Шәһәрне телевизордан күреп кенә белә ич ул. Җитмәсә бик еракка, Чиләбе якларына ук барасылар икән. Әтисе ак «жигули»ен ялт итеп юды,

аның багажнигына әллә ниләр тутырдылар. Тургайга өр-яңа күлмәк-ыштаннар, аягына сандалилар кидерделәр. Бу киемнәр аңа гәүдәсен калай белән төргән кебек итте. Теләсә дә, теләмәсә дә, карыша алмады. Шәһәргә трусиктан, яланаяк барырга ярамаганны белә ул.

Алар иртән, ашап-эчү белән үк, кузгалдылар. Әбисе белән бабасы хәерле юл теләп, Тургайны кочаклап үбеп калдылар. Ул шәһәр бик ерак булып чыкты. Урман эченнән әле болытларга таба күтәрелеп, әле түбән төшеп баручы юлның азагы беркайчан да булмас кебек тоелды. Алар чокыр эчендә диярлек урнашкан ул шәһәргә кояш сүрелә башлаганда гына барып җиттеләр. Әнисенең апасы Сабира өстәлләр әзерләп көткән иде, ул көнне шәһәр күрергә вакыт булмады. Икенче көнне Сабира апалары белән Рәсүл җизниләре шәһәр күрсәтергә алып киттеләр. Машина белән чыкмадылар, автобус, троллейбус, такси белән йөрделәр. Тургайга иң кызыгы аттракцион булды. Ул анда коточкыч зур тәгәрмәчкә әтисе белән янәшә утырып, болытларга кадәр күтәрелде, бөтен шәһәр уч төбендәге кебек күренде. Бу Галимҗан абыйсының һавага чөюеише генә түгел иде инде! Тургайны шәһәр урамнарында кешенең күплеге шаккатырды, барысының да каядыр бик ашыгуы, хәтта терәлеп үткәндә дә бер-берсенә күз салмаулары, исәнләшмәүләре мәзәк иде. Борынга әледән-әле кайнар асфальт, таш, машина исе бәрелә. Урамдагы агачларны ул кызганып карады. Алар бу шау-шуга аптырап, туктаусыз ашыгучы халыкка үпкәләп басып торалар кебек тоелды. Автобус көткәндә, Тургай бер юкәнең астагы ботагын иеп, очындагы яфракларын үпмәкче булган иде, сыбызгысын сызгыртасызгырта зур гәүдәле бер полицейский килеп тә җитте. Аның сары калын мыегы, эре ак тешләре арасыннан тавышы күкрәп чыкты:

– Почему ломаешь?!

Тургай ботакны ничек чиерттереп җибәргәнен сизми дә калды. Ул куркуыннан әтисенең артына качты. Әтисе русча ниләрдер аңлаткач, полицейский китеп барды.

– Нигә ачуланды ул? – дип сорады Тургай.

– Сине агач ботагын сындыра дип уйлаган.

– Нишләп алай уйлаган?

– Шәһәрдә хулиганнар агач ботакларын сындыралар, ди.

– Мине хулиган дип уйлаганмыни?

– Полицейский тәртип сакларга тиеш. Ул бусы әйбәт кешедер, тегесе начардыр дип уйлап тора алмый.

Алар курчак театрында булдылар. Бик кызык икән. Зоопаркта әллә нинди җәнлекләр күреп бетерде. Аларга дәшеп-дәшеп караса да, берсе дә җавап бирмәде. Кыр кәҗәләре янына килгәч, бик кызык булды. Шәмседоха әбисенең кәҗә бәрәне кебек кызганыч итеп кычкырган иде, берсе Тургай турына килеп басты. Әтиәниләре генә түгел, алар белән янәшә торучы башка кешеләр дә моны күреп шаккатты. Алар «Давай, парень, ещё раз», дип аны кыстый башладылар. Әтисе рөхсәт иткәч, Тургай тагын берничә мәртәбә кызганыч тавыш белән «мә-мә-мәә», дип сузуга, теге кыр кәҗәсе борчылып читлегендә арлы-бирле йөрергә кереште. Тургайны барысы да «молодец» дип мактады. Аның сыер, сарык, каз, әтәч, тавык булып та кычкырасы килгән иде дә, зоопаркта ул хайваннар юк иде.

Тургайны әллә ни шаккатырган нәрсә күренмәде яңадан. Кәҗә булып мәэлдәсе дә булмаган ахрысы. Кычкырып туктарга өлгермәде, кәҗә саклау урыннары, Бормалы инеше, Ык буйлары, Нух тавы күз алдына килде дә басты. Эчендә нәрсәдер ачы итеп тешләгәндәй авырттырып алды. Авыл ерак! Авыл бик тә, бик тә еракта! Әбисе белән бабасы хәзер нишли икән? Малайлар су коенадыр. Инде шәһәрнең матурлыгы кызыксындырмый иде. Кич табын янында аны кыстадылар да кыстадылар, алдына гомер күрмәгән әллә нинди тәмле ризыклар, авыз суларын китерердәй җимешләр куйдылар. Тик нишләптер аның юньләп ашыйсы килмәде.

Капкалап утыра торгач: «Иртәгә кайтабызмы инде?» – дип әле әтисенә, әле әнисенә карады. Иң элек Сабира апалары белән җизнәләре «Нинди кайту әле, шул кадәр җирдән бер җитешеп килгәч», дип аның соравын юкка чыгарды, аларга әтисе белән әнисе кушылды. Әмма Тургай «кайтыйк, җитте», диде, йөзенә канәгатьсезлек чыгарып. «Бездә ошамыймыни сиңа?» диде җизнәләре. Тургай дәшмәде. «Әле иртәгә җизниләренең энеләренә кунакка барасы бар, аларның кызлары, малайлары белән рәхәтләнеп уйнарсың», дип әллә ниләр белән кызыктырдылар. Тик Тургайга ул сүзләрнең берсе дә тәэсир итмәде. Ул телен тешләп, үзе йокларга тиешле бүлмәгә кереп караватына ауды. Рәхәт түгел иде, ай, рәхәт түгел иде. Нишләп болай икән соң бу, дип баш ватты ул. Ел буе «шәһәр», «шәһәр» дип кызыктырдылар бит югыйсә. Монда җаның ни тели, шул бар. Бернинди эш юк. Казларны инешкә куасы да, бозауны ашатасы да, яшелчәләргә, агачларга су сибәсе дә юк. Ашап, кикереп тик ят. Телевизорлары да тәрәзә чаклы. Ә менә әллә нәрсә тарта да тора. Ул тарткан саен, эч яна, эч янган саен, кайтасы килә, кайтасы килгән саен, шәһәрнең матурлыгы каядыр китеп юкка чыга... Бөтен нәрсә тавышсыз җыр төсле.

Җизниләренең энеләренә кунакка баргач та, андагы бер көтү бала белән әллә ни кызык тапмады Тургай. Күбесе татарча әз-мәз генә пупалый икән. Ул татарча сораса, русча җавап бирделәр. Алар русча дәшсә, Тургай татарча дәште. Ул әллә нинди тар урынга кысылгандай бәргәләнде. Сүз әйтергә оялып, кыенсынып кына уйнар-уйнамас вакыт үткәрде шунда.

«Кайтыйк, кайтыйк», дип туйдырып бетерсә дә, әти-әнисе ашыкмады. Аны һаман шәһәрнең әллә нинди урыннары белән кызыктырырга тырыштылар. Суыткычны мороженый белән тутырдылар, өстәлләр җиләк-җимештән, әллә ничә төрле сулардан сыгылып торды. Быҗырдап кайнап торган әчкелтем-төчкелтем ул суларны эчкәндә, вак күбекләренең тамчылары битләренә кадәр килеп җитеп, борын эчләрен кытыклап рәхәтләндерсә дә, ул үзләренең тау чишмәсенең суын сагынды. Алдына китереп куйган йогыртны капкач, үзләренең ачкылт катыгы искә төште. Йокларга яткач, чикерткә сайравын тыңлыйсы килеп бик озак көтте, ләкин бернинди чикерткә тавышы ишетелмәде. Бүлмәгә урамдагы машиналар гөжелдесе генә тулды.

Дүртенче көнне кайтырга кузгалгач, Тургайның эченә җылы йөгерде. Әле кайтасы да кайтасы, юлның очы да, кырые да юк, ләкин кайту шатлыгы бөтенесенә дә түздерде. Район үзәгенә җиткәч, бөтен гәүдәсенә шатлык уты йөгерде. Авыл белән ике арадагы юлның һәр метры аның йөрәге аша үтте. Ниһаять, машина тау башына килеп җитте, авыл күренде.

– Әтием, тукта! – диде Тургай, сулышы кабып.

– Нәрсә булды?

– Туктат, йөгереп кайтам!

Ул сандалиларын, оекбашларын әллә кайчан салып куйган иде инде. Әтисе белән әнисе мәгънәле елмаешып бер-берсенә караштылар да аны төшереп калдырдылар. Юлның кайнар туфрагына китереп басуга, гәүдәсе дерт итеп китте, табан астыннан күтәрелгән ниндидер җылы бөтен гәүдәсен чолгап алды. Барлык үлән, барлык чәчәк аңа төбәлгән. Нинди тәмле исләр! Чабыр үләненең исе бөтенесен кысрыклап борынга тула. Һәрберсе аңа сәлам бирә, һәрберсе җырлый! Тургай сикергәләп-сикергәләп торды да, өч мәртәбә тауга түбән мәтәлчек атты. Аннары йөгерә-атлый авылга томырылды. Карале, гел бәйләнеп интектергән җил дә аны сагынган инде әллә? Шулай булмаса, битләреннән, муеннарыннан йомшак итеп сыйпамас иде.

– Сагындыңмы, апай?! – диде ул көлә-көлә. – Сагынгансың шул, кычкырып әйтәсең генә килми. Эре бит син!

Ул ике кулын тегермән канаты кебек кызу-кызу әйләндереп җилгә каршы

торды. Өстендәге төркем-төркем болытлары белән бергә авыл да аңа таба йөгерә икән бит. Җил йомшак канатлары белән ромашка, кыргый бөтнек, җиләк, алсу тукранбаш, кыңгырау чәчәк, тәбәнәк әрем исләрен тургайга бөркеде... Зәңгәр чәчәкле һиндыбалар, ак мәтрүшкәләр, сары чәчәкле кандала үләннәре үрелеп каты сабаклары белән аны туктатмакчы булдылар. Әмма ул аларга «иртәгә, иртәгә, бүген вакыт юк!» дигәндәй көлә-көлә йөгерүен дәвам итте.

Тургай, кулларын югары күтәреп авыл ягына сәлам бирде, аннары тезләнеп ромашка, меңъяфрак, кәрешкә, кыңгырау чәчәкләренә иреннәрен тидерде, кочагына җыярга теләгәндәй, куллары белән үзенә таба сыпырды. Әз генә уңдарак бүректәй күпереп утырган чабыр үләненең исенә түзә алмыйча, аның күкшел-алсу чәчәкләренә битен терәде. Шулчак күз читен авырттырып корт чагып алды.

– Әллә-лә-лә! – дип сикереп торды ул һәм төкереге белән шул урынны ышкыды. – Күргән идем бит мин син усалның шунда утырганын. Әз генә кагылырга да ярамый үзеңә.

Шактый түбәнәйгән кояш аны үртәп күз кысты. Каяндыр килеп чыккан бер саескан, өч карганы ияртеп, Тургайны корт чакканын сөйләргә авылга очты. Каршысында басып торган йомран бер генә мәртәбә сызгырды да оясына чумды.

## Ник сукты?

Тургай иртән уянуга шаккатты: уң як бите күпереп шешкән, уң күзе бөтенләй ябылып беткән! Кулы белән сыпырып-сыпырып караган иде — шоп-шома, кайнарланып тора. Ул сикереп торып көзге каршына килде һәм, үзенең танымаслык булып үзгәргән йөзен күргәч, тыела алмыйча кычкырып көлеп җибәрде. Әти-әниләре, әбисе белән бабасы кече якта чәй эчеп утыра иде, алар да, аның йөзен күргәч, елмаешып-көлешеп алдылар.

– Ай-яй, нык симереп кайткансың шәһәрдән, улым, – диде әтисе, эчә торган чәен өрә-өрә.

Тургай ашык-пошык юынып, ике кабып бер йоткач, чыгып йөгерде. Әле малайлар торырга иртә. Кеше күбрәк җиргә барырга кирәк. Бу вакытта алачык тирәсендә механизаторлар җыела, шеш беткәнче авылны әйләнеп чыгарга кирәк.

Алачык тирәсендә кеше күп иде. Тургайны күргәч, елмаешып аның тирәсенә җыелдылар. Автобус шофёры Әнәс Тургайның каршына ук килеп чүгәләде.

– Кем белән сугыштың, үскәнем? – диде ул, аны үртәп.

– Мин бит син түгел сугышырга...

Алачык буе бердәм көлү тавышыннан дерелдәп куйды. Ник дисәң, Әнәснең салып кешегә бәйләнә, сугыша торган гадәте бар иде.

Тургай исән күзен акайтып, кашларын сикертеп, авызын кыеш-мыеш китерә-китерә, телен чыгарып дерелдәткәч, барысы да рәхәтләнеп көлделәр. Ул сикерә-сикерә инешкә йөгерде, тар басмадан чыккач туктап калды.

Ничек кызыграк итәргә соң моны? Кесәсеннән бәләкәй көзге чыгарып йөзен әле тегеләй, әле болай кыландырып карагач, ләм белән калынайтып, кашларын уртадан тоташтырып та куйды, борын очын да каралтты. Болай кызыграк икән бит! Тыкрыктан күтәрелеп, урам буйлап йөгерде. Кибеткә кергән иде, сатучы Тәскирә апасы да, әйбер алырга килгән кешеләр дә көлештеләр.

Кибеттән чыккач, культура йортына йөгерде, җирле Совет бүлмәсендәгеләрне көлдереп чыгып китте. Аннары ул әллә ничә урамны буйлады, кемне күрсә, шуңа барып, йә бал корты белән үбешкәнен, йә сугышканын сөйләде. Ниһаять, Шәмседоха әбисенә килеп җитте. Кендек әбисе дә башта куркуга төшкән иде, аннары рәхәтләнеп көлде. Тургай монда кәҗәне ашатырга дип килгән иде. Башына Шәмседоха әбисенең иске яулыгын бәйләп, бер як пыяласы төшкән хан

заманындагы күзлеген кигәч, кәҗә янына чыкты. Ристан башта гаҗәпсенеп карап торса да, Тургайны таныды, йөгереп килеп борынын кесәсенә төртте, кулын ялады. Кәҗәне аптырата алмавына бераз кәефе кырылса да, Тургай аңа дип кесә тутырып алып килгән печеньеларын ашатты. Шәмседоха әбисе биргән бер йомры сөтне эчкәч, ул рәхмәт әйтеп капкага таба юнәлде.

– Улым, маңгаеңдагы ул сызылган кашларыңны сөртик әле, – диде Шәмседоха әбисе, кулына юеш чүпрәк алып.

– Әйем, кирәкми, алайса кызык булмый! – дип Тургай капкадан чыгып йөгерде.

Тизрәк малайларның күңелен күтәрергә, аннары бергәләп Галимҗан абыйсы янына көтүлеккә төшәргә уйлады. Кем очраса да, көлә, аның иңбашыннан коча. Юк, мең шәһәргә дә алыштырасы юк Тургайның үз авылын! Шәһәрдә болай итеп йөри алмыйсың, сине полицейский тотып алып китәргә мөмкин. Ә авылда менә бу койма буендагы кычытканнар да сиңа тыныч кына карап тора, чагарга үрелми. Ул кычытканнар алдында сикергәләп, бөтерелеп алды, тик алар көләмени? Үзе генә гөлдерәп көлеп куйды. Җыелсын иде хәзер бөтен авыл! Менә рәхәтләндерер иде ул аларны! Биер дә, җырлар да, сөйләр дә, мәтәлчеген дә атар иде. Тукта, әнә капкасыннан Госман абзый чыкты. Тургай аның янына йөгереп килде.

– Исәнме, Госман абзый! – диде ул елмаеп.

Ләкин Госман хәрәкәтсез карап тора бирде. Аның колакка каты икәнен белә Тургай. Госман абзыйның бер күзе дә сукыр. Тургай аңа иреннәрен әллә ниләр кыландырып, телләрен чыгарып, бал корты белән үбешүен сөйләде. Тик Госман абзый нишләптер көлмәде, аңа сыңар күзе белән зәһәр карап торды да:

– Син генә җитмәгән идең! – дип яңагына чабып җибәрде.

Тургай телсез-өнсез калды. Башын иде дә Бормалы буена йөгерде. Оя-оя булып тезелешеп утырган каз-үрдәкләрне куркытып үткәч, кәүсәсе урталай ярылып төшкән тирәкнең төбенә барып капланды. Бары шул чакта гына аның кайнар күз яшьләре бәреп чыкты. Ул әллә ничек көйли-көйли бик озак елады, күз яшьләре чишмә кебек акты, башы берни уйлый алмады...

Күпмедер вакыттан, инде елап тәмам арыгач, башына бер сорау килде: «Ник сукты?» Суккан яңагы авыртмады да бугай, ул аның авыртуын сизмәде. Үксүенә буылып, шул хәтәр сорауга җавап эзләде. «Госман абзый ник сукты?» Аның маңгаен-йөзен, терсәкләрен мең мәртәбә ташка, агачка бәргәне, пыялага басып табанын ярганы бар. Беркайчан елап та карамады. Шыңшып алса да, шундук онытты. Ә бу? Ни соң бу? Аның өстенә тын да алдырмаслык авыр тау ятты. Бу тауны ничек булса да алып атарга кирәк, ләкин Тургайның җеп өзәрлек хәле дә юк иде. Күз яшьләре белән бергә аның барлык көче чыгып беткән иде... Баштарак, ярсып елаганда, ул Госманны зәхмәт сугуын, өе-ние белән давыл очырып алып китүен теләде, аның акыра-бакыра очып киткәнен, өенең түбәләре, бүрәнәләре таралып һавада бөтерелүен күз алдына китерде. Тик бу Тургайга бернинди тынычлану бирмәде, киресенчә, үзендә шундый явыз уйның тууы елавын көчәйтте генә. Ахырда бу тауның ни икәненә төшенә башлаган кебек булды ул. Моңа кадәр Тургайны бөтен авыл елмаеп-көлеп, иркәләп-сөеп кенә йөртте, һәрберсе мактады. Аның өчен бөтен авыл әтисе белән әнисе, әбисе белән бабасы кебек иде. Ул һәр өйнең яраткан баласы иде. Аңа ни кыланса да килешә иде һәм ул ни тели шуны кылана иде. Өйдә дә, урамда да, кибеттә дә, башка җирдә дә. Тик аны яратмый торган Госман абзый да бар икән бит! Тургай өчен иң коточкыч әйбер шушы иде. Ул барлык кешеләр гел сөенешеп-көлешеп кенә яшиләр, алар арасында бер-берсенә яхшылык кылудан башка нәрсә була алмый, дип саный иде.

Ул нишләптер тагын көзгесен чыгарасы итте, әмма елаудан шешенеп беткән йөзен күрәсе килмәде. Шулай да бер генә мәртәбә күз төшереп алырга булды. Карады да кабалана-кабалана көзгесен кулы белән каплады. Көзгедәге кыяфәтендә

ниндидер коточкыч нәрсә бар иде бугай. Ул аның ни икәнен аңлап бетерә алмады, кабат карарга курыкты. Күпме генә тыелса да, түзә алмады, тагын көзгесен йөзенә күтәрде һәм тәне эсселе-суыклы булып китте: аның ләм сылап ясаган кашлары нәкъ Госман абзыйныкы төсле иде! Хәтта борын турында ике кашының кушылуына кадәр шуныкы иде! Ниндидер аңлаешсыз көч Тургайны кинәт торырга мәҗбүр итте. Ул дүрт-биш сикерүдә инеш ярына барып җитте һәм, тездән суга кереп, битен ашыга-ашыга юды. Кабат тирәк төбенә утырганда, ул тагын әллә нишләде. Тургайның бөтен барлыгын аптырау биләгән иде. «Ничек булды соң инде бу?» дигән сорау аны туктаусыз ээрлекли башлады, әлеге ээрлекләүдән ул туктаусыз качарга теләде. Госман абзый дөрес суккан булса? Ул, кесәсеннән йолдыз кыйпылчыгын алып, көзгесе өстенә куйды һәм икесен дә шактый вакыт кайнар учларына кысып торды. Нух тавы ягыннан талгын җил исеп куйды, каз мамыгыдай йомшак кагылып, битләрен сыйпап үтте... Тирәк, тал, җирек яфраклары лепердәшеп нидер серләшә башлады. Зәп-зәңгәр күк үзе дә, кояш та аның баш очында юатырга теләгәндәй карап тора, эремчек болытлар төркеме дә нәкъ аның турында туктап калган. Уң яктагы талда инде күптән тыныч кына сайраган сандугач Тургай утырган тирәккә күчте дә чут-чут килеп өзгәләнергә тотынды. Сандугач үзенең иптәшләрен югалткандыр кебек тоелды Тургайга. Әзрәк үткәч, сандугач аны юатырга килгәндер, дигән өмет тә уянып куйды. Тургай тирәкнең аска бөгелеп төшкән яшь ботакларын, яфракларын кочагына җыеп, аларга йөзен терәде. Сусыл яфраклар битләрен, колакларын кытыклады, таныш исе борыннарына тулды. Шушы яфраклар арасыннан яшеллеккә күмелгән бөтен җирне, ак болытлар йөзгән күкне, кояшны күрде. Барысы да урынында, бүген дә, иртәгә дә шулай булачак, сөенечләр белән мөлдерәмә тулы һәр көнне малайлар мичтән яңа пешеп чыккан хуш исле ипи кебек кабул итәчәкләр. Кояш баеганда, бүгенге көн белән рәхмәтләр әйтеп хушлашачаклар, иртүк яңасын каршылаячаклар. Дөнья дигән бу могҗизаның бер татлы тамчысы, аны татып карау зур куаныч. Бер генә җан иясенең дә моннан туйганы юк, беркемнең дә моны бозарга хакы юк. Тургайның бүген Госман абзый янына барып чыгуы да бозарга тиеш түгел аны. Әйе, кайсыдыр төшендә ялгыш киткән. Ул Госман абзыйларга йөгерде, ләкин аның өенә якынайган саен аяклары авырайды һәм барып җиткәнче үк туктап калды. Юк, аның күзенә карый алмый иде ул. Аның аңа әйтер сүзе әзер түгел иде. Аңа үзе өчен дә, Госман абзый өчен дә оят иде кебек. Һич тә болай була алмый, әмма бу шулай һәм моның ник шулай икәнлеген ул аңламады, сизенде генә...

## Биштирәк

Гөлбакча авылының иң серле урыны – Нух тавы. Аңа халык ярым табынып, ярым шомланып карый. Чөнки анда менү тыелган, бик тәвәккәлләр генә менмәкче була, ниндидер серле сәбәпләр, көтелмәгән хәлләр аркасында менә алмый калучылар да күп...

Тагын шундый серле урыннарның берсе – Биштирәк үзәне. Борын заманнарда Ык уртасында озынча утрау булган ул, яр белән тоташмаган булган. Утрау әйләнәсендә очлары болытларга тиеп торган биш тирәк һәм колач җитмәс имәннәр үскән. Болгар дәүләте яшәгән дәверләрдә биредә хан сарае һәм асылмалы бакча булган, ул бакча әлеге биш тирәккә асылган булган, дип сөйлиләр. Яшь хан үзенең кәләше белән шул бакчада ял итә торган булган, өйләнешүче яшьләр шул бакчада мәңге бер-берсенә тугры булырга ант иткәннәр. Хан сараен Нух тавыннан алып кайтылган затлы ташлар белән төзегәннәр. Ул ташлар мең төсле нурлар сибеп уйнап торган, аларга кагылу түгел, якын гына килгән кешеләргә дә биниһая көч иңгән. Бакча уртасында көмеш фонтан атып торган. Хансарайны ак яллы бүре саклаган, диләр. Ул бүренең йөзе кешенеке төсле булган, имеш тә кеше кебек көлә дә, елый да, сөйләшә дә белгән. Хан белән берлектә гаделлек урнаштырып торган.

Берәр җан иясе икенчесен рәнҗетсә, Нух тавыннан рәнҗетүчегә җәза сораган. Җәза бик каты булган, кешеләрнең кечкенә гаделсезлеге дә гафу ителмәгән. Ак бүре йолдызлы төндә Нух тавына таба авызын күтәреп улап, җәза сораган. Рәнҗетүчене көчле давыл чыгып күтәреп алып киткән, яисә яшен суккан.

Ул заманнарда кешеләр Нух тавындагы изге чишмәгә салу өчен алтын-көмеш акчаларын шунда йөрүче аерым кешеләр аркылы биреп җибәрә торган булганнар. Шушы вазыйфаны башкаручы бер егет кешеләрдән җыелган акчаларга кызыккан да, бер өлешен яшереп, бакчасына күмгән. Калганын Нух тавына алып килгән һәм чишмәгә салырга ниятләп торганда, үзе таш баганага әверелгән. Чишмә янында хәзер дә торучы таш багананы шул егет, диләр. Кемгәдер зарар салу, урлашу, алдау, кемнедер рәнҗетү рәхимсез җәзага тартылганлыктан, кешеләр гадел яшәгәннәр, бик тә бәхетле булганнар. Әмма кемнәргәдер бу ошамаган, алар хансарайның нурлар чәчеп торучы ташларына кызыккан. Аңа керү юлын көне-төне саклаган ак бүрене үтерү өчен дошманнар иң усал сихерчене эзләп тапканнар. Бер пот алтын хакына ул сихерләнгән җиде көзге һәм тартмага ябылган җитмеш кара елан биргән, ак бүрене ничек юк итәргә икәнен өйрәткән. Күкне кара болытлар каплаган йолдызсыз төнне сайлаганнар. Хансарай капкасына теге җиде көзгене җиде яктан юнәлткәннәр. Ул көзгеләр яшен утыннан да яктырак нур чәчкән, ди. Ак бүре аларның берсен дә күздән ычкындырмаска тырышып күзәткән, әле берсенә, әле икенчесенә ыргылган. Тик бераздан бүренең ике күзе дә сихерле нурлар тәэсирендә агып чыккан. Бүренең күзләре сукыраю белән, тартманы ачып җитмеш еланны аның тарафына селкегәннәр. Ак бүре сизенеп өлгергәнче, аны дистәләгән елан берьюлы чагып алган. Ул шундук җан биргән. Дошманнар капкадан ташкын кебек эчкә бәреп кергән. Аларның саны хан гаскәреннән ун мәртәбә күбрәк булган. Җиде көн, җиде төн дәвам иткән сугыш болгарларның соңгы кешесе аугач кына туктаган. Дошманнар хансарайны җимереп, аның ташларын алып китәргә олауларга төйи башлауга, Нухның маңгае ачудан җыерылган, күзләреннән яшен уты чәчелгән. Шундук утлы өермә күтәрелеп, хансарайны басып алган дошманнарның берсен дә калдырмыйча яндырып көлгә әйләндергән. Бу урын бик күп еллар буе күмер кебек кап-кара булып яткан, диләр. Агачлар да яфрак ярмыйча күмерләнгән хәлдә утыра биргән. Нух беркайчан да әшәкелекне гафу итмәгән. Күп гасырлар узгач кына, Нух ничектер күңеле бераз йомшап, бирегә шифалы яңгырын җибәргән һәм шул яңгыр яуганда ук яшел үләннәр дәррәү борын төртеп чыкканнар, агачларны яфраклар каплаган. Бу тирәләрдә бөтенләй күрелмәгән чәчәкләр – кара тюльпаннар үсә. Алар ак бүренең күзе агып тамган урыннарда шытып чыккан, диләр. Тюльпаннарны бакчага да, болынга да күчереп утыртып караганнар, әмма беркайда да үстерә алмаганнар, алар ап-ак төскә кереп корыганнар…

Гөлбакча кешеләре бу хикмәтләрне гел күңелләрендә саклый, Нух тавына, аның маңгаена бераз куркыбрак та, янәшәсендә үзен саклаучы көч итеп, горурланып та карый. Әмма халык гел шушында тартыла, үзенең иң матур бәйрәмнәре вакытында Биштирәккә юнәлә. Өлкәннәр шушында булганнан соң, тәннәренең сызлавы басылуы, ниндидер көч иңүе турында үзара бик җитди итеп сөйләшәләр.

Хансарай ташлары тылсымлы көч таратканын белгәнгә күрә, Нух тавы кешеләрне бик кызыктырган. Тауның эче шундый ташлардан тормый нәрсәдән торсын инде. Тәвәккәл, батыр йөрәкле кешеләр төрле дәверләрдә Нухка таш сорап барганнар, имеш. Ә шулай да Гөлбакча кешеләре арасында Нух янына менүчеләр булган, диләр. Имеш тә ул кешенең ниятен өеннән чыккан чакта ук белеп тора, шуңа карап аңа йә ярдәм кулы суза, йә юлына киртә кора. Тик бу хакта авылда моның ничек булганлыгын беркемнең дә кистереп сөйләгәне юк. Барысы да серле томанга төрелгән, ә томан һаман таралмый да таралмый…

## Нухның кире кагуы

Төшке ашны ашагач, Тургай беркем белән дә сөйләшеп тормыйча ишегалдына чыкты. Аның яшерен уе бар, аны беркемгә дә әйтергә ярамый иде. Берүзе кузгалырга әзрәк шикләндерә шикләндерүен. Акбайны ияртсәң, әйбәт булыр иде дә. Ул чакта өйдәгеләр сизәчәк, аны анда җибәрмәячәкләр. «Юк, Акбай, син калып тор инде», дип ул аның маңгаеннан сыпырды да абзарга керде, бозауның ияк астын кашыгач, тавык кетәгенә менеп китте. Бүген аңа көч күп кирәк булачак. Әнә, көрәшчеләр, юкка гына йомырка эчмиләр. Күкәй салып, оядан кытаклап чыгып килүче чуар тавык аңа каршы булды. Анда дүрт күкәй ята иде. Тургай җырлый-җырлый ояга үрелде:

Җәйгә чыксам, арбам бар,
Кышка керсәм, чанам бар.
Берне алам, икене алам,
Өчне алырга чамам бар.

Аның ике йомырканы эчеп җибәргәнен чуар тавык, кытаклавыннан туктап, башын кыйгайтып карап торды. Йомыркаларның буш кабыгын тавыкның алдына ыргытты да төшеп сызды. Артык тоткарланырга ярамый, тизрәк барырга кирәк иде. Инде әллә ничә көннәр шушы уй аның эчендә ут кебек йөрде. Йоклаганда Нух тавы кат-кат төшләренә керде, берсендә Тургайны үзенә чакырды хәтта. Болай булгач, ул аны мөгаен борып җибәрмәячәк. Нух аны кабул итсә, кайчан да булса халык җыелып, таудан таш чыгарып, Гөлбакчага бөтен кешеләр сыеп бетәрлек хансарай салырлар иде! Асылмалы бакча да ясарлар иде. Һәркемгә сихәтлек, көч иңәр иде! Барлык халык рәхмәт укыр иде!

Тургай авыл башыннан чыкканда, бүрек кадәр бер кара болыттан гайре нәрсә күренмәде. Гәүдәсе җиңел, иңнәренә канат үскәндәй тоелды. Ул тауга таба бөтен көченә йөгерергә тотынды.

Ул башын күтәреп Нухка карый, аның кояшта елтыраган маңгаеннан миһербанлык билгеләре эзли, әмма берни дә аера алмый. Күңелендә шик уяна башлый. Тик ул аны бик тиз юкка чыгара. Ни булса да бүген менәчәк инде ул анда. Әле бит тауның яртысына да җитмәде.

Тау текәләнгәч, йөгерә алмады. Аннары аркасын кояш бик нык көйдерә башлады, көн бөркүләнде. Кай арада теге бүрек кадәр болыт ярты күк йөзен каплап алган, аннан тавышсыз гына яшен телләренең җиргә сузылып-сузылып алганы күренгәләде. Тургайның күңеленә шом йөгерде. Дөньяны күтәреп сайраган чикерткәләр дә, кош тавышлары да тынып калды. Хәтта җил дә каядыр кереп качкан! Бу бик сәер тынлык иде. Тургайның адымнары акрынайды, ул авылга таба борылып карады. Авыл да бик еракта калган. Ул үзен япа-ялгыз итеп тойды һәм Нухка карады. Аның маңгае шом уятты. Шулчак кара болыт кояшны каплады, тирә-юньдәге бөтен нәрсәгә куе күләгә ятты...

Тургай йөрәгенең дөп-дөп тибүен ишетте. Аяклары атларга теләмәде, нәрсәдер шикләндерә иде. Их, Акбайны алган булсам, дип үкенеп уйлап куйды ул. Әллә Нух ачуланганмы? Тургай, соңгы көчен җыеп, югарыга атлады, ләкин әллә ни ерак китә алмады. Күзләрне чагылдырып яшен яшьнәде һәм күк йөзен урталай ярган шикелле көчле чытырдау ишетелде, тавышы болытлар өстеннән төрле якка дөбер-дөбер таралды. Юлның уң ягындагы агачлыкның яшен яшьнәгәндә яп-якты булып күренгән аскы өлешләре кап-кара булып калды. Аннан әллә нинди куркыныч нәрсәләр килеп чыгар төсле тоелды. Тургай югарыга омтылды, әмма аяклары аңа буйсынырга теләмәде. Җил дә көчәеп китте. Агачлар төрле якка чайкала, биек үләннәрнең сабаклары җиргә ята. Бөтен нәрсә урыныннан купмас

өчен җил белән тартыша. Каршы яктан кара тузан булып һавага күтәрелгән өермә, «ә» дигәнче килеп җитеп, Тургайның башындагы чүпрәк кепкасын очырып алып китте. Олыларның Нух тавына менмәгез, өермә алып китәр, зәхмәт сугар дигән кисәтүләре исенә төшеп, куркуын тагын да көчәйтте. Шулай да ул әле һаман югарыга үрмәләде. Тагын берничә мәртәбә нәкъ баш очында яшен уйнап, күк күкрәгәч, шаулап яңгыр яварга тотынды. Яңгыр тамчылары шундый эре, салкын иде. Тургай юл читендәге куе ботаклы юкә төбенә кереп чүгәләде. Яңгырның болай чиләкләп койганын, җилнең бу кадәр котырганын, агач яфракларының җил белән тартышып бу кадәр шыбырдашканын аның күргәне юк иде.

Юлдан кызыл балчыклы гөрләвек шаулап ага, төрле чүп-чарны, агач яфракларын ияртеп, гопыр-гопыр түбәнгә алып китә. Яшен аны сугу өчен шулай кыланадыр кебек тоелды. Күк чытырдап шартлаган саен күзләрен йомды, тын алудан туктап, яшеннең китереп сугуын калтыранып көтте. Тургай, кулы белән юкә ботагын аскарак каерып, тау түбәсенә карады. Ялт-йолт уйнаган яшен Нух маңгаен куркыныч итеп кинәт-кинәт яктыртып ала, яктыртканда маңгай калтыранып куя… Тора-бара яңгыр бераз кимеде, ә җил тынычланырга уйлап та карамады. Ул менәсе юлга ниндидер агачның зур гына ботагы сынып төште. Тургай чүгәләгән җирдән ерак та түгел коры яфраклар астыннан кара елан килеп чыкты. Ул коты очып сикереп торды. Бер корыган ботакны сындырып кулына тотканда, елан кабат яфраклар астына кереп юк булды. Тургайның башка түзәрлеге калмады, ул күкрәген яндырып, күз яшьләренең күтәрелүен сизде һәм, гөрләвекне ерып чыгып, үлән өстеннән түбәнгә – авылга таба йөгерергә тотынды. Тик үлән биек һәм юеш булганлыктан, лайлы тайгак юлга чыгарга мәҗбүр булды. Сындырып алган таягын кысыбрак тотты, чөнки агач арасыннан әллә нинди куркыныч җан ияләре аңа ташланыр кебек тоелды. Тургай яшенне дә, күк күкрәүне дә, яңгыр яуганны да сизмәскә тырышып йөгерде дә йөгерде. Кинәт аягы ләмнән таеп китеп, алга сөрлекте һәм тезе белән тәгәрмәч эзенә баткан очлы ташка, куллары белән юл читендәге шайтан таягына килеп төште. Тезенең, кулларының авыртуына түзә алмыйча, кычкырып елап җибәрде. Тургай көч-хәл белән торды, инде йөгермәде, акрын гына атлавын дәвам итте һәм туктаусыз елады, күз яшьләрен яңгыр тамчылары битеннән юды, алар тозлы булып авызына керде. Ул үзен кызганып елады.

Яңгыр басыла төште, авыл һаман якынайды, ул якынайган саен, үзен кызганып елавы тиргәү-ачулануга әйләнә барды. Тургай үзенә-үзе үртәлде. Иптәш малайлары алдында гына әллә кем икән ич ул. Үзе генә калса, кулыннан берни дә килми икән. Авылга якынлашканда, бу юеш, пычранган киемнәр белән ничек өйгә кайтып керәчәген күз алдына китерде һәм ни өчен бүген шушы хәлгә төшүен аңлады. Нух тавы юкка гына ачуланмаган аңа. Ул бит тауга барасын өйдәгеләргә әйтмичә, яшерен генә китте. Менә шуның өчен җәза бу. Әле кайткач әтисеннән дә эләгәчәк. Алар инде аны дөнья бетереп, әллә кайлардан эзлиләрдер. Теге чакта арышлар эчендә адашкач, бөтен авыл эзләргә чыккан иде бит. Бу хакта уйлаган саен, аның башы катты, җилкәләренә авыр йөк салгандай, гәүдәсе авырайды.

Яңгыр инде туктады, яшен дә дөберди-дөберди Болынкыр ягына китте. Тургай Ыкка төшеп, аяк-кулларын, битләрен юды, күлмәген чистартты. Башта өйдәгеләргә кая барганын әйтмәскә дә уйлаган иде дә, аннары ул уеннан кайтты, тагын бер мәртәбә алдакчы булып калырга теләмәде. Дөресен сөйләп бирергә һәм гафу үтенергә кирәк. Әтисе нишләтсә дә риза иде ул. Кешеләрне гел сөендереп йөргән була. Ә менә бүген үзенең иң якын кешеләренә күпме борчу китергәндер. Әтисе бер якка, әнисе икенче якка чыгып китеп эзләгәннәрдер. Әбисе, яңгыр яуганда түзә алмыйча капка төбенә басып, Тургайны көткәндер. Тургай өчен хафаланудан бабасының йөрәге авыртып, туктаусыз дару эчкәндер. Ишекне ачуга ук борынына йөрәк даруы исе ярып керде.

– И, улкаем, кайларда югалдың?! – дип әнисе елый-елый кочаклап алуга, Тургай күпме генә түзәргә тырышса да, булдыра алмады, тавышсыз гына елап җибәрде.

– Аллага шөкер, исән икәнсең! – дип бабасы белән әбисе аны аркасыннан сөйде.

Әтисенең йөзе кырыс иде.

– Кайда йөрдең? – диде ул усал итеп.

– Нух тавына... менгәнием... – диде Тургай еламаска тырышып.

– Ник безгә әйтмәдең?

Тургай бусына җавап бирә алмады, әнисе аны тизрәк шифоньер янына алып китте, өстенә коры киемнәрен кидерде. Әтисе бик озак ни әйтергә белмичә баш чайкап торды. Тургай бөтен гаепнең үзендә икәнен белә, әлбәттә.

– Яңадан болай эшләмим... – диде ул башын аска игән килеш – Гафу итегез...

Берсе дә «ярар, гафу итәбез», димәде. Ул бераз басып торгач, аларның борчулы йөзләрен күрмәс өчен акрын гына үзенең диванына барып ятты. Шаян сикереп менеп, аның куенына керде. Ул шундый йомшак, җылы иде. Тургай үз-үзенә ант итте: яңадан өйдәгеләргә әйтмичә беркайчан да мондый хәвефле җирләргә бармаячак ул. Шушы антын бирүгә, тирән йокыга талды...

## Аяз абый

Иртәгә сабантуй дигән көнне кич кояш баеп, күктә беренче йолдызлар Тургайга шаярып күз кыскач, ишектән култык таякларына таянган бер абзый килеп керде. Яшел түбәтәй, вак шакмаклы зәңгәрсу күлмәк, кара чалбар кигән кечкенә гәүдәле бу кешене күрүгә, Тургай куркып киткәндәй булса да, аның елмаеп-көлеп сәлам бирүен күргәч, куркуы шундук юкка чыкты.

– О-о, Аяз, рәхим ит, Казакъстан кунагы! – дип өйдәгеләр бөтенесе берьюлы аны урап алдылар, күтәрә язып түргә утырттылар.

Аяз абыйның киң маңгаеннан, коңгырт күзләреннән әллә нинди җылылык бөркелә иде. Култык таягы белән бергә аның кулында бер букча да булган икән. Ул Тургайны үзе янына чакырды да, букчасыннан рәсем ясау өчен альбом, бик күп карандашлы фломастер бирде. Букчага әбисе белән бабасына да, әтисе белән әнисенә дә төрле-төрле бүләкләр салынган булып чыкты. Аларны өләшкәч, Аяз абый альбомның беренче битенә әллә кай арада гына Нух тавын, шул тау алдында атка атланган, башына шлем кигән, кулына сөңге тоткан җайдак рәсеме ясады. Рәсемне кулдан-кулга йөртеп карадылар, бу малай сиңа охшаган бит, дип Тургайга күрсәттеләр. Аязның яшь чактагы кебек рәсем ясау осталыгына сокландылар. Өлкәннәр табын янында туйганчы гөрләштеләр, яшь чакларын искә төшерделәр, туктаусыз көлештеләр. Тургай аларның сүзләреннән Аяз абыйның гомере буе шахтада эшләгәнлеген, шунда ташкүмер басып, үлемнән көч-хәл белән котылганлыгын, җәй саен гаиләсе белән авылга кунакка кайтуын белде. Кунак китәргә кузгала башлаганда гына, Галимҗан абый килеп керде. Ул кулындагы ике букчаның берсен Тургайның әнисенә сузды:

– Бер атна сагаладым, тәки бүген эләктердем бит, – диде ул мактангандай итеп. – Җәен ите. Тургайга ашатсаң, бер көндә бер сантиметр үсәчәк.

Инде аның янына килеп баскан Тургайның яратып башыннан сыпырды, иңбашыннан кагып куйды. Аяз абый белән иртүк күрешкән булган, аның монда кереп киткәнен күреп калган икән.

– Сиңа җәеннең башын алып кердем, – диде Галимҗан абый аңа мөрәҗәгать итеп. – Сиңа ризык булырга дип капкандыр ул минем кармакка.

Галимҗан абый букчаны идәнгә куйды да җәен башын ике мыегыннан күтәреп алып, барысына да күрсәтте. Бу кадәр зур балыкны Тургайның беренче күрүе иде һәм ул аның коточкыч олы авызына, борын тишекләренә, күзләренә хәйран калып карады. Аннары әтисе белән бабасы ике кунакны берьюлы озатырга чыгып киттеләр.

Тургай Аяз абыйсының альбомы белән фломастерын янәшәсенә куеп йокларга ятты. Тизрәк йоклап, сабантуй иртәсен тизрәк каршылау уе белән күзләрен йомды, йоклагандагы кебек озын-озын итеп сулады, әмма йокы нишләптер читтә йөрде. Тургайның тынычланып җитмәгәнлеген сизә иде бугай ул. Әнә өч мәртәбә телефон шалтырады, Мәскәүдәге туганнары, теге шәһәрдәге Сабира апалары, Украинадан Фәндүс абзыйлары бәйрәм белән котладылар, әниләренең аларга кат-кат рәхмәт әйткәне ишетелде. Капка төбендә Аяз абыйсы белән әтисе бер-берсеннән һаман аерыла алмыйлар, сөйләшеп сүзләре бетми. Кош сайраган тавышлар белән кушылып, бу, агач яфраклары талгын җилдә лепердәгәндәй, тоташ бер рәхәт бәйрәм сәламләвенә әверелә. Сабантуй инде килеп җиткән, җирләргә, күкләргә тулган, күңелләрне мөлдерәтеп гөрли, көйли, җырлый, башка нәрсә хакында уйларга да ирек бирми. Тургайның йомшак мамык ояга төрелгән кош балаларын күп мәртәбәләр күргәне, аларга тын да алмыйча сокланып карап торганы бар. Ул үзен дә менә хәзер оядагы кош баласыдай сабантуйның дәртле, җылы һәм серле кочагында кебек итеп тойды. Тик кош балаларыннан аермалы буларак, аның оясының иге дә, чиге дә юк, аның түшәлгән мамыгы күренмәсә дә, ул искиткеч җылы, могҗизаи иркен иде. Анда: авылның барлык кешеләре, кайткан кунаклар гына түгел, бөтен дөнья, әллә нинди рәшәле офыклар, бер-берсен алыштырып торучы серле күренешләр, аккан сулар, искән җилләр, һавада йөзгән болытлар, ул болытлардан яуган карлар-яңгырлар, урман-кырлар, кошлар һәм адәм балалары сузган җырлар... Якынлашып килүче сабантуй үзенең күренмәс нәфис бармаклары белән аның керфекләрен йомдырды, әнисе кыяфәтенә кереп, җылы иреннәре белән битләреннән үпте, татлы йокыга салып, аны тибрәтергә кереште. Тик боларын Тургай үзе сизми иде инде...

## Көрәш

Көрәш башлануын хәбәр иттеләр. Малайлар дәррәү шунда йөгерделәр. Көрәшне карап торуы бик тә кызык иде. Җиңгән беренә зуррак малайны кертәләр, зуррагы җиңә дә, аны тагын зуррагы белән көрәштерәләр. Малайларның бил алышканын караса да, Тургай багана төбенә бәйләнгән сарыкны да кызганды. Аны көрәш батырына бирәчәкләрен ул белә иде инде. Сарык әлсерәгән борынын сары чәчәкле үләнгә төрткән дә эчен дерелдәтеп еш-еш сулыш ала. Әгәр бәйләнмәгән булса, ул бу үләнне рәхәтләнеп ашар иде дә, бәйләнгәч, куркадыр, бу кадәр халык уртасында кая килеп эләккәнен дә аңламыйдыр бичара. Көрәш оештырып йөрүче, беләгенә кызыл тасма бәйләгән Әнвәр абыйлары алар янына килде.

– Әйдәгез, егетләр, көрәшкә чыгыгыз!

Малайлар бер-берләренә караштылар, берсенең дә сикереп чыгасы килмәде.

– Җиңгән кешегә менә шушы бүләк булачак, – дип ул кулындагы катыргы тартмадан алып, матур машина күрсәтте. Әллә кай төшен борып чирәмгә куйган иде, машинаның утлары кабынды, тәгәрмәчләре әйләнде, эченнән татарча бию көе яңгырады. Моны күргәч, малайларның күзләре ут булып янды.

– Мин чыгам, – диде Фаил. Аңа Зөлфәт иярде.

Менә алар билләренә сөлгеләр салып көрәшергә тотынды. Тик берни дә эшли алмадылар, сөлгеләрен тоткан килеш, башларын җилкәләренә куеп йөрделәр-йөрделәр дә икесе берьюлы егылып киттеләр.

– Сөлге белән билегездән кысып күтәрегез дә җиргә сырт белән салыгыз, – дип Әнвәр абый бик нык кыстый башлагач, Фаил Зөлфәтнең билен ару гына кысып китерде, ләкин күтәрә алмады, тагын егылып киттеләр. Пых-пых килеп, кызарынып-бүртенеп беткәч, Фаил Зөлфәтне еккан кебек итте, өстенә ныгытып ауды. Зөлфәт акрын гына торды да, сөлгесен селтәп ташлады һәм тешсез авызын

күтәреп, ачы итеп кычкырып еларга тотынды. Ул елаганга бөтен мәйдан халкы көлә башлады. Әтисе йөгереп килеп Зөлфәтне күтәреп алып чыгып китте. Фаил күкрәген киереп, йөзен кояшка табарак юнәлтеп, «тагын кайсыгызның башына җитим?» дигән кыяфәттә басып калды. Шулчак беркем чакырмаса да, Мансур аның каршына йөгереп чыкты. Әнвәр абый, «молодец», дип аңа сөлге тоттырды. Мансурның, күрәсең, көрәшеп караганы булгандыр (әтисе көрәшче бит), Бүсмәнне сыдырып китерде дә, алып та бәрде. Мәйдан шау-гөр килде, шаулатып кул чаптылар. Фаилгә бүләк итеп бизәкле кружка бирделәр. Шунда Тургай үзләреннән биш-алты адым гына арада әнисе белән торучы Сөмбелне күреп алды. Ул бик матур сары күлмәктән, киң читле ак эшләпәдән иде. Сөмбел аңа карап елмайды, Тургай кулын болгады. Янына барып, кесәсендәге берәр тәмлүшкәне бирим, дип уйлап та бетерә алмады, Әнвәр абый аны җитәкләп Мансур янына алып килде, кулына сөлге тоттырды.

– Кайсыгыз җиңә – машина шуңа булачак, – дигәч, сыбызгысын черелдәтеп, көрәшергә сигнал бирде.

Алар олыларга охшатып, көлешә-көлешә бер-берсенә кул бирделәр дә, сөлгеләрен билләренә салып көрәшә башладылар. «Кысыгыз, сөлге белән кысыгыз!» дип өйрәтте алар тирәсендә йөрүче Әнвәр абый. Мансур китереп тоту белән Тургай аның үзеннән күпкә көчле икәнен сизде. Аның күзенә генә карап торучы, ни әйтсә шуны үтәүче Мансур түгел иде бу. Җен кебек көчле икән ләбаса. Мансур аның билен, кабыргаларын шундый итеп кысты, аларның авыртуына тын алырлык та рәт калмады. Әгәр тагын бераз шушылай кысса, Тургай хәлсезләнеп тезләнәчәк иде. Шуңа күрә ул да сөлгесен көчәнеп үзенә таба тартырга керешә. Тик Мансур, сырты кычыткан бозау кебек, гәүдәсен әле бер якка, әле икенче якка уйната башлады. Болай иткәч, Тургайның сөлгесе аның биленнән ычкынып, аркасына шуды, ә өстән берничек тә кысып булмый. Тургай җиңә алмаячак иде. Ләкин ул сөлгесен ташлап мәйданнан чыгып китәргә оялды. Янәшәсендә генә бабасы, әтисе, тагын әллә кемнәр, «Тургай, бирешмә!» дип кычкырып торганда, ничек шулай итәсең ди. Шулчак Мансур аны уңга-сулга чайкалдырырга тотынды, бер аягы белән чалды да Тургайны артка этеп екты, дык итеп күкрәгенә ятты.

– Аяк чалды, аяк чалды, ярамый! – дип гөр килде мәйдан халкы.

– Хәрәмләшмә, ник хәрәмләшәсең?! – дип Мансурга төртеп күрсәтте кемнәрдер.

Тик ул аларның әйткәнен колагына да элмәде, тагын өч мәртәбә Тургайны аяк чалып екты.

– Туктат көрәшне, Тургай җиңгән саналырга тиеш!

– Тегесен мәйданнан чыгарырга кирәк! – дип Әнвәр абыйлары янына әллә кемнәр ярсып керде.

Шабыр тиргә баткан хәлдә икәүләшеп еш-еш сулап басып торганда, Шүкә дә Мансурның борын төбеннән йодрыгын болгап үтте. Үз хәлләре хәл булса да, багана төбендәге сарыкка күзе төшкән саен, аны кызганудан Тургайның йөрәге кысылып куйды. Ул, бичара, муенына бәйләгән бавын туктаусыз дылык-дылык тарта, су эчәсе килүдән борын тирәләре кара көйгән…

Әнвәр абыйлары, ярсулы тавышларга игътибар итмәстән, аларны кабат көрәштерә башлады.

– Соңгы мәртәбә бил алышасыз, малайлар! – дип кисәтеп тә куйды.

Алар тагын бер-берсен этә-төртә йөрергә керештеләр. Тургайның кроссовка эченә ниндидер очлы нәрсә – әллә таш, әллә пыяла кисәге кергән, табан астын пычак белән кискәндәй авырттыра иде. Ул авыртудан кычкырып җибәрмәс өчен тешләрен кысты, сусаудан тешенең аңкавына ябышканын сизде, кояш аларны юри сынагандай тагын да рәхимсезрәк кыздырды, икесенең дә хәле беткән, сулышлары гыжлап чыга. Табан астының авыртуына түземе бетеп, ул инде көрәшүдән туктарга дигән уйга килгән иде. Барыбер җиңеп булмаячак. Шулчак Мансур, аяк чалмакчы

булып, аның әлеге авырткан аягына уң яктан китереп бәрде. Тургай ыңгырашып куйды, аның котырып ачуы чыкты. Чалырга ярамаганын белә торып, ник шулай кылана ул?! Мансурның җилкәсе аша Тургайга әтисе белән бабасының, Галимҗан абыйсының, Рөстәмнәрнең, Фаилләрнең, Камбәр, Аяз абыйларының, тагын әллә кемнәрнең таныш йөзләре чагылып ала. Ә Сөмбел, аяк очларына басып, аңа таба кулларын сузган... Тургайның бөтен гәүдәсеннән рәхәт җылы сыйпап үтте. Хәзер инде ул үлсә дә мәйданны ташлый алмаячагын сизде һәм, тагын бер ыргылыш ясап, Мансурның билен алмакчы булды. Тик Мансур аны элеккедән дә ныграк кыса башлады. Билләрен әле берсе, әле икенчесе тартып китерде. Көрәшә торгач, алар тигезлек югалтып, кырын барып төштеләр. Кызулары шул кадәр җиткән иде, үлән өстендә тәгәрәшергә тотындылар. Әле Мансур Тургай өстенә чыкты, әле Тургай аны күкрәге белән җиргә кысты.

– Җитте, җитте, әтәчләр! – дип, Әнвәр абыйлары аермакчы булса да, берсе дә аны тыңламады, җиңүче рәвешендә өстә каласы килеп, һаман тартыштылар. Ниһаять, сүз берләшкәндәй, сикереп тордылар да, Әнвәр абыйларының сыбызгы сызгыртуын да көтмәстән, борыннарын лышык-лышык тартып, бер-берсенә омтылдылар. Мәйдан халкы туктаусыз «Тургай, Тургай!» дип кычкыра иде. Мансурның ачудан кара коелган йөзе елаган кыяфәткә керде, Тургай биленең аяусыз кысылып торуын сизде. Мансурга ирек бирергә ярамый иде. Ул тирән итеп сулыш алды, баягы рәхәт җылының сулышы белән бергә эченә ургылып керүен, кул-аякларына йөгерүен тойды. Мансурның билен кинәт үзенә тартты да, кысып алып гәүдәсен югары күтәрде. Мәйдан «ах» итте. Бөтен нәрсә бер мизгелгә туктап, тораташ катып калган шикелле булды.

– Сыртына сал, ат! – дип мең авыз төрле яктан кычкырды.

Табан астындагы утлы күмер һаман тирәнгәрәк керде... Тургай чайкалдырып алды да, Мансурны дөпелдәтеп сыртына салды. Моны ничек шулай эшли алуын ул үзе дә аңламады, моны ниндидер бер көч эшләде кебек...

Мәйдан гөр килде, аңа нинди генә мактау сүзләре яңгырамады! Әтиләреннән башлап, барлык туган-тумача, танышлар, бөтенләй таныш булмаганнар аркасыннан сөйделәр, батыр икәнсең, булдырдың, диделәр. Сөмбел дә утыргычка ук менеп баскан, үзе туп кебек туктаусыз сикергәли, нидер кычкыра-кычкыра кулларын чәбәкли иде. Тургай бу тамашага рәхәтләнеп, онытылып карап торды. Күпмедер вакыттан гына ул янәшәсендә кып-кызыл булып, башын аска иеп басып торган Мансурга борылып карады һәм аны чын күңеленнән кызганып куйды. Ничек ярдәм итәргә белмәде, аптырагач кулын аның җилкәсенә салды. Шуңа Мансурның йөзе ачылып китте. Тургайга теге матур итеп бию көе чыгаручы машинаны, Мансурга көмеш читле бәләкәй түгәрәк көзге бирделәр. Тургай белән көрәшергә бик зур гәүдәле малай чыкты һәм ул малай аны селтәп кенә салды. Ләкин бу җиңелү түгел иде инде. Моны Тургай үзе дә, мәйдан халкы да шулай кабул итте. Егылган җиреннән торуга, аны Мансур култыклап алды, мәйдан читендә Рөстәм, Зөлфәт, Фаил, Риф каршылады. Шәп көрәштегез, дип икесен дә туйганчы мактадылар. Тургай аларның мактауларына игътибар да итмәде, ул күзе белән Сөмбелне эзләде.

## Уртак уен

Тургай Сөмбелнең шушы тирәдән әллә ни ерак булмаска тиешлеген чамалый иде. Шуңа күрә малайларга «хәзер киләм», дип кызу-кызу китеп барды. Ничә адым атларга өлгергәндер, Сөмбел белән маңгайга маңгай бәрелешә язып туктап калдылар. Кызның әнисе Хәнифә апа да килеп җитте.

– Нихәл, көрәшче егет? – шулай дип ул Тургайның кулын кысты. – Кызым, син дә күреш.

Сөмбел сусыл калын иреннәрен ачыйм микән, юк микән дигәндәй мимылдатып торды да, ак тешләрен күрсәтеп елмайды, ике бите алмадай кып-кызыл булды.

– Исс-әнме... – диде ул, нечкә бармакларын Тургайга сузып.

Тургай аның кулын кысты, алмакчы булып тартылса да, җибәрмичә шактый тотты.

– Минем күлмәгем матурмы? – дип сорады Сөмбел.

– Эшләпәң матуррак, – диде Тургай.

– Ә күлмәгем?

– Сары матур, сары матур, сары матур сайласаң, – диде Тургай көлемсерәп.

Шунда ниндидер кунаклар Сөмбелнең әнисен үзләре янына чакыра башладылар. Сөмбел бер әнисенә, бер Тургайга тартылды. Аннары сары күлмәгенең кесәсеннән бер бәләкәй тарак чыгарып, Тургайның кулына тоттырды һәм шул минутта ук әнисе белән җитәкләшеп китеп тә барды. Тургай алар артыннан талпынып куйган иде дә туктап калды. Ничек Сөмбелгә иярмәк кирәк? Ул аларга беркем дә түгел ич. Шуңа күрә бөтен игътибарын мәйданга юнәлдерде. Ә анда ниләр генә юк! Карап кына бетер! Боларны бит яңадан беркайчан да күрә алмаячаксың. Әнә егетләр көрәшеп яталар. Аларга халыкның көч бирүен, хуплавын гына кара. Бөтенесе уйный кебек, ә бөтенесе чын. Көрәше дә уен, ә үзе шулкадәр һәркемнең күңелен әсир итә.

Малайлар, көрәшчеләрне шактый караганнан соң, халыкны ырып-ерып уң якка – чүлмәк ваткан җиргә юнәлделәр. Менә бу тамаша дисәң дә тамаша! Көч тә куясы юк. Ә үзе нинди кызык икән. Кеше кырына аркасы белән баса. Аның күзен бәйлиләр. Менә ул саллы колгасын тотып атлап китә. Ун адым атлый. Шуннан соң туктап борыла да, чүлмәккә таба атларга тотына, халык саный: бер, ике, өч, дүрт... Чүлмәкне ватам дип ул бөтенләй икенче якка каера, чүлмәк читтә кала. Менә ул туктый һәм, колгасы белән коточкыч кизәнеп, җиргә китереп суга! Җир селкенеп куйгандай була, халык рәхәтләнеп көлә. Чүлмәк ватылган тавышны ишетмәгәч, кабат китереп суга, әмма чүлмәк ике-өч метр читтә аны мәсхәрәләп көлеп утыра. И интектеләр, и интектеләр – берсе дә вата алмады. Шулчак ашыкмый-кабаланмый гына Сөмбелнең әнисе Хәнифә апа чыкты. Тургай карашы белән Сөмбелне күпме генә эзләсә дә күрә алмады. Күзләрен бәйләүгә, Хәнифә апа башкалар кебек калтыранып, туктый-туктый адымнарын санап та тормады. Җәһәт-җәһәт кенә тиешле адымнарын атлап китте, кырт борылды һәм чүлмәккә туп-туры килә башлады. «Күрә бу, күрә!» дип кычкырышты кемнәрдер. Аның яулыгын тикшереп карадылар, тагын да кысыбрак бәйләделәр. Менә ул чүлмәккә килеп җитә язды. Колгасын өскә күтәрде, бер генә мизгелгә туктап калды. Мәйданның сабыры бетте:

– Бәр, бәр тизрәк! – дип кычкырды кемнәрдер буылып.

– Көлгә әйләндер! – дип өстәделәр башкалар, Хәнифә апага көч биреп.

Ул шартлатып бер генә сукты. Чүлмәк мең кисәккә чәрдәкләнеп чәчелде. Мәйдан шау-гөр килде, кунак хатыны күрмәгәнне күрсәтте! дип куаныштылар, елгыррак ир-атлар аны күтәреп чөймәкче дә булганнар иде, Хәнифә апа үзенә кагылдырмады. Самоварны аңа бирделәр. Микрофоннан әйттеләр: унсигез кеше чүлмәкне ватмакчы булып караган, берсе дә булдыра алмаган, шуңа сабантуйның иң абруйлы бүләкләреннән берсе – Камчаткадан ук Камбәр алып кайткан самовар бирелә, диделәр. Шунда бөтен мәйданны шаккатырып, Камбәр абый Хәнифә апаның бит очыннан үбеп алды. Анысына чүлмәк ваткандагыдан да ныграк кул чаптылар.

Аннары йомырка салынган агач кашыкны капкан килеш узышу уены башланды. Мәйданга ун кеше чакырдылар.

– Әнә, әнә минем Америкадан кайткан җизни дә керде, – дип кычкырды Мансур.

– Кайсысы?

– Әнә арада иң озын нечкәсе.

– Исеме ничек җизнәңнең? – дип сорады Фаил.

– Джон. Джон исемле ул.

Американ җиңсез буйлы әйбер кигән, кулларын сары йон баскан иде.

– Синең Джон җизнәң гел йон гына икән, – дип көлде Фаил.

Бу ярышны караганда, көлә-көлә малайларның эчләре катып бетте. Йомырканың чи икәнлеген, кашыктан төшсә ватылачагын уенны оештыручы алдан ук әйтеп куйды. Унлап кеше – ирләр дә, хатыннар да бергә тезелеп бастылар, кашыкларына йомыркалар салып, авызларына каптылар. Куллар белән тотарга ярамый, йомыркасын кулы белән тотучылар уеннан чыгарылачак, дип кисәтте алып баручы. Йомырканы төшермичә алдан килүчеләргә бүләк биреләчәге әйтелде. Менә команда яңгырады:

– Бер, ике, өч!

Авызларын алга сузып, тезләрен бөкләп, аякларын шудыра-шудыра гына атлап, барысы да кузгалдылар. Тик берсе дә кызулый алмады: зуррак итеп атлауга кашыктагы йомырка сикерергә тотына икән. Һәрберсенең күзе кашыктагы йомыркада. Кайсылары йомырка төшсә-нитсә, тотарга дип ике учын сузып бара. Иң кызыгы Джон иде. Бүләкләр бәйләгән колгалардан әз генә кыскарак гәүдәсен ул кәкрәйтеп, билен артка, ияген алга чыгарды. Үтә нык тырышканлыктан, сары йон баскан кулларын ике якка сузган, нәрсәдер умырып алырга җыенгандай, ун бармагы ун якка тырпайган. Аның озын аяклары башкалар кебек шудырып вак-вак кына атлый алмый, олы итеп бер адым ясауга кашыктагы йомырка өскә сикерә. Ул сикергән саен тамак төбеннән «хын, хын, хын» дигән сәер тавыш чыга. Бер шаяны шунда мәйдан яңгыратып сорап куя:

– Ни ди ул, җәмәгать?

– «Йон, йон!» ди бит.

– Йомыркада йон үсмәгәнне белми микәнни?

– Татар тавыгының йомыркасы әмерикәнекенең кәҗә маен чыгарамы?

– Татар кашыгы авызын ничек бүлтәйткән!

Халык шау-гөр килә, көлешә, кызык итеп кул чаба. Американның кыланмышыннан көлмәскә тырышып шактый түзсә дә, Тургайның түземе сынды: эченнән «ыһһы-ды-ы!» дигән көчәнүле көлү тавышы бәреп чыкты һәм дулкын-дулкын кабык өстеннән кәтүкләр тәгәрәткән төсле тылсымлы авазларга меңнәрчә кеше буйсынып көләргә тотынды. Джонның кашык өстендә «төшәм-төшәм» дигәндәй сикергәләп барган йомыркасы төшеп тә китте. Моны күргәч, Тургай тагын да ныграк гөлдерәп көлә башлады. Халык меңнәрчә авыз белән тагын аның көлүенә кушылды. Джон туктап, әле буш кашыгына, әле аяк астына төшеп ватылган йомыркасына карап тора иде. Тургайга янәшәсендәге малайлар да, олылар да «тагын бер генә көл инде», дип ялынырга керештеләр. Ләкин Тургайның кабат көләсе килмәде. Уенны алып баручы Сәҗидә апа Джонның кашыгына исән йомырка китереп салды. Иң соңгы кеше булып килсә дә, аңа бик матур борынгы сөлге бирделәр. Джон сөлгене күкрәгенә кысты да, җиргә тигерә язып, башын өч мәртәбә иде, халыкка рәхмәт әйтте.

Катыктан акча эзләргә башта беркем дә чыгарга теләмәде. Шактый тирән табакка куе катык салдылар, шуңа ун сумлык тимер акча ташлап, уклау белән бик нык болгаттылар. Кем акчаны авызы белән эзләп таба, шул кешегә сок чыгара торган машина биреләчәк, дип бүләкне күрсәтеп, шунда җиргә куйдылар. Нишләптер беркем дә тәвәккәлләмәде. Күп кыстый торгач, Тургайлар очында ялгызы яшәүче үзбәк Хәлил бабай чыкты. Ул күлмәген салып майкадан гына калды. Ике кулы белән җиргә таянып, сакал-мыеклары белән табакка чумды. Үзбәк колакларына тиклем катыкка күмелде, маңгае белән сөзеп, авызын табак читенең әле бер, әле икенче урынына төртте, теге тиенне шунда кысып китереп эләктермәкче булды. Ләкин катык куе, акча эткән саен читкә китә, авызга һич тә якынаймый иде, күрәсең. Тыны беткән саен, Хәлил бабай башын күтәреп пошкыргандай «пох» итте. Аның ап-ак катыкка баткан йөзенә, сакал-мыекларына карап, халык рәхәтләнеп көлде.

Ул әз генә хәл ала да «бисмилла» дип тагын катыкка чума. Бик озак җәфаланса да, акчаны барыбер туры китерде. Тешләренә кысып чыгаргач, чирәмгә төкерде. Аңа катыгын сөртергә сөлге, аннан соң теге бүләкне бирделәр. Бабай сөенеп туймады, авызында булган биш сары тешен күрсәтеп елмайды.

Аннары ике төркемгә бүленеп, юан бауны һәр төркем үзенә таба тартты. Анысына Тургайлар да чыгып булышты, каршы якны сөйрәп алганда, үзләре чалкан барып төштеләр. Кара-каршы утырып, аякларын сузып таяк тартышу, гер күтәрү, капчык киеп йөгерү, баганага атланып, печән тутырылган капчык белән сугышу – тагын әллә нинди уеннар карадылар.

Картлар йөгерешенә чыгучы бабайлар шактый нык йөгерделәр. Карчыклар йөгерешендә йөзләре, куллары кипкән өрек җимеше төсенә кергән бер әби мәйданга килеп җиткәндә, әле тезләнде, әле торып басты, әмма йөгерүеннән туктамады. Мәйдан эченә ул дүрт аяклап үрмәләп керде. Әбинең иреннәре бөрелгән, тешсез авызыннан сулыш алганда мәче мырылдаган, гармун кычкырткан тавышлар чыга иде.

– Үләсең бит, Сәлимәтти, карап кына утырсаң, ни булган? – диде шунда йөгереп килеп җиткән медсестра Нәфисә.

– Гомерем буе йөгергәнне быел гына каласым юк! – диде әби гыжылдап сулый-сулый.

– Сиңа ничә яшь соң? – дип сорады кемдер.

– Ходай биргән яшемнең барысы да үземнеке, – диде әби, тешсез авызын чәпелдәтеп көлә-көлә.

Бу сабантуй бик кызык икән. Олыларның башка вакытта уйнап йөрергә вакытлары булмаганга ясыйлардыр моны, дип уйлады Тургай. Юкса шушы кадәр каударланып кайнашырлар идемени?

## Дөньяның чите кайда?

Нух тавы туктаусыз Тургайның төшенә керә. Бу аны үзенә чакыруы инде. Ул анда беренче менгәндә, хансарай өчен таш сорамакчы булып ялгышты. Аны сорау өчен әле ныграк үсәргә кирәктер. Шуңа менгермәде. Хәзер Тургайга таудан көч алып төшсә – җитә. Ә ничек менәргә? Алгысынды  инде ул менәм дип. Ник дисәң, җене гел үрти. Булдыра алмыйсың, ди, син җебегән, ди. Тургайны ул гел интектереп, эткәләп-төрткәләп кенә тора. Шуның аркасында әйбәт кенә барганда йә урындыкны аудара, йә өстәл почмагын эләктерә, йә чынаягындагы чәен түгә, берәр нәрсәне төшереп вата. Тимер-томыр белән уйный башласа, кулын бәрмичә, канатмыйча калмый, тезләрендәге яраларын да санап бетермәле түгел. Сине җенең кабаландыра, сабыррак бул,  диләр әти-әниләре. Алай ансат кына сабыр булып булса ул. Җене «булдыра алмыйсың», дип үртәгән саен, яшерен теләге көчәйгәннән-көчәя генә барды. Бүген ул һичшиксез Нух тавына менәчәк.  — Кесәсенә йолдыз кыйпылчыгы белән Сөмбел биргән канатлы ат уенчыгын салып. Тарагын алмаска булды, югалтудан курыкты. Үзбәкстаннан кайткан Хәлил бабай күргән саен, Нух тавына барсаң, миңа янар чәчәк алып кайт, ди. Аны тану өчен кәгазьгә төреп үләннең үзен дә бирде. Яфраклары вак нарат энәләренә охшаган, сары чәчәкле үсемлек ул. Хәзер чәчәкләре коелып беткәндер, диде. Тауның иң биек урынына җитәрәк үсә, ди. Йөрәккә бик файдалы икән. Аны җыярга пакет та алды. Бабасының да йөрәге сау түгел, аңа да бик әйбәт булыр.

Ләкин Тургайны бер нәрсә бик тә борчый. Әти-әниләренә сезгә әйтмичә андый хәвефле җиргә бармам, дигән иде бит. Менә хәзер ничәмә-ничә көннәр нишләргә дә белми. Әйтсәң – җибәрмәячәкләр. Ә тауга менмичә кала алмый, ул бит аның өчен генә түгел, барлык кеше өчен кирәк. Өйдәгеләр янында үзен һәрвакыт гаепле сизә, хәтта битләре кызыша, тирләпләр чыга. Малайлар белән уйнаганда

онытылып торса да үзе генә калуга, шул яшерен нияте кузгала, йокларга яткач та, иртән уянгач та тауга менүне һәм биргән антын уйлап, бик озак борчылып ята. Баш вата торгач, серен Мансурга чишәргә булды.

Бүген иртүк аларга барып, барысын да сөйләп бирде. Беркемгә дә, хәтта малайларга да аның кая киткәнен әйтмәскә кушты. Төштән соң сәгать өчләрдә кайтып җитмәсәм, әниләргә барып әйтерсең, диде. Мансур башын кашый-кашый сорап куйды:

– Нишләп баштук әйтмәдең, дисәләр?

– Онытканмын, диярсең.

Ул капкадан чыккач шактый басып торды, аннары урам уртасыннан башын аска игән килеш акрын гына атлады. Нишләптер өйдәгеләрнең берәрсенең арттан чыгып кычкыруын, туктатуын көтте. Сабантуй булган җирне үткәнче, артына борылып карый-карый, берәрсенең дәшүен көтеп атлады ул. Аннары адымнарын кызулатты, атлар чабып килгән юлга чыккач, бар көченә йөгерергә тотынды. Хәзер ул берәрсе арттан килеп туктата күрмәсен дип йөгерде.

Зәңгәр күктә ак сарык йоны төсле өем-өем болытлар йөзә. Җил дә арттан этеп кенә бара. Нишләптер кичә кич әнисенең «И минем хыялыем!» дигән сүзләре исенә төште. Тургай Нух тавына ничегрәк менәргә дип баш ватып ятканда, әнисе килде дә:

– Улым, ни уйлыйсың маңгайларыңны җыерып? – диде.

– Уйламыйм, – дип Тургай әнисенең муеныннан кочаклап алды. Әнисе шундый җылы иде, аңардан сөт, коймак, ипи исләре килде, йомшак чәчләре beләкләрен рәхәт итеп кытыклады.

– Әнием, синнән җан исе килә!

– Ни дидең, улым, кабатла әле? – диде әнисе.

– Синнән җан исе килә, – диде Тургай.

– Җанның исе булмый, җылысы гына була.

Тургай күзләрен кысып көлеп җибәрде һәм:

– Җан кайда соң ул? – дип сорады.

– Кешенең эчендә. Җан тәнне җылыта, тере итеп тота.

– Әнием, миңа синең яныңда шундый рәхәт, – диде ул пышылдап. – Син бөтен кешенең дә әнисе булсаң, аларга да рәхәт булыр иде, әйеме?

– И, минем хыялыем! – диде әнисе аның битләреннән, колакларыннан үбеп.

Әнисе исенә төшкәч, Тургайга тагын кыен булып китте. Тауга барасын аңа да әйтә алмады шул. Теге чакта сүз кузгаткач, әтисе мазут исе килеп торган йодрыгын бер генә селкеде борын төбендә. Ә аның шундый көчле буласы, тизрәк үсәсе килә. Ул үссәме? Ул үссә, әллә ниләр эшләр иде. Бөтенесен шаккатырыр иде. Малайларны гына түгел, олыларны да ияртер иде. Шүкәне дә тыяр иде. Шәмседоха әбигә, үзбәк бабайга өй салдырыр иде. Госман абзыйның күзен дәвалатыр иде. Хансарайны да истән чыгармас иде.

... Зәңгәрсу томан артыннан серле булып күренгән Нух маңгае аңа якынайган саен яктыра, ә тау текәләнә бара. Юл бөтенләй бетте. Тургай, эреле-ваклы ташлардан торган киртле урынга җиткәч, туктап хәл алырга булды. Кесәсендәге әйберләрен барлады, йолдыз кыйпылчыгын алып, Нух маңгаена карады һәм кыйпылчык сыры белән маңгай сырының төп-төгәл туры килүен күрде. Бу аны гаҗәпләндерде дә, шатлык та өстәде. Тургай тагын да дәртләнебрәк югарыга омтылды. Тау шулкадәр текәләнде, хәзер иелеп, ташларга таяна-таяна атларга, кайбер урыннарда үрмәләргә туры килде. Аяк астыннан ташлар кубып тәгәрәп киткәндә, тезләре дә бәрелде, сыдырылды, канады. Югарыда зәңгәр күк йөзе, ак болытлар һәм Нух маңгае. Тауның ике ягыннан сузылган урман да аста калды. Ул әледән-әле туктап ял итә, тау-таш арасында үскән чәчәкләр өстендә очучы бал кортлары, шөпшәләр гөжләвен, чикерткәләр черләвен тыңлый. Аның аяк астында

кырмыскалар йөгерешә, мәтрүшкә сабагыннан үрмәләп менгән камка Тургайның иягенә тия язып очып китә. Күпме чебен-черки, кигәвен, Тургай аларны әрем сабагы белән куып кына тора. Сары бөгәлҗәннәрдән дә кызыгы юк. Алар биткә тия язып бер урында безелдәп торалар. «Ни кирәк?» ди Тургай көлеп. Китмиләр, безелдәүләрен дәвам итәләр.

Тургай артына борылып, аска карыйсы килсә дә, тыелды. Баш әйләнмәсен өчен алар малайлар белән тирәк, өянке кебек биек агачларга менгәндә дә аска карамыйлар. Аска карасаң, куркуың бар. Ул кузгалды.

Киртләнеп торган тагын бер урынны узгач, Нух маңгае аның каршында бөтен зурлыгы белән ачылды. Аларның чана шуа торган ындыр тавы кадәр бар икән бу! Авылдан караганда, кеше башы кебек кенә күренә үзе. Әле аңа менеп җитәргә тагын ике өй биеклеге ара бар. Тирә-юне гел ташлардан гына тора. Тургай чиләк зурлыгы бер түгәрәк ташка баскан иде, таш урыныннан кубып, сикерә-сикерә аска тәгәрәде. Аның коты очты. Яңадан һәр ташны селкетеп карамыйча аягын да басмады, кулы белән дә таянмады. Тагын ике генә, өч кенә талпынса, Нух маңгае янына менеп җитәчәк. Ул бүген Тургайны куркытмады, аңа күптәнге танышына караган кебек карады. Тагын берничә омтылуга, Нух маңгаеның янына ук килеп җитте. Сул ягында өстәл өсте кадәр генә тигез урын бар икән. Ташлары да ваграк, араларыннан мүк төсле кыска үлән дә чыккан. Тургай шунда үрмәләп менде. Ул шабыр тиргә баткан иде. Күлмәген салып, итәк очы белән тезенең канаган урынын сөртте. Ташларга кан тисә, Нухның яратмавы мөмкин ич. Аннары күлмәген читкәрәк куеп, җил очырып алып китмәсен өчен, көлчә шикелле юка таш белән бастырды. Аягүрә торырга курыкты. Тезләнеп ике кулына таянган килеш курка-курка гына Нух маңгаена карагач, тыны кысылып куйды. Менә ул күпме гомерләр аның котын да алып, үзенә чакырып та торган серле зат. Үзе түгәрәк, үзе саргылт көрән төстә, үзе ялтырый. Җил болытларны куып китереп, Нухның маңгаен яңгыр тамчылары белән юып тора, дип сөйли авыл халкы. Шулайдыр, болай ялтырап тормас иде. Аның тирәсендә болытларның куерганын Тургайның үзенең дә күп мәртәбәләр күргәне бар.

Күз урыны да бар бугай моның. Тургай йөзен якынрак китереп карады. Маңгайның таш-туфрактан чыгып торган мүкле җиреннән өстәрәк бар шул! Ике түгәрәк урын батынкыланып, каралыбрак тора. Уң яктагысында тары ярмасы кадәр генә ярык та бар. Ярыкта сәйләндәй су тамчысы ялтырый, тик ул агып чыгарга өлгерми, ташка дым булып җәелә. Шуңа күрә түгәрәкнең бусы тегесеннән караңгырак күренә. Кинәт ниндидер моң ишетелеп киткәндәй булды. Ул тын алудан туктады. Тагын, тагын, тагын... Әйтерсең лә күктән калай таз төбенә өч олы тамчы тамды... Аннары ул сизелер-сизелмәс кенә өзек-өзек көй булып колакларны иркәләп үтте. Әллә җилме бу? Ләкин көй маңгай ягыннан килә иде. Тургай маңгайның кул сузымы җитәрлек төшендә чәй калагы сыярлык кына түгәрәк тишек күреп алды. Әллә шуннан чыга иде инде ул моң? Кинәт ул Нух маңгаена акрын гына шуышып менеп килүче бер сары еланны күреп алды һәм ирексездән артка чигенде. Елан теге тишеккә шуып кереп тә китте һәм баягы моң да туктады. Тургай үзенең курыкмавына аптырады. Кулларына, аякларына ниндидер көч иңүен сизде. «Менә мин тау башында!» – дип кычкырасы килде аның. Ул акрын гына тора башлады. Тезләрен кузгатып аягүрә басуга, каршысындагы күренештән башы әйләнеп китте. Ах, бу нинди сихри манзара?! Әллә ул күкнең җиденче катындамы?! Ничек еракта, аста калган бөтенесе! Ул ничек шушы кадәр югары күтәрелгән?! Ык елгасы әбисенең тезләренә салган зәңгәр чәчүргече төсле нечкә генә булып шәйләнә. Гөлбакча да әллә кайда ук, өйләр дә бәләкәйләнгән. Әрәмәләр, урманнар, үзәнлекләр, юллар, иген басулары, сыер-сарык көтүләре – барысы да аста, әллә кайда еракта... Офыкка тия язып утырган әллә ничә авыл күренә, күк белән тоташкан таулар, урманнар шәйләнә. Монда менеп күрмәсә,

Тургай аларның барлыгын да белми иде. Офыклар әйләнә-әйләнә сабантуй мәйданы шикелле түгәрәк ясыйлар икән. Шул түгәрәккә кергән бөтен нәрсә аның аяк астында җәйрәп ята! Алар каршында ул берүзе! Гәүдәсе шундый җиңеләйде. Нәрсәдән икән? Әллә инде шушы җәйрәп яткан күренеш әнисе кебек аны үз кочагына алдымы? Болын-кырлар өстенә җәелгән әнә теге сыек зәңгәрсу томан аның гәүдәсенең авырлыгы түгелме икән? Шактый көчле искән җил дә ничектер тынып калган. Тургай җилгә каршы тырышып басудан арыган балтырларына ял бирде, аякларын рәхәт итеп йомшатты. Әмма һич көтмәгәндә җил арттан шундый итеп этте, чак кына йөзтүбән аска егылмыйча калды. Аны ниндидер йомшак канат күкрәк турына кагылып, аварга ирек бирмәде кебек. Тургай үзе дә сизмәстән Нух маңгаена уң кулы белән таянды. Ул мичтән алган таба кебек кайнар иде! Тургай аның кайнарлыгын тойгач, куркуыннан кулын шундук тартып алды. Аның Нух маңгае янына менүенә җилнең ярсуы түгелме икән бу? Арттан этеп, алдан егылдыртмый калучының да җил булуы бар. Нухтан шөлли бит инде ул. Тургай менә хәзер генә бер нәрсәгә гаҗәпләнде: ул үсте! Ул гәүдәсенең биегәйгәнен сизеп тора. Күпме нәрсәләрнең барлыгын шушыннан карап кына белде. Ул үзен дә аларга күрсәтә. Монда менү кирәк булган. Бусында сүзендә тора алмады. Тургай биргән антын яңадан беркайчан да бозмаячак. Их, шушы җирләрнең бөтенесен дә көн саен күреп торсаң! Аларның чите кайда икән? Бик еракта тагын бер тау шәйләнә. Аның янәшәсендә икенчесе, аннары урманнар. Бөтенесе күк белән тоташкан. Җирнең чите анда гына түгеллеген белә ул. Сабира апалар шәһәренә озын көн буе бардылар. Машина юлы Нух тавыннан да биегрәк җиргә килеп чыккач, Тургай куркуыннан кычкырып җибәрде. Аста, әллә кайда ук урманнар, күлләр. Машина алга таба мәтәлчек атып китмәсен дип курыкты ул. Чокырның төбенә төшеп җитүгә, анда болытларга тиеп торган тау күренде. Анысына менеп җиткәч, тагын төшеп киттеләр. Көне буе шулай бардылар. Әнисе: «Ничек монда юл салдылар икән?» – дип сорагач, әтисе: «Әле сез Кавказ тауларын күрсәгез, алар белән чагыштырганда, Урал таулары бер көрәк балчык өеме генә», – диде. Әле Кавказы да бар икән. Үзбәктән кайткан Хәлил бабай андагы ком чүлләренең очы-кырые юк, ди. Кошлар ел саен бик-бик еракка – җылы якларга очып китәләр. Торналарның очып киткәнен ул былтыр әтисе белән карап торды. Телевизордан әллә нинди шәһәрләрне, пароходлар йөзә торган диңгезләрне күрсәтәләр. Ә чите кайда икән соң? Җирнең бер төшендә бөтенесе дә бетәдер бит инде. Яр кебек булып тора микән? Кеше-мазар, мал-туар төшмәскә койма коеп куйганнардыр.

Әгәр кулыннан килсә, Тургай бөтенесен үзләренең авылы тирәсенә җыяр иде. Сабира апалары, Рәсүл җизниләр, Камбәр, Аяз абыйлары да читтә тилмереп йөрмәс иде, кошларга да әллә кайларга очасы булмас иде. Шушы уйлардан аның бөтен тәненә җылылык йөгерде. Әллә тауның җаны җылыта – белмәссең. Ул үзе дә сизмәстән кулларын өскә күтәрде һәм кычкырып җибәрде:

– Һи-һи-һи-и-и! Һи-һи-һи-и-и!

Тавышы күкрәгеннән гел өзелмичә ургылып чыкты. Ниндидер көч аны җырга әйләндерде:

Саумысез, болыннар, басулар,
Урманнар, елгалар, күлләрем!
Каршыма килдегез, көлдегез,
Булдыгыз күңелем гөлләре!

Алар аның җырын аңладылар. Шулай булмаса, тагын да яктырыбрак, якынаебрак китмәсләр иде. Тургай, колачын җәеп, аларның җавабын көтте, ишетергә теләде, ләкин бу мөмкин түгел иде. Ә җыры язгы тургай сайравы кебек һавада тирбәлде:

Кайда соң бу, кайда соң бу
Гүзәл җирләрнең чите?
Ак болытларга утырып,
Уйларым шунда китте…

Тургайның тавышы үзенеке түгел, ул бая югарыдан өч мәртәбә яңгыраган моңның әллә нинди рәвешләргә кереп көчәюе, җәелүе иде. Аның тавышы еракларга очты, үзәннәр, авыллар өстеннән йөгереп, ерак офыкларга барып бәрелде, аннары кире кайтып, Нухның алдына ауды… Тургай, шатлыгын тыя алмыйча, әле дөнья яңгыратып көлде, әле җырлады…

Шушы җырларын Нух маңгае астындагы чишмәгә төшеп кабатларга, аннары күкрәгендә саклап авылга алып кайтырга кирәк иде. Ул күлмәген киде, тагын бер мәртәбә Нухка, аның күз урыннарына карап торды, аннары төшәргә кузгалды. Ул канатларда талпынгандай җиңеллек һәм җитезлек белән бер ташка уң аягы белән басты, икенчесенә басыйм дип сулын күтәрүгә, шул таш янына түгәрәкләп ясалган кечкенә оя, анда яшькелт күкәйләр күрде. Аларга басмас өчен, ерактагы ташка сикерде, таш умырылып очты. Тургай тигезлеген саклый алмыйча барып төште һәм аска тәгәрәде. Тәгәрәве һаман кызулый барганда, ул нәрсәгәдер бәрелеп туктап калды. Күтәрелеп караса, әтисенең сырмасы кадәр генә калку җиргә килеп төртелгән икән. Аның өстен куе яшел үлән каплаган. Ташка бәрелеп авырткан кабыргаларын, беләкләрен сыпыргалап торганда, ул бу үләнне танып алды. Хәлил бабай җыярга кушкан янар чәчәк ич бу! Тикшереп карау өчен, ул төреп биргән үсемлек белән чагыштырды. Нәкъ үзе шул. Янар чәчәкне җыярга пакетын алыйм дип кулын кесәсенә тыкса, канатлы аты юк! Тәгәрәгәндә төшеп калган инде ул болай булгач. Тургай үзенең төшкән җирен әллә ничә мәртәбә менеп карады, уенчыкны таба алмагач, кәефе кырылды. Пакетына янар чәчәк җыйнап, чишмә янына төште. Чишмә өстәл-өстәл ташлар арасыннан ага, суының эзен ямь-яшел үлән каплаган. Ике ягында берничә тәбәнәк юкә үсә. Алар алтын төсле чәчәкләргә чумып утыралар. Яннарына килерлек түгел, бал кортлары сырып алган, гөжләү тавышлары кайчакта кош сайрауларын да каплап китә. Чишмәдән өстәрәк тә ике юкә үсеп утыра. Бу юкәләрнең кәүсәләрендә зур ярыклар бар, шул ярыкларга бал кортлары оялаган, диләр. Имеш тә шуларның балы агач тамырларыннан чишмәгә дә төшә. Аны баллы чишмә дип йөрткәннәрен белә Тургай. Тамагы да кипкән иде, иелеп куш учлап су эчте. Бернинди дә бал тәме килмәде. Ул шундый салкын иде, маңгаена кадәр бәрде салкыны. Чыккан урынында ком бөртекләре, төрле төстәге вак ташлар рәшә кебек дерелдәп күренә. Бераз китүгә, чишмә җир астына кереп югала икән. Аска кадәр төшсә ни булган? Әле генә чыккан югыйсә, нигә инде кабат җир астына төшеп китәргә? Шунда тагын аны гаҗәпләндергән хәл булды. Чишмә янындагы таш астыннан акрын гына шуышып сары елан килеп чыкты. Өстәге еланга охшаган, әллә шулмы? Елан телен энә очы кебек туктаусыз чыгара-чыгара аңа карап торды да, чишмәнең дымлы җиреннән шуып әйләнгәч, кабат таш астына кереп югалды. Тургай әз генә дә куркып карамады. Элек булса, куркыр иде. Әтисе дә, бабасы да малай кеше бернидән дә курыкмаска, көчле булырга тиеш, диләр. Менә ул бүген курыкмады бит. Нух янына менүе аркасында инде бу. Сүзеңдә тормадың дип битәрләсәләр.

Чишмәнең шушы кадәр биеккә күтәрелеп чыгуы гаҗәп иде. Нух маңгаеннан ук урап төшә бит. Тауның эче тулы су микәнни? Суы булгач, бәлкем анда балыклар да бардыр? Әгәр бу олы ташларның берәрсен кубарып алсаң, суы агып бетеп, тау ишелер идеме икән? Тау башына кадәр күтәрелерлек юл булгач, җир ничә катлам икән соң? Күкнең җиде кат икәне билгеле. Җир эчендә әбисе тәмуг та бар ди бит әле. Гөнаһлы кешеләрне шул тәмуг утында яндыралар, ди. Бер үк җирнең эчендә уты

да, суы да, еланы да. Ә тышынданиләр генә юк! Күк тулы йолдыз. Әллә берсенең дә чиге юкмы соң боларның? Күктә оҗмах та бар, ди әбисе. Анда шундый рәхәт, ди. Кешеләр тәмле-тәмле ризыклар ашап, уйнап-көлеп кенә йөриләр, уйнарга әллә нинди матур уенчыклары күп, ди. Карт кешеләр, авырулар бөтенләй юк, бөтенесе яшь, берсеннән-берсе матур, ди.

Тургай бик озак уйланып утырды боларны. Күпме генә уйласа да, очына чыга алмады. Бер генә сорауга да җавап юк иде. Ул җавапларны табу өчен, тагын бераз үсәргә кирәктер ахрысы…

Ул кайтырга кузгалды.

## Сары елан биргән көч

Ул инде тауның астына төшеп җитә язган иде. Сөйләшкән тавышлар ишетеп, туктап калды. Юл буендагы агачлыктан Рөстәм, Зөлфәт, Риф, Мансур, Фаил чыгып килә иде. Ул аларга каршы йөгерде.

– Һи-һи-һи-и-и!

Иптәшләре аны авызларын ерып каршы алдылар.

– Кая барасыз?

– Синең янга, – диде Рөстәм.

Тургай Мансурга шикле караш ташлап алды.

– Кем әйтте минем монда икәнне?

– Мансур, – диештеләр малайлар.

– Ник әйттең? – диде Тургай аның каршына килеп.

– Ул бит үзе, – дип эһ-эһ килде Мансур.

– Кем үзе?

– Син әйтмәскә кушкан әйбер… Гел эчтән этә, күргән бер кешегә сөйлисе килә… Эһ… Түзә алмагач, барып әниләреңә әйтим дип урамга чыкканда, болар килде… Эһ… Сине сорыйлар…

– Әйттеңме?

– Әйтмәде! – дип сузды Зөлфәт. Бәйләнгән ике бармагын авызына китереп, капмыйча кире төшергәннән соң өстәп куйды: – Кайда икәнеңне белмим, диде.

– Аның хәтле тешләк, – дип өстәде Фаил.

Мансур көлә-көлә аның иңбашын тешләп алды.

– Менә шушылай була ул тешләк!

Фаил аны этеп җибәрде.

– Тешең белән күлмәкне ертсаң, әтигә әйтеп артыңны пешерттерермен!

– Синең әтиеңне минем әти чеметеп кенә ыргыта бит! – диде Мансур.

– Ыргытты ди ыргытмаган!

– Ыргыта шул. Минем әти фермада эшли, аның куллары сөялләнеп беткән, мускуллары – во! Ә синең әтиең товар сата. Аның бүксәсе олы, мускулы бәләкәй.

– Ярар, зурлар кебек үртәшеп тормагыз әле! – дип туктатты аларны Тургай.

Дөресен генә әйткәндә, Мансурның серне чишүенә ул шат иде. Берүзең кайтканчы бергә-бергә күңелле була бит ул.

– Йә, менеп җитә алдыңмы? – диде Мансур, сүз саен нык эһелдәп.

Малайлар колакларын торгызып аңа төбәлделәр. Ул юри дәшми торды.

– Тизрәк әйт инде! – дигән соравы белән Рөстәм, күзлекләрен елтыратып, сукыр чебен шикелле аның күзенә керде.

Фаилнең йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыкты:

– Менә алмадыңмыни?

Кысталган кебек сикергәләүче Зөлфәт туктаусыз бер сүзне кабатлады:

– Әйт! Әйт! Әйт инде!

Тургай бөтен гәүдәсе белән тауга борылды һәм кулын Нухка таба сузды. Малайлар аның кулына төбәлделәр. Күзләре дә, авызлары да ачылган килеш йомылмыйча калды, тын алудан туктадылар. Ул әллә нинди куркыныч калын тавыш белән:

– Мин шушы кулым белән Нух маңгаен ярты сәгать сыпырып тордым! – диде.

Малайларның эченнән ниндидер ахылдау ишетелде.

– Алдыйсың! – диде Мансур.

– Булмас! – диде Зөлфәт.

– Беләбез без сине! – диде Фаил.

– Ефыртасың ефырткыч! – диде Риф.

Малайлар авызларыннан ни ычкынганын да чамалый алмас хәлгә төшеп шаулаштылар. Чөнки бу ышана торган хәл түгел иде. Авылда бер генә кешенең дә анда менгәнлеге турында сөйләгәннәре юк. Бу – сабантуйда җиңү генә түгел, Тургайның үзен бөтен авылдан өстен итеп күрсәтүе иде. Моңа ышанасы да килми, ышанасы да килә, шул ук вакытта бу көнләштерә дә, ачуны да китерә иде.

– Әле сез ышанмыйсызмыни?! – диде Тургай, күтәргән кулын төшереп. – Алайса тапшыру бетте, каналны күчерәбез!

Ул, авылга таба шарт борылып, юлдан кызу-кызу атлап китте. Малайлар аны бөтенесе төрле яклап килеп тоттылар.

– Ышанабыз, ышанабыз, сөйлә генә! – диештеләр ялварып.

Сөйләүдән болай да көч-хәл белән генә тыелып торган Тургай тегеләрне юри үртәде. Йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыгарып, авырыксынып кына туктаган булды, уйга баткан кыяфәттә һавадагы болытларга карап торды. Бер үк вакытта әбисе дога укыгандагы кебек итеп, авыз эченнән «Лә иләһә илләллаһ» дигән сүзләрне кабатлады, ике мәртәбә башын иеп куйды. Малайлар, аның һәр хәрәкәтен йотып, Нух маңгае янындагы таш багана шикелле торататш каттылар. Өсләрендә очып йөргән чебен-черкине куу да онытылды.

– Мин Нухның каршына бастым да: «Исәнме, Нух бабай», — дидем. Син чакырдың – мин килдем, дидем. – Тургай сүзен бүлеп уйланып торды. – Нух селкенеп тә карамады. Сез ул маңгайның олылыгын күрсәгез! Астан караганда, аның яртысын урман каплап тора бит. Ул безнең ындыр табыннан да олырак.

– Ай-яй-яй! – диеште малайлар.

– Шуннан соң мин беләсезме нишләдем?

– Нишләдең?

– Әйт инде тизрәк: нишләдең?!

– «Әллә син авырыйсыңмы?» дип менә шушы кулымны аның маңгаена китереп салдым! – Тургай малайларның һәрберсенең йөзен карап чыкты. Берсенең дә рәте калмаган, күзләре урыныннан купкан, борын тишекләре киңәйгән. Ул дәвам итте: – Аның маңгае ут кебек кайнар иде. Кулым пешеп маңгаена ябышканчы алып кына калдым. Аннары гел сыпырып тордым. Кулым менә әле хәзер дә кызарып тора.

Ул кулын малайларга сузды, тегеләр учын капшый-капшый карадылар. Учы ташларга тотынып менә торгач, пешкән төсле булып кызарган, сыдырылган иде. Малайлар аның һаман сөйләвен сорадылар. Тургай сүзен дәвам итте:

– Нух дәшмәсә дә, кешенең уен белә, диләр бит. «Син миңа көч бир, мине үстер», дидем. Шунда зәһәр итеп сызгырган тавышка борылып карасам, бер нәмә шуышып минем өскә килә. – Тургай шушында туктарга кирәген чамалады.

– Йә инде, йә? Туктама, сөйлә! – дип өзгәләнде малайлар.

– Карасам – сап-сары елан! Башы сарык башы кадәр! Озынлыгы... озынлыгы... безнең турдан Фаилләр турына кадәр бар.

– Әнәче! Уһу-у-у! – дип гаҗәпләнде малайлар.

– Телен авызыннан менә болай итеп туктаусыз чыгара! – Тургай телен еш-

еш чыгарып күрсәтте. – Елан акрын гына Нухның маңгаена шуышып менде. Күзләренең куркынычлыгы! Гәүдәсе балык төсле, үзе чуп-чуар. Шул чак маңгайның бер ягында йомры тишек күреп алдым. Елан шунда керде дә китте. Бу – Нухны саклаучы елан икән. Соңыннан белдем. Нух миңа шунда беренче ярдәмен күрсәтте.

– Нинди ярдәм? – дип сорады Фаил.

– Хәлил бабайга үлән җыясым бар иде. Аның әйләнә-тирәсе гел таш кына. Шунда артыма борылып карасам, таш арасыннан җир чыккан, ул җирдә шул үлән. Менә пакет тулганчы җыйдым.

Малайлар пакетны кулдан кулга йөрттеләр, үләнен тотып та, иснәп тә карадылар.

– Еланнан курыкмадыңмы? – дип сорады Зөлфәт, шикле карашын төбәп.

– Курыкмассың сиңа! – диде Тургай. – Маңгай астындагы чишмәгә төшкәч, шундагы таш астыннан тагын килеп чыкты. Чыкты да, «тизрәк тай моннан!» ди.

– Кеше сыман сөйләшәмени? – дип сорады Рөстәм.

– Әйе. «Р» дип кенә әйтә алмый.

– Шуның арттырганына ышанып тормагыз инде! – диде Фаил үпкәләгән тавыш белән.

Тургай бөтен җирне яңгыратып көлеп җибәрде.

– Кеше сыман сөйләшми инде! – диде ул.– Телен менә болай итеп авызыннан чыгара да кертә, чыгара да кертә. Шуннан аңладым «тай моннан» дигәнен. »Көч бир, шуннан соң китәрмен», дидем. Бу миңа шуышып килде дә аяктан өскә таба уралырга тотынды. Чагып үтерә хәзер, дип котым алынды. Аякны урагач, качып та булмый. Урала-урала менде дә башка ниндидер салкын әйбер тамызды. Менә шушы төшкә. – Тургай кулы белән баш түбәсен тотып күрсәтте. – Елан төшеп киткәч, кулны тигереп караган идем, тамызган урында бармак сыярлык тишек. Нух маңгаендагы тишек төсле.

– Күренми бит! – дип кычкырды Рөстәм үрелеп карап.

Тургай аны ишетмәмешкә салынып сүзен дәвам итте:

– Бер яфракны чишмә суында чайкап бөтердем дә, бөке итеп тыктым теге тишеккә.

– Кайда соң ул? – дип малайлар аның баш түбәсен тотып-тотып карадылар. – Юк бит!

– Мин үзем дә шаккаттым, – диде Тургай. – Тауның астына җиткәндә тотып карасам, эзе дә калмаган. Еланның сихере инде бу. Көчем дә артты.

Малайлар ышанырга да, ышанмаска да белмичә торганда, Тургай сызгыра-сызгыра кайту ягына атлады...

– Тагын сөйлә инде, – дип ялындылар малайлар

– Тагынмы? Аннары чыпчык хәтле кигәвеннәр сырып алды. Әнә тезләрне күрәсезме? Умырып-умырып тешлиләр. Ярый астан каен ботагы тотып менгән идем. Шуның белән куып таратмасам, үтерәләр иде. Әле чишмәне әйтергә онытып торам икән бит. Чишмәнең суы шыр бал. Кушучлап туйганчы эчтем. Оҗмахтагы чишмәләр дә ширбәт була ди бит. Бервакыт авызымны бал кортлары сырып алмасынмы?! Авызга кергән берен төкереп ташлыйм, иреннәрдән кул белән сыпырып төшерәм менә шушылай итеп. Ярый берсе дә чакмады, Нух чакмаска кушкандыр, безнең кортлар булса, иреннәр хәзер ияккә кадәр асылынып төшә иде шешеп.

## Кояшлы җыр

Тургай иң кирәклесен сөйләмичә калдырган кебек тоелды. Шуңа күрә:

– Мин анда җырладым да бит әле, – диде.

– Ничек җырладың?

– Нух маңгае кырына баскан идем. Шунда җырлыйсым килде. Ике кулымны һавага күтәрдем дә җырлап җибәрдем:

Саумысез, болыннар, басулар,
Урманнар, елгалар, күлләрем!
Каршыма килдегез, көлдегез,
Булдыгыз күңелем гөлләре!

Тургай сүзләрен хәтерләсә дә, теге көйне онытKан иде. Бусы әллә нинди бормалы-бормалы көй иде. Бу көйдә Нух янында җырлаган көй дә бар, яңа моңнар да кушылган иде.

Тургайның җырлавын малайларның беренче ишетүе иде. Алар сихерләнгәндәй телсез-өнсез булып калдылар, Тургайга әллә нинди әүлиягә караган сыман карап тордылар. Иптәшләре аның көченә тәмам ышандылар. Мондый җырны көчсез кеше җырлый алмый, аңардан таралган дулкын һәркайсын бөтереп алган иде. Малайларның күңелендә тыелгысыз булып бер сорау уянды һәм аны Фаил телен көчкә әйләндереп әйтеп бирде:

– Тургай... Тургай... Син бу җырны каян откан идең?

– Отмадым, – диде Тургай һәм күкрәген шапылдатып күрсәтте: – Менә моннан кояш белән чыкты.

– Ни сөйлисең? – диде Мансур. – Кояш бит ул күктә.

– Күктә генә түгел шул! Аның күбесе бездә! – диде Тургай, малайларны тагын да ныграк аптыратып. – Кич яткач, керфек араларыгыздан кереп, кояшның бергә йоклаганын сизмисез әллә?

– Юкны сөйләмә, кич кояш байый, – диде Фаил.

– Кояш ничек баесын, – диде Тургай аны үртәп. – Синең әтиең сыман әйбер сатып йөрсә, баер иде дә. Кояш ул безнең белән йоклый.

– Ул бит басу артына төшеп китә, – диде Рөстәм.

– Анысы аның гәүдәсе генә. Җаны безгә керә.

– Ни соң ул җан? – дип сорады Риф.

– Тәннең җылысы. Нуры кая төшә – шунда җан калдыра.

Тургай кызу-кызу атлап кызгылт тукранбашларның, зәңгәр, сары, ак, алсу чәчәкләрнең иң куе булып үскән җиренә килде. Малайлар аңардан бер тотам да калмадылар.

– Менә болар үзләре дә бәләкәй кояшлар, – диде Тургай, ике кулы белән чәчәкләрне сыпырып. – Кояш аларга да кереп ята сиздерми генә. Агачларга, бөҗәкләргә, кошларга, җәнлекләргә дә кереп ята. Иртән әтәчләр кычкырып, җилләр исеп уяткач, сиздермичә генә китеп, теге түгәрәк гәүдәсенә кайта...

Малайлар аны аңларга тырышып бик зур игътибар белән тыңладылар. Аларның үзләренең дә Тургай кебек җырлыйсы килә иде. Шуңа күрә ялынырга тотындылар:

– Әйдә, безне дә өйрәт инде!

– Өйрәтәм, – диде Тургай шатланып.– Кулларыгызны югары күтәреп, миңа иярегез. Күзләрегезне безнең каршыдагы чәчәкләргә, агачларга, болыннарга, басуларга, авылларга төбәп дәшегез:

Саумысез, болыннар, басулар,
Урманнар, елгалар, күлләрем!

Барысы да җырның шушы өлешен туктаусыз кабатладылар. Алар сихерләнделәр, аларга чиксез рәхәт иде. Күзләре очкынланды, битләре алланды, сулышлары киңәйде. Бусын өйрәнеп бетергәч, Тургай дәвамын сузды:

Малайлар өчен шушы җырдан башка нәрсә калмады. Гүя аларның пакъ күңелләренә җырлап торучы табигать үзенең бөтен бизәкләре, төсләре, исләре белән язгы ташкын булып кереп тулды. Берни уйларга да, тырышырга да кирәкми, шул ташкынга ияргергә генә кирәк иде...

Әз генә эчтәрәк алтын чәчәкләргә күмелеп, ялгыз юкә үсеп утыра иде. Рөстәм чум-чум атлап, сикергәли-сикергәли шул юкәгә таба китте. Бөтенесе дәррәү аның артыннан атладылар, аңа ияреп, юкә тирәсендә әйләнергә керештеләр. Барысы да әле генә өйрәнгән җырны җырлый, барысы да көлә, сикергәли. Алар белән бергә зәңгәр күк гөмбәзе, андагы өем-өем ак болытлар да әйләнә.

– Әнә кояш та безгә ияргә, әле бер яктан, әле икенче яктан карый! – диде Тургай, юкә чәчәкләренә сикерә-сикерә үрелеп. Чыннан да кызу-кызу әйләнгәндә, кояш күпереп торган алтынсу юкә чәчәкләре арасыннан бер күренә, бер югала, әйтерсең лә ул качышлы уйный иде.

Кайда соң бу, кайда соң бу
Гүзәл җирләрнең чите?
Ак болытларга утырып,
Уйларым шунда китте!..

Малайларны җыр канатлары күтәрә, алар табаннарының җиргә басканын да тоймыйлар. Шундый рәхәт, дөнья шундый якты, моны аңлатып бетерү мөмкин түгел иде. Алар шушы җырның өзелмәс моңы кебек — берсе икенчесенең дәвамы, аларны аерып алу мөмкин түгел иде. Аларга бу дөнья тулаем буйсынган, бу җир, бу күк йөзе, бу кояш аларныкы, аларга башка берни дә кирәкми иде. Алар кеше гомерендә бик аз гына була торган бәхетле мизгелләрнең иң татлысын кичерәләр иде. Аларның гөнаһсыз сабыйлыктан балачакка атлаган мәлдәге иң гүзәл көне иде. Бу көн аларның күңелләрен һәрчак җылытачак, хәтерләреннән мәңге җуелмаячак нурлы көн иде...

## Беренче көн

Тургай йокларга ятар алдыннан уку әсбапларын тагын бер мәртәбә карап утырды. Китапларның рәсемнәре шундый матур, исләре тәмле. Дәфтәрләр, төсле карандашлар, ручкалар, кечкенә тартмада буяулар, бозгыч белән линейка... Аларны сумкасына салып, утны сүндереп яткач та, бөтенесе күз алдында биеште, кыштырдаган, шылтыраган тавышлары колагын иркәләде. Их, тизрәк укырга-язарга өйрәнергә дә, әллә ниләр белергә иде! Әле төн бар, кояш кайчан чыгар да, кайчан мәктәпкә барырлар, кайчан иптәш малайлар белән очрашырлар. Йокысы һаман килми. Ул шулай качып йөри дә, сиздерми генә килә дә йоклата. Тургай күзләрен йомды, әбисе өйрәткән доганы укуга, оеп киткәнен сизми дә калды.

– Улым Ислам! Тор инде...

Шулай ягымлы итеп аның әнисе генә дәшә ала. Әнисенең йомшак тавышына иркәләнеп, кояш нурларының керфек арасыннан кереп шаяруларына изрәп ята бирде Тургай. Тагын бер генә дәшсә, сикереп торачак ул. Әнисе иелеп колагына ук пышылдады:

– Улым, мәктәпкә барасыңны онытмадыңмы?

Аның җылы сулышы, колак яфрагыннан бөтен тәненә таралып, аякларына кадәр төшеп китте. Тургай күзләрен ачар-ачмас елмаеп, әнисен муеныннан кочаклады һәм аны битеннән үбеп алды.

– И, минем җылы кояшым! – диде әнисе җыр кебек моңлы итеп.

Тургайга шундый рәхәт! Аңа әллә нинди көч иңде, йокысы качты. Сикереп тә торды, әбисе җим салып куйган полиэтилен букчаны алып ишегалдына

чыкты. Гадәттәгечә, иң элек Акбайны ычкындырып, капкадан чыгарып җибәрде. Тавыкларга җим салганда, Баһадирның каршына чүгәләп:

– Мин бүген мәктәпкә барам, апай! – диде, аның кикригенә кагылып алды.

Әтәч, аның сүзләрен хуплагандай, «кы-кы» килде дә «Кик-ри-и-кү-үк!» дип кычкырып җибәрде, канатларын җилпеп куйды. Аннары Тургай абзарга керде, бозауга ике телем ипи ашатты. Бозау аның кулын кытыршы теле белән ялый-ялый капкага кадәр ияреп килде. Чабулап кайтып кергән Акбайга ризык салганда, әнисе чыгып, бакчадагы иң матур чәчкәләрдән ике букет ясадылар. Юынып ашауга, әнисе, әбисе белән бабасы кайсы күлмәк, кайсы чалбар, кайсы костюм тотып, аны киендерергә керештеләр. Сумкасын алган иде, әнисе урынына куйдырды.

– Беренче көнне китап-дәфтәрләрсез генә барабыз, – диде ул.

Аннары әбисе белән бабасы капка төбендә кул болгап озатып калды. Тургай йөгереп әнисен уза да, аңа йөзе белән борылып, арты белән бара башлады.

– Егылырсың, алдыңа карап бар, улым, – диде әнисе.

– Егылмыйм, сине күреп барасым килә, – диде Тургай.

Мәктәп алды халык белән тулган. Матур итеп киенгән кызлар, малайлар арасында бәләкәйләре дә, олылары да бар. Алар килеп җитүгә, чем-кара чәчле, ап-ак түгәрәк йөзле бер апа:

– Беренче сыйныфлар, бирегә килегез, – дип иң бәләкәйләрне бер урынга җыйды.

Рөстәм, Фаил, Мансур, Риф белән янәшә баскач, тагын да күңелле булып китте. Шунда ул үзләреннәнерактарак абыйсы Шүкә янында басып торган Зөлфәтне күреп алды. Зөлфәт турсайган, каш астыннан гына карап тора. Аны яше җитмәгәнлектән укырга алмаганнарын Тургай белә иде инде. Белмәс иде, берничә көн элек елап аларның өенә килде. «Син алырлар дигән идең, алдагансың. Әти дә барып карады, алмаганнар», дип авызын бүлтәйтте. Бармагыңны артык озак суырдың бит, дигән булды Тургай ни әйтергә белмичә. Киләсе елга алырлар, бармагыңны кабат суыра башламасаң.

Кинәт музыка яңгырады. Мәктәп алдындагы мәйданчыкка Шүрәле, Убырлы карчык, бүре, куян, төлке, тагын әллә нинди җәнлекләр булып киенгән балалар чыгып биергә, җырларга тотындылар. Тургай аларның: «Без дә мәктәпкә барабыз, укыйбыз да язабыз!» дигән сүзләрен генә исендә калдырды. Тагын әллә ниләр кыландылар, Шүрәле Убырлы карчыкны бик кызык итеп куып йөрде. Аларның уены беткәч, район үзәгеннән килгән ап-ак чәчле, ак костюмлы абыйга сүз бирделәр. Ул беренче сентябрь – Белем көне белән котлады, тагын бик күп нәрсәләр сөйләде, тырышып укыгыз, диде. Аннары мәктәп директоры Илдар Каюмович сөйли башлады. Шунда Тургайның йомшак җирен кемдер бик каты чеметеп алды. Борылып карасаЗөлфәт! Менә-менә елап җибәрер төсле иреннәре бер җәелә, бер җыела, күзләренә мөлдерәп яшь тулган, үзе мыш-мыш килә. Тургай аны тартып китерде дә иңбашына кулын салды.

— Тәки алмаслар микәнни? – диде Зөлфәт, мөлдерәп торган зәңгәр күзләрен аңа төбәп.

— Тавышланма! — дип, Тургай аның авызын каплады.

Шунда Зөлфәт аның учын баш бармагы тирәсеннән тешләп алды. Тургай авыртудан кычкырып җибәрде, Зөлфәт юк булды. Ярый әле директор сөйләгәнгә халык шаулатып кул чаба иде, аның кычкырып җибәргәнен ишетмәделәр. Тагын нindидер апалар, абыйлар сөйләде. Тургайга аларның сүзләре кызык тоелмады, ул тезелешеп баскан малайларны, кызларны күзәтте. Бөтенесе матур итеп киенгәннәр, олырак кызларның алкалары, муенсалары да күренә. Күбесе белән бергә уйнаган, җәй көне су коенган, җиләк җыйган, әрәмәгә шомырт, бөрлегән, камырлык, балан җыярга барган, кыш көне боз өстендә кәшәкә суккан, таудан

чаңгыда, чанада шуган малайларны-кызларны хәзер танымалы түгел. Чәчләре матур булып күпереп тора, үзләре шундый җитди кыяфәт белән басып торалар. Каникул чорында эшләгәннәренә бүләкләр дә бирделәр. Олырак укучылардан бер төркем җырлый башлауга, теге матур апа иелеп:

– Хәзер сезне мәктәпкә кабул итү булачак. Барыгыз да минем арттан иярегез, – диде.

Аннары бер кызның колагына нидер пышылдады да:

– Арагызда шигырь сөйләүчеләр бармы? – дип сорады.

– Әнә ул нинди шигырь кирәк – барысын да сөйли, – дип Мансур Тургайга күрсәтте.

– Алайса Алсу сүз әйткәч, син бер шигырь сөйләрсең, яме? – диде матур апа.

– Ярар, – диде Тургай елмаеп.

Озакламый аларны чакырдылар. Барысы да мәктәп баскычыннан күтәрелеп, шунда басып торган укытучы апаларга, абыйларга чәчәкләрен бирделәр дә бер якка тезелеп бастылар. Алсу дигән кыз үтә нечкә тавыш белән тырышып укырбыз, мәктәп тәртипләрен үтәрбез, дип сөйләде. Шуннан соң, хәзер беренче сыйныф укучысы Ислам Нуруллинга сүз бирелә, диделәр. Тургай чыгып баскач, хәйран калды. Бу кадәр халыкны аның сабантуйда гына күргәне бар иде. Бөтенесе таныш, исемнәре белән эндәшәсе килеп китте хәтта. Эндәшмәде, сузмыйча гына бер көлеп алган иде, бөтенесе аңа ияреп көләргә тотынды. Шигыреңне сөйлә инде, дип пышылдады кемдер арттан.. Ул куллары белән чатый-ботый хәрәкәтләр ясый-ясый сөйләп китте:

Чакта, чакта.
Мин яшь чакта,
Әти унөчтә,
Үзем унбиштә чакта,
Әби ишектә,
Бабай бишектә чакта,
Бардык борчакка,
Төядек корсакка,
Килеп чыкты Якуб,
Без калдык ятып.
Килеп чыкты Йосып,
Калдык буразнага посып.
Килеп чыкты Барый,
Кармалый да кармалый!

Тургай шушы урында кулларын, бармакларын кармалаган шикелле әллә ниләр кыландырды һәм озын итеп сузып көлеп җибәрде. Аның гөлдерәп көлүе һәркемгә кытыклагандай тәэсир итте һәм бердәм көлү дулкыны таралды.

Бөтенесе көлә-көлә шаулатып кул чапты. Районнан килгән ак чәчле абый көлә торгач бөгелепләр төште, кесәсеннән кулъяулыгын алып, күзләрен, авыз-борыннарын сөртте. Тургайга бик рәхәт булып китте. Бөтенесе кашларын җыерып интегеп торалар иде, хәзер йөзләренә елмаю җәелде. Сөйләүләр, чыгышлар беткәч, беренче сыйныфларны мәктәпкә керергә чакырып, зур кыңгырау шалтыраттылар. Теге матур апа аларны ияртеп мәктәп эченә алып керде. Монда салкынча икән. Коридорлар киң, түшәмнәре шундый биек, тәрәзәләр үтә дә олы, якты. Сөйләшкән сүзләр дә, аяк белән идәнгә баскан тавыш та әллә кая яңгырап ишетелә. Тәмле булып буяу исе килә. Икенче катка менә торган баскычларның култыксалары ялык-йолык килеп тора. Менә алар үзләре укыячак бүлмәгә керделәр. Укытучы апа малайларны кызлар белән парлап утыртты. Тургай белән Фәйрүзә исемле кыз

утырды. Коңгырт чәчле бу кыз бик басынкы иде. Чана шуганда да, яз көне тау башы ачылгач, бергәләшеп уйнаган чакларда да, инештә су коенганда да Фәйрүзәнең көлгәнен, кычкырганын бик сирәк ишетәсең.

Матур апа өстәл артына утыргач:

– Мин сезнең сыйныф җитәкчегез булам, миңа Әлфия апа дип дәшәрсез, – диде.

Шулчак әнисенә әйтәсе сүзе исенә төшеп, Тургай торды да ишеккә таба атлады. Укытучының:

– Кая барасың? Кире борыл әле! – дигән тавышы аны аякларына китереп суккан кебек, туктап калырга мәҗбүр итте.

– Кая барасың? – диде аның янына килеп җиткән Әлфия апа. Аның йөзе дә, тавышы да кырыс иде бу мизгелдә.

– Әнигә әйтәсе сүзем онытылган, – диде Тургай.

– Дәрес вакытында беркая да барырга ярамый, – диде Әлфия апа. – Кул күтәреп миннән рөхсәт сорарга кирәк.

Тургайны ул кулыннан тотып алып килеп, урынына утыртты. Тургай бөтенләй аптырашка калды. Мәктәптә берни эшләргә ярамый икән ич.

Әлфия апа өстәлдәге журналны ачты.

– Кемнең исем-фамилиясен әйтәм – шул «мин» дип басарга тиеш, – диде дә укып китте:

Афзалов Рөстәм.

– Мин! – дип Рөстәм торып басты.

– Утыр, – диде Әлфия апа. – Бакыев Риф.

Риф тә нәкъ шулай басып урынына утыргач, укытучы:

– Баязитов Фаил, – дип башын күтәрүгә, Фаил акрын гына торып басты.

Ул елык-елык килеп торган кап-кара костюмнан, ак күлмәктән, куе зәңгәр галстуктан иде. Шактый торгач кына:

– Мин,– дип куйды.

– Бүсмән, – дип өстәде Мансур.

Әлфия апаларының кисәтүле тавышы көлүне туктатты:

– Ни дигән сүз ул Бүсмән?

– Мин ул, – диде Фаил.

Малайлар, кызлар тагын җиңелчә генә көлеп куйдылар. Укытучы апаларының шушыны да белмәве һәм белергә тырышып төпченүе кызык иде.

– Син бит Фаил.

– Безнең кушамат шундый. Әтинеке дә, минеке дә.

Нишләптер бүлмәдә шау-шу башланды. Әлфия апалары кулындагы ручкасы белән өстәлгә шакы-шокы бәрүгә, бөтенесе дә тынып калды.

– Ярый, утыр, Баязитов, – диде Әлфия апа. – Бер-берегезгә кушамат такмагыз, балалар. Бу – бер-берегезне кимсетү була. Аңладыгызмы?

– Аңлавын аңладык та, Бүсмән шәбрәк, – дип куйды Риф.

– Безнең авылда дүрт Фаил бар, – диде Бүсмән басып. – Берсе — «чәй корты» Фаил, икенчесе — кораңгыш, өченчесе – тискәре Фаил.

Аның бу сүзләренә бүлмәдәгеләр тагын көлү белән җавап бирделәр.

– Синең фамилияң ничек әле? – дип сорады Әлфия апа Тургайдан.

– Нуруллин Тургай.

– Нинди Тургай ул тагын? Нуруллин Ислам дип язылган журналга.

– Мин инде ул, апа. Кушамат Тургай минем.

– Кушамат таккач кыендыр бит?

– Кыен түгел. Мин бит тургай булып сайрый беләм.

– Сайрыйсың?!

Малайлар аның каз булып та, үрдәк, күркә, кәҗә булып кычкыруын да бер-

берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләргә керешкәннәр иде, укытучы тагын ручкасын өстәлгә шакылдатып, аларны туктатты. Шул тынлыктан файдаланып, Тургай:

– Апа, тургай булып сайрап күрсәтимме соң? – дип сорады.

Әлфия апалары ышаныргамы-ышанмаскамы дигәндәй, көлемсерәп карап торды да:

– Әйдә, сайрап күрсәт әле, – диде.

Тургай алга чыгып басты да үзенчә сайрап җибәрде.

– Чүр-р-р! Чү-ү-үрр! Фи-фю, фиюн! Һөрр-һөрр! Фырр! Фүрр-фүрр!

Үзе шул арада ботларына куллары белән шапы-шопы сукты. Барысы да елмаешып аңа карап тордылар.

– Каян өйрәндең? – дип сорады укытучы, исемлек барлавын онытып.

– Әти белән яз көне басуга барам мин. Шунда өйрәндем. Мин бозау булып та кычкыра беләм, апа.

Тургай ике учын кара-каршы куеп куыш ясады да авызына китерде һәм:

– Өмм-мү-ү-ү! Өмм-мү-ү-ү! – дип сузып җибәрде.

Учлары арасыннан кысылып яңгыраган тавыш бозауныкыннан аерырлык түгел иде. Ул икенче мәртәбәсенә кычкырганда,мәктәпнең беренче катындагыларга кушылып, икенче катындагылар да көләләр иде инде.

Шунда ишек ачылып китте, директорның пеләш башы күренде.

– Сез нишлисез, Әлфия Замановна?! – диде ул гаҗәпләнүле тавыш белән.

– Кошлар, хайваннар телен өйрәнәбез, Илдар Каюмович, – диде укытучы.

Директор иңбашларын сикертте дә ишекне япты. Исемлек тикшереп бетергәч, Әлфия апалары мәктәптә уку тәртипләрен аңлатты. Иртәгәдән алмаш аяк киемнәре алып киләсез, диде. Кыңгырау шалтырау белән кереп утырасы, укытучы кушканнарны төгәл үтисе, берәр нәрсә сорыйсың булса, кул күтәреп кенә мөрәҗәгать итәсе икән. Дәрес вакытында сөйләшергә, тавышланырга, урыныңнан кузгалырга ярамый. Сәгатьләр буе болай утыру Тургайның башына барып җитә алмады. Ничек түзмәк кирәк моңа?! Әйтәм җирле әбисе укуны энә белән кое казу, ди. Нишләп алай әйтә микән дип, Тургай иң зур энәне алып чыгып җирне казымакчы булып та караган иде былтыр җәй. Казырсың, казымый ни! Борчак сыярлык тишек тә ясый алмады. Уку чыннан да шулай булып чыгарга охшап тора бит әле.

– Хәзер өйләрегезгә кайтасыз, – диде Әлфия апалары, һәрберсен күздән кичереп. – Иртән сумкагызга китап-дәфтәрләрегезне, ручка-карандашларыгызны салып киләсез. Укулар сәгать сигездә башлана. Соңга калырга ярамый. Әле звонок булмады. Шуңа күрә шаулашмый гына чыгабыз…

Әлфия апалары, аларны коридор аша алып барып, ишектән чыгарып җибәрде. Сүз берләшкәндәй, малайлар бөтенесе берьюлы капкага йөгерделәр. Кызлар килгәнче, Фаил капканы урам яклап җилкәсе белән терәде. Алар күпме генә этсәләр дә, Фаилне кузгата алмадылар.

– Йә, интектермә инде кызларны, – диде Тургай, Фаилгә якынлашып.

– Кул күтәреп сорасагыз, чыгарам, – диде Фаил, көлә-көлә.

– Син укытучымы әллә кул күтәртергә, Бүсмән тәре! – диде Риф, аның бүксәсенә учы белән шапылдатып.

– Күтәрмәгез, кызлар, – диде Тургай.

– Чыгарыгыз инде, малайлар! – дип ялынды кызлар.

– Фаил абый, капканы ач инде, без сиңа тәмле шоколад бирәбез, дисәгез, ачам.

– Карале, кызлар хакына тамак туйдырмакчы буласың икән син! – диде Тургай, көлеп. – Теге кулыннан тот әле, Риф!

Тургай шулай диде дә Фаилнең уң беләгеннән тотып алды. Риф сул кулын эләктерде. Алар икәүләп аны читкә тартуга, кызлар капкадан атылып чыктылар. Алсу Фаилнең җилкәсенә сап-сары чаган яфрагы чәпәде дә:

– Менә сиңа безнең шоколад, – диде.

Кызлар көлешә-көлешә йөгерделәр.

– Нигә катыштыгыз инде, – диде Фаил үпкәләгәндәй. – Мин аларны кул күтәртеп сората идем бит.

– Ичмасам урамга чыккач оныт инде кул күтәрүне! – диде Риф усал итеп. – Хәлнең мөшкел икәнен күрәсезме сез?

– Ни бар?

– Нишләп мөшкел? – диешеп малайлар аңа төбәлделәр.

– Мордага эләккәнегезне сизмәдегезмени?

Тургай кычкырып көлеп җибәрде.

– Нинди морда, нинди морда?! – диде ул Рифкә җиңелчә төрткәләп.

Риф кулларын селти-селти дәвам итте:

– Кыймшанырга ярамый, сүз әйтергә ярамый, бүлмәдә йөрергә ярамый, тышка чыгарга ярамый. Бөтенесенә кул күтәреп рөхсәт сорыйсы. Тургай, Бүсмән, Кытай дип әйтергә ярамый.

Фаил дә башын кашый-кашый сүзгә кушылды:

– Риф дөрес әйтә бит, малайлар, – диде ул. – Нишлибез?

– Ни кушалар, шуны эшлибез, – диде Рөстәм.

– Әгәр мәктәпкә бармасак? – диде Риф, һәрберсенең күзенә карап.

Сорау бик җитди иде, малайлар атлаудан туктадылар. Күзләр Тургайга төбәлде.

– Минем укырга өйрәнәсем килә, – диде Тургай. – Укыйк әле.

## Молодец, Нуруллин!

Капкадан чыгуга, Тургайның битенә пәрәвез җебе шаярып килеп кунды. Ул, урам уртасына чыгып, адымнарын кызулата, уңнан да, сулдан да елмаеп калучы тәрәзәләрнең кайсына тел шартлатып, кайсына кул изәп сәлам бирә. Аннары дәрестә Әлфия апалары өйрәткән җырны суза:

Ай былбылым, вай былбылым,
Кунып сайрый талларга.

Бераздан ул кызыл сумкасын аркасына аскан Алсуны куып җитә, аның колак яфрагын кытыклап:

– Нихәл, тишек борын? – ди.

– Ә синең ике колагың тишек, – ди Алсу, көлә-көлә.

Тургай, аңа йөзе белән борылып, каршыннан арты белән бара, үзе аны һаман үрти:

– Авызыңны шул кадәр ачма, чәүкә очып керә күрмәсен!

Алсу тагын да ныграк көлә, Тургайны урап китеп йөгерә башлый.

– Әле син миннән качасыңмы? – ди Тургай, юри ачулы тавыш чыгарып һәм аны куарга тотына.

Алсу урамның әле бер, әле икенче ягына чыга, Тургай аның үкчәсенә басып диярлек бара, сумкасыннан тотып туктата алса да, туктатмый, баһадирга охшатып, «Котырр! Котырр! Кыт! Кыт!» дигән тавышлар чыгара.

Тимерче Нурмый абыйлар турына җиткәч, Алсу абынып егылды һәм кычкырып еларга тотынды. Нурулла абыйлар койма буена таш кайтарганнар да шуның берсе йөри торган җиргә тәгәрәгән булган. Алсу тезен туктаусыз угалады, елавыннан туктамады. Аны ничек юатырга белмәгәч, Тургай ташка тибеп куйды да, аны тиргәргә кереште:

– Юньле булсаң, син кеше йөри торган җиргә килеп ятар идеңмени?

Кичә сыерны көтүдән алып кайтканда, мине дә чак кына абындырмадың бит син, оятсыз! Ник дәшмисең, дөресен әйткәч, әйтер сүзең юкмыни?! – шунда Алсу елавыннан туктап, Тургайга карап тора башлады. – Хәзер менә әтинең олы кувалдасын алып килеп, маңгаеңа берне тондырсам, танавыңнан суың чәчрәп чыгар! – Алсу көлеп җибәрде. Тургай ташка таба иелде. – Ә-ә, шөлләдеңме? Таш түгел, юләр баш син! Мыш-мыш килә, Алсу, тыңлап кара әле.

Алсу авызын ерган килеш җиргә таянып, колагын ташка якын китерде.

– Ишеттеңме?

– Ишеттем, – диде Алсу көлеп.

Тургай койма буеннан бака яфрагы өзеп, кулы белән тузанын сөртте, костюм җиңенә ышкып алды да:

– Шушы яфракны төкерекләп тезеңә ябыштыр, – диде.

– Ник?

– Авыртуны бетерә.

– Алдыйсың син, – диде Алсу, ышанмыйча.

– Алдамыйм. Әби минем бәрелгән урынга гел бака яфрагы ябыштыра. Кара янганны да, авыртканны да бетерә.

Аның бу сүзләреннән соң Алсу яфракны тезенә ябыштырып, өстеннән гольфасы белән бастыргач, алар мәктәпкә юнәлделәр.

Беренче дәресне Әлфия апалары кичә үткән «А» авазына мисаллар сораудан башлады. Барысы да кулларын күтәрделәр. Әлфия апалары беренче Алсудан әйттерде.

– Алма, – диде Алсу.

– Бу сүздә ничә «а» авазы бар? – дип сорады Әлфия апалары.

– Ике, – дип җавап бирде Алсу. – Беренчесе дә «а», соңгысы да «а».

Шуннан бер-бер артлы «абзар», «автомобиль», «урам», «табак», «кабак» кебек сүзләр яңгырады. Дәрес шулай әйбәт кенә барганда, Рөстәмне бастыргач, ул:

– Бакыев – бака! – дип куймасынмы.

Бөтенесе көләргә тотынды. Риф, рөхсәт тә сорап тормастан, сикереп торды да:

– «Кытай» дигәндә дә «а» авазы бар, – диде.

Тагын көлештеләр. Әлфия апалары, малайларның бер-берсен ни дип үртәүләрен белеп бетермәгәнгә, аларның ник көлгәнен аңламады. Инде үз мисалын әйтмәгән берничә генә кеше калган иде. Шунда Риф:

– Апа, мине гел бака дип үртиләр, безнең фамилия бакадан алынганмыни? – дип сорады.

– Бер-берегез белән үртәшергә ярамый, балалар, – диде Әлфия апалары. – Ә синең фамилияң бик зур мәгънәгә ия. Сезнең бабагыз Бакый исемле булган. Ә Бакый – ул мәңгелек дигән сүз.

Сыйныф тып-тын калды.

– Кайсыгыз аңлата ала мәңгелек дигән сүзне?

– Мин! – дип торып басты Мансур. Әлфия апалары рөхсәт иткәч. – Тузмаган әйберләрне мәңгелек диләр.

– Ык суы ул, апа, – дип өстәде Фаил. – Әти, Ык суы мәңгелек, ди.

– Тагын нинди фикерләр бар? – дип сорады Әлфия апалары.

Моңа кадәр икеләнебрәк торган Тургай, сүзгә кушылып:

– Ялкаулык ул! – дип ярып салды.

Барысы да дәррәү көлешеп куйдылар.

– Нишләп алай? – дип сорады Әлфия апалары.

– Бабай әйтә, ялкаулык кешенең җилкәсенә мәңгегә менеп атлана, ди. Ул безнең китап-дәфтәрләр тутырган сумка белән бергә утыра, ди. Тырышсаң, ялкаулык

җиңелә икән. Тырышмасаң, ул сине җиңә, мәктәптә дә «икеле»гә укыйсың, хәерчегә әйләнәсең, ди.

– Сезнең барыгызның да фикерләрендә дөреслек бар, – диде Әлфия апалары. – Мәңгелек нәрсәләр беркайчан да юкка чыкмый, – дип, кояш, күк белән җир мисалында бик күп кызыклы әйберләр сөйләргә кереште.

Тургай, тәрәзәгә борылып, апасы әйткән мәңгелек кояшка карады. Аның нурлары астында чыпчыклар агач ботакларының берсеннән икенчесенә фырр-фырр очалар…

– Нуруллин, син кайда утырасың?

Әлфия апаларының дәшүе аны уятып җибәргәндәй булды.

– И, апа, күрсәң анда!.. – диде Тургай дулкынланып. – Агач ботакларында чыпчыклар әбәкле уйный!

Аның бу сүзләреннән иптәшләре тагын көлеп куйды. Тургай Әлфия апалары туктатканчы әйтеп калырга ашыкты:

– Әнә берсе, калганнарын үртәп, иң өске ботакка кунды да чырык-чырык килә. Әнә башкаларын үрти…

Иптәшләре, парталарыннан торып, тәрәзәгә таба бара башлауга, Әлфия апалары аларны шып туктатты. Ләкин шунда инде тәрәзә янына ук килеп җиткән Риф кычкырып җибәрде:

– Апа, кара әле, бакчага тавыклар тулган! Кәбестәләрне чукыйлар! Калган помидорларны ашыйлар!

Аның бу сүзләре бөтенесен тәрәзәгә җыйды.

– Бакыев, Афзалов, барыгыз куып чыгарыгыз!

– И, апа, анда бакча таптап йөрелгә киләкми безгә! – дип каршы төште Рөстәм. – Тулгай алалга бел генә кычкыла!

Апалары кушарга өлгергәнче Тургай:

– Апа, чыгарыйммы? – диде дә, тәрәзәне ачып, бакчага сикерде. Ул үзләренең Баһадирына охшатып, ачулы тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Кыт-кыт-кыт-кы-ы-ыт! Кыту-урр! Кырр-кыт-кыт!!!

Бу тавышка тавыклар котлары алынып, оча-куна коймага таба йөгерделәр. Тургай тагын да дәһшәтлерәк итеп «Кыт-кыт-кытты-рру-у!» дип сузгач, тавыклар, канатларын җилпи-җилпи, бер-берсен таптап, коймага килеп өелделәр, аның астындагы тишектән кысыла-кысыла чыгып та беттеләр. Тишекне таш белән каплагач, Тургай тәрәзәгә йөгереп килгән иде, Әлфия апасы: «Ишектән кер», дип борып җибәрде. Тургай капкага йөгерде, ләкин ул тыштан бикле иде. Койма башына үрмәләүдән бүтән чара калмады. Җиргә сикереп төшүе булды, каршысына директорның килеп басуы булды.

– Бакчада нишләп йөрисең, Нуруллин? – диде директор бик усал карап.

Тургай коймадан шактый еракта йөрүче тавыкларга күрсәтеп:

– Әнә теге тавыкларны куып чыгардым, – диде.

– Ә кем керткән?

– Анысын тавыклар миңа әйтмәделәр, – диде Тургай юри җитди кыяфәт белән.

– Молодец, Нуруллин! Бу сүзең өчен «бишле» сиңа, – диде директор елмаеп. – Бар, дәресеңә кер.

Илдар Каюмович йөгереп мәктәпкә кереп баручы малайга караган килеш башын чайкап куйды. «Картаясың бугай, иптәш директор, – дип куйды эченнән. – Бу сабыйга андый сорау бирергә тиеш түгел идең бит син. Нуруллинга «бишле», ә сиңа дипломыңның почмагына «берле» куела. Диплом үз көчен югалтсын өчен ничә «берле» кирәк икән?» Пенсия яшенә якынлашып килүче Илдар Каюмович бу сорауга җавап таба алмады…

## Бака туе ясамагыз!..

Ул көнне Тургай мәктәптән бик җитди кыяфәттә кайтып керде. Сумкасын почмакка атты да бер сүз дәшмичә диванга барып чалкан ятты. Әти-әниләре чәй эчеп утыралар иде. Урамнан ук җырлый-җырлый кайтып керә торган Тургайның болай кыдануы өйдәгеләрне аптырашка төшерде.

– Улым, киемнәреңне алыштыр да ашарга утыр, – диде әнисе.

Тургай дәшмәде, ике кулын баш астына салып, уйга батты.

– Ни булды, улым? – дип сорады бабасы.

– Буласы булган инде...

– Бүген нәрсә үттегез соң? – диде әтисе аның янына килеп.

Тургай җавап бирмәскә ниятләгән иде дә, әтисе ачуланыр дип, әйтергә булды:

– Күп инде ул. «Ә» хәрефен өйрәндек. Математикадан азрак белән күбрәкне үттек. Агач рәсеме ясадык.

– Кызык булгандыр бит? – диде әтисе.

– Кызыгын кызык та. Анда бит...

– Нәрсә анда? – дип төпчende әтисе.

– Сез бит берни дә белмисез... Күрсәтимме соң?

– Әйдә, күрсәт, күрсәт, – диештеләр барысы да.

– Барыгыз да өстәл янына утырыгыз, – диде Тургай төп-төз басып. Ул башын югары тотып, әбисе белән бабасына, әтисе белән әнисенә аерым-аерым текәлеп карап алды. Кыяфәте коточкыч җитдигә әйләнде.

– Туры утырдык, Нуруллина, – диде ул имән бармагы белән әбисенә төзәп. – Нишләп бөкрәеп утырасың? Парта белән күкрәк арасында йодрык сыярлык ара калырга тиеш.

Ул, әбисе янына килеп, аның уң кулын тотып, өстәл белән күкрәге арасына куеп күрсәтүгә, бөтенесе тыела алмыйча көлеп җибәрделәр. Тургай үзенә ашарга дип әнисе куйган тимер кашыкны алып, өстәлгә бик җитди кыяфәттә шакы-шокы сугып алды.

– Балалар, – диде ул ялварулы тавыш белән. – Без бит дәрес вакытында көлешмәскә, мин сөйләгәнне тыңлап кына утырырга сөйләштек. Нуруллина, беренче булып син көлә башлыйсың! – дип Тургай кашыгын әнисенә таба сузды.

Шуны гына көткәндәй, әтисе хихылдап башын артка ташлады, бабасының авызындагы ясалма теше идәнгә очты. Тургай аны алып, бабасының алдына куеп, аңа кисәтү ясады:

– Нуруллин, ашау әсбапларыңны идәнгә коеп утырма!

Шулчак диванда йоклап яткан Шаян идәнгә сикереп төшеп, койрыгын күтәреп киерелде, башын өскә каратып, авызын зур ачып иснәде.

– Мияушин, иптәшләрең алдында шулай ямьсез итеп иснәргә ярыймы соң? – диде Тургай мәче янына килеп. Аннары тәрәзә төбеннән газеталар алып, һәрберсенең алдына куеп чыкты.

Дәфтәрләрне ачтык. Ручкаларны алдык. «А» хәрефен язабыз.

Ул, әнисе каршына килеп, аның алдындагы газета өстенә бармагын куйды.

– Нуруллина, хәрефләрең төрле якка авышкан. Менә бу юлга ашыкмыйча гына язып чык, – диде. – Яздыгызмы? Хәзер басабыз, гимнастика ясап алабыз. Кулларны өскә күтәрдек...

– Уф, йөрәгем, көлдереп үтерәсең, улым! – дип бабасы күкрәген тотты.

Әбисе үзе кеткелдәде, үзе эһ-эһ килде.

Әтисе:

– Җитте, бер хәлем дә калмады, – дип урыныннан торды.

– Үләм, үләм! – дип кулларын мәзәк итеп Тургайга таба чайкады әнисе.

– Бака туе ясамагыз, балалар! – диде Тургай кашыгы белән өстәл шыкылдатып.

Шулчак бабасының таягы шап итеп идәнгә ауды.

– Нуруллин, нинди таяк белән маташасың анда, – дигән булды Тургай, тагын да җитдирәк кыяфәткә кереп. – Нишләп аксыйсың син? Кайда йөрдең?

– Булды, булды, аңладык, улым, – диде әнисе, көлүеннән тыела алмыйча.

– Сезгә рәхәтме соң шушы? – диде Тургай, мәсьәләнең бөтен җитдилеген аңлатырга тырышып.

– Нигә рәхәт булмасын? – диде әтисе. – Белем алырга, тәртипле булырга барыбыз да шулай өйрәндек инде.

– Алайса нишләп көлдегез? – диде Тургай.

– Синең кебек рәхәт, бәхетле вакытларыбызны искә төшереп көлдек, – диде әтисе.

– Алайса үзем дә яшь чакларны искә төшерим әле! – диде дә Тургай, гөлдерәп көлеп җибәрде.

Тургай ашагач, ихатадагы барлык җан ияләре белән сөйләшкәннән соң, ындырга йөгерде. Анда туйганчы туп тибеп, кич кенә кайтып керде. Әбисе оекбаш бәйләп утыра иде.

– Әби, кемгә була ул? – дип сорады Тургай.

– Сиңа бу, улым, – диде әбисе. – Менә карлар явар, кыш килер. Шушы оекбашларны кигәч, аягың җылыда йөрер.

Тургай әбисен кысып кочаклады, битеннән үбеп алды. Аннары әбисенең битендәге җыерчыкларын бармак очлары белән йомшак кына сыпырды.

– И, әбием? Бөтен җирең ярылып беткән. Авыртмыймы алар?

– Ярылмаган ул, балакаем. Яши-яши җыерылган. Яшь чакта минем йөзләрем дә синеке кебек шоп-шома иде.

– Ә бабайның йөзендә бигрәк тә күп. Беләге әллә ничек ярылып киткән.

– Бабаң бит сугышта булган. Шунда беләген яралаганнар.

– Телевизорда күрсәткәндәге кебекме?

– Әйе.

– Ә кемнәр яралаган?

– Бабаңның үзеннән сора инде анысын, – диде әбисе.

Тургай аларның бүлмәсенә кереп китте дә шундук борылып та чыкты.

– Бабай «пуф-пуф» итеп йоклап ята, – диде ул. Әз генә уйланып торгач, әбисенә сорау бирде: – Нишләп икегез дә «пуф-пуф» итеп йоклыйсыз сез? Әти белән әни алай йокламый бит.

– Тешләр булмаганга ул, бәбекәем, – диде әбисе елмаеп.

Тургай үзе дә шулай түгел микән, дип уйлаган иде, ялгышмаган икән. Шунда иртәгә җыр дәресе керәсе исенә төште. Апалары «Кәрия-Зәкәрия»не ныклап өйрәнеп килегез, дигән иде бит. Ул йөгереп ишегалдына чыгып җырлый гына башлыйм дигәндә, кәбестә түтәлләре янында йөргән әтисе белән әнисен күрде. Тургай ачкан авызын йомарга мәҗбүр булды. Йә бүлдерерләр дип, мунчага керде дә бар көченә җырлап җибәрде:

Бу бик яхшы укучы, бу бик яхшы укучы,
Аның укуы яхшы, аннан үрнәк алыгыз,
Аның укуы яхшы, аннан үрнәк алыгыз.
Кәрия-Зәкәрия комая, Кәрия-Зәкәрия комая,
Кәри-кома-Зәкәрия, Зәкәрия-комая,
Кәри-кома-Зәкәрия, Зәкәрия-комая.

Ялгышмыйча җырларга өйрәнгәч кенә өйгә керде. Барысы да телевизор карап утыралар иде. Ул туп-туры бабасы каршына килеп:

– Бабай, сине сугышта яраладылармыни? – дип сорады.

– Әйе, улым, – диде бабасы.

– Кемнәр соң ул?

– Әшәке кешеләр. Бөтен җирне бомбага тоталар, яндыралар, кешеләрне үтерәләр.

– Син анда нишләдең?

– Без ярдәм итәргә бардык. Теге әшәке кешеләрне куып, сугышны туктаттык.

Телевизорда снарядлар шартлаганны, йортлар янганны, пулемётлардан атканны, егылып яткан кешеләрне күрсәтә башладылар.

– Сугышны бетердек, дигән идең бит, бабай, – дип Тургай телевизорга төртеп күрсәтте.

Бабасының күзләре яшьләнде, кулын күкрәгенә куйды. Йөрәге авыртканда шулай итә ул.

– Бусы – бүтән сугыш, улым, – диде ул авыр сулап. – Бер илнең әшәке кешеләре икенче илнаң байлыгын алмакчы була...

Тургай экрандагы сугыш күренешләрен карап, бераз уйланып торды да бабасына тагын сорау бирде:

– Ә ул ике илнең начальниклары сугышны ник туктатмый соң?

Аның бу сүзләреннән соң өйдәгеләр бер-берсенә карап баш чайкадылар. Ә әнисе Тургайны күкрәгенә кысып:

– И, улым, бу башларың белән син кем булырсың икән? – диде.

– Авылның бер дурагы булырмын!

– Син бик начар сүз әйттең бит, улым! – диде әтисе, бармагын кисәтүле селкеп.

– И, әти, кайчагында сез дә әни белән бер-берегезгә «дурак» дисез бит!

– Без шаярып кына әйтәбез.

– Мин дә шаярттым гына, – диде Тургай елмаеп. – Миңа исәре дә җиткән.

Әтисе белән әнисенең йөзләре үзгәрде, алар хәтта урыннарыннан сикереп тордылар.

– Анысын каян алдың тагын? – диде әтисе ачулы тавыш белән.

– Күрше Нурия апа гел шулай ди. Минем бакчада агачлар, кошлар белән сөйләшеп йөргәнемне күргән саен: «Булса да булыр икән исәр», дип үз-үзенә сөйләнә. Беркөн шулай сөйләнеп койма ярыгыннан карап тора иде, җирдән туфрак алдым да сиптем. Шуннан «дурак» ди башлады.

– Олы кешегә туфрак сибәргә ярыймыни?! – дип әтисе йодрыгын селкеп куйды.

– Олы кеше булгач, «исәр» димәсен.

– Күзенә керсә? – диде әтисе.

– Күзенә кермәде. Авызы ачык иде, авызына туры килде. «Тфү-тфү» дип төкеренә-төкеренә өенә кереп китте.

Кич җиткәч, Тургай бик озак йоклый алмыйча ятты. Бабасының сугышта йөргәннәрен уйлады, бабасы белән әтисе бая телевизорда күрсәткән сугышка китмәсә ярар иде, дип хафаланды. Инде йокысы куерганда ул әтисе белән әнисенең пышылдашканын ишетте.

– Менә синең күршегә каш сикертүләреңнең әҗере, – диде әнисе.

– Телең ни сөйләгәнне колагың ишетми, – диде әтисе төксе генә. – Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә.

– Мин сөйләмим, кешеләр сөйли, – дип әнисе сүзне бетерде.

Тургай аларның сөйләшүеннән берни дә аңламады. Тик нәрсәнеңдер әйбәт түгеллеген генә чамалады...

## Морда

Табигатьне өйрәнү дәресе бара. Әлфия апалары безнең тирә-юнебез, елгалар, таулар, үсемлекләр, җәнлекләр, авыллар, шәһәрләр турында сөйли. Кеше шуларның уртасында, ди. Тургайның укытучы сөйләгәнне тыңлыйсы килә, колаклары белән аның тавышын да ишетә, әмма әллә нинди бер көч сиздерми генә Бормалы буйларына алып китә, борынына дымлы үлән, ләм исләре килә, инеш аркылы ташлардан, агачлардан салынган басма өсләреннән челтерәп аккан су тавышы колагын иркәли. Инешнең салкынча суына иелеп кулларын тыгыйм, дип үзе дә сизмәстән парта астына сузыла һәм куллары Фәйрүзәнең тезенә тия. Фәйрүзә Тургайның кулын чеметеп ала, коңгырт күзләрен түгәрәкләндереп аңа карый. Чәрелдәп кычкырып җибәрмәгәч ярый инде. Тургай инеш суына кулымны тыга идем, дип аның колагына пышы-пышы килә. Фәйрүзә берни дә аңламый, ни көләргә, ни аның сүзләренә ышанырга белми. Әлфия апалары кисәтү ясагач, Фәйрүзә тау башындагы йомран төсле үрә катты, керфеге дә селкенми. Тургайның йомранга охшатып сызгырып җибәрәсе килә. Бик шәп сызгыра да сызгыруын. Ярамый шул. Их, йомран Фәйрүзә! Тауны искә төшердең бит син. Әле кайчан гына тау түбәсеннән аска таба мәтәлчек атып уйнаганнар иде. Уйнап хәлдән тайгач, болынга Галимҗан абыйсы янына киттеләр. Әрәмәгә кереп, кызыл карлыган, шомырт, камырлык ашадылар. Әрәмә буйлап сузылган төнбоеклы күлнең камышлары арасында кыркылдаучы кыр үрдәкләре белән дә сөйләшә алмыйлар хәзер. Чөнки көн дә мәктәпкә баралар, сәгатьләр буе менә шушылай беркая чыкмыйча утыралар, укырга, язарга, рәсем ясарга, җырларга өйрәнәләр. Үзе кызык та кебек, бик кыен да. Һәркем үзенчә түзә. Фәйрүзә озын көн буе гел тыңлап кына утыра, укытучы әйткәнне төп-төгәл үти, сүз катсаң да дәшми, хәтта борылып та карамый. Шулай өйрәнгән Фәйрүзә, мәктәптә дә нык түзә. Алсу да Фәйрүзә кебек тыныч, тәртипле. Рөстәм белән утыручы Энҗе менә кыбырсык ичмасам! Чем-кара чәчләре гел тузган, кашларына ук төшкән була. Үзе туктаусыз чыркылдый. Көлүе шулай. Чыркылдаган саен авызын кулы белән каплый. Үзе утырган урынында туктаусыз боргалана, як-ягында утыручыларның гына түгел, артындагыларның да китап-дәфтәрләрен, каләмнәрен карый. Үзенеке дә шундый ук югыйсә. Ни эзли – белмәссең. Аның һәрвакыт нәрсәсе дә булса идәнгә төшеп китә, ул шуны алырга йә парта астына кулын сузып озаклап кармалана, кайчакта парта астына ук төшеп китә. Инде тураеп кына утырды дисәң, тагын нәрсәсендер төшерә, тагын иелә. Фаил дәрес саен кул күтәреп тышка чыгарга сорый. Әллә чын, әллә юри. Рифне Әлфия апалары тактага чакырса, артыннан берәрсе «Ык буенда бакалар баталар да калкалар», дип пышылдап кала. Мансур Фатыйхов белән Лилия Латыйпова бергә утыра. Укытучы сөйләгәндә, Мансурның күзләре әз генә кысыла да, ул төп-төз утырган килеш оеп йоклап китә, ике борын тишегеннән «мес-мес» тавыш чыга башлый. Әлфия апалары «Фатыйхов!» дип дәшүгә, Мансур дерт итеп уянып китә. Бөтен сыйныф көлешеп ала. Фаил белән утыручы Айгөл Заһидуллина иртән көн саен диярлек соңга кала. Ул да йокымсырап киткәли, әмма Мансур кебек месләми. Йокымсырый башласа, Фаил аны колагына чиертеп уята. Арада барысыныкыннан да биек булып Рөстәмнең башы тора. Шул түп-түгәрәк күзлекле озынча башын ул бәбкәләре уртасындагы ата каз кебек туктаусыз боргалый. Янәшәсендә утыручы Энҗе белән икесе шулай бүлмәне вентилятор кебек «җилләтәләр». Тагын бер нәрсәне әйтми булмый: Рөстәмнең авызында төкерек күп. Шуңа ул теле белән иреннәрен гел төкерекләп тора. Берәр нәрсә сөйли башласа да, теленең ярты көче сүзгә тотынасы урында, ирен юешләүгә китә. Теле шул кадәр тиз йөри, авызыннан бер чыкканда өске иренен, икенче чыкканда аскы иренен ялт кына итә дә куя, күрми дә каласың. Кайчакларда Рөстәм дәрес барганда авызында бәләкәй генә

кәгазь кисәге чәйни дә, озын бармагы белән берәрсенә чирттереп җибәрә. Ул килеп тисә, бөтенесенә дә кызык була. Берсендә математика дәресендә Әлфия апалары тактага саннар язганда, ялгыш аның аркасына барды да тиде. Бөтенесе тын алудан туктады, Рөстәмгә ачулы караш ташладылар. Рөстәм үзе дә кып-кызыл булды. Аларның бәхетенә кәгазь үзе кубып төште һәм барысы да җиңел сулап куйдылар. Шуннан соң Рөстәм бу гадәтен ташлады.

Тургай үзе утырып та тора алмый, сөйләшмичә дә тора алмый. Әбисе «Улым, синең эчеңдә җен бардыр», дип юкка әйтми инде аңа. Шул җен ни тели, шуны эшләргә мәҗбүр итә. Тактага чыкса, басып торган җирендә таптанырга тотына, әле уңга, әле сулга атлап ала.

– Нуруллин, болганмыйча гына, болганмыйча гына! – дип кисәтә аны укытучы.

Дәрес вакытында, берәрсе янына барып, колагына нидер әйтеп көлдермәсә, утыруы утыру булмый. Ә апалары карап кына тора, кайчакта үзе җитәкләп алып килеп урынына утырта. Фәйрүзәгә дәшеп-дәшеп карый, ә ул чәтнәби – башын юри читкә бора, Тургай сөйләшмичә тора алмый. Рөстәмнең теле иренен ялап рәхәтләнсә, Тургайның теленә шаяртып сөйләшү, малайлар белән үртәшү, көлешү, котыру кирәк. Ә болай авызын томалаган, кул-аягын бәйләгән кебек. Кыска гына тәнәфестә берни дә эшләп өлгерә алмыйсың. Сөйләшә, әйтә алмагач, башына да, теленә дә әллә нинди уйлар җыела да җыела, берсе өстенә икенчесе өелә, аларны иптәшләренә әйтәсе килә – ярамый! Әти-әниләренә, әби-бабаларына әйтә торганнары да бик күп тә, алар еракта шул… Тургай үзе дәфтәренә апалары кушкан «И» хәрефен яза-яза әлеге уйларын уйлый. Менә Әлфия апасы алгы партада утыручы Мансур белән Лилия янына килеп, дәфтәрләрен карарга тотынды, ничек матуррак язарга икәнен өйрәтә башлады. Лилия – алар арасында иң таза кыз. Чәчләре җирән, йон өеме төсле кабарып тора. Лилиянең сумкасында конфеттыр, шоколадтыр гел булып тора, дәфтәренә язганда шуларны суыра, чәйни. Ул таза, олы гәүдәсе аска нык басканлыктан, аяклары кыска булып калган.

Тургай акрын гына тәрәзә каршына барды. Күктә өере белән каргалар оча, җил агачларның сары яфраклары белән шаяра.

– Сезне бәйләп куймаганнар, – ди Тургай ярым пышылдап. – Сезгә түзәсе юк. Тышта гына укытсалар, ничек рәхәт буласы югыйсә…

Бакча уртасында ялгыз чия сап-сары яфракларга төренгән ботакларын болгап җил белән шаярып маташа. Җил аны танцыга чакыра, ул юри киреләнә. Кинәт ул гел Лилия булып тоела Тургайга. Әнә кәүсәсе дә нәкъ аның көрән гольфысын хәтерләтә. Әнә җилфердәп торган сары чәчләре уртасында нәрсәдер чәйнәп маташкан авызы да күренә, әнә авыз читеннән төшеп киткән печенье кисәге төсле бер яфрак та төшеп китте. Тургайның көләсе килә. Былтыр Тургай Лилиянең таудан менгәндә чанасын кызарынып-бүртенеп, тезләнә-тезләнә сөйрәвен күреп, аңа ярдәм итмәкче булган иде – киреләнде, чана бавын дырт итеп тартып алып читкә китте. Кушаматы да – Тискәре. Лилиягә барып, әнә син, дип әйтмәкче иде, Әлфия апасының: «Нуруллин!» дигәнен ишетеп, туктап калды.

– Нуруллин, сөйләшмә, урыныңа утыр, – диде Әлфия апалары.

Ул урынына барып утыруга, апалары алар партасына килеп, Тургайның дәфтәрен кулына алды.

– Нишләп болай яздың, Нуруллин? – диде ул бер урынга өелешкән «И» хәрефләренә бармагы белән күрсәтеп. – Әнә Фәйрүзәнең хәрефләре ничек тигез булып тезелгән.

– Минем хәзрефләрем җыелышып «очты-очты»лы уйныйлар бит, апа, – диде Тургай ихлас күңеленнән. – Ә Фәйрүзәнекеләр кайгырышып ялгыз басып торалар.

Тургайның язуын күрергә сыйныфтагылар бөтенесе дә килеп җитте.

– Ә бу юлыңдагы хәрефләрең нишләп төрлесе төрле якка ауган?

– И, апа, әнә бит тышта җил уйный. Җил таратты аларны.

– Ә бусы нишләп бик бәләкәй?

– Анысы җилдән ышыкланып агач астында алма ашап утыра.

– Син, Нуруллин, кабалануыңны җилгә аудармa әле, – диде Әлфия апалары. – Өйдә әйбәтләп язып кил.

Соңгы дәрес әдәби уку иде. Берәм-берәм үзләре уйлап килгән табышмакларын әйттеләр. Алсуның табышмагын аеруча мактады апалары.

– Ак тана, вак тана, тутырам дип мактана, – диде ул.

Җавабын таба алмыйча аптырашып беттеләр. Риф «яңгыр» диде, Рөстәм «бал» дип кычкырды, кемдер «кар яву», кемдер «он иләү» диде, тагын әллә ниләр әйтеп бетерделәр. Ә чын җавабын Алсу үзе әйтеп салды:

– Ул безнең сөтләч тана!

Кайберәүләр табышмак уйлый алмаган иде. Кул күтәрүчеләрдән икәү генә – Тургай белән Фаил генә калды. Апалары Фаилне такта янына чыгарды.

– Үзе йомшак, үзе каты, үзе кәкре, үзе төз, – диде Фаил, бөтенесен шаккатырып.

Күпме генә баш ватсалар да, җавабын таба алмадылар.

– Һи, шуны да белмисез, керәндил! – диде Фаил.

Аңа «табышмагың чалышкан», дип кул гына селтәделәр. Тургай ике табышмак уйлап килгән иде.

– Яратам дип танышты, гомерлеккә ябышты, – диде беренчесен.

Күп уйлый торгач, җавапны Фәйрүзә әйтте: кушамат, исем диде.

Шуннан соң ул икенчесен әйтте:

– Бер җиләк, ун җиләк, күп җиләк – тулды чиләк. Өсте капланды, хуҗа шатланды.

Җиләк дигәч, кызлар бик кызып тотынганнар иде, җавап табылмады. Ахырда апалары Тургайның үзенә әйтергә кушты.

– Морда, – диде ул барысын шаккатырып.

– Нинди морда?! – дип аптыраштылар.

– Мәктәп! – диде Тургай көлемсерәп. – Эләктек бит…

Кемнәрдер көлеп җибәрде, кемнәрдер «әйе, дөрес» дип пышылдашып алды. Әлфия апалары гаҗәпләнүдән башын чайкап:

– Ай-яй, Нуруллин! – диде. – Ничек шулай уйлый аласың? Укыйсың килмимени?

– Килә, апа, – диде Тургай. – Бик килә. Бөтенесен беләсе килә. Тик… бүлмәдә кымшанмыйча утыруы… их…

– Әйтмә дә!Үлем! – дип куйды шунда Рөстәм.

– Ничек шулай дия аласыз, балалар? – дип Әлфия апалары аларның һәрберсен карашы белән кичерде. – Сөйләшәсез, көлешәсез, хәтта торып йөрисез.

Шунда Мансур сүзгә кушылды:

– И, апа, без бит курка-курка гына. Сезнең рөхсәттән башка. Рөхсәт булсын иде ул…

– Бөтенебезгә дә, – дип куйды Риф.

Әлфия апалары аларның сүзен кире кагып баш чайкады:

– Алай булалмый, балалар. Аттестат алып, мәктәптән чыккач та әле бар нәрсәгә рөхсәт булмаячак.

– Ә нишләп? – диде Рөстәм.

– Үзегез уйлагыз анысын. Шуннан соң бу хакта тәрбия сәгатендә ныклап сөйләшербез.

Кыңгырау шылтырады, бу дәрес шуның белән бетте.

*Ахыры киләсе санда*



Иделбикә

# КАН ТАМЫРЫ КЕБЕК ЕЛГАЛАР

*Туендырган – коендырган энҗекәем,*
*Кан йөрешем, яшәр суым ак, Эккәем.*

***

Дөньялыкта Яшәү, Җир-Су, Һава –
Аллаһ биргән җан ияләренә.
Һәркөн иртән сызылып аткан таңда,
Рәхмәт укып Язмыш-тәкъдиренә,
Нур-ямь, бәхет өсти кеше көненә.

Кайда яшәсә дә, торган җире
Кешегә ул – Аллаһ бүләгедер.
Вакыт сыман аккан гомерендә
Кыла кеше барлык гамәлен, дим.

***

Өч дистәгә якын еллар элек
Дуслар әйтте миңа беркөнне:
– Иделгә соң ни катнашың бар?
Исемен алып,
Кимсетмимме, имеш, Иделне.

Кар сулары җиргә бетми сеңеп,
Ерганаклар ага яз көне.
Күбекләнеп, әй, агалар алар,
Яз яңарта җанны, күңелне.
Җәйге Эк тә истә – комлыгында
Тәгәрәпләр яттык, су кердек.
Дуслар белән сәйраннарга чыгып,
Колач салып йөзеп кинәндек.

---

ИДЕЛБИКӘ – *шагыйрә; «Бәхеткә үс, Кеше!», «Дөнья авазлары», «Күңел күккә омтыла» исемле китаплар авторы; С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Ульяновск шәһәрендә яши.*

Үсә төшкәч, җиз самавыр, тазын
Ялтырату катык, ком белән...
Кайтса иде тагын шул мизгелләр
Балачакның алтын түреннән.

***

Агыйделкәй кушылып  Чулманга,
Ага  Пермь, Чаллы ягына.
Ул җаныма тагын кагыла:
Әнкәй туган  Пермь ягында,
Саплык дигән татар авылында.

Кыска гыйбарәмдә үз язмышым,
Укысагыз булыр ап-ачык.
Язган вакыйгалар тормышымнан –
Хикәятем – «Моңлы балачак».

Йөрим, әнкәй, тугры синең эздән,
Шагыйрьлегем – синең сәләтең.
Дөнья җәүһәрләре байлыгына
Әткәй салды бар мәхәббәтен.

Идел – Эк, Соя , Әй, Агыйделкәй,
Чулман кушылдыгы каныма
Ярты гасыр коя яшәр көчен –
Ничек баш имисең, ди, син аңа!

Каләмемә алдым милли исем –
Иделбикә, дидем, яратып.
Идел белән бәйле уйларымны
Языйм әле, дидем, яңартып.

Идел, Идел! Исемем юктан түгел –
Идел белән бәйле язмышлар.
Ярларында басып калды яшьлек,
Дуслар мәхәббәте, алкышлар.

Идел – соңгы җирем. Үстерәм гөл –
Рухым-җаным өртә шигырь гел:
Дөньялыктан каләмемә төшкән
Тере-якты хисем ул минем.

Кем гөлләре чәчәк ата димсең –
Гүзәллекне күрә белгәнгә.
Йөрәгендә бөре йомарланып,
Шытуларын күтәп йөргәнгә.

Сүз ул мәгънәң тирәнәйтсә генә,
Шигыреңнең гамен арттыра.
Илгә-көнгә бер куаныч булып,
Җыр шикелле килеп кушыла.

***

Ульян – Сембер. Никтер икесе дә
Якын сыман Анам теленә:
Сембер – «бер»е, Ульян нигезе
Ул җан кебек керә күңелгә.

Казанлылар шулай әйткәнгәме
Ульян чыннан якын күренә.
Ярты гасыр тулып үтте менә,
Тәү басканга гүзәл җиренә,
Монда тудым кебек сизелә!

Җыр дигәне тумый бит ул юктан –
Күз алдыма Идел килеп баса.
Сембер белән Казан гел янәшә,
Сәлам юллыйм сезгә моңым аша.

Җыр-моң – әткәй-әнкәй авазлары
Сеңеп яшәгәннәр каныма.
Галиябану, Гөлҗамаллар аша
Җанкаемны тетрәндереп үтеп,
Идел дулкыныдай кагыла.

Кандалый, Сүнчәләй, Кол Галиләр,
Тукай, Җәлил – бездән элгәре,
Чор шавының гамен безгә биргән,
Сөйли аңлы каләм эзләре.

Рәхмәт укыйм Ходай Тәгаләгә:
Саклавына йөрәк тибешем.
Каләмемне кулдан төшермәвем –
Шигъриятькә кертер өлешем.

Кан тамыры кебек Иделкәем!
Җаным  ярсуының ярасын –
Серләремне Сиңа бүлешүнең
Нидәнлеген инде аңларсың –
Үз иттең бит Экнең баласын,
Килә сиңа башым иясем!



Вакыйф
Нуриев

# НИ ХӘЛЕҢ БАР, БАЛАМ?..

БӘЯН

«Сиңа килдем. Хәлеңне белергә килдем. Иминлекме? Рәхмәт, сиңа! Быел да чыдадың, түздең. Күпме йөк күтәрергә туры килде үзеңә. Йөк түгел, уңыш ул. Икмәк бит ул! Байлык-муллык, шатлык-куаныч, өмет-ышаныч бит ул! Безнең кебек авыл кешесенең теләк-хыялы, максат-омтылышы, тормышның асылы-мәгънәсе. Горурланам синең белән! Ничәмә-ничә ел тонналарны «эһ» тә итми күтәрәсең. Ыңгырашмыйсың, зарланмыйсың, көйсезләнмисең. Минем дә авылдашларым алдында йөзем ак. Тиздән Уңыш бәйрәме булыр. Уракта шәп эшләгәннәрне мактарлар, бүләкләрләр. Синең белән мине телгә алучы да булмас. Борчылма. Икмәк өчен көчебез кергәнгә куанып яшик.

Хәтерлисеңме соң шушында килеп, шушы урынны бил тиңентен кычыткан, алабута, шайтан таякларыннан чистартып, җир казып мәш килгән тиктормас егетне. Сине шушында бастырып киткәнемне хәтерлисеңме? Әйе, мин идем ул. Ул көннәрне оныта алмыйм. Бәхетле көннәр!»

* * *

Факил Казан авыл хуҗалыгы институтында укый иде. Практикага туган авылына җибәрделәр. Кәнсәләргә кергәч, председатель белән сөйләшү кыска булды:

— Энем, үлчәү кирәк колхозга. Үлчәү. Автовеса! Шуны корып бирсәң иде син безгә.

— Аңладым.

Аңлавын аңлады. Тик кулыннан килерме бу эш? Авылдашлары алдында адәм көлкесенә калмасмы? Институт кадәр институтта укый дигән даның бар. Авылдан беренчеләрдән булып керде ул анда. Азмы-күпме дары исен дә иснәп карады. Факил сугышка кырык бишенче елның язында алынды. Псков десант дивизиясенә эләкте. 177 тапкыр парашют белән сикерде. Кайчан гына ыргытмадылар аларны: иртән дә, кичен дә, көндез дә, төнлә дә. Кая гына килеп төшмәделәр: далага, суга, сазлыкка, урманга. Урманга төшү бик хәтәр иде, чыршы очына эләксәң, корсагыңны ярасың. Агач башында кунып калсаң, җиргә төшә алмый җәфаланасың. Бергә

---

Вакыйф НУРИЕВ (1958*) — язучы. «Бүре кадәр бүрек», «Җиденче палата», «Ана догасы» китаплары авторы. ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

хезмәт иткән иптәшләренең күпмесе шулай харап булды. Бүген-иртәгә сугышка кирәбез дип торганда, Гитлер тәпиен ялтыратты. Аның каравы, сугыштан соң исән калганнар өйләренә кайтып китте, ә Факил кебек «егерме җиденчеләр»гә тагын җиде ел хезмәт итәргә туры килде.

Армиядән кайткач, авыл мәктәбенә укырга китте. Малай-шалайлар белән сабак өйрәнде. Беркөнне мәктәп бәдрәфендә төтен эленеп торганын күреп алган директор Хөсәен Хәсәнович малайларны тезеп куеп тентеде. Тәмәке Факилдән чыкты.

— Бу гамәлең мәктәп стенасына сыймый, — дип сүкте аны Хәсәнович.

«Мәктәп стенасына сыймый». Кемнең дә булса бер-бер хилаф эш кылганын белсә, директор гел шушы сүзләрне әйтә.

— Нишләп сыймый соң ул? Нигә мәктәпне зуррак итеп салмадыгыз? — диде дөнья күреп кайткан, лаеш шулпасын шактый чөмереп өлгергән, самолётның тар ишегеннән очсыз-кырыйсыз күккә атылырга күнеккән Факил.

Директор десантчы егеткә бүтән бәйләнмәде.

* * *

Иртәгесен Факил йөрәксенеп эшкә тотынды. Алдына җәймә кадәр кәгазьләр җәйде. Болар — үлчәүнең сызымнары. Егет аларны дөньясын онытып өйрәнде. Җәйнең кояштан нур яудырган бер көнендә янына хатыны Рәкыя килеп басканын да сизмәде.

— Нихәл, картым, эшләп буламы? — дип сорады, битендәге сөйкемле сипкелләре уңып, сизелер-сизелмәс кенә язылып калган, икедән үргән сары чәч толымын баш түбәсенә такыя кебек түгәрәкләп салган якты кыз.

Факил сискәнеп китте, каушап калгандай булды.

— Маташып карыйм әле, ни килеп чыгар, — диде ул һәм маңгаендагы тамчы-тамчы тибеп чыккан тирләрен кул аркасы белән сыпырып куйды.

— Ярый, мишәйт итеп тормыйм. Бер сәгатьтән аш өлгерә, әбәдкә кайт!

Рәкыяны ай күрде, кояш алды.

Студент егет аны ягымлы-якты карашы белән күздән югалганчы озатып калды.

Факил белән Рәкыя тиз кавыштылар.

Егетнең армиядән кайткан чагы иде. Кайтып төште сержант авылга. Тәбәнәк буйлы, җиңел сөякле, бит очлары ялтырап-янып торган солдат-десантчыны күреп кызлар «аһ» итте. Күрше кызы Фәһимәнең дә күңелен ымсытты. Алай гынамы?! Кызның йокысы качты.

Егет ике арадагы бакчага турник ясап куйды. Көн саен иртәнге алтыда торып чыга да шунда атына. Аның ничек атынганын көтү куарга чыккан күрше кызы койма буена килә дә ярыктан шыпырт кына карап тора. Факил башта ике кулы белән өскә тартыла. Ияге турникның тимере белән тигезләшкәч, ике аягын бергә куеп алга кискен ыргым ясый. Һаваны яра. Таган кебек атына да атына. Амплитуда үскәннән-үсә бара. Берзаман аяклары өскә чөелә. Егет ботларын, кулларын сузган хәлдә туры сызыкка әверелә һәм турникны әйләнеп чыга. Гәүдә күзнең явын алырлык якты түгәрәк ясый. Нәкъ кояш инде менә. Хәер, бу тамаша үзе дә «кояш» дип атала бит! Авылда Факил турында «ул турникта «солнце» ясый икән» дигән могҗизалы хәбәр тарала. Күпме егет газапланып та, черәшеп тә булдыра алмаган хәл бит бу! Көч-куәтнең, матурлыкның гаҗәеп тантанасы.

Фәһимә — күрше йорттагы ун баланың бишенчесе. Түгәрәк битле, бөдрә чәчле, зәңгәр күзле кыз. Чибәр! Күр әле син бу Факилне, моңарчы читкә-миткә чәчрәп тормаган, каралты-курада, өй тирәсендә тыныч-сабыр гына үз эшен эшләп йөргән мыштым кызны нишләтеп ташлады бит, ә! Хәзер Фәһимә өчен бу дөньяда армиядән кайтып аның һушын алып йөргән күрше егете генә бар. Мәхәббәт дигәннәре шушы буладыр инде ул.

Иртән көтү куганда күрше-күлән бер түгәрәкләнеп ала да хәл-әхвәл сораша, тегене-моны ишетә, эчен бушата. Авыл кешесенең сөйләгән сүзе гадәттә тавык-чебеш, мал-туар, печән чабу, утын хәстәрен күрү тирәсендә бара инде.

— Җәй ничек килер? Яңгырлар булырмы? Корыга китмәсме? Курмы әзерләп булырмы?

— Чалгыларны таптап куясы бар.

— Чалгы алырга кирәк әле быел. Былтыр безнеке, мужикны әйтәм, урманда сындырды. Артыштауда бар микән чалгы?

— Бүген минем мужик әче таңнан урманга китте. Өстерилек белән. Агач келәймәләргә.

— Кайда келәймәлиләр икән? Кайсы диләнкене?

— Без былтыр туксанда, Поп елгасында әзерләгән идек утынны. Фартал юлы кырыйларын чистарттык.

Фәһимә бу сөйләшүләргә колак салып тора да уйлап куя: «Бигрәкваклана бу кеше дигәнең. Телләрендә бер сүз: йә утын, йә печән. Әйтерсең, дөнья шулардан гына тора. Әй, сез, Адәм балалары! Җир йөзендә мәхәббәт бар! Пүчтәк сезнең печәннәрегез аның белән чагыштырганда. Чуртымамы печән-мечәннәрегез, утын-мутыннарыгыз, көгдә монда мәхәббәт бар! Гыйшык-мыйшык бар!»

Тик Фәһимә гыйшык утында үзе генә янды. Егетне ничек каратырга соң? Вечерга (кичке уеннарны Солы авылында шулай дип йөртәләр) чыккач, гел Факил тирәсендә чуалды, боргаланды, сырпаланды. Клубтан аның белән бергә кайтып та, кич чыкмаган көннәрендә күршесен капка төбендәге эскәмиядә көтеп алып та карады. Тик егетнең исе китмәде. Аның күңелендә бер генә теләк — мәктәпне тәмамлагач институтка укырга керергә!

Көннәр үтә торды. Фәһимә эчтән сызды, янды, көйде. Җавапсыз мәхәббәтнең ни икәнен үз башына төшкән кеше генә аңлыйдыр. Факил күрше кызының үзенә карата булган кайнар мөнәсәбәтен, ташып торган уй-хисләрен сизмәде түгел — сизде. Дөресен әйткәндә, кызның чытлыкланулары аны туйдыра да башлаган иде инде. Бу «сыткый сагыз» белән бер кистереп сөйләшмәкче дә иде. Япь-яшь кызны үпкәләтүдән курыкты. Үпкәләтү генә түгел, җиләк кебек өлгергән туташның гыйшык-мыйшык хисеннән гайрәтен чигерерсең, күңелен сындырырсың. Юк, юк, песигә дә «прес» дип әйтә алмаган Факилнең үзе өчен дә бик авыр мондый сөйләшү. Фәһимәнең мәхәббәт канатларын каермаслык сүзен дә таба белергә кирәк бит әле аның. Туры әйткән туганына ярамаган, ди.

Шөкер, Факилгә тел тирләтеп азапланырга туры килмәде. Җәйнең ашыгып аткан бер галиҗәнап таңы барысын да хәл итте дә куйды. Беркөнне кызның башына бер уй килгән иде: «Һәркем үз тиңен ярата. Укытучы — укытучы белән, артист артист белән кавыша. Ни булыр икән, әгәр Фәһимә дә турникта күрше егете кебек «сунце» ясаса? Аның әллә ни авырлыгы да юктыр инде. Прусты катырак атынырга гына кирәк. Атынасың да үзеннән-үзе әйләнеп чыгасың. Фәһимә ике кулында атына алмыймы?! Фәһимә «сунце» була алмыймы?! Теләсә кояш та, ай да була ала. Ике кояш бергә кушылачак. Менә күрерсез!» Кызның башына шундый уй килеп торуын күр әле.

Фәһимә әче таңнан торды. «Кояш»ны ул кеше-кара күрмәгәндә ясап карамакчы булды. Шул ният белән, аратасыннан купкан черек тактаны бер якка авыштырып, койма тишегеннән шыпырт кына күрше бакчасына керде. Керде, ике кулын өскә сузып сикерде. «Кояш»ның кучәренә эләгә алмады. Икенче омтылыш. Әһә, эләкте. Эләгүен эләкте, тик шул мизгелдә йомры гәүдәсенең галәмәт авыр, лапшык булуын тоеп алды. Кая соң инде, кая соң... Кайда ката, кайда тун? Атынырга кирәк бит. Атыныр өчен аякны күтәреп алга ыргытырга, Факил кебек һавага кушаяклап тибәргә кирәк. Фәһимәнең аякларына ике потлы гер асканнармыни, асылынып тик

тора. Бераздан кыз хәл-җегәре беткән кулларын ычкындырырга мәҗбүр булды һәм, келәттәге матчага эленгән җиреннән өзелеп төшкән симез сарык түшкәсе кебек, җиргә гөрселдәде. Үзе тиз генә сикереп торды тагын. Кагынды. Тагын асылынды. Ботларын күтәрергә азапланып карады. Мыш-мыш килде, ахылдады-ухылдады. Җиргә лапылдады. «Кеше-мазар юкмы», дип як-якка каранып алды. Ах, үҗәт кыз да инде үзе. Тагын менеп маташа бит. Бу юлы турникка эләгә алмыйча җиргә йөзтүбән капланды. Кыз буялып-пычранып бетте. Шулвакыт тын келәтнең бакча ягындагы бер канаты аз гына ачылып торган серле тәрәзәсе бөтенләй ачылды. Һич көтмәгәндә, һич уйламаганда, хикмәти Хода, анда Факилнең башы пәйда булды. Ул кызны әллә кызганып, әллә шаяртып әйтеп куйды:

— Җитәр инде, күрше, турникны сындырасың бит.

Шушы мизгелдә җир тишегенә кереп китәрдәй булган Фәһимә койма тишегенә кереп чумды. Факилнең исә келәттә, төн буена йокламыйча, имтиханга әзерләнеп ятуы булган.

Шул көннән күрше кызы Факилнең күзенә чалынмаска тырышты.

Факилгә насыйп яр исә күршедә дә түгел, еракта да түгел, үзләренең өендә үк булган икән. Рәкыя педагогия училищесын тәмамлап, «өстенә бетле тун кигән» кыз. Үзе шулай ди. Институтта читтән торып укуны бетле тун кию белән чагыштыра ул. Солыда мәктәптә укыта. Факилләрдә фатирда тора. Иртән чыгып чаба. Укытып кайткач, өй җыештыра, чишмәдән су ташый. Аннары — фермага. Агитатор буларак, монда күпме тамак ерта. Төнлә киләсе дәрескә план төзи, дәфтәр тикшерә. Рәкыя эшне тиз эшли үзе, җиңел эшли. Чәчен дә кешенеке төсле генә итеп үрми бит ул. Озын, куе, коңгырт чәчләрен әүвәл «фәс» иттереп алга ата. Башы чәч чүмәләсенә күмелеп кала. «Көлтә»не озын агач тарак белән җәт-җәт тарый, тарап чыккач, тасылдатып артка ата. Чәч аркасына, биленә килеп ябыша. Аннары шушы муллыкны уң як җилкәсе аша алга төшереп кызу-кызу үрә. Үрелгән толым кызның баш түбәсенә түгәрәк таҗ булып куна. Юк, чәч үрү генә түгел бу. Бу — тылсымлы сәнгать. Бу — моҗизави тантана!!. Яшьлек, матурлык, илаһилык тантанасы! Моны күргән саен, кызның үзенә сиздерми генә карап-күзәтеп йөргән Факилнең күңелендәге бер кылы зеңгелдәп куя.

Рәкыя атна буена чатыр чабып эшләп йөри-йөри дә, шимбә кичкә таба Солыдан биш чакрымдагы Карлыган Сазы авылына әтисе белән әнисе янына кайтып китә. Бер шимбә үтә шулай, ике, өч... Факил шунысын искәреп ала: Рәкыя кайтып киткәч, күңелсез кала, өйнең яме бетә икән ич. Бер шимбәдә егет квартирантканы калырга үгетләде. «Кич клубка вечерга алып чыгам мин сине», — диде. Кыз баштарак карышты. Факил тәки күндерде үзен. Бер малайны ат менгереп Карлыган Сазына чаптырды. Ат белән бергә күрше авылга Рәкыя исеменнән «Әти-әни, бу атнада кайта алмыйм. Эш күп. Борчылмагыз», дигән хәбәр очты.

Кич. Аскы ниргәләре чергән, кайбер бүрәнәләре бүселеп чыккан, идән такталары калҗайган клуб. Яшьләр ду килә. Танцы-манцы, уеннар: «Наза», «Шыгырдавык», «Тәңкә салыш», «Түгәрәк уен»... Факил Рәкыяне кулыннан ычкындырмады. Клубка бергә керделәр, бергә биеделәр-уйнадылар, бергә кайтып киттеләр. Тора-бара Рәкыянең «эше күп» шимбәләр үзләре дә күбәеп китте.

Көннәрдән бер көнне Факил Карлыган Сазына кәләшнең әти-әнисеннән кыз сорарга төште. Мәсьәлә тиз хәл ителде. Ике авылда яшәсәләр дә, бер-берсенә кунакка йөрешеп, аралашып гомер кичергән бу ике гаилә, ике нәсел элек-электән бер-берсен яхшы белә иде. Шуңа күрә эшне озакка сузып тормадылар, кул бирештеләр дә, баста. Хәер, Рәкыя авылына кайтмый калган шимбәләрнең беренчесендә үк атлы малай-җайдак килеп, хәбәрне ирештергәч, кызның әти-әнисе эшнең кая таба барганын чамалаганнар иде инде.

...Үлчәүне эшләгәндә, Факилнең күңеле алгысып, дәрте ташып торды. Туган

авылың, авылдашларың өчен тир түгүеңне тою, яраткан хатынының ара-тирә килгәләп хәл белешеп китүе аны рухландырды, иңнәренә канатлар куйды. Сызымнарның очына чыгып, үлчәүне җиренә җиткереп монтажлады ул. Чокырын да казыды, измәсен дә изде, бетонын да түшәде.

Тиздән урак башланды. Үлчәү беренче олауларны кабул итте. Председатель Галимҗан да егетнең эшеннән мәмнүн.

— Институтта исән-сау укып, катыргыңны алгач, туры үзебезгә, яме. Көтәбез.

***

Диплом алу җиңел булмады. Рәкыя күрше авылдагы Чор Иле бүлнисеннән башта тупырдап торган кыз, өч елдан симез малай алып кайтты. Гаилә — авылда. Факил — Казанда. Барысы да ачлы-туклы. Студент Ирек мәйданы янында бер әбидә фатирда торды. Кортканың салкын-юеш бүлмәсендә буыннарына салкын тидереп түшәккә егылды. Полиартрит, диделәр табиблар. Дәвалану бер елга сузылды. Егет бер ел укырга йөри алмады. Рәкыя дә дәүләт имтиханнарына килеп җиткәч, педта укуын ташларга, балаларын — улы берничә айлык кына иде әле — каенанасына калдырып, эшкә чыгарга мәҗбүр булды. Үзе хәлсезлектән интекте. Сөте бетте. Симез малай ашарга сорап көне-төне акырды. Хатын табибка барды.

— Бүген нәрсә ашадыгыз? — дип сорады табиб.

— Чәй.

— Кичә нәрсә ашадыгыз?

— Такта чәй.

— Чәй дә чәй — голова качай. Каныгыз аз. Шуңа хәлегез юк. Сезгә күп итеп фрукты, ит, бавыр, балык ашарга, вино эчәргә кирәк. Күп итеп сок эчегез. Аңладыгызмы?

— Аңладым.

Ашарга кирәк, эчәргә кирәк! Өйдә чебен чукындырырлык та акча юк. Келәттә тычкан асылынып үлгән… Нишләсен соң Рәкыя? Яшь ананың күңелен кимсенү, гарьләнү, хурлану хисе кимерде.

Бер ел «академический» алганнан соң, Факил укуын ялгап җибәрде. Рәкыя исә институтка бүтән бара алмады, «незаконченное высшее» белән калды. Аның авылда көннәре элеккечә бертөсле үтте: мәктәп, дәресләр, өйдәге эшләр, ферма…

Беркөнне фермадан кайтканда вакыт соң иде инде. Ат караучы Сабирлар яныннан үткәндә, Рәкыя, өйдәге тавышны ишетеп, туктап калырга мәҗбүр булды. Сабир ду килә, кызы Гөлсирәне сүгә. Әниләре өйдә юк. Аның Ахманга бертуган сеңлесенә кунакка китүен Рәкыя белә иде. Укучысын ут эчендә калдырып китәргә намусы кушмады, Рәкыя өйләренә керде. Почмакка бастырылган, елый-елый шешенеп беткән кызны күреп, йөрәге чәнчеп куйды.

— Сабир, ни булды?

— Әтисе белән сөйләшә белми. Сөйләшергә өйрәтәм.

— Төнлә өйрәтергә булдыңмыни? Менә болай, Сабир, аның иртәгә мәктәпкә барасы бар. Бала йокларга тиеш. Әйдә, сеңлем, чишен дә ят. Әтиең сиңа башка бер сүз дә әйтмәячәк.

Рәкыя урамга чыккач, беравык әлеге йортка карап торды. Анда ут сүнгән, тынычлык иңгән иде.

Икесе ике җирдә яшәп яткан йөрәкләрне тормыш гел сынап торды. Акча җитмәү, ач яшәү — бер хәл. Өйгә конвертка салынган мәктүпләр килә башлады. Анда дүрт кенә сүз язылган: «Факил, мин сине яратам». Кемдер җәнҗал чыгарырга теләде булса кирәк, әмма Рәкыя үзен бик тыныч тотты, Факилгә бәйләнмәде. «Записка»ларны бергәләп укыдылар да көлештеләр. Тиздән, бик тиздән конвертлар килми башлады.

Кышның ябалак кар явып торган мамыклы бер кичендә урамда Рәкыяны мут Раиф туктатты:

— Рәкыя дим, әйтергәме-юкмы дип бик озак уйлап йөрдем. Әйтсәм әйтим инде, Казанда Факил «гуляйт» итә бит. Бер бик чибәр, бик зәһәр «фонтанка» белән «Вузовец» кинотеатрыннан чыгып киләләр иде. Күрсәң, мин сиңайтим, куллар — кулда, авыз — авызда.

— И-и-и, Раиф абый, Факилнең хатыны янында юк, аңа сүз әйтеп булмый. Син бит әле хатының янында була торып та баргалап килдең бугай.

— Ни әйтер микән дип, сине юри сынап карамакчы идем. Бирешмәдең бит каһәр. Казанга бармаганыма бишбылтыр инде. Факилне күрмәгәнемә дә…

Рәкыяның «баргалап килдең бугай» дигән сүзләрендә хаклык бар. Язгы кар сулары киткәндә, авылда Раифның кыңгыравы чыңлап алды шул.

Дипломны кесәгә салгач, Факилне авыл хуҗалыгы училищесына укытырга чакырганнар иде. Анысы урман артында, авылдан унике чакрым ераклыктагы бер бистәдә. Фатир бирәбез, дип кодаладылар. Факил бармады. Дипломлы белгеч күз төбәп туган авылына, туган колхозына кайтты.

Факил авылларны күп күрде. Әмма Солыга чыкканы юк инде. Өй тәрәзәсеннән күренеп торган мәһабәт таулар, шул тауларда көне-төне җырлап торган чишмәләр, шул чишмәләргә кушылып шаулаган калын урманнар, шул урманнар өстендә балкыш уйнатып камчылаган арыш басулары… Монда аны газиз әнкәсе, аңа терәк булган сөекле хатыны, киләчәккә өмете — кызы белән улы көтә.

Факил кайтты. Иртәгесен өстенә кара халат киеп, ашкынулы бер дәрт, ярсулы бер омтылыш белән эшкә чыкты ул. Чыгуын чыкты, тик эшне нидән башларга белмичә аптырашта калды. Колхозның бөтен техникасы тузып-таралып, кымкырыч кырылып ята. Язгы чәчүне ничек ерып чыкканнардыр, рәтле-башлы тырма да калмаган. Йөреп торган бер бензовоз бар. Анысы да кич соң гына Артыштаудан «тончыгып» кайтты. Төнлә кибет каршындагы бөтен авылга лампочка куелган бердәнбер багана төбендә, «тычкан уты» астында аның свечаларын алыштырдылар, «зажигание»не көйләделәр.

Иртән кәнсәләргә нәрәткә керер алдыннан Факил мәктәп бакчасына сугылып чыгасы итте. Шунда күптән түгел балалар җыйган тимер-томыр өемен күреп алды. Бәй, тырма түгелме соң бу? Нәкъ үзе! Ул үтил тавында казына башлады. Тагын ике тырма тартып чыгарды. Төшкән тешләрен куйсаң, эшкә ярый бит әле болар. Нәрәттән соң Факил конюх Сабирдан ат алып, әлеге тырмаларны тимерчегә алып кайтып тапшырды. Тимерче алачыгыннан чыккач, кәефне кырып, йөрәккә шом салып, ватылып-таралып яткан трактор-машиналарга карап куйды. Боларга ничек җан кертергә соң? Запчасть кирәк. Механизаторларның телендә дә шул бер сүз:

Запчасть!

Запчасть!!

Запчасть!!!

Факилнең юлдан кайтып кермәве, эшләп алган акчасын өйдәгеләрнең күрмәве, йокысыз төннәре, баш авыртулары, чәченең агарулары — барысы да әнә шул каһәр суккан запчасть белән бәйле. Ватык трактор, машиналарның җансыз тимер тавы булып торуы йөрәгенә төшкәнгәдер инде, Өтернәс МТСында трактор ремонтлап ятканда, директорга керде ул. Ул керде, киң җилкәле, кызыл битле директор аңа күтәрелеп тә карамады. Йомышын сорамады да сорамады инде. Ник кергәне болай да билгеле.

— Авыруларның хәле начар, — диде Факил.

— Ниткән авырулар? Бүлнис түгел, мытыес бу. — Директор кәгазьләреннән аерылды, күзлеген ашыкмый гына салып, аңа күтәрелеп карарга мәҗбүр булды.

— Нинди авырулар булсын, «ЧТЗ»лар, «ДТ»лар, «ГАЗ»лар, «МАЗ»лар…

— Тәк, тәк, сөйлә, сөйлә. Кай төшләре авырый аларның? Диагноз куелганмы?

— Берсенең — йөрәгендә «шум», икенчесенең — бавыры, өченчесенең күзләре күрми.

Йөрәк, дигәндә — двигательне, бавыр, дигәндә — фильтрны, күзләр, дигәндә фараларны күздә тота иде Факил.

— Тәк, тәк, сөйлә-сөйлә…

— Бер трактор аяксыз — йөри алмый таяксыз.

— Матур сөйлисең. — МТС хуҗасы бүлмәне яңгыратып көлеп җибәрде, күзләре дымланып чыкты. — Сез «Большевик»тан бит әле. Исемегез…

— Факил.

— Факил, мин бит бала чактан врач булырга теләдем. Авыруларны терелтәсем, аякка бастырасым килә иде. Барып чыкмады. Язмыш тимер-томыр арасына китереп тыкты. — Бу юлы директорның күзләреннән чын-чынлап яшь бәреп чыкты. — Тыңла әле, бүген-иртәгә республикадан запчастьләрнең саллы гына партиясе кайтырга тиеш. Булышырбыз.

Директор Тимерхан Ханович үзе дә фронтовик икән бит. Атаклы Рокоссовский дивизиясендә хезмәт иткән. «Кызыл Йолдыз» ордены иясе. Факилне ул кул биреп озатты. Берсенең техникага, җан иясенә караган кебек каравын искәрткән, икенчесен балачак, үсмерчак хыялларына кайтарган, хәтта бүген азга гына булса да, әнә шул хыялдагы образ ролендә булып алырга мөмкинлек биргән бу сөйләшү әңгәмәдәшләрнең киләчәктә аралашып, дустанә яшәүләренә нигез булды. Ханович Факилгә хәл кадәри булышырга тырышты.

* * *

Ул юеш борыннар әбиләр кулында бик тиз тәпи китә, сөйләшә башлый икән. Көннәрдән бер көнне Факил улын үзе белән гаражга алып китте. Нияте — аны техникага орындырып алу иде. Кем белә, бәлки киләчәктә Вахиттан да инженер-механик чыгар.

— Улым, күр әле, машина бу, машина. Менә аның руле, монысы рычагы, менә монда бассаң, «пип-пип», ди.

Малай дәшмәде, кабинада авызын турсайтып, гамьсез генә утыра бирде.

Аннары Факил аны трактор янына алып килде. Бу гыйфрит-албастыны күргәч, малайның кәефе кырылды, чырайларын чытты, борынын җыерды.

Шулвакыт гараж яныннан, сиртмә-арбага җигелгән атын каулап, конюх Сабир үтеп бара иде. Атны күргәч, малайның күзләре ут алды, авызы ерылды.

— У-у-у… Бахбай, — диде ул, кулларын чәбәкләп, һәм аякларын чалыш-полыш китереп, ат артыннан йөгерә башлады.

Сабир да аны шунда ук күреп алды, атын туктатты, мышнаган сабыйны күтәреп алып, ямь-яшел клевер түшәлгән арбасына утыртты. Факил аларны моңсу караш белән озатып калды, гүя ошбу арба аның бөтен уй-теләкләрен, хыялларын үзе белән бергә ияртеп алып китте.

Шул көннән Вахит конюшнидан чыкмады. Өйдән ипи, шикәр ташыды, үзе исә атларга башак бирергә әзерләгән борчак оныннан авыз итте. Өйгә кайткач, әбисе аның авыз кырыйларына, күлмәк-ыштаннарына кунган-сыланган саргылт онны чистарта-чистарта иза чикте. Чистартып кына бетерә, оныгы тагын ат абзарына чыгып йөгерә. Бахбайлар аны ахактай күзләрен балкытып, бәрхет иреннәрен сузып каршы ала.

Авыл халкы Вахитка «Ат механигы» дигән кушамат такты.

Бераз үсә төшкәч, битенә, борынына мул булып сипкел сибелгән «Ат механигы» конюхтан ат сорый башлады. Сабир атны бирергә ашыкмады.

— Әүвәл кеше белән сөйләшергә өйрән, — дип кырт кисте.

— Ничек сөйләшелгә сун?

— Барыбер сөйләшә белмисең син, Ат механигы.

— Ә син тулгай (авылда Сабирның кушаматы «Тургай» иде) механигы.

— Ах, кәтүк малай. Күр әле син аны, абыйсы кадәр абыйсына ни дип тора бит.

— Ат бил.

— Бирермен мин сиңа ат. Башта сөйләшергә өйрән әле, кәтүк. Хөрмәтле Сабир абый, диген. Ни хәлләреҥ бар, диген. Хатының Сәлимә җиңги ни хәлдә, диген. Ахмандагы баҗаең белән балдызыңның ни хәлләре бар, диген. Авырмыйлармы, диген. Ахман Сабан туен сораш. Шәп булдымы, диген.

Ахман үзе — урман артындагы күрше район үзәге. Солыдан әллә ни ерак түгел, ун-унике чакрым тирәсе. Сабир ел саен андагы Сабантуйга бара. Барганда, өч өйле, гомер-гомергә урман белән яши, гөмбә, җиләк, чикләвектән өзелми торган Гәр Хуторга сугыла. Гәрәй, Мингали, Мәрхәбләрдә кунак була.

Ахман Сабан туе көнне ул атын көтү куганчы ук җигеп куя. Малкаена көмеш тәңкәле шлея кидерә, дугасына кыңгырау тага. Арбага, калын итеп җәелгән яшь-сусыл печәнгә хатынын утырта. Халыкның нәкъ көтү куган вакытында юлга кузгала. «Әй сез, кемнәр анда, күреп калыгыз, Сабир абзагыз Ахманга Сабантуйга бара. Сез, «ахломоннар», монда калыгыз, менә мин Ахманга барып Сабантуй күреп кайтыйм әле».

Сабантуй Солыда да, күрше авылларда да була анысы. Сабирның сүзләренә караганда, Ахманныкына чыкканы юк инде. Анда алган тәэсирләр аңа ел буена җитә. Сабир булган җирдә Ахман Сабан туе телгә алынмый каламы соң?! Атларның иң зәһәре, гармуннарның иң фырты, сөлгеләрнең иң озыны, көрәшчеләрнең иң гайрәтлесе Ахман Сабан туенда гына, имеш. Каклаган каз, яңа суйган сарык ите, тутырма, бәлеш, өчпочмак, тәбикмәк, күзикмәк, кош теле, пәрәмәч, чәк-чәк, бавырсак, катык, әйрәннәрнең иң тәмлесе фәкать Ахман Сабан туенда гына, имеш. Сабантуй көнне Ахманда кырык коймак — бер тиен, имеш.

Булсын. Яшәсен Ахман! Яшәсен Сабантуй!!

* * *

Атна буена Өтернәстә МТСта ятты алар. Тракторның «эчен алдылар». «ДТ» шыр сөяккә калды. Кабина да рама. Сүтү бер хәл, җыясы бар бит әле. Тракторчы Нур да, Факил үзе дә муеннан майга, мазутка баттылар. Ярый әле, Радиатор булышты. Шушында МТСта эшли ул. Исеме дә бардыр инде аның, монда Радиатор дип йөртәләр. Үзе дә трактор хәтле. Буе да озын, җилкәсе дә киң. Башы гәүдәгә муенсыз гына тоташкан. Көрәк кадәрле итле кулының май-мазут сеңдергән күзәнәкләре бик оста рәссам ясаган, карап туймаслык бер картина кебек. Күтәрәсе-төшерәсе булса, аны чакырып алалар. Аның көч-куәте турында риваятьләр сөйлиләр. Бервакыт урманнан печән алып кайтканда, бер фырт «Волга» моңа юл бирми. Радиатор нишли, дисезме, төшә дә машинаны күтәреп ала һәм юлга аркылы куя. Шундый итеп куя, машинага борылырга хут калдырмый. Алда да — агач, артта да — агач. Үзе тракторы белән кырыйдан узып китү җаен таба. Капкынга эләккәнен аңлап алган «Волга» хуҗасы йөгереп барып каршына чыга һәм ялынырга-ялварырга тотына:

— Зинһар, машинаны борып куй!

— Ник үзең бормыйсың?

— Булдыра алмыйм.

— Әллә кем булып йөрергә булдырасың бит. Юл бирергә җай да бар иде бит сиңа югыйсә. Уңга кереп калала идең. Күрәсең бит йөк белән кайтып килгәнне. Ишетсен колагың, масаеп йөрүләреңнең соңгысы булсын.

— Вәгъдә — иман, моннан соң кырмыскага да юл бирәчәкмен.

Радиатор Сабантуйларда да бер дә галәмәт көрәшер иде. Хатыны мәйданга

кертми икән. Бер бәйрәмдә түзеп тора алмаган, кергән ул. Читтән килгән бер егет көндәшләрен азаплый, бил алышу башлануга, гел җиргә яту ягын карый икән. Радиатор кергән дә тегене җирдән суырып алып күтәргән. Әмма атмаган. Тегене күтәргән килеш мәйдан әйләнгән. Теге егет ике кулын күтәреп бирелгән һәм тайган. Радиатор исә бүтән кереп тормаган, көрәш матур гына дәвам иткән.

Менә шул пәһлеван тракторның «эч-баш»ын урнаштырганда, Факилләргә дә күтәреште-төшереште. Рәхмәт төшкере.

Бүген «Большевик» егетләре авылларына кайтып китәргә тиеш иде. Атна буена тимер-томыр арасында яту, төннәрен мазут-май сеңгән каты сәкеләрдә аунап чыгу тәмам туйдырды. Ашказаны — кайнар аш, баш — йомшак мендәр, күңел җылы өйне тансыклады. Арка кычыта, чәч киезләнде, тән мунча сорый. Иң яманы — тамак ач. Алып килгән ризык бетте. Запас юк. Кесә буш. Акча юлга гына җитә. Җитсә әле. Башта машина тотып Артыштауга барасы, аннары стансага төшеп өч вагонлы дизельгә утырасы, поезддан төшкәч, авылга хәтле җиде чакрым тәпи-тәпи атлыйсы. Иртәгә тагын шул маршрут белән киләсе. Килмичә булмый. Эш бетте дип кулларын керосин белән юганнар иде инде, тракторның каяндыр май җибәрүе билгеле булды. Тагын сүтәргә, тагын актарырга кирәк. МТСтан болай чыгу килешми бит инде.

— Вакыт әрәм итеп кайтып тормыйбыз мәллә, — диде Факил, башын кашып, — бер төнгә ничек тә түзәрбез. Өйгә кайтып йөрсәк, моннан ике-өч көнсез чыга алмаячакбыз. Калсак, иртәгә эшне бетереп, трактор белән кайта алабыз. Урык-сурык йөргәнче, калыйк. «ДТ»ны карыйк. Бөтен Солының карап торган бер тракторы бит ул.

— Бер кичкә кер мичкә, ди. — Нур ризалык белдереп баш какты.

Шулвакыт яннарына Тимерхан Ханович килеп басты. Директор кул биреп күреште.

— Ни хәлләрегез бар, егетләр? Терелттегезме бу баланы? Аның ни хәле бар?

— Бу бала капризный булып чыкты бит әле, Тимерхан Ханович. — Факил тагын башын кашып куйды.

— Бала түгел, бәла бу, — диде Нур, авыр сулап.

— «ДТ», димәк, «дитё» инде ул. Шулаймы, Факил дус?

— Дитё инде, дитё, Тимерхан Ханович. Тик менә балабыз астына «пес итә». Энурез. Ярый йөрәген кеше иттек, монысын гына дәваларбыз.

Директор шаркылдап көлеп җибәрде һәм Факилнең терсәгеннән тотып әйтте:

— Йөрәкне йөрәкле кеше генә дәвалый ала. Сездә йөрәк бар, егетләр. Астына җибәрү гадәтен генә бетерә алырсыз, шәт. Ярдәм кирәк булса, мине беләсез.

Шулай итеп, Факил белән Нур Солыга кайтмыйча калдылар. Көн кичкә авышты. Тимер-чүкеч чыңыннан яңгырап, компрессорларның берөзлексез һава өрдерүеннән гөжләп торган МТС тынып калды. Арган-талчыккан инженер-механик белән тракторчы икесе ике сәкегә ауды. Үтереп-үтереп ашыйсы килә. Их, булса иде бер сынык ипи. Шуны капсалар да йөрәкләренә ял булыр иде, ичмаса. Юк бит. Иртәгә кадәр ризык капмыйча ничек түзәргә? Факил түзәр анысы. Ул ачлыкның ни икәнен белә. Аңа өч яшь булганда әтисе үлә. Әнисе биш бала белән тол кала. Итәк тулы бала белән урамда да кунарга туры килә әле аңа. Төпчек улы күрше малае (алар да ач инде) белән абзар артында учак ягып бәрәңге пешермәкче була. Бөтен урам янып бетә. Сугыш башлангач, камыт буе Факил ат җигеп урман чыгара. Шунда ике атын бер-бер артлы агач басып үтерә. Ул атларны түләтәләр.

Кырык биштә сугышка алынгач та, Факил парашют белән төшкән урман-далаларда аны табын җәеп көтеп тордыларммы?!

Түз, ашказаны! Түз, йөрәк!!

Юк, Факил бүген түзмәде. Үзе генә булса, түзәр иде. Шыр ялангач сәкедә яткан Нурның ах-вах килүләрен, авыр сулап куюларын тыңлап ятты-ятты да әкрен

генә торып киенә башлады. Егетне кызганды. Яшь, таза организм. Гәүдәсе дә сөбханалла! Төн буена шулай интегеп чыгачак бит ул. Ач килеш йоклап буламыни?!

— Син кая җыендың? — дип сорады Нур зәгыйфь тавыш белән.

— Тышка чыгып керәм.

Факилнең исә һич икеләнүсез ризык эзләргә җыенуы иде. МТС тан чыгуга авылга юл тотты ул. Тирә-як тып-тын. Ара-тирә этләр генә өреп куйгалый. Салкынча. Тән калтырый. Эчтә кайнар ризык булмаганга да калтырый торгандыр инде ул.

Факил авылга керде. Керде һәм һушын югалта язды. Кемдер мичтә таба ашы, камыр ризыгы пешерә. Урамда әйтеп-аңлатып булмый торган тәмле май исе. Факилнең күз алдына утын күмере өстендә күпереп пешкән алсу-кучкыл күзәнәкле көлчә, тәлинкәдән алгач, майлары тамып торган кайнар кыстыбый, камыр өстенә ябылган бәрәңгесе кызгылт элпә белән капланган пәрәмәч (бу якта нәкъ менә шушы ризыкны «пәрәмәч» дип атыйлар) килде. Их син, авыл, нигә шулай җәфалыйсың ач бәндәне?! Бер-ике телем каткан ипи булса да ярар иде югыйсә. Тик анысын да кемнән сорарга? Урамда эт тә юк. Гомердә булмаган хәл, бүген Факил теләнергә чыкты. Ходай күрсәтмәсен мондый язмышны.

Теләнчеләрне күп күрде ул. Псков янындагы бер авылның чиркәвендә дивизиянең бәрәңгесе саклана иде. Десантчылар һәр төнне монда чиратлашып каравыл тора. Чират Факилгә дә җитә. Татар малае чиркәүдә япа-ялгызы. Дөм караңгы. Шомлы тынлык. Кылт иткән тавышка да йөрәгең ярылып үләрлек. Җитмәсә чиркәүгә китәр алдыннан иптәшләрең биргән «инструктаж» эчтә боз булып ята. Аларның сөйләвенә караганда, төнге сәгать берләргә-икеләргә кадәр түзәргә була. Аннары башлана мәхшәр: ишек кагалар, дөбердиләр, ваталар-ишәләр, җимерәләр. Үзләре күзгә күренми.

Ничек чыдарга? Утыра шулай Факил афәт көтеп. Сәгать бер тула. Ике тула.

Ишек шакыйлар!

«Әһә, башланды», дип уйлый ул эчтән генә.

Бераздан тагын шакыйлар!!

Юк, ачмаска. Ачмаска, ачмаска!..

Нигә ачмаска?! Тукта әле, син җиде төн уртасында, күкнең җиденче катыннан, кая килеп төшәсеңне дә белмичә, кап-кара дөньяга сикергән десантчы татар егете монда — җирдә, черек бәрәңге күче янында куркып утырасың. Позор!

Факил барып ишекне ача. Ачса… тасма-тасма ертылып-умырылып беткән бишмәт кигән ак сакаллы, бөкре бер карт басып тора. Кулын сузган.

— Ради бога, две картошки!

Факил төнге дәрвишнең тетелеп беткән биштәренә бәрәңге тутырып бирә. Карт елый-елый рәхмәт укый.

...Урамда берәү дә очрамагач, Факил дә, төнге чиркәүгә килгән мескен бабай кебек, берәр йортның ишеген шакып карарга булды. Ыңгырашып яткан бичара Нурның газиз ашказаны өчен ул теләсә-кайсы өйгә керергә риза. Юк, уты сүнгән өйгә кермәячәк ул. Ябык капкага да кагылмаячак. Бәй, әнә бер капка — төбенә кадәр ачык. Бездә — татарда ачык капка «әйдә, кер, рәхим ит!» дигән сүз бит инде. Ачык капкалы әлеге йорт үзе дә балкып тора, тәрәзәләрдә дә — ут, ишегалдында да — ут.

Ишекне башына ак яулыгын килештереп бәйләгән тәбәнәк буйлы, җиңнәре сызганулы хуҗабикә ачты.

— Әссәламегаләйкүм!

— Вәгаләйкүмәссәлам!

— Апа, борчыган өчен гафу итегез. Без мытыеста ремонтта идек. Солы авылыннан. Бүген өйгә кайтып китәсе кешеләр идек. Кайтасы булгач, харчаларны да бетергән идек. Харча бетте, тик эш бетмәде. Тамак ялгап алырга бер-ике телем ипиегез булмас микән?

— Әйдүк, өйгә керегез! Иптәшләрең кайда соң?

— Тракторчы белән икәү без. Ул мытыеста калды.

— Бар, чакыр аны да. Кайнар ризык ашап китәрсез. Мунча да ягылган. Килегез, кил! Көтәбез.

Факил белән Нур башта мунча чабынып чыктылар. Мәтрүшкә, бөтнек кыстырып бәйләгән миллек белән тәннәре кызарып чыкканчы чабындылар. Бер-берсенең аркаларын керендереп чаптылар. Ак мунчаның сап-сары такталары ялтырап торган идәненә утырып, салкынча су белән рәхәтләнеп коендылар. Иртәгә өйгә, хатыннары янына чип-чиста кайтачаклар, Алла боерса.

Өйгә кергәч, хуҗабикә аларны табынга дәште. Һәркайсының алдына тәлинкәгә чөмәкәйләп өйгән кыстыбый китереп куйды. Ул арада хуҗа үзе дә кайтып керде. Авылның икенче башында торучы, быел гына өйләнеп башка чыккан улы белән киленен мунчага чакырырга дип киткәнен хатыны әйткән иде инде. Кунаклар хуҗаны күргәч, телсез-өнсез калдылар. Ул бүген көн буена алар белән кайнашкан Радиатор иде. Исеме Рәдис икән.

— Мин сезне кайтып киттеләр дип торам. Килеп бик дөрес эшләгәнсез. Ачка интегеп яткачы. Ашагыз рәхәтләнеп.

— Кайсы тәлинкәдән ашый башларга соң? — Факил бер хуҗага, бер хуҗабикәгә карап алды.

— Һәркайсыгызга берәр тәлинкә, — диде Радиатор, кистереп.

— Моның кадәрне ашап бетерсәң?..

— Бетерәсез. Порция!

— Әйе, бездә порция шундый, — дип иренең сүзен куәтләде хуҗабикә.

— Добавка да булачак! — дип өстәде Радиатор.

* * *

— Ут бар!

— Пожар!!

— Янабыз!!!

Авыл дерт итте. Барысы да дулкынлана-дулкынлана, кайный-кайный күккә күтәрелгән каракучкыл төтен манарасына таба чаба башлады. Пилорам яна икән бит. Халык акырыша:

— Кайда су?

— Мотопомпа кайда?

— Пожарник Сабир кайда?

Берсе дә юк.

Сабир колакка каты. Өенә биш яшьлек Вахит — Аны Факил йөгертте — атылып килеп кергәндә, ул уттан бихәбәр, тирләп-пешеп чәй эчеп утыра иде.

— Пожал, пилоламда пожал! — диде сулуы капкан малай.

— Ах, ананңы корт чаккыры, Ат механигы, кеше белән сөйләшергә һаман өйрәнә алмыйсың. Башта ни дип әйтергә кирәк?

— Исәнмесез, Сабил абый.

— Хөрмәтле Сабир абый, диген, хәчтерүш.

— Исәнмесез, бик хөлмәтле Сабил абый.

— Аннары?..

— Ни хәлегез бал? Хатыныгыз Сәлимә җиңгинең ни хәле бал?

— Тәк, тәк, дәвам ит.

— Анда пожал…

— Баҗайны оныттыңмыни?!

— Ә-ә-ә… Баҗай белән теге кем әле…

— Балдыз. Шуны да белмисең, тинтәкбаш.

— Баҗай белән балдыз үлмәделәл мәле?

— Ах, ахмак Ат механигы, нишләп үләргә тиеш ди алар?!

— Баҗай белән балдызыгыз авылмыймы? Ахман Сабан туе шәп булдымы?

— Вәйт маладис. Тырышсаң, булдырасың бит! Бирәм мин сиңа ат.

— Миңа ат киләкми. Пожал анда.

— Ишеттем. Аңладым. Пилорам зур түгел. Такта гына. Янып беткәндер инде, шәт. Һәрхәлдә «Өе биек, яна биеп», дип әйтерлек түгел инде.

Төшке ашка өенә кайткан Сабир атын — Барсны тугармыйча, бакча ягында алдына печән салып, суга кушып кергән иде. Мотопомпаны да өендә тота. Мондый коры елда үзенең һәм кибетченең бәрәңге бакчасына су сибеп тора ул.

Чыксалар, бичара Барс суын да эчмәгән, печәнен дә ашамаган. Авылда ут хәвефе барын белгән-сизгән малкай, бәйдән ычкына алмавына гаҗиз булып, аяк астындагы җирне дагалы тояклары белән казып-казып бетергән иде. Берничә минуттан арбасына мотопомпа салынган ярсулы ат, авыл урамнарында тузан болыты күтәреп, кушаяклап чаба иде инде. Җан-фәрманга чабып килеп ут эченә кереп китәсе иде — үзен чак тыеп калдылар.

Әйе, пилорама кечкенә иде. Ләкин пожары кечкенә булмады. Эчендә юан-юан бүрәнәләр яткан. Алар шәп янды. Аннары ут тыштагы бүрәнәләргә капты. Ярдырырга дип хәстәрләнгән агач тау-тау өелгән. Өелмини, бу якта урман өскә аварга тора. Бусы — бер. Икенчедән, кырык урыска — бер дуңгыз дигәндәй, җиде авылга — бер пилорама.

Отыры пожар киңәя башлады. Сабир тешләрен ыржайтты, төкерек сибә- сибә сүгенде. Төкерек кенә сибә алды шул, су сиптерә алмады, чөнки мотопомпа кабынмады. Әллә нинди хикмәтле насос булып чыкты ул, бакчага су сиптерергә җәт кабына, пожарда хет үл — кабынмый.

Факилнең дә бәгыренә тиде ул мотопомпа. Үзенә күрә шулай ук техника бит, инженер-механикка аның өчен дә җавап бирәсе. «Кирәкле» кешеләрнең бакчасына су сиптерүен күргәләгәч, насосны эштән чыгаралар инде, дип уйлап куйган чаклары булды аның. Тик шуны бер ачтырып каратырга кулы җитмәде.

Пожар җәелгәннән-җәелә барды.

Ялкын телләре бүрәнәдән бүрәнәгә сикерә-сикерә үрмәли. Коточкыч хәл — ут янәшәдәге заправкага юл алды! Эреле-ваклы бүрәнәләр аның коймасына ук килеп терәлгән. Ут та килеп җитсә — эш харап. Койманың еллар буена кибеп-каралып беткән рәшәткәләре аша эчкә сикерү аңа берни түгел. Сикерсә, дистәләрчә еллар үзенә бензин, керосин, мазут сеңдергән майлы җиргә шунда ук ябышачак һәм күз ачып йомган арада бөтен заправканы чолгап алачак. Ягулык белән тулы баклар-цистерналар шартлый-шартлый, утны бөтен авылга сибәчәк.

Китте йөрәк өзгеч акырулар-бакырулар:

— Бетәбез бит!

— Авылыбыз белән бетәбез!

— Һай, Ходаем! Коткар, зинһар!!

Хатын-кызлар үкерә-үкерә елый башлады. Балалар катып калды. Бер кызның өянәге килде, бер бабай эчен тотып җирдә тәгәри башлады. Китте паника.

Ут халыкның йөрәгенә капты.

Мотопомпа кабынды кабынуын. Тик аның кабынуыннан ни файда?! Мичкәдә су булмагач. Суны чиләк белән сибеп бетергәннәр иде инде. Чарасызлыктан нишләргә белмәгән ирләр, ат арбасын кендегеннән алдылар һәм бүрәнәләрне ике тәгәрмәчле ал күчәргә салып, читкә тарттыра башладылар. Ат та, үзләре дә шабыр тиргә баттылар. Әмма аларның ут белән көрәшә алмаячагы көн кебек ачык иде. Шулвакыт... Ни булды дисезме?.. Чаттан, мир үгезе кебек үкереп, трактор килеп чыкты.

Кичә кич белән генә Өтернәстән ремонттан кайткан Нур иде бу. «Булган да егет

инде үзе, тракторының алдына күрәкне ни арада куеп өлгергән», дип уйлап куйды Факил. Бульдозер ыжгырып килеп җитте. Торбасыннан кучкыл төтен көлтәләре очырып, дөньяның астын өскә әйләндерә башлады. Бүрәнәләр аркылы-торкылы килде. Кайсы читкә тәгәрәде, кайсы багана кебек торып басты. Басты да йә алга, йә артка, йә янга ауды. Нурның максаты — пилорама белән заправка арасында утның юлын кисү-өзү. Халык бу көрәшне «ах» итеп карап торды. И Раббым! Ярдәмеңнән ташлама! Тракторны саклый күр! Аңа да ут каба күрмәсен.

Техникадан Барсның коты алына. Бүген дә трактор пәйда булгач, аны көч-хәл белән тотып тордылар. Трактор үкереп җибәргән саен, ул «дерт» итеп куя, сискәнеп читкә тайпыла.

Йа Хода, ниһаять, коридор ачылды. Аннары Нур аны киңәйтергә, пилорам ягындагы янып яткан бүрәнә өемен тузгытырга тотынды. Халыкка җан керде, күзләрдә өмет чаткысы күренде. Кумерләнгән бүрәнәләрне трактор этеп чыгара тора, барысы да дәррәү аңа балчык, ком сибә башлый.

Ходай саклады үзләрен. Афәт узды. Узуын узды, тик тагын бер көтелмәгән хәл килеп чыкты. Кемдер шул тирәдә чуалып йөргән Вахитны күтәреп алып Барс өстенә атландырып куйган бит. Кем кушкан? Үзе сорагынмы? Шайтан белсен. Утыра малаең ат өстендә кукраеп. Трактор сүнеп торган вакыт иде бу. Нур аны яңадан кабызды. Мотор тавышы һаваны ярды. Шул мизгелдә Барс куркуыннан җан ачысы белән кешнәп җибәрде һәм алга томырылды. Дилбегә белән йөгән башын тоткан ике егет икесе ике якта тәгәрәп калдылар. Ат Вахитны беренче ыргылуда ук чөеп җибәрде. Ходайның рәхмәте, Ат механигы җиргә барып төшмәде, Барсның ялына асылынып калды. Җиргә килеп төшсә, йә ат, йә алгы күчәрнең тәгәрмәче астына эләгәчәк иде. Барс җигелгән булса да, очты гына, хәер арбасын кендектән өзгәч, ике тәгәрмәч, бер күчәр аңа йөкмени?! Атның юеш ялыннан кулы шугандыр инде, отыры Вахит тәртәгә, аннары тәҗегә ябышып җилфердәде. Ат артыннан җирдә аунап калган егетләр торып чапты, алар артыннан — куркудан чәчләре үрә торган, йөзе агарган Факил.

Барс очты-очты да, ат абзарына кайтып җиткәч, ишеккә терәлеп туктап калды. Вахит җиргә төшәргә ашыкмады. Ул күзләрен йомган, тәҗегә чытырдатып ябышкан килеш асылынып торуында булды. Ат механигы шулкадәр нык ябышкан иде ки, ике егет һәм Факил өчәүләшеп аны көч-хәл белән куптардылар.

Ат абзарыннан кайтканда, кулына кыршылып беткән чемодан тоткан Моталлап очрады. Казанда бер хатынга йортка кереп тора ул. Кайтышы икән. Пожарны ишеткән. Алар пилорам янында гына тора. Пожар вакытында чирәмдә тәгәрәгән бабай аның әтисе иде инде. Кайчан кайтса да, Моталлапның телендә бер сүз:

— И алма күп булды быел безнең Казанда, бакчабызда. Аллага шөкер.

— Моталлап, Аллага һәм алмага шөкер, диген. — Факил елмаеп куйды.

Моталлап шаркылдап көлде һәм чемоданын селки-селки китеп барды.

Өйгә кайткач, Факил Рәкыяга сүз катты:

— Кая соң, карчык, бер-ике сум акча бирмисеңме? Кибеткә төшеп, бер «чәки» алыр идем. Авыр көн булды бүген.

— Кибеткә төшеп, күз көеге булып йөрмә инде. Хәзер көтү кайта. Сыерны каршы ал, кертеп яп. Аннары үзем сиңа бер «чәкүшкә» бирермен.

— Ай рәхмәт, карчык!

Факилнең сыерны каршы алу исәбе белән капканы ачуы булды, тук малкай юеш танавын төртеп тора иде инде. Аны кертеп япкач, урамга чыкты ул. Бүген мәхшәр эчендә кайнаган авыл тынып калган. Кайдадыр адашып йөрүче сарык бәтиләренең «бәэлдәве»н, елгадан әче камыр ашарга ашкынып кайткан казларның ишегалдына керү өчен капка астына куелган тактаны алуны таләп итеп каңгылдауларын, баш очыннан очып үткән ала карганың канаты белән һавага бәргәндә тонык кына

ишетелеп калган «шапы-лапы»ларын янгын вакытындагы котыңны алырлык үкерүләр, ташны ярырлык тавышлар, йөрәккә төшәрлек кычкырулар белән чагыштырып буламы соң?! Чагыштырып буламы соң көн буена урманда йөреп, көтү, көтүчеләр ияртеп кайткан җиләк, ылыс, сәрдә, җиленнәрдән тамып торган җылы сөт исен күңел болгаткыч пожар исе белән?! Яшел-зәңгәр рәшәткәләргә, алар буенда таслап өеп куелган бүрәнәләргә кунган җылы тузан да кара корым түгел инде.

И авылым!

Синең менә шушындый җылы тузанлы, сабыр кичләреңә ни җитә?! Исән-имин генә була күр. Ут хәвефе сиңа бүтән кермәсен!

...Ул көнне Моталлапның әнисе Гыйльмениса карчык кибеттән өч алма үлчәтеп алды.

* * *

Урак якынлаша. Колхозның бер бригадасы булган күрше Яфраклы авылының ындыр табагындагы ашлык чистарту, киптерү агрегатларын карыйсы, подшипникларын алыштырасы, майлыйсы-көйлисе бар. Әйберләрне илтер өчен, Факил ат алды. Ат булган җирдә Ат механигы булмый каламы инде. Вахит чатыр чабып килеп җитте һәм арбага менеп тә утырды. Олылар кебек аякларын салындырып утыруын күр әле син аның.

Көн искиткеч матур! Күктә — ак-зәңгәрсу болытлар, кырда — аксыл иген диңгезе. Арышлар йөгерә, ашыга, ага... Алар офыкка җиткәч, болытлар белән бергә кушыла, һәм гаҗәеп матур манзара туа. Күңел якты омтылыш, ак моңсулык, чип-чиста самимилек белән тула.

Игеннәр офыктагы ак болытларга таба ага, ага, ага...

Үзеңнең дә агып, очып китәсең килә. Вахит исә ат барган шәпкә арбадан олылар кебек сикереп төшәргә чамалап утыра икән бит, хәерсез малай. Сикереп төште һәм арбаның арткы тәгәрмәче астына барып та керде. Малай белән бергә Факилнең йөрәге өзелеп төште. Ул бер мизгел тәгәрмәч астына карарга куркып торды. Тәгәрмәчтәге кан чәчрәгән тугым, бүкән, кыршау, кигиләр мизгел булып күз алдыннан үтте. Шулвакыт өстеннән авыр тәгәрмәч чыгып киткән Вахит сикереп торды да бар көченә авылга таба чаба башлады. Факил аны куып җитеп тотканда, тирләп-пешеп чыккан иде.

— Улым, син исәнме, аяк-кулларың исән-саумы? Нигә чабасың?

— Син ачуланырсың дип курыктым, шуңа чабам.

Факил улын кочаклап елады.

Сабыйлар егылган җиргә фәрештәләр канатын җәеп торыр ди. Хактыр.

* * *

Шакирның тракторы ватылды. Пырт итә дә сүнә, пырт итә дә сүнә.Тикшерәказына торгач ачыкланды: моторга ягулык килми икән бит. Факил өр-яңа насос, тасмалы һәм кәтүкле фильтрлар алып кайтып бирде. Бик озак куйды Шакир аларны тракторына. «ДТ»сы атна буена моңаеп тын гына торды. Аның каравы, «өч борын»га берне җибәреп өлгергән хуҗа үзен иртән үк кабызып куя. Бер кабындымы, Шакир «ягулык»ны өстәп кенә тора. «Насос»ы эшли, «фильтр»ын алыштырасы юк. Исәбендә ремонтны сузу, кәефләнеп йөрүләрне дәвам иттерү иде әле, иртән трактор янына Факил килеп басты һәм әйтте:

— Шакир, бүген эшне бетерәбез, яме. Иртәгә тракторыңның бик кирәк булуы ихтимал. Әнә бит теге вакытта Нур белән мытыеста кунып калмаган, ремонтны коры тотмаган булсак, пожарда эш харап иде. Ярый бульдозер булды. Без элекке көнне генә ремонтлап алып кайткан трактор иде бит ул.

Их, Факил, Факил!

Адәм баласы иртәгә ни булачагын, башының ни күрәчәген белми шул. Син дә белмисең. Әгәр белгән булсаң... Бүген бу тракторның янына килмәс идең син. Борылып та карамас идең.

Әгәр...

* * *

Кояш төшкелеккә менеп җиткәндә, тимерчелек ишеге төбендә басып торган Факил алагаем зур гәүдәле берәүнең гаражга таба килүен искәреп алды. Радиатор түгелме соң бу? Шул ич. Нәкъ үзе. Ничек килеп чыккан ул Солыга? Нинди җилләр ташлаган?

Алар кочаклашып күрештеләр.

Рәдис улы белән килененә мунча кайгыртып йөри икән. Бурага дип Солы урманыннан агач белешкән. Шуны кисеп төягәннәр. Кайтканда урман юлында машиналары баткан. Тартып чыгарырга трактор кирәк.

— Булыр, — диде Факил, һич икеләнүсез.

Алар ферма ягына китте. Нур тракторы белән чокырда силос тыгызлый иде. Рәдисне күргәч, кабинасыннан җәт сикереп төште, ике куллап күреште. Ул Радиаторның ни йомыш белән йөрүен бик тиз аңлап алды һәм бер генә сүз әйтте:

— Киттек!

— Рәдис кирәкми инде анда. Үзең генә бар да тартып чыгар. Урта юлда, урман авызында гына батканнар алар. Без Рәдис белән өйгә кайтып чәй эчик.

— Аңладым. — Нур кабинадан ничек тиз төшсә, шулай тиз генә менеп тә утырды. Трактор урманга таба юл алды. Җиңелчә генә җилләгән хуш исле печән исенә күзне әчеттерә торган солярка, төтен исе кушылды.

Өйгә кайткач, Факил баздан куе сөттән оетылган салкын катык алып менде, иртән Рәкыя пешереп киткән ашны җылытты, бер түшкә каклаган каз турады.

— Гаеп итмә инде, Рәдис. Хатын өйдә юк. Артыштауга киткән иде. Бүлнискә. Ул өйдә булса, башкачарак булыр иде бу табын. Әйдә җитеш, бары — бергә, югы — уртак. Үзегез теге юлы, без Нур белән мытыеста ачка интегеп, болыт чәйнәп, боз бөркәнеп ятканда, ничек сыйлап җибәрдегез!

— Һи-и-и... Әйттең сүз. Нинди гаеп итү ул. Өстәл тулы сый. Булып ашкан. Хатыныңны бүлнискә китте, дисең. Авырмыйдыр бит?

— Бәби көтәбез. Тиздән туарга тиеш. Врачка күренергә китте.

— О-о-о... Шулаймыни! Бик әйбәт! Сезнең бер малай, бер кыз бит әле, име.

— Әйе. Кыз Карлыган Сазында, әбиләрендә, кунакта. Малай — механик.

— О-о-о... Сиңа охшаган алайса.

— Охшамаган шул. Ат механигы ул. Кушаматы шундый. Кәнюшнидән чыкмый. Тагын бер малай туса, анысын тимер-томырга ияләштереп булмасмы дип хыялланам.

— Ходай кемне язгандыр бит... Монысы Ат механигы, дисең, ә, — Радиатор бөтен өйне яңгыратып көлеп җибәрде.

Рәдис ризыкларны мактый-мактый ашады. Казга мөкиббән китте. Итен-маен ләззәтләнеп чәйнәде, кабыргаларын, бот сөякләрен суырды. Аннары үзенең майга баткан ике кулын, бармакларын ялап бетерде.

— Күптән нәфсем бар иде каклаган казда. Рәхәтләнеп ашадым. Безнең каз юк шул. Утыртып карыйбыз, бәбкә чыкмый.

Ул арада капка төбенә агач төягән машина килеп туктады. Факил шофёрны да өйгә алып кереп, табынга утыртты.

Кунак ашы — кара-каршы, диләр. Нинди матур, мәгънәле сүзләр.

* * *

Артыштау бүлнисендә кеше күп булса да, Рәкыя көндезге поездга өлгерде тагын. Вагонга кереп утыруы булды — колагына таныш тавыш ишетелде. «И алма күп безнең быел. Әйе, бик күп безнең алма. Аллага һәм алмага шөкер». Күрше Моталлап кайта икән бит. Стансадан авылга кайтырга иптәш бар Рәкыяга. Артыштаудан ипи, кала күмәче, чәйләр алган иде. Моталлап күтәрешер әле. Юлда мамык та авыр, диләр бит. Корсаклы хатынның болай да йөге бар.

Поезд Казарма стансасында халыкны төшерде дә урманга шуып кереп китте. Күр әле, авылга кайтучылар Моталлаптан башка да байтак монда. Солыдан трактор да бар икән бит. Җәяү кайту кайгысы бетте болай булгач. Трактор белән килүче Шакир икән. Барысы да аңа таба дәррәү чапты. Бу эсседә әлсерәп җәяү йөрисе килми шул.

Халык тракторның арбасына төялде. Рәкыяне — кабинага, Шакир янына утырттылар.

Баштарак беркөйгә генә барган трактор, юлдан чыгып, арпа басуына килеп керде. Килеп керде дә кырны ярып бара башлады. Баярак арбага менү, әйберләрне бирү-алу, барлау ыгы-зыгысы, кылбырдак килү белән искәреп өлгермәгәннәр — тракторчы ләх исерек икән бит! Ах, Шакир, Шакир... Моны иң беренче кабинадагы Рәкыя сизеп алды һәм кычкыра башлады:

— Шакир! Шакир дим! Кая барасың? Туктат тракторыңны!

Аңа җавап бирүче булмады. Шакир изелеп бетеп йокыга киткән иде.

Трактор бара. Ах, шайтан алгыры, туп-туры коры елгага төбәп бара бит. Болай булса, хәвефкә, алай гына түгел, коточкыч фаҗигагә дучар булырга мөмкиннәр. Хәтәр сигнал арбадагыларга да барып җитте. Алар шаулаша-ярсый башлады. Шулвакыт өскә Моталлапның чемоданы чөелде. Аның буш чемоданы үтә күренмәле рәшә биегән һавада тибрәлеп-селкенеп, эссе җәйдә бераз эленеп торды, аннары кайнар дулкын агымында арпалар арасындагы зәңгәр керфекле, оялчан күкчәчәкләр өстенә кыяр-кыймас төшеп кунды. Чемоданы артыннан Моталлап үзе дә сикерде. Ул арада башкалар да арбадан коела башлады. Сикерешеп беттеләр. Рәкыя калды. Сәрхуш тракторчы белән бергә, бер калды. Үзенә буйсынмас техника белән бергә бер. Фаҗига каршында бергә бер... Трактор барган шәпкә йөкле хатын кабинадан ничек сикерсен?! Шунда ук чылбырга эләгеп, трактор астында калачак. Рәкыя Шакирны уңлы-суллы чәбәкләргә, ике куллап аның күлмәк якасына ябышып селкетергә тотынды. Шакир уянмады. Башын — бер якка, авызларын икенче якка кыйшайтып йоклый бирде.

Рәкыя!

Син монда үзең генә түгел бит. Сез — икәү. Карыныңда — бүген-иртәгә туачак бала. Аның якты дөньяга туасы килми дисеңме?! Аның чәчәкле-чуклы болыннарда чабып йөрисе килми дисеңме?! Аның кысыр кызыктан да кызык табып, шаркылдап көләсе килми дисеңме?!

Сикер!!!

Рәкыя трактор барган шәпкә гәүдәсен бар көченә уптым-илаһи җиргә томырды. Гөрселдәп барып төште. Ипи, күмәчләр сумкасыннан атылып чыгып тәгәрәде, кәгазьләр очты. Эчендә нидер өзелде, аяк-балтырлары тырналды-сыдырылды, тәнендәге бихисап кыллар чатыр-чытыр килде. Тез астыннан кан тибеп чыкты. Рәкыяның сикерүен генә көткән диярсең, трактор пыт-пыт килде дә сүнде.

Тракторның кинәт туктавы да Шакирны уята алмады.

Рәкыя өенә көч-хәл белән кайтып егылды. Ул түшәктән торыр хәлдә түгел иде. Факил машина белән аны бүлнискә алып чыгып чапты. И Алла, куркынычсызлык кагыйдәләрен бозганда, кеше үләргә генә түгел, туарга да мөмкин икән. Бала туды. Тик...

Иртәгесен баланың әбисе Хәтирә карчык уч төбенә сыярлык сабыйны шартын китереп юды, кулъяулык кадәр кәфенгә төрде һәм догаларын укып озатты.

Ул көнне козгынлы зиратта карт нарат төбендә кечкенә генә бер түмгәк пәйда булды. Ул көнне бу хәбәрне ишеткәч, ае-көне җитмәгән Рәкыяның «Һай, балам! Һай, улым!» — дип өзгәләнеп әйткән сүзләреннән бөтен бүлнис тынып калды.

* * *

И гомер, гомер… Бигрәк бәрәкәтсез инде син. Кайчан гына Факил корып йөргән үлчәү дә чирек гасырдан артык эшли икән инде. Гомер ага… Күр әле, аның агышларын үлчәү белән дә үлчәп була икән бит. Юк, ул вакытны күрсәтми. Аны гөрәнкә дә, гер дә күрсәтми. Гомер уза — үлчәү туза. Юк, Факилнең үлчәве бүген дә эшли. Иске сәгать кебек төгәл-дөрес эшли. Тик бүгенге заман өчен тар инде ул. Озын сыйраклы «КамАЗ»-лафетлар сыя алмый.

Яңа үлчәү кирәк!

Соңгы елларда председательләр килеп тора, китеп тора. Монысы килгәннән бирле, бөтен эш — шабашниклар кулында.

Көннәрдән бер көнне авылда ике яшь егет пәйда булды. Берсе озын буйлы, озын муенлы, икенчесе аннан бер башка тәбәнәк, пеләш. Авыл халкы аларның ни йомыш белән йөрүен бик тиз белеп алды. Хәбәр таралды:

— Автовеса корырга килгәннәр.

— Тагын колхозны «печеп» китәргә.

— Берсе бик зур түрәнең пләмәше икән.

Иртәгесен эш башланды. Иске үлчәүдән чүт кенә өстәрәк, ындырдан чүт кенә читтәрәк Маркиз җир казырга тотынды.

Маркиз — утыз яшьләр тирәсендәге ир-егет. Шушы аылныкы. Кушаматы — Февраль. Мәктәпкә укырга йөреп караган булды, ташлады. Башы бик тулы түгел. Шуңа күрә — Февраль. Үзе генә тора. Әнисе күптән түгел генә вафат булды. Өендә тавыклар тота. Йомырка ярата. Шуның белән генә тора да инде ул. Бу егетләр каян белеп, каян табып алганнардыр аны. Маркиз эшне сытып, үтен чыгарып эшли. Ашлык керткәндә, симәнә чыгарганда, берьюлы өч капчык күтәрә, икесен ике култык астына кыстыра, берсен теше белән ала, имеш.

Февраль казый. Җене белән казый. «Замана яшьләре. Кеше яллап эшләтәләр, үзләре интекми», дип уйлап куйды Факил, аларны күргәч һәм үтеп барышлый егетләр янына сугылып китәргә булды.

— Алла ярдәм бирсен!

— Бирсен. Ни йомыш, бабай?

— Менә җир казыганыгызны күрдем дә килдем әле.

— Кабер кирәк мәллә, бабай? — Озын муенның шулай дип әйтүе булды, пеләш баш шаркылдап көләргә тотынды.

— Кабер кирәк булыр инде ул. Бүген кирәкми иде әле.

— Кирәк булса, казып бирәбез.

— Юк, кирәкми. Минем әле колхозда тавык чүпләп бетерә алмаслык эшләрем бар.

— Колхоз эше бетми ул, бабай. Эш-эш дип үләргә онытма. Колхоз — диңгез, без — корабль. Батабыз да калкабыз.

— Тормышта төрле чак була инде. Батасың да, калкасың да. Сез колхоз өчен бик кирәкле эшкә тотынган әле.

— Без эшнең кирәклесен генә эшлибез.

— Әйбәт итеп эшләгез инде. Нигезе нык булсын. Техника авыр хәзер. Йөкләре дә зур.

— Бабай, син химиянең ни икәнен беләсеңме?

— Химичать итмәкче буласыз мәллә? Шартламасын тагын.

— Шартласа да, сиңа коткарырга туры килмәс.

— Ярдәм кирәк булса, дәшегез. Мин бу эштә азмы-күпме тоз ашаган кеше.

— Бабай, монда килеп «мешайт» итеп йөрмәсәң, иң зур ярдәм безгә шул

булыр. — Өстенә затлы спорт кәчтүме кигән Озын муен Факилнең тирләгән тәненә ябышкан, майга-мазутка баткан кара халатына җирәнгеч караш ташлады һәм теш арасыннан черт иттереп төкерде.

«Зәһәр егетләр. Мондыйлар тотынгач, үлчәү булыр, шәт», дип уйлап куйды Факил.

Инженер-механик шабашниклар янында бүтән күренмәде.

* * *

«Зәһәрләр» эшне кызу тотты. Маркиз телен чыгара-чыгара казыды, дуамалланып измә изде. Атна-ун көндә үлчәү әзер иде инде. Озын муен белән пеләш баш комиссия көтте. Комиссия дигәннәре бензинлы, соляркалы кара халаты тәненә сыланган теге «бабай» булып чыккач, «зәһәр»ләрнең балтасы суга төште. Эшне фәкать инженер-механик кабул итеп алырга тиеш. Тәртибе шундый. Факил эшкә бәяне бер карауда бирде:

— Булмаган бу, егетләр. Гафу итегез, приём-сдача актына кул куя алмыйм. Моны сүтеп-җимереп, яңадан эшләргә кирәк. Монтажлавыгыз ук дөрес түгел. Тайпылыш гади күзгә дә күренеп тора. Баганаларыгызның нигезе дә ташка үлчим. Кем үлчәүне шулай эшли инде?!

Инженер-механикның «кәҗәләнеп маташуы» турындагы хәбәр көне-сәгате белән председательгә барып иреште.

Факилне кәнсәләргә чакырдылар.

— Син нишләп җилгә каршы пес итәсең? — дип башлады сүзне хуҗа. — Син бу егетләрнең кем икәнен беләсеңме? Озыны — замминистрның пеләмәше.

— Хет министрның үзе булсын. Эшне алай эшләмиләр. Әйткән иде диярсез, автовеса озакка чыдамаячак.

Ул арада тормозларын чинатып, машина килеп туктады. Кабинетка кулларына икешәр пакет тотып, Озын муен белән Пеләш баш килеп керделәр. Хуҗа аларга эчтәге бүлмәгә үтәргә ым какты.

— Син кул куй. Үлчәү өчен кайгырма.

— Кул куярга кулым бармый. Үлчәү ватылгач, халыкка, авылдашларның күзенә ничек күренермен?

— Ватылса, шушы егетләрне чакыртырбыз. Рәтләп бирерләр.

— Болармы? Тотарсың койрыкларыннан. Кулларына акча керсә — хуш, авылым! Көндез чыра яндырып та таба алмаячаксың аларны.

— Ярар, юкка башны ватмыйк әле. Баш болай да авыртып тора. Кичә Казаннан кеше килгән иде. Умарталыкта бал кортларына булышып йөргәнбез. Башны төзәтеп алыйк. — Председатель Факилне эчке бүлмәгә чакырды. Инженер-механик ачык ишек аша ул бүлмәдә Озын муен белән Пеләш башның мәш килеп табын көйләп маташуларын, өстәлдә бер тәлинкә чөмәкәй ит, эреле-ваклы шешәләр торуын искәреп алды. Хуҗа кыстап караса да, кермәде, «рәхмәт», диде дә чыгып китте. «Зәһәрләр» ни әйтергә белмичә, бер хуҗага, бер табынга карап алдылар. «Зыян юк, — диде хуҗа, — кул куяр ул — падла, куймый кая барсын?! Куйдыртабыз аны! Әмәлен табармын мин».

* * *

Факил төшке ашка өенә кайтты. Өстәл янына утырган гына иде — мышный-мышный кәнсәләр җыештыручы Бану килеп керде:

— Сине пред чакыра.

— Кайтып җиттемени? Казанда дигәннәрие ич аны.

— Әле яңа кайтып керде. Кайтып керде дә сине чакыра.

Ишекне ачып керүгә, Факилнең борынына идәннәре яңа гына юылган кәнсәләрнең иске кәгазь исе белән тулган дымлы һавасы килеп бәрелде. Хуҗа түрдә

кемгәдер телефоннан шалтырата иде. Факилне күргәч, трубканы атып бәрде һәм, бурлаттай кызарып, шардай кабарып, акырырга тотынды:

— Атам! Без суда и следствия атам! Бүген үк эштән китәсең.

— Чү, тукта әле. Сабыр. Мин ни өчен китәргә тиеш, аңлатып бир.

— Менә моны күрдеңме? Безне язганнар. — Председатель Факилнең алдына район гәҗитен атты.

— Укыдым мин аны. Комбайннарның ремонты Казаннан мин табып куйган запчастьләрне һаман да алып кайта алмавыбыз аркасында тоткарлана. Атна буена сездән машина сорыйм. Машина бирәсез икән — проблема бетә. Шакир малаеның тракторына тагылган сука, чыннан да, күтәрелми иде. Корреспондент кызны күргәч, күтәрелде. — Факил киеренкелекне йомшартып көлеп җибәрде.

Хуҗаның да иреннәре тартышып куйды. Ул инде Факилгә кычкырырлык хәлдә түгел иде. Факилгә эштән китәргә гариза да яздыра алмады. Инженер- механик чыгып киткәч, председатель үзен кая куярга белмәде. Ишекле-түрле йөрде, үзе бертуктаусыз сөйләнде: «Бүген китмәсә, иртәгә китәчәк ул эштән. Абзагызның тоткан җирдән сындырмый калганы юк әле. Күрсәтәчәк әле ул сезгә — авыл гыйбадларына».

Бераздан теге шабашниклар кереп чыкты.

— Үлчәү акчасы шушы көннәрдә кулыгызга керер, — диде председатель.

— Теге кул куйды мәллә?

— Куймады. Куймаячак та.

— Аннан башка акча алып буламыни?

— Әмәлен табармын, дидем ич инде мин сезгә. Бер план бар минем.

* * *

Төш турыларында Бану, ут капкандай, тагын Факилләргә килеп керде.

— Кәнсәләргә, приткә!

Бу юлы Фазылович аны урыныннан торып каршы алды, ике куллап күреште, гәрчә иртән нәрәдтә күргән булса да. Бүлмәдә хуҗадан башка ак күлмәк кигән, аклы-каралы авыш сызыклы галстук таккан бер егет тә бар иде. Факил аны башта районнан килгән бер-бер вәкилдер дип уйлаган иде.

— Факил Нурмөхәммәтович, — председатель аңа беренче тапкыр әтисе исеме белән эндәште. Сез бу эштә матур гына эшләдегез. Техниканы тәртипкә китердегез.

— Аны тәртипкә китергәнче әле…

— Калганын сездән башка эшләп бетерерләр. Безнең терлекчелек бик авыр хәлдә. Сездән ярдәм кирәк. Фермаларга су юньләп килми. Ключиның бер фермасында ул бөтенләй юк. Быел анда үгез бозаулар кертергә исәпләп торабыз. Сез бүгеннән терлекчелек буенча механик. Эшегезне менә бу егеткә тапшырыгыз. Быел гына авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын тәмамлаган. Яшь, энергичный. Эшне дә яңача оештырыр дип уйлыйбыз. Шулай хәл итсәк, ни диярсез?

— Ни дип әйтим. Хәл иткәнсез бит инде. Нигә кети-мети итеп торасыз.

— Сез инженер-механик идегезмени? — егет Факилгә шаккатып карап торды.

«Үзе кечкенә, үзе ябык. Өстендә — ямьсез халат. Изүе ачык. Нинди инженер-механик булсын бу?! Хәчтерүш бу», дигән сүзләрне укырга була иде бу караштан.

* * *

Ключи — очсыз-кырыйсыз урманның борылган төшендә, яшеллекнең куенына кереп поскан кечкенә генә авыл. Солыдан аңа җиде-сигез чакрым тирәсе булыр. Авылга бер генә яктан керәсе. Икенче ягыннан кереп тә булмый, чыгып та булмый. Карурман. Теге көнне председатель әйткән иске фермага су кертергә дип, Факилне менә шушы тупикка җибәрделәр. Дөресрәге, сөргенгә сөрделәр.

Автовеса егетләренең эшен кабул итеп, алар белән исәп-хисапны ясаганчы, аның күзгә-башка чалынмый торуы кирәк иде.

Ключи — серле, моңсу, әллә ниткән шомлы бу авыл. Урамнарында бил тиңентен кычыткан, шайтан таягы. Бу әрсезләр шушындый коры елда да үсә бит. Фермасын эт белән эзләсәң дә табарлык түгел. Ферма димәсәң, хәтере калыр, бәбкәләре сынган, жолаплары чергән, түбәсенең бер башы сытылган, тәрәзәләре коелган, ишекләре каерылган, котсыз, җансыз хәрабәләр. Факил менә шуңа су кертергә тиеш. Төпсез чүмечкә сап кую белән бер бит инде бу. Суны янәшәдәге сыер фермасыннан кертәсе. Анысы да ташка үлчим. Ни сайгагы, ни тагарагы. Сыер дигәнең соңгы тапкыр кайчан булды икән соң монда?! Хәзер әнә талымсыз чытлык-чыпчыклар гына хуҗа.

Ярый, фермасы да, сыеры да булсын ди. Тик кем карар да, кем савар соң ул бичаракайларны?! Авыл урамында ник бер җан иясе булсын.

И Ключи, Ключи!.. Кайларга сибеп бетердең соң кешеләреңне? Өйләреңне дә чәчеп аткансың. Тегендә-монда берән-сәрән кукраеп утыралар. Ни урамың, ни тыкрыгың калмаган.

Факил бер ташландык хуҗалыкның ишегалдына килеп керде. Ватык тәрәзә аша өй эченә күз салды. Аның йөзенә сайгаклары куптарылган идәннән, акшары коелган мич авызыннан, морҗа белән дивар арасындагы ятактан, өйнең түрдәге өчпочмаклы такта кадакланган почмагыннан шомлы дулкын килеп бәрелде. Кайчандыр бу тактада икона, тәре, шәм торгандыр. Хуҗалар шулар каршына килеп, иелә-бөгелә чукынгандыр.

Аннары Факил бакчага күз салды. Өсте ачык калган, чүп-чар белән тулган баз, такталары каралып беткән беседка, кулдан ясап куелган өстәл, эскәмияләр.

Кайчандыр тормыш кайнап торгандыр монда. Кичләрен беседкага чыгып ял иткәннәрдер, алмагачтан тып-тып алма коелганын тыңлап утырганнардыр. Бу йорт, бу бакча белән бәйле күпме истәлек-хатирәләр бардыр. Көннәрдән бер көнне шуларның барысын да ташла да чыгып кит инде. И язмыш. Кеше язмышы, авыл язмышы.

Факил беседкага кереп, эскәмиягә утырасы итте. Идәндә уенчык трактор аунап ята иде. Аны күргәч, Факил бетте генә инде. Шушы трактор белән «тр-р-р-р» дип уйнап йөргән малайны күз алдына китерергә тырышып карады ул һәм үзен дә яраткан уенчыгын җуйган сабый хәлендә калгандай хис итте. Аның тракторын тартып алдылар. Алай гынамы соң, гүя таш атып, чабыш атының аягын сындырдылар, гүя пуля тидереп, күктә очып барган кошның канатын имгәттеләр.

...Факилне үз уйлары белән калдырып торыйк та колхозның гаражына кайтыйк әле. Яшь инженер-механигыбыз да бүген яңа эшкә чыкты. Рәвеш шәп: ак күлмәк, үтүкләнгән чалбар. Галстукны алмаштырган, бу юлы чәчәклене таккан.

— Факил абый кайда соң? — дип сорады аннан яңа инженер-механик килгәнен белеп алган Нур, майлы кулларын чүпрәккә сөртә-сөртә.

— Абзарда. Аны фермага куйдылар. Карап-карап торам да, бардак сезнең монда.

— Нинди бардак?

— Техникагыз бер рәткә тезелеп тормый.

— Парад кабул итәргә килгән генерал түгелсеңдер бит.

— Мин — инженер-механик.

— Бездә инженер-механик берәү генә — Факил абый! Мондый ак күлмәкле инженерны белмибез без.

— Белмәсәгез — белерсез, — егет җил-җил атлап китеп тә барды.

Туры кәнсәләргә юл тотты ул. Исәбе председательдән үзенә бер бүлмә сорау иде. Хуҗа Казанга киткән икән. Кайчан кайтасы билгесез. Хәлбуки, ул үлчәүне кабул итү актына яңа инженер-механиктан кул куйдырып өлгергән, шабашниклар шул көнне үк акчаны алып тайган иде.

Кичкә таба председатель шалтыратып алды. Бухгалтер Сәкинә аңа тракторчыларның,

шофёрларның, гаражда эшләүчеләрнең җыелышып кәнсәләргә килеп керүләрен, Факилне эштән алган өчен ризасызлык белдерүләрен җиткерде. Нурның «Уборкага төшәр алдыннан ниткән башбаштаклык бу!» — дип кычкыруын да әйтте.

...Факил уенчык тракторның тузаннарын өрә-өрә очырды. Шул мәлдә колагына бер тавыш килгәндәй булды. Кемдер өй каршыннан сызгыра-сызгыра үтеп бара. Чыгып караса, кояшта кубалакланып беткән борынлы, тез башлары кубарчыкланып кутырлаган бер малай.

— Нихәл, яшьти! — диде Факил, шаяртып.

— Әйбәт.

— Нәрсәсе әйбәт инде? Бер кеше юк авылыгызда.

— Нишләп булмасын — Призрак бар. Урман очында яши ул.

— Нинди Призрак?

— Бер бабай шунда. Аны Призрак дип йөртәләр.

— Ирләр тагын бармы соң?

— Бар.

— Кайда соң алар?

— Әнә анда аста, Угрюм рекада.

— Син нигә сызгырып йөрисең соң?

— Сызгырмыйм мин. Җыр ич ул.

Малай «җыр»ын дәвам иттереп, трусигын җилфердәтә-җилфердәтә китеп тә барды.

«Угрюм река». Нинди елга ул? Ирләр нишли анда? Нишләп «Угрюм река» ул? Андый роман бар. Факил аның татарчасын укыды. «Хәсрәт дәрьясы» дип атала. Факилнең аяклары үзеннән-үзе аска, елгага таба атлады. Төшкәч күрде: елга үзе, ачуым бер килмәгәе, чыпчык тезеннән генә. Яр буенда ике ир заты утыра. Яннарына килеп сөйләшкәч, боларның күршедәге Почык авылында шабашкада булуы, кичә эшне тәмамлаулары, шуны «җуулары», бүген баш авыртудан интегүләре мәгълүм булды. Моңсу күзләрен яр буендагы тәрәзәләренә такта кадакланган, ишегенә зур йозак эленгән йортка төбәгәннәр дә, бу дөньяга ник туганнарына үкенеп утыралар. Бу — элекке кибет. Күптән түгел генә япканнар. Шуннан соң бу елга «Угрюм река»га әйләнгән. Факил эченнән генә болай уйлады: «Дөрес кушканнар бу исемне елгага. Тик монда бәла баш төзәтергә хәмер таба алмауда түгел. Хәсрәт тирәндәрәк. Авыл җан биреп ята. Язмыш күпме гаиләләрне туган өйдән, туган туфрактан кубарып алып киткән. Ключиның шәп чаклары бар иде бит. Сугышта аягын өздереп кайткан, шуңа карамастан протез белән комбайнда эшләп, «Октябрь революциясе» ордены алган легендар Добрынин авылы бит бу. Факилнең аңа төн уртасында запчасть алып кайтып биргән чаклары булды. Дуслар иде алар. Очрашсалар, сөйләшеп сүзләре бетми иде. Тракторчы Вагыйз Хановны ал. Җәйләрен Солыдан тракторы белән караңгы төшкәч кенә кайтып китә, иртән көтү куганчы килеп җитә иде. Кайчан гына йоклагандыр ул. Менә шушы Ключи бүген «Призраклар авылы»на әверелгән. Факилнең монда күптәннән булганы юк иде. Авылның бетеп баруын ишетеп торды. Хәзер Ключидан кәнсәләргә нәрәдкә килүче дә юк. Председатель авылның шушындый хәлгә төшүен белгәндер бит инде. Иләк белән су ташырга җибәргән түгелме соң ул Факилне. Бәлки өрәкләр янына юри җибәргәндер.

Факил Хәсрәт дәрьясының үзенең тамырларында куллары, аяклары буйлап акканын, йөрәгенә кан сава башлавын тойды.

* * *

«Тагын килдем әле сиңа. Күптән күрешкән юк. Бик сагындым үзеңне. Басуларда игеннәр өлгереп килә. Алда сине тагын зур эшләр, зур сынаулар көтә.Быел да йөкнең иң авырын сиңа күтәрергә туры килмәгәе. Теге шабашниклар калдырып киткән «брат»ың үле туган бала булып чыкты ул.

Уңыш әйбәт быел. И күрсәң ул арыш, бодай кырларын. Офыктан офыкка аксыл-саргылт дулкыннар йөгерә. Бөртекләр ашыга. Амбарларга, келәтләргә керергә, кешеләрне шатландырырга ашыга. Куаныч һәм өмет олаулары булып, кырдан туптуры сиңа кайта бит алар. Ипи төягән машиналар синең биеп- селкенеп торган, кытыршы, шырпылы идәнеңә орынып уза.

Син әйтеп торасың:

— Фәлән тонна.

— Төгән тонна.

Шунысын да белеп тор: бу дөнья, бу тормыш син әйткән саннардан гына тормый. Анда шәфкать, игелек, миһербанлык бар. Бар анда башбаштаклык, рәхимсезлек, явызлык, кабахәтлек, мәкер, ялган. Син аларны үлчи алмыйсың. Кешенең кичерешләрен, түккән күз яшьләрен, михнәт-газапларын үлчи торган үлчәү-бизмән булса... Ул нинди зурлыкта булыр иде икән?! Ләкин аларны да үлчәп торучы бар.

Ул — күңел.

Ул — бәгырь

Ул — йөрәк.

Кеше күңеле, кеше бәгыре, кеше йөрәге. Бик сизгер бизмәннәр алар. Йөрәк тә синең кебек туза-таушала. Комсызлар, тар күңелле бәндәләр, хөсетлеләр, кабихләр, кара йөзләр, адәм актыклары таушата аны. Кеше башына кеше җитә, дип юкка әйтмиләр.

Сине дә, мине дә зур сынаулар көтә. Түз!»

* * *

Шул китүеннән председатель авылда бүтән күренмәде. Утсыз төтен булмый, диләр. Аның Казанга китәчәге, колхозга яңа председатель киләчәге турында имеш-мимешләр таралган иде инде. Алар тәки дөрескә чыкты. Башкалага киткән хуҗаның кая урнашканын тәгаен әйтеп бирүче бумаса да, «урында эшләячәк икән», диделәр. Инженер-механикны эшеннән алып, өрәкле авылга җибәрүе, үлчәүне кабул итү актына тиз-тиз кул куйдырырга тырышуы юкка булмаган. Бар шундый кешеләр — алар үзләренең максатларына ирешер өчен башкаларны таптап, изеп, сытып китәләр. Андыйлар хәтта хыянәттән дә, җинаятьтән дә чирканмый.

Яңа председатель дә үзен озак көттермәде. Район башлыгы кызыл битле, кара калын кашлы бер ир затын ияртеп килде дә шалт итеп куеп та китте. Болай үзе төпле, сабыр кеше күренә. Төньяктан әче җил исеп, яңгыр сибәләп торган ямьсез көн иде ул. Шуңадырмы клубка кеше әллә ни күп килмәде. Җыелыш тыныч узды. Буза куптаручы булмады. Хәер, яңа хуҗа булсынга эшләп йөргән инженер-механикның яңа гына эштән алынуын, бу җәһәттән механизаторларның тавышланып йөрүләрен ишеткән иде инде.

«Нишләргә соң? Эшне шау-шудан башлыйсы килми. Мәсьәләне хәл итәргә кирәк». Яңа хуҗа шулай баш ватып утырганда, кабинетка Ак күлмәк үзе килеп керде. Элекке председатель киткәч, ул бер-ике көн авылда күренми торган иде.

— Миңа шушы кәнсәләрдән бер кабинет бирегез! — диде ул, бернигә дә исе китмәгән кыяфәт белән.

— Нинди кабинет сорыйсың син? — Яңа хуҗа аңа гаҗәпләнеп карады.

— Кәнсәләрдә инженер-механикның кабинеты булырга тештер бит.

— И энем, энем, монда нинди кабинет булсын соң? Синең кабинет гараж инде.

— Гаражда салкын. Миңа тёплое помещение кирәк.

— Колхозда инженер-механикка нинди тёплое помещение инде ул?!

Егет шул көнне хушлашып китеп тә барды.

* * *

Дөнья шулай бер болганып алды да тынды. Гали дә — үз эшендә, Вәли дә үз эшендә, дигәндәй, Факил яңадан инженер-механик булды. Яңадан көне-төне гаражда ятасы, техникасы эштән чыккан механизаторларның зарын тыңлыйсы, запчасть эзлисе, ереле-ваклы түрәләрнең ишек төбен таптыйсы, юл газапларын күрәсе, мазутка-майга батасы. Булсын сана. Ни дисәң дә, белгән, яраткан эш. Ключи сөргененнән соң тимер-томыр сагындырып та өлгергән. Механизаторларның кәнсәләргә килеп «бунт күтәрү»ләрен ишеткәч, аның күңеле тулды, күзеннән яшь бәреп чыкты, эшкә тагын да катырак ябышты.

Бүген дә ул юлда. Запчасть эзләп Казанга барышы. Сумкасында — каклаган каз. Җимсез балык капмый. Каз үзләренеке. Һәр язда өйдә кырыклап бәбкә аваз сала. Хатыны Рәкыя алар белән мәш килә. Кош-кортның рәтен белә, дигән даны бар. Галәмәт зур, симез була аның казлары.

Артыштау стансасында Казанга поезд көтеп йөргәндә, күрше кызы Фәһимә очрады. Әгерҗе ягында кияүдә ул. Оныклары белән авылга кунакка кайтышы икән. Үзгәрмәгән. Һаман да шул, теге вакытта Факилләрнең бакчасына кереп, турникта «кояш» ясарга маташкан, күрше егете Факилгә гашыйк булып йөргән Фәһимә. Янып торган битле, җаныңны, тәнеңне пешерерлек кайнар сулышлы.

— Теге вакытта оялуымнан нишләргә белмәдем, Факил абый. Җир ярылса, кереп китә идем, валлаһи. Турникта әйләнәм, имеш. Синең кебек мәтәштермәкче булам. Мәтәштерерсең, бар! Ярата идем бит мин сине, күрше. Прәме гашыйк булып йөрдем. Син өйләнгәч тә, запискалар җибәреп тордым әле.

— Ах, җүнсез, син язган идеңмени әле аларны?!

— Мин язган идем, Факил абый. Ачуланма инде. Яшь чак — җүләр чак. Хатыныңны көнләштерәм янәсе. Ярый Рәкыя акыллы булды. Тавыш куптармады. Аннары мин дә туктадым.

— Тормышың түгәрәк инде синең, алайса?..

— Аллага шөкер. Үзем колхозда сыер савам. Ирем — мал духтыры. Биш бала үстердек. Өч кыз, ике малай. Өчесе башлы-күзле булды. Бер кызны кияүгә бирәсе дә, бер малайны өйләндерәсе бар. Печәнне, курмыны җитәрлек әзерләдек. Уттай кызу эшләрдән соң авылга кайтып килергә булдым. Үзеңнең кая барыш та, нишләп йөреш?

— Минем эш бер инде — көне-төне запчасть артыннан чабам.

— И-и-и... безнең кохозның инженеры да кайтып керми. Бездә Чыңгыз Мусин дигән тагын бер инженер-механик бар әле. Байтак еллар мытыеста да эшләде ул. Ирем яхшы белә аны. Шул аптыраганнан шигырь язган:

Бушадылар шешәләр,
Бушадылар кесәләр.
Упкыннарга төшәр идем,
Запчасть шунда дисәләр.

— Күр әле, ничек шәп әйткән. Үз башына төшкән кеше генә яза ала мондый шигырьне. Әле дә менә шул запчасть дип Казанга, Арбузовларга барыш.

Шулвакыт Фәһимә янындагы ике карачутыр оныкның берсе:

— Казанга, карбыз алырга, — дип әйтеп куйды.

Факил дә аларга Арбузовларның бөек галим-химиклар булуын, алар җитәкләгән институтның колхозны шефлыкка алуын, шул шефларны авылда «арбузовлар» дип йөртүләрен аңлатып тормады.

Институтта Факилне һәрвакыт үз итеп, әйдүкләп каршы алалар. Монда эшләүчеләрнең байтагы — авылдан чыгып, хәзер калада урман-кырларны, болын-тугайларны, чишмә-елгаларны сагынып яшәүчеләр. «Колхозник абый» белән

сөйләшеп утыру тансык үзләренә. Тагын шунысына бик мәмнүн алар: «дерёвня» буш кул белән килми. Кучтәнәч белән килә. Кутәнәчнең дә нindие бит әле — капкач авызда эри торган каклаган каз! Бу килүендә дә арбузовлар эшне тиз тотты, Факил бирәсен — биреп, аласын алып кичке поездга өлгерде. Ходайның рәхмәте, стансадан да җәяү төшәргә туры килмәде. Поезд каршына ат җигеп Сабир менгән иде.

— Минем кыз күренмәдеме анда? Кайтырга тиеш иде, — диде Сабир, кыяр-кыймас кына.

Җәй буена көтә инде ул кызын. Ике көннең берендә стансага менә. Кызы Казакъстанда аның. Кайтмаганына ун ел. Хәбәре дә юк. Әнисе аның рухына дога кыла башлаган иде инде... Быел яз саесканнардан хәбәр килде. Әллә Иделнең, әллә Чулманның аръягындагы авылларның берсенә Кзакъстаннан бер кыз кайткан булган, имеш. Шул: «Артыштауның Солы кызы Гөлсирә белән бер бистәдә яшибез. Ул да җәй авылга кайтып киләсе булыр дип сөйләшә», — дип әйткән, имеш.

Җәй үтеп бара. Гөлсирә күренми. Сабир кызганыч, ун ел аңа «әти» дип эндәшүче юк, ун ел инде аның «нихәл, кызым» дип әйткәне юк.

И Сабир, Сабир. Кайтасы кеше бер кайтыр иде инде. Ун ел хәбәрсез йөрмәс иде. Беркатлылыгың белән, саескан хәбәренә ышанып, кысыр өмет белән йөрмисең микән.

Хәер, кысыр булса да, өмет бит ул.

* * *

Бүген Бану Факилне гаражда эзләп тапты һәм әлеге дә баягы ике сүзен әйтте:

— Кәнсәләргә, приткә!

«Бу юлы эштән ни өчен куалар икән инде...» — дип уйлап куйды инженер-механик.

Факил килеп керешкә, председатель урыныннан торып басты. Өстәленнән чыгып, каршысына килеп, кул биреп күреште һәм бер генә сүз әйтте:

— Коткар!..

— Үлчәүме?

— Үлчәү.

— Җимерелдеме?

— Җимерелде.

— Аның җимереләсе билгеле иде инде. Ну болай бик тиз җимерелер дип уйламаган идем. Бисмилласыз эш. Ордым-бәрдем эшләделәр шул...

— Беләм, Факил, беләм. Эшләп бир инде. Мин сиңа шуның өчен ике капчык бодай бирермен.

— Рәхмәт! Ике капчык бодайны кесәгә тутырып та ташыйлар аны.

— Уракка төштек бит, Факил. Икмәк күп быел. Лафетлар иске үлчәүгә сыймый. Икмәк хакына эшләп бир.

— Икмәк хакына мин риза. Тик шунысы бар: бу автовесаны корудан бигрәк сүтүе авыр булачак.

Чыннан да, үлчәүне җимерә-җимерә, Факил җык булды. Ашавын онытты. Йокысы качты. Шабашникларның дөрес монтажламаулары — бер хәл, күпме цемент, бетон әрәмгә киткән.

Факил шабыр тиргә батып, нервланып, таш кисеп ятканда, янына кызы Ләйсән килде. Ул пединститутны тәмамлап, Казан мәктәпләренең берсендә укытып йөри. Өченче көн кунакка кайткан иде. Китеп барышы икән.

Автобус тукталышы үлчәү янында гына. «Әтисе белән саубуллашырга килгән», дип уйлады Факил. Әмма кызы үтенеч белән килгән иде:

— Әти, сумкамны автобуска кертеп куялмассың микән?

— Сумкаң авырмыни?

— Авыр түгел.

— Авыр булмагач, үзең күтәрәсең дә алып керәсең инде. Минем аркадан пар чыга. Эшем күп. Син пүчтәк бер сумка белән баш катырып йөрисең.

Ләйсән, башын аска иеп, теләр-теләмәс кенә китеп барды. Аның китүен аста — чокырда лом белән бетон ватып яткан Факил сизми дә калды. Ул кызын бүтән беркайчан да күрә алмады.

Икенче көнне Казаннан улы Вахит, апаны бүлнискә салдым, дип хәбәр итте.

* * *

Рәкыя зиратка килде.

Тынлык.

Шом.

Сагыш.

«Кызым Ләйсән, әнкәй», — диде ул шыпырт кына һәм чардуган аша үрелеп һәркайсының салкын кабер ташларын сыпырып алды. Коръәннән сүрәләр укыды. Аннары кушучын иягенә терәп диярдәй укыганнарын багышлады: «И Раббым! Барлыгыңны, берлегеңне белгән хәлдә укыдым Синең хакый хөрмәтеңә. Хата вә кимчелекләре өчен гафу итеп кабул итеп ал. Бу укыганнарымны пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа рухына ирештерсәң иде. Бу укыганнарымны барлык-барлык пәйгамбәрләребез рухына ирештерсәң иде. Бу укыганнарымны ошбу зиратта яткан әнкәй Хәтирә, кызым Ләйсән рухларына ирештерсәң иде...»

Төнлә Рәкыя тирләп-пешеп уянды. Факилне дә уятты һәм яңа күргән төшен сөйләп алды:

— Телефон шалтырый. Бала тавышы. Үкереп елый бер малай. Елый да елый. Аннары трупканы мәрхүм әнкәй алды: «Ишетәсеңме? — ди кырыс кына. — Ашарга сорый ул бала. Ашарга. Аңладыңмы?!» Беләсеңме, кем ул? Мин трактордан сикергәч, үле туган улыбыз. Коръән чыксак та, аш уздырсак та, дога багышлаганда аны оныткanбыз бит. Кичә зиратта да аны әйтми калдырганмын, укыганнарымны Ходайдан аның рухына ирештерүен сорамаганмын. Аңа да бит карында җан иңгән булган. Ул малай туганчы ук, Вахит аңа исем табып куйган иде. Вафа.

Иртәгесен Рәкыя, табын әзерләп, мулла чакырды.

* * *

«...Килдем. Тагын килдем. Нихәл? Күңелем тулганда, эчем пошканда, йөрәгем авыртканда сиңа киләм. Синең яныңа килү — яраткан балам янына килгән кебек. Хәер, тагын кемгә килим инде мин. Улым үле туды. Кызымны да җирләдем. И кызым. Соңгы кайтуында аны эчендә яман чир кимереп ятканын белгән булсам, автобуска сумкасын гына түгел, үзен күтәреп керткән булыр идем. Өенә кадәр илтеп куйган булыр идем. Бер тиенгә ярамаган эш эшләп, кесә тутырып акча алып, авылны мыскыллап, бездән көлеп киткән теге бәдбәхетләрнең үлчәвен сүтеп-җимереп яткан чагым иде шул. Ачу чыккан чак. Шунда кызыма күтәрелеп карарга да вакыт тапмаганмын. «Авыруы йөзенә чыккан иде инде», — ди хатыным Рәкыя. Ул сумкасын күтәрергә дә хәле булмаган Ләйсәнне тукталышка озаткан. Кучтәнәчкә каклаган каз тыгарга онытkan. Кире өйгә йөгергән. Ул арада Кирәмәт тавында автобус та күренгән. Менә шул вакытта кергән булган инде ул үлчәүгә, минем янyма. Казанда Вахит күпме тырышса да, апасын коткарып калалмады. Ярый әле улым Вахит исән-сау. Тырыш, тәүфикълы малай. Кремльгә каршы гына, Казансу буенда әллә ун, әллә унбиш катлы бер бинада утыра ул. Эше тыгыз. Авылга кайтырга да вакыт таба алмый. Безнең якка командировка-мазар булганда, үтеп барышлый кереп чыга. Вахитыбыз кайта дип әнисе бәлеш пешерә, мин мунча ягам. Ул исә кабыл-тибел бер чокыр чәй генә эчә дә китеп бара. Рәхәтләнеп сөйләшеп

тә булмый. Вахит киткәч, әнисе җөгенеп берәр көн урыннан тора алмыйча ята. Улыбыз үзе бик мәрхәмәтле. Акчасын, күчтәнәчен гел биреп, җибәреп тора. Үзен генә туйганчы күреп булмый. «Ни хәлең бар, улым?» — дип тә сорый алган юк.

Әнә тукталышта Маркиз басып тора. Озын муен белән Пеләш баш аны эшләттеләр-эшләттеләр дә бер тиен акча бирмичә киткәннәр. Ул ахмак беркатлы, мәхлук җан ай буе шуларны көтеп йөри. Тегеләр килеп, акча бирерләр дип ышана. Алырсың эт авызыннан сөяк. Ул кабахәтләр җүләрне эшләтеп өсләренә бер гөнаһ алсалар, инде шушы бичара ятимнең өлешен ашап, икеләтә гөнаһлылар.

Кичә тагын басулардан үттем. Игеннәр дулкынлана, йөгерә, ашыга. Сиңа ашыгалар. Тизрәк үлчәүгә керергә ашыгалар. Аллага шөкер, яңа үлчәүне дә эш итеп бирдем.

Без — Адәм балалары да, шул игеннәр кебек: ыгы-зыгы киләбез, чабабыз, кабаланабыз, ашыгабыз.

Без — Адәм балалары да, шул игеннәр кебек, офыкка омтылабыз.

Без — Адәм балалары да, шул игеннәр кебек, офыкка җитеп күккә ашкач, үлчәүгә килеп керәчәкбез.

Беркайчан да ялгышмый, тузмый торган бердәнбер үлчәүгә.

Бу — Аллаһы Тәгалә үлчәве!

Иң дөрес, иң төгәл, беркайчан да ялгышмый торган үлчәү.

Аңа беркем дә кермичә калмый. Озын муен белән Пеләш баш та, шул ук Фазылович та басачак анда. Басачак һәм кылган гөнаһлары өчен җавап бирәчәк.

Кеше үз гомерендә бик күп үлчәүләр күрә. Дөрес үлчәгәнен, дөрес үлчәмәгәнен. Үзе дә бихисап бизмәннәр аша уза. Ул үлчәүләрнең дә төрлесе бар. Күпме адәм заты бу дөньядан үзенә тиешле бәяне алалмый китә. Күпме адәм заты нахак сүз ишетә.

Бу бизмәннән без бер бизгән идек,
Безне тагын тезеп үлчиләр.
Барлы-юклы бизәкләрне бозып,
Безнең биздән бизнес ясыйлар.

Үчләнмим мин ошбу үлчәүләргә,
Гөрәнкәгә дәген, гергә дә.
Бу дөньяда адәм балаларын
Үлчәп иңдерәләр гүргә дә.

Моны кем язган дисең? Улым язган! Мунча мичендә яндырырга дип алып кайтып аткан кәгазьләре арасыннан килеп чыкты. Газапланып язган, сызгалап-бозгалап бетергән. Шигырь язганы юк иде аның. Каян чыккандыр. Повестьлар, хикәяләр яза ул.

Мин синең хәлеңне белергә килгән идем, балам. Ачуланма инде, гел үземнекен сөйләдем. Синең яннан китәсе дә килми, балам».

* * *

Күктә кояш күзне чагылдырып яна, тургайлар аның нурларын китеп-китеп, ватып-ватып, телеп-телеп җиргә чәчә. Шушы чәрдәкләнгән, чәлпәрәмә килгән якты моң өстеңә сибелә-чәчелә. Күңел тырысыннан ташып чыга да игеннәрнең дулкынына ияреп офыкка ага, ага, ага…

Менә ул — тормыш, аның асылы, мәгънәсе, рухияте. Шуны аңыбызга сеңдерергә тырышып, игеннәр ага, ага, ага…



Мөхәммәт Садыйков

# ТАМЫР ҖӘЙДЕК ТУГАН ТУФРАККА

## Безнең буын

Без хәрефләр танып өйрәнгәнче,
Тормыш безне эшкә өйрәтте.
Сугыш елларында үскәнгәдер,
Без – куркусыз, батыр йөрәкле.

Аударылган тирәк тамырыдай,
Тал чыбыктай үстек як-якта.
Мәңге аумас, мәңге корымас булып,
Тамыр җәйдек туган туфракка.

Көзге кырда уҗым булып шыттык,
Язгы кырда буйга үрләдек.
Кайгыларны эшкә җигә белдек,
Җиңә белдек, җиңелә белмәдек.

Аты бетсә, үгезләрен җиктек,
Камытын да кидек муенга.
Корабльдә Галәм иңләргә дә
Насыйп булды безнең буынга.

## Авыл һаман шулай

Авыл һаман икмәк, катык ашый…
Ир кендеге җиргә береккән…
Ямьле яздан сары көзгә чаклы
Гел басуда… Эшләп күнеккән.

Ал таңнарга карап, ак өметтә
Авыл агай һаман уйлана…
Җиргә хуҗа булып, теләгәнчә
Яшәү насыйпмы соң дөньяда?!

Мөхәммәт САДЫЙКОВ (1934) – *шагыйрь; «Зәңгәр юллар», «Дуслык», «Яшьлек таңы» һ.б. китаплар авторы. Россиянең халык мәгарифе отличнигы. Питрәч районы Шәле авылында яши.*

Авыл һаман икмәк-катык ашар,
Чәй кайнатыр чишмә суыннан...
Бал кортлары таңнан кичкә кадәр
Нектар ташыр басу-болыннан.

Авыл һаман матур төшләр күреп,
Таң нурлары белән уяна.
Пакь күңелдән ак өметтә яшәп,
Якты киләчәген уйлана.

Авыл һаман икмәк-катык ашый.
Шулай яши элек-электән...
Ил язмышы – ир һәм җир язмышы
Тир, кан белән бергә береккән.

## Парсызлар

Ярын җуйган Адәм яшь яр табар,
Парын җуйган кошка – һәлакәт.
Адәм баласын да, кошларны да
Утка-суга сала мәхәббәт.

Сандугачлар ялгыз яши алмый,
Тугры кала мәрхүм ярына;
Йә таш ярга төшеп бәрелә ул,
Йә йөрәге шартлап ярыла.

Тормыш кыенлыгын яра-таптый,
Мин яшәүгә сусап яшимен.
Яшен уты бәреп юлга төшкән,
Чуер ташка калган кеше мин.

## Яшәүче көч

Иген игеп, маллар көтеп була,
Бизеп була җырдан, шигырьдән.
Иң яманы: сөю-мәхәббәттә
Тиң яр тапмый китү бу җирдән.

Акылыңны чуалтырга була,
Уйлап йөрсәң төн дә, көндез дә...
Гашыйк җанны үтерергә мөмкин
«Сине сөймим» дигән бер сүздә.

Туң котыпка илтеп япсалар да,
Яшәүдә зур мәгънә бар – беләм...
Сөрген-каторганы кичеп була,
Яшәгәндә сөйгән яр белән.

## Җәяү генә кайтып килешем

Туган якта үскән әремнәр дә
Мине сагынып, көтеп торганнар.
Мишә болыныннан яулык болгый
Сөт болыты кебек томаннар.

Яшь чыршылар ымсындыра мине.
Охшаганнар сөйгән ярыма.
Яшь куаклар энеләрем булып
Шинель итәгемә сарыла.

Тигез сафка басып, солдатларча
Яшь наратлар чыга каршыма.
Генералдай өлкән нарат кала,
Олы кулын куеп кашына.


Миләшләрем суза тәлгәшләрен,
Гөлҗимешләр – татлы җимешен.
Сандугачлар моңын тыңлый-тыңлый,
Җәяү генә кайтып килешем.

Балаларча ятып аунар өчен
Кочак ачкан таныш аланым.
Ерак илләр гизгән ир булсам да,
Туган туфрак өчен бала мин.

## Шагыйрь истәлегенә

*Ринат Рәхимовка*

Үсмәсен дип, алмагачның
Тамырын чабып була;
Сайрамасын дип, кошчыкны
Читлеккә ябып була.
Язмасын дип, шагыйрьләргә
Ялалар ягып була;
Салларга бәйләп агызып,
Утларга салып була.
Мәсхәрәгә түзеп була,
Сөйгәнеңне сөйсәләр,
Дуэльгә чакырып була,
«Син – дошманым», дисәләр…
Яралардан үлеп була,
Туган туфракка ятып,
Дошманыңның маңгаена
Соңгы пуляны атып…
…Ничә киссәң дә үсәләр…
Талларны була кисеп…
Мишә буйларында йөрдем,
Шагыйрь дус искә төшеп.
Бары да була… тик шагыйрьне
Булмый кабат терелтеп…
Фанилыктан бакыйлыкка
Китте гомере үтеп.



Рашат
Низами

# БЛОКАДА ХАТИРӘСЕ

ХИКӘЯ

## I

Сугышның дүртенче елы бара иде. Кызыл Армиянең Ленинград блокадасын өзүе, Украина һәм Белоруссия җирләрен немец илбасарларыннан азат итү турындагы куанычлы хәбәрләрне авыл халкы шатлыклы күз яшьләре һәм өмет-ышаныч белән каршы алды. Шулай булмый ни – йорт-каралтысыннан чыгып киткән ирләрнең, әле юньләп мыек та чыгып өлгермәгән яшь егетләрнең язмышы турында «Батырларча һәлак булды», «Хәбәрсез югалды» дигән хат-хәбәрләр күпме йортларның ишеген шакыды. Инде менә, насыйп итеп, җиңү көннәрен тизрәк күрергә язсын иде...

– Зимагур Нурмый сугыштан кайткан!

Бу хәбәр авылның олысын-кечесен дигәндәй «дерт!» итеп аякка бастырды. Әнә, узган ел аның хакында да «Хәбәрсез югалды» дигән кара кәгазь килгән иде. Менәтерә, исән икән бит, яңак сөяге чәрдәкләнгән булса да, аягында нык басып йөри икән үзе, дигән хәбәр минуты-сәгате белән күпләрнең ихатасына барып иреште.

Моның шулай икәнлеге тиз арада ачыкланып та өлгерде. Донбасс якларыннан «Зимагур» кушаматы ияртеп кайткан гаярь Нурмый югалып кала торганнарданмы соң – аңарда бабасыннан килгән татар каны ага лабаса! Каян-ничек юнәткәндер (монысын тәгаен генә берәү дә белмәде), егерме җиде яшьлек Нурмый акча белән кайткан иде.

Кибеттән ике шешә аракы күтәреп чыкты да кибет арты чирәмендә көтеп утырган санаулы ирләрне сыйларга кереште ул. Бушлай бит, күзгә кырып кына сала торган зәхмәт суыннан баш тартучы табылмады. Авыл хәлләрен, фронт вакыйгаларын сөйләшеп, күңелне азмы-күпме бушату өчен бер дигән сәбәп иде бу.

Нурмый, кушаматы «Зимагур» булса да, бик ачылып китмәде, күбрәк авылдашлары сөйләгәнне тыңлады. Нәрсә-нәрсә, күкрәк кагып мактана белми иде ул. Аның Ленинград блокадасы турында сөйләгәннәрен исә йотылып та, сораулар белән бүлдереп тә тыңладылар.

---

Рашат НИЗАМИ (1950) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Кызыл кар яугач», «Ут һәм җыр», «Тормыш трамвае», «Алдым каләм кулыма» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

– Немец дигәннәре бигрәкләр дә явыз булып чыкты, анасын сатыйм! Җирдән дә, һавадан да шәһәрне бертуктаусыз утка тоттылар. Шундый сәгатьләрдә күк йөзе кара төтенгә күмелә, көн белән төнне аермас буласың, хәерсез. Безнең зениткалар «тәре»ле самолётларны бәреп төшергәндә, бомбалардан да курыкмыйча, сикереп торып кул чаба идек, валлаһи!..

Мактана белми дисәк тә, күлмәк төймәләрен аска табарак чишеп җибәргәннән соң Нурмыйның күкрәге киңәеп киткәндәй була. Иң мөһиме – менә шулвакыт күлмәк эченнән кигән буй-буй сызыклы тельняшкасы да күрер күзгә мул ачылып китә аның. Диңгезчеләр генә кия торган аклы-зәңгәрле бу тельняшка кемнең генә игътибарын үзенә җәлеп итмәс икән!

Колхоз бригадиры аксак Шакир түзми, сүзне нәкъ менә шул якка таба борып җибәрә:

– Ниме, Нурмый энем… Ленинградта булгач, син инде теге атаклы «Аврора»да хезмәт иткәнсең түгелме? Тельняшкаңны әйтәм, шунда кидергәннәр, ахры, үзеңә…

– Юк, авылдашлар. Алдашсам, гөнаһ булыр, – диде Нурмый, ихлас әйткәнен сиздереп. – Ладога күле аша блокада сугышчыларына, шәһәр халкына корал һәм азык-төлек ташыдык без. Җигүле атларны исәпләмәгәндә, төп транспорт полуторка иде. Дүрт көпчәкле әлеге машинаның рулен кулымда байтак боргаларга туры килде миңа… Рейсларның берсендә йөкне Фин култыгындагы безнең корабларга бушаттык. Менә шул чакта, рәхмәт йөзеннән, матрослар бүләк иткән иде аны миңа…

Ә инде ерактагы, әллә кайдагы сугыш хәлләре турында сөйләгәндә, «әйдәгез…» дия-дия кыстап куйгалаганда, авылдашлары каршында Нурмыйның абруе бер карышка үсеп китте, билгеле.

– Ул Лилин шәһәрендә каты ачлык булган, диделәр. Халык ничек түзде икән? – диде ферма каравылчысы Баһаветдин агай, үзенең дөньядан ул кадәр үк бихәбәр түгеллеген искәртергә теләгәндәй.

Китапча сүзләрне кай арада табып өлгергәндер:

– Ачлык патша рәхимсез кыланды шул, – дип авыр сулады Нурмый, чалбар кесәсеннән махра янчыгын тартып чыгарганда. – Әйе, парин, бомба һәм снарядлар белән генә тезләндерә алмагач, немец дигәнең шәһәр халкын ачлык белән буарга керәште… Юньләп ризык күрмәгән адәмгә каян килсен ди көч? Кышкы салкында шакырдап каткан кеше гәүдәләре күз алдыма килсә, әле дә аркамнан кырмыскалар йөгергәндәй була…

– Суга да интеккәннәрдер инде, – дип, арадан кемдер аны куәтләп куя.

– Дөрес әйтәсең, агайне. Шәһәрдә канализация җимерек. Суны халык каян ала, кайдан табамы? Кышын, боз ватып, елгадан яки күлдән ташый иде. Узган елны кыш, ай-һай, зәһәр килде. Кошларга хәтле очып барган уңайдан таш кебек җиргә егылып төшә иде. Бервакыт, су чиратында, боз өстенә егылып төшкән бер кошчык өчен ике хатынның тарткалашуын күреп, имәнеп киткән идем. Шулпалык ит өчен талашулары булган икән…

Байтак гыйбарәләр ишетеп, әнә шулай таралыштылар. Сүз арасында бер мәлне Нурмыйның «Катя-катюша» дип кинәт талпынып куюын һәм кулына ничек итеп пистолет эләктерүен авылдашлары аңлап та бетермәделәр. Әйе, Нурмый сугышта һәм блокадада күргәннәренең барысын да сөйләп бетермәде шул. Аның урынында башка берәү булса, һичшиксез, китап язар иде. Ләкин Нурмыйгамы соң уку-язу! Каләм эше нәрсәгә хирыслыгы юк. Менә күрерсез, ике-өч көннән соң ул колхозның калтырча машинасын яисә күтәрәмгә калган атын йөгәнләр дә басу-кырга чыгып китәр. Ни әйтсәң дә, җир эшен, крәстиян хезмәтен тансыклап кайтты бит ул.

Әйе, барысын да сөйләп-әйтеп бетермәде Нурмый. Аның бер урында «Катя-катюша…» дип ычкындыруын немецларның котын алган атаклы «катюша» дип

аңлады кибет арты иптәшләре. Әйдә, шулай булсын. Ә менә вакыйганың икенчесе – бер яктан, исән калу, икенче яктан, фаҗига иде... Юк, монысын ул беркайчан да һәм беркемгә дә сөйли алмастыр, мөгаен. Ачылмаган хат шикелле, әнә шулай сер булып, авыр йөк булып күңел почмагында посып ятачактыр ул. Тәүбә кылу да йөрәк сызлавын баса алмады шул егетнең...

## II

...Халык телендә «тормыш юлы» дип аталган Ладога күленә немецларның кулы җитмәде. Шулай да фашист самолётлары, зениткалар сызыгын уза алса, вакыт-вакыт бомба ташлап киткәли иде.

Фронт дошманга каршы аягөсте сугыша. Снаряд, пуля яңгырлары астында да тормыш дәвам итә. Кешеләрнең күңеле каралмады, тупасланмады. Һөҗүм тынып торган арада солдатлар блокадада калган кешеләр белән аралаша, бомбалар пыран-заран китергән җимерекләрне төзәтә, мәетләрне җыйнап күмә, ачлыктан котылырга ярдәм итәләр.

Рядовой Нурмыйның да кемнәргәдер булышканы булды ич. Берсендә полуторкасы белән шәһәр урамыннан узып барганда күрде: унбиш-унҗиде яшьләр тирәсендәге ике кыз бала чана тартып бара. Йөкне көч-хәл белән өстериләр, мескенкәйләр. Кызларның олырагы – шәлгә, кечерәге чуклы яулыкка уранган иде. Чанадагы су багын төшерергә дә хәлләре юк бичараларның. Машина әрҗәсе он капчыкларыннан бушатылган иде. Шунлыктан, бер дә икеләнмичә, кар өстенә сикереп төште дә аларга таба атлады Нурмый. Күпне күргән, берничә урыннан яньчелгән су багын күтәрешеп, алар яшәгән йортның өченче катына күтәрелде. Фатир дигәнең фәкыйрьлек чәчә, иске ашъяулык җәелгән өстәл өсте шыр ялангач диярлек иде. Кече як бүлмәдә авыру аналары торалмыйча урын өстендә ята икән. Аның хәлсез генә итеп йөткергәне ишетелеп куя...

Котылгысыз, җан әрнеткеч бу хәлләрне күргәч тә Нурмый, баштарак сүз табалмыйча, тетрәнеп калды. Буяулары куба башлаган тумбочка өстендә – рамга беркетелгән фоторәсем. Фронтовик әтиләре Мәскәү яны сугышларында һәлак булган икән... Кызларның олырагы – Катя, сеңлесе Валя исемле булып чыкты. Катяның балалык чыгып та өлгермәгән йөзеннән чарасызлык бөркелеп тора. Ни хәл итәсең, бу ятимнәрнең бала чагын сугыш урлаган...

Кинәт Нурмый солдатның күзләре ялангач диварга төште. Анда кадак-мазар беләнме уеп: «Лена 12 лет. Умерла 8 ноября. 1942 год» дип язылган иде. Әлеге язмага бернинди аңлатма кирәкми, фаҗига ачысы сүзсез дә аңлашыла иде.

Нишли алсын Нурмый. «Хәзер, көтеп торыгыз...» – диде дә урамга, машинасы янына ашыкты. Капчык төбендә он бетми дигәндәй, паёк хәзинәсеннән сохари, консерва ише ризыклары бар иде аның. Солдат биштәреннән чыгарып, әнә шуларны өстәлгә салды. «Күктән» төшкән мондый күчтәнәчләрне күргәч, ике кыз да телсез калды, рәхмәт әйтергә дә оныттылар шикелле: инде ике ел буе елмаю күрмәгән йөзләрендә өмет, килер көнгә ышаныч чаткылары кабынды.

Вакыты һәм җае килгәндә, бигрәк тә ерак һәм хәвефле юлдан кайтканнан соң, ул Катяларның ишегенә сугылмый калмады. Киткәндә Катя аны һәрвакыт аягүрә һәм күзләре белән сүзсез генә озатып кала. Нурмый, шушы ике ятим үсмер өчен үзенең күктән төшкән фәрештә сыйфатындагы кеше икәнлеген аңлап бетермәсә дә, аларга яхшылык эшли алуы белән эчтән генә горурланды. Бигрәк тә Катя белән аны нindидер күзгә күренмәс җепләр бәйләп тора иде. Күрәсе-күрешәсе килүме? Сагышлы, ләкин тирәндә нindидер тылсым яшеренеп яткан төпсез күзләреме? Әллә башка берәр сәбәпме? Әйтүе читен. Менә шушы очрашулардан соң Нурмыйның кинәт кенә тәне дә, җаны да үзгәрде шикелле...

Карлы-бозлы Ладога күлендә килеп чыккан бер вакыйга исә болайрак булды.

Колонна алга бара. Машина моторлары тонык кына гүелди. Ап-ак җил карларны туздыра. Буран чыгарга чамалый булса кирәк. Капчык һәм әрҗәләр төягән полуторкалар кәрваны ярты юлны диярлек кичте инде. Димәк, алар хәзер Ладога күленең кыл уртасыннан баралар. Ленинградка таба. Анда фронт һәм шәһәр халкы өстәмә корал, боеприпас һәм азык-төлек көтә, вакытында һәм тоткарлыксыз кайтып җитү кирәк.

Кар куера башлаганда, үтә күренмәле пәрдә булып, эңгер-меңгер якынайды. «Нурмый-татарин» (аны үзара шулай дип йөртәләр) колоннаның алгы сафында бара иде. Машина тәрәзәсен юка кар капламакчы була, менә шуны сөртеп-чистартып алу өчен бертын тукталып аласы иде бит. Шулай дип уйлап кына барганда… ирексездән тукталыш ясарга туры килде аңа. Юлның кыл уртасында йөк төялгән җигүле ат егылган. Юлга аркылы ята. Малкай, мескенкәй, бәкәлләре белән һаваны ертып, тибә һәм тыпырчына, бәргәләнә. Әллә бозда таеп, әллә инде хәле бетеп егылган ул. Аңламассың. Янәшәсендә, чәбәләнеп, ике кеше кайнаша. Нишләргә, төшеп булышыргамы? Әллә бер як читтән әйләнеп узаргамы? Узарсың, бар, йөгең һәм дүрт көпчәгең белән кар көртенә кереп чумасыңны көт тә тор…

Шуларны уйлап өлгергән арада кинәт кемдер сүгенә-сүгенә кабина ишеген каерып ачты. Майор Нефёдов икән. Бигрәкләр дә чандыр гәүдәле булганы өчен солдатлар аны үзе югында «юка майор» дип йөртәләр. Кансыз кеше. Сугыш йөгенә баткан солдатларны кызгана белми, еш кына каннарына тоз сала. Ә үзен кем дип саный икән? Бервакыт аның азык-төлек складыннан сумка тутырып тушёнкалар алып чыкканын үз күзләре белән күрде Нурмый. Карга күзен карга чукымас дип, бу эшне өстәгеләргә «җәвить» итәргә базмады. Дөресрәге, «әләкче» дигән исем алудан курыкты. Тылдагы әзерләү пункты капкасына эре хәрефләр белән «Берегите народное продовольствие!» дигән сүзләр һәркемгә кагыла түгелме?..

Майорның чырае караңгы, талканы коры иде.

– Син нәрсә тукталдың, анаңны… – дия-дия ачы итеп сүгенде.

– Күрәсез бит, алда җигүле ат егылган…

– Атны кызганып торыр чакмы? Приказ бирәм, атны таптa да кит!

Балачакта ат җене кагылган Нурмыйның шушы эшкә кулы барачакмы соң, Алла сакласын… Иң яхшысы – кабинадан сикереп төшәргә дә булышырга, берәр әмәлен уйлап табарга кирәк…

Гап-гади бер солдатның фәрманга буйсынмавы үзсүзле майорны чыгырыннан чыгарды. Ул:

– Безне блокада көтә, колоннаны тоткарлау җинаять! Мин сине судсыз-нисез атып үтерәм! – диде дә бушлаты астындагы кобурасына ябышты.

Нурмыйның язмышын, ә бәлки гомерен (?) менә-менә секундлар хәл итәчәк иде. Яшисе килә бит, сугыштан исән-имин кайтып туган авылында тамырланасы килә. Менә шушы уй һәм инстинкт яшен тизлегендә баш миен көйдереп узды. Әллә кайдан гына тәненә, беләкләренә көч ургылды, зимагурлыгы ташып чыкты: «Йә ул мине, йә мин аны…» Мизгел эчендә, әйе, мизгел эчендә кинәт дерматин тышлы утыргыч астында яткан трофей пистолетын тартып чыгарды да курокка басты… Җил-буран эчендә тонык яңгыраган шартлау авазы кешеләргә әллә ишетелде, әллә юк. Нефёдовның гәүдәсе акрын-акрын гына аска таба шуып төште дә кар өстенә ауды…

Нурмыйның баштарак күңеле томаланды, күз аллары караңгыланды. «Нишләдем мин, нишләдем?..» дигән уй күңелен талкый башлаган иде, аннары зиһененә кинәттән аклану чаткылары бәреп керде: «Йә ул мине, йә мин аны… Тәкъдир үзе шулай кушты, Ходай кичерә күрсен…»

***

Күпме генә яшерергә һәм котылырга тырышмасын, Нурмый җилкәсендәге бу ачы «йөк» авылга да ияреп кайтты. Кибет артында авылдашларын сыйлап азаплануы да барыннан да элек әнә шул киеренкелекне күңелдән алып ташлау, языкны йомшарту ниятеннән иде.

«Мин дөрес яшимме?..» дигән сорау аны Белоруссия җирләрен азат итүдә катнашып, яраланып, инде авылга әйләнеп кайткач та еш кына бимазалый иде шул. Кешеләрдән читләшеп, менә шушы газаптан бер атна чамасы ялгызы гына диярлек эчте ул, эчендә утырган шайтанны куарга тырышты. Ләкин алга таба һаман шулай үз-үзеңә ясканып, кыйналып яшәү мөмкин түгел: йорт-җирне аякка бастырырга, рәтле генә гаилә корып җибәрергә кирәк иде аңа.

...Сугыштан кайткан шәпкә бертуган абыйсының улы – Замир дигән алты-җиде яшьлек малай: «Миңа пистолет алып кайттыңмы?» – дип теңкәсенә тигән иде аның. Бөтен җавапларын тегендә-монда таба борып, бу сораудан ансат кына кача иде ул. Авылдашлары каршында да корал белән масаеп йөрү килешмәс иде. Шуңа күрә ул өйдә берәү дә юк чакта яшергән җиреннән трофей пистолетын тартып чыгарды... Шайтаннар ияләшмәсен дип, иске өйнең аралык ягы почмагына ике тапкыр шартлатып атты да, кирәксезгә санап, бакча артындагы кое суына ташлады. «Чулт!» иткән тавыш утлы коралның мәңгегә югалуын, тынып калуын аңлата иде.

## III

Исәпләсәң, исең китәрлек: сугыштан соң кырык ел вакыт узып та киткән әнә... Шушы зур гына вакыт арасында Нурмый өйләнде, яңа йорт җиткереп керде, шадра битле Хупҗамалы белән бергәләшеп балалар үстерде.

Беркөнне ул, җитмешен тураклап баручы ир заты, әнә шуларны уйлый-уйлый һәм «Катя-катюша» дип сөйләнеп, бертуган абыйсының улы Замир янына сугыласы итте. Әйе, үзе генә белгән уе, яшерен дип әйтерлек нияте бар иде аның. Сәбәпнең дә мач килеп торуын кара син! «Мондый форсатны кулдан ычкындыру ярамас. Дөнья бит бу, нигә әле тәвәккәлләп карамаска? Бер генә яшибез ич», – дип эченнән генә фәлсәфә корды ул.

Хикмәт шунда иде ки: бертуган абыйсының улы Замир Шәрәфетдинов калага китеп биш ел укыды да, үзе әйткәнчә, номенклатура баскычларын үтеп, яхшы гына карьера ясап куйды, менәтерә! Ул – республика күләмендә танылган хөкүмәт гәзитендә бүлек мөдире булып эшли иде. Белемен тагын да күтәрү өчен, аны Ленинград югары партия мәктәбенә ике еллык курсларга укырга җибәрәселәр икән. Шул уңайдан, әти-әнисе һәм туганнары белән күрешү-саубуллашу өчен, туган авылына кайткан ул.

Әйткән сүз – аткан ук.

Канкардәш Замир энесе белән ике куллап күрештеләр, бакчадагы чатыр-беседка эскәмиясенә утырып әңгәмә кордылар. Август урталары иде бу. Алма өлгереп килгән чак. Алмагачның кызыл-яшькелт алмалар белән бизәлгән ябалдашлары, ымсындырып, беседканың ачык тәрәзәсенә орынып тора диярлек. Бакчага хуш исләр таралган.

Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Нурмый туганының өс-киемнәре генә түгел, инде килеш-кыяфәте дә тәмам шәһәрләшеп беткән укымыш иясенең күзләренә туп-туры карады да мәгънәле генә итеп:

– Кайчандыр мин йөргән эзләрдән атлап йөриячәксең икән, Замир энем, – дип әйтеп куйды.

Бу сүзләр Замирның күңеленә хуш килде, билгеле. Яңа-ерак сәфәргә ашкынып торган җанын горурлык белән тутырды. Сөйләшү ачыктан-ачык барды. Нурмый,

әйтәсе килгәнен тел очында яшереп тормыйча, сүзне блокада көннәреннән, шәһәрнең фашистларга каршы көрәшеннән башлады һәм шул чакта апалы-сеңелле Катя белән Валяга ничек булышканын, үзенең солдат паёгыннан өлеш чыгарган чакларын сөйләп бирде.

Замир аны игътибар белән тыңлады. Азактарак, түземсезләнеп, капыл гына сорап куйды:

– Нурмый абый, синең кебек чая кешенең хәтер тартмасында аларның өй адресы сакланып калгандыр бит?

Энесенең шундый сорау бирүенә балаларча куанды абыйсы, шатлануы йөзенә үк бәреп чыкты.

– Адрес бар, энем, бар!.. Мин аны көнче Хупҗамал апаңнан ерак яшергән идем. Эзләп таптым, алып килдем менә… Шоссейная урамын тапмый калмассың, – дип, нәсел кардәшенең кулына саргая төшкән кәгазь кисәген тоттырды.

Журналистлык мәктәбе узган, язарына азык эзләргә яратучан Замир бу мәлдә кулына нинди табыш килеп керүен бөтен күңеле белән тойган иде. Ләкин Нурмый, аның шул теләген сизеп-чамалапмы шунда, җай белән генә кисәтеп куюны кирәк тапты:

– Кара аны, улым, гәҗит-фәләнгә язар өчен бирүем түгел бу. Шушы адрес белән барып, шәт иншалла, йортларын тапмый калмассың. Исән-саулыкларын белешеп, миннән сәламнәр тапшыра күр, зинһар… Үтенечем шул.

– Аңладым, – диде Замир, ризалашып. Ни генә булмасын, Нурмый абыйсы аңа кыенлык китерми торган бик тә кешелекле, дөньяви бер йомыш куша лабаса…

Канкардәш ике туган арасында сакланачак яңа сер әнә шулай бөреләнеп килде бу минутларда.

## IV

Илнең төньяк башкаласы Ленинградка килеп, уку йортының заманча тулай торагына урнашу белән, Замир икенче көнне үк шәһәргә чыгып китте. Әле укулар башланмаган иде. Алдагы көннәрдә Кышкы Сарайны да гизәр ул, атаклы «Аврора»ны күрер, шәһәрнең тагын-тагын күп кенә тарихи урыннарына да сәфәре булмый калмас аның. Есенин яраткан «Астория» ресторанына да кереп чыгар, боерган булса. Ә бүген, бүген ул Нурмый абыйсының эзләреннән барып, аның үтенечен, һичшиксез, үтәргә тиеш.

Шәһәрнең кешеләре бик ачык, гади һәм игелекле булып чыкты. Кайсы транспортка утырасын, кая-ничек барасын җиңел генә аңлатып бирделәр.

Шулай итеп, үзенә кирәкле Шоссейная урамын чагыштырмача ансат кына эзләп тапты ул. Йөрәге ешрак тибеп, күңеле алга ашкынса да, уйларын тәртипкә китерү өчен салмак атларга тырышты. Нинди очрашу көтә икән аны? Әйбәт кабул итәрләрме? Әгәр өйдә туры килмәсәләр яки башка адрес белән күчеп киткән булсалар…

Әнә шундый уйлар катламын ера-ера, күңеле инде ятлап өлгергән утыз икенче номерлы биек йорт янына якынлашып килүе… Августның кояшлы-җылымса җиле, мәрхәмәтен кызганмыйча, битләрне йомшак кына иркәләп уза. Замир, бер мәлгә тукталып, кинәт кенә өченче каттагы ак пәрдәле тәрәзәгә караш ташлады. Пәрдә почмагын ачып, аннан өлкән яшьләрдәге бер хатын урамга баккан иде. Замир түбәннән аның йөз чалымнарын күреп өлгергәнче, ул арада пәрдә кинәт ябылды һәм яулыклы шәүлә юкка чыкты. Замир өчен әйбәт фал иде бу – әлеге йортта кешеләрнең барлыгы, яшәп ятулары аңа нindидер көч һәм ышаныч өстәде шикелле.

Туры килүен күр син – ул эзләгән фатир да нәкъ менә шушы өченче катта булып чыкты. Дулкынлануын тыеп, кыңгырау төймәсенә басты.

Ишекнең теге ягында кыштырдау-сөйләшү кебегрәк авазлар колакка чалынды. Йа Хода, өйдә кешеләр барлыгы Замир өчен сер пәрдәсенең бер почмагын ачып куячак түгелме соң?

Шулай да ишек ачылырга ашыкмый иде. Хәер, бер белмәгән, ягъни урамнан кергән кешегә берәү дә ишеген ачарга ашкынып тормастыр шул. Замирга үзенең кем икәнлеген һәм ни өчен килгәнлеген бәйнә-бәйнә аңлатырга туры килде, әлбәттә. «Казан» һәм «Нурмый» дигән сүзләрне кат-кат ишеткәннән соң гына, чылбыр чылтырап куйды, аннары ишек ачылды.

Каршыда алтмыш белән җитмеш арасындагы бер хатын басып тора иде. Ярым бөдрә чәчләре чалара төшкән, ә өстендә эре чәчәкле халат иде аның. «Керегез», – диде ул йомшак кына һәм үзен Валя дип таныштырды. Шикләнмәскә мөмкин, Замир каршында, чыннан да, авылдагы абыйсы сөйләгән Валя-Валентина басып тора иде.

Көтелмәгән кунакка түрдән урын тәкъдим ителде.

Сөйләшеп киттеләр. Баштарак кырыс сыманрак тоелган Валя ханымның йөзе тиз арада ачылып китте, еллар томанына кереп югалган Нурмыйның кече энесен күргәч, күңеле куаныч һәм дулкынлану белән тулды.

– Нурми-Нуралей… Это он спас нас от голода, – диде ул, хөрмәт һәм горурлыгын яшереп тә тормыйча.

«Нуралей». Күр әле, яшьлектәге Нурмый абыйсын, үзләренчә җайлаштырып, менә ничек атап йөрткән икән алар! Татарча да, русча да әйбәт яңгырый торган исемне таба белгәннәр әнә…

Нурмый – фронтовик Катя турында талпынып, аерым бер мәхәббәт белән сөйләгән иде бит. Исән-саумы, кайда-кайларда икән ул менә хәзер? Аңлашылса кирәк, Замирның әнә шул хакта беләсе, сорашасы, нинди дә булса мәгълүмат ишетәсе килә иде.

Шулвакыт ишеге ябык булган каршы як бүлмәдә кемнеңдер урындык-мазарнымы этеп куйганы кебегрәк тавыш ишетелде. Димәк, бу фатирда тагын кемдер бар. Ә нигә ерак-еракләрдан килгән кешене күрергә чыкмый икән ул? Катя булса, зал якка чыкмый калмас иде. Замирның йомышыннан бихәбәр икенче бер кеше яши микәнни анда?.. Серле тоелды бу.

Валяның сөйләгәннәреннән сер бик тиз ачылды.

…Моннан ун еллар чамасы элек Катя кинәт кенә билгесез чир белән авырый башлаган. Сул як аягын һәм кулын параличлаган бу чирне «Паркинсон авыруы» дип атыйлар икән. Аны җиңүдә медицина көчсез. Фабрикадагы эшеннән азат итеп, Катяга икенче группа инвалидлык биргәннәр. Менә шуннан бирле Катя-Катерина дару төймәләре белән гомерен озайтып яши икән. Калтыравыннан уңайсызланып, кеше күзенә күренмәскә, аралашмаска тырыша…

Боларны ишеткәч, Замир кинәт күңелсезләнеп китте, чәй янына утырырга да ашыкмады. Казан күчтәнәчләрен чыгарырга да оныткан иде.

– Беләсезме, – диде Валя ханым, кунакка игътибар белән төбәлеп. – Ул бит синең атлап килүеңне тәрәзәдән карап торган икән… «Нурми-Нуралей!» дип кычкырып җибәргәнен ишеткәч тә янына атылып кердем. Саташуыдыр дип уйлаган идем. Чөнки Нуралейны сагынып яшәде ул. Көннәрнең берендә килми калмас дип, озак еллар көтте ул аны. Тәкъдир язмаган икән… Ә син абыеңның яшьлектәге чагына охшагансың. Сине ул дип кабул итте бугай ул…

Ханымның соңгы сүзләрен Замир ишетмәде диярлек. Ул Катя турында уйлый һәм бөтен барлыгы белән аны күрергә, сүз кушарга тели иде. Шуңа да үтенечен ачыктан-ачык әйтергә ашыкты:

– Миңа аны күрергә рөхсәт итегез. Берничә минутка булса да…

– Юк, юк… – диде хатын, ике кулын берьюлы ишарәләп. – Аның сүзен аяк астына

салыр хәлем юк. Сине үз янына кертмәскә кушты. Сиңа үзенең чарасызлыгын, авыр кыяфәткә калуын күрсәтәсе килми аның...

Бүлмәдә уңайсыз тынлык урнашты.

– Алайса... – дип, бер кавым уйланып торды Замир. – Алайса, ишекне бармак киңлеге генә ачып, бер тапкыр булса да читтән генә күреп калыймчы, зинһар...

Ходайның рәхмәте, ханым аңлады бугай. Имән бармагын иреннәренә куеп, сүзсез генә ризалыгын бирде.

Замир, аяк очларына гына басып, ишеккә таба якынайды. Үзе вәгъдә иткәнчә, ишекне юка гына ачты да бүлмә эчен күзләде. Тәрәзә буендагы кәнәфидә... яулык ябынган, киң итәкле күлмәк кигән бер карчык утырып тора иде. Кинәт Замир эсселе-суыклы булып китте. Катя-Катеринаның кәнәфи иңсәсенә салынып төшкән куллары тигез бер ритм белән туктаусыз дерелди иде. Аскарак иелә төшкән башы да, дәү курчакны хәтерләтеп, алга-артка салмак кына калтырана... Ул үзалдына тын гына сөйләшеп утыра иде шикелле.

Замир барысын да аңлады.

Көченнән берни дә кылә алмавына гарьләнеп, авыр сулап куйды, каты гына йомарлап йодрыгын кысты. Их, дөнья! Нигә шулкадәр дә рәхимсез икәнсең син... Дөньялыкта яшәп яткан кайбер бәндәләреңне рәхим-шәфкатеңнән мәхрүм иткәнсең.

Шулвакыт ханым ымлап кына Замирны үз янына чакырды.

– Син утырып тор, – диде ул, нииндидер уе барлыгын сиздереп. – Мин сезгә гаилә реликвиясен күрсәтәм хәзер. Сабыр итегез...

Шулай диде дә, бүлмәгә кереп, берничә минуттан кире әйләнеп тә чыкты. Кулында – еллар чалымын сеңдерергә өлгергән әллә кайчангы бер фоторәсем иде.

Замир әлеге фотоны кулына алып, сүзсез генә озаклап карап торды. Йөзенә моңсулык катыш елмаю җәелде. Анда... рәсемнән аңа, үтә күренмәле еллар пәрдәсе аша, егерме яшьләр тирәсендәге Нурмый солдат карап тора иде. Тельняшкадан. Башында бескозырка. Түгәрәк йөзле, мускуллары кабарып тора. Күзләрендә генә блокада көннәренең кырыслыгы чагылып калган...

– Абыең биреп калдырган истәлек... – диде ханым, бүтән сүзләр таба алмыйча.

***

Алдагы көннәренең берсендә Казанга, аннары туган авылына кайткач та, фронтовик Нурмыйның әлеге фотоны кысып-кочаклап елавын, хатыны Хупҗамалның көнчелек галәмәте күрсәтеп алуларын күз алдына да китерми иде Замир. Блокада хатирәсе аның күңелендә, хәтер күгендә мәңгелек бер симфония-музыка булып уелып калачак – шушы хакыйкатьне ул еллар үткән саен ныграк тойды, якты дөньяда кеше кадеренең бетмәс-төкәнмәс икәнлеген аңлап яшәде.

*Апрель, 2014*



Гөлүсә
Батталова

# ИХЛАСЛЫККА СУСАГАН ҖАН

***

Мең ел үткән…
Далаларда – тояк тавышлары.
Гасырларның тоям агышларын.
Мең ел үткән…
Яулар килгән, яулар киткән.
Милләт көткән –
Мең ел үткән.

Мең ел үткән –
Тарих төшкән кылыч кыннарыннан,
Язмышыбыз – күңел кылларыннан.
Мең ел үткән!
Хөрриятен, нәсел җебен
Хәтерендә горур йөрткән
Татар җаны нидер көткән.
Мең ел үткән.

Мең ел үткән.
Сиратларны мең кат кичкән…
Кара козгын чыкмый истән.
Мең ел үткән!
Гасыр җөен үрәм, сүтәм,
Чулпыларым чыңласа да,
Хәбәр диеп өмет итәм.
Киләчәгем татарына
Динем белән телем илтәм.
Оланнарым йөз чөермәс –
Тамырларда меңәр еллык
Татар кызы канын йөртәм.
Мең ел үткән!
Моң өзелмәс, рух җиңелмәс –
Тарих көтәр: мең ел үтәр!

Гөлүсә БАТТАЛОВА – *яшь шагыйрә; «Таян Аллага» Бөтенроссия әдәби конкурсының Гран-при иясе (2016). Әтнә районы Күәм авылында яши.*

## Гафу итмәс тарих

Дары исе сеңгән җилләр аша
Хәтер төпкелләрен урадым.
Без кардәшләр түгел идекме соң,
Төне буе буран дулады.

Бүрәнәләр авыр шыгырдады,
Айга карап этләр улады.
Инде дуслар дошманмыни хәзер,
Төне буе буран дулады...

Йорты, курасында сыену тапкан
Мөһаҗирләр рухын уйладым.
Якын ара кинәт ерагайды –
Төне буе буран дулады...

Фал ачканмы әллә Исхакыйлар –
Инкыйразны күптән юрады.
Үз илендә һаман үги шул без,
Төне буе буран дулады...

Хаталарны гафу итмәс тарих –
Дары исле җилләр елады.
Канга баткан кансыз уен бара.
Төне буе буран дулады...

## Дога кылам

Каешланган күптән инде күңел,
Язмыш җилләрендә сыналып.
Яшәп ятыш. Уч төбемдә – өмет.
Шөкер итәм мең кат сыналып.

Фанилыкның сиратларын кичәм,
Ачу тотмый кырыс дөньяга.
Рәхмәт укып ихлас дога кылам,
Йөзем төбәп көн дә кыйблага.

Ялган төсләр ялган буяуларда,
Заман кулларында пумала.
Боек күзләр, җансыз йөзләр аша
Дөнья яктылыгы югала.

Бәгырьләрне телә нахак сүзләр,
Кырау ала җылы хисләрне.
Көндез чыра ягып эзләп йөрим
Изгелектән калган эзләрне.

Каешланган күптән инде күңел,
Яшьләр кипкән, ахры, күзләрдә.
Явызлыктан түгел, яхшылыктан,
Елыйм кайчак җылы сүзләрдән.

Бу дөньяда юкка яшәмимдер,
Үз бәхетем, сагыш, ярам бар.
Калебемне ачып сыенырга,
Ышанырга газиз Аллам бар.

## Күңел

Шәһәр йоклый.
Тузан катыш тынчу мәйданнарда
Бәргәләнә үги күңел.
Ихласлыкка сусаган җан,
Яугир рухы кайнаган кан –
Дөньялыкта тере түгел.
Бәргәләнә минем күңел.

Шәһәр кайный.
Таш урамнар санга сукмый,
Җәберләнә ятим бәгырь.
Ваемсызлар арасында,
Битарафлар карашында
Бер елмаю – үзе кадер.
Җылы сүзгә кем соң әзер?!

Шәһәр тынды.
Диварларда бары сулык-сулык
Тәүбә кыла җансыз кала.
Тышауланган хисләремдә,
Чынга ашмас төшләремдә –
Далалардан калган яра,
Яралардан торган дала…

## Безнең кавем

Безнең тарих фаҗигале,
Безнең язмыш яралы.
Безгә тәкъдир насыйп иткән
Актан бигрәк караны.

Кылычтан үткән кавем без,
Ватаныннан куылган.
Дөньяны яулар көчебез
Җир йөзеннән җуелган.

Богауланган горурлыгы,
Тарайтканнар ызанын.
Күпне күргән халкым, әмма
Югалтмаган иманын!

Онытмаган бисмилласын,
Манаралар ауганда.
Аллам диеп яуга кергән,
Күктән кургаш яуганда.

Калдырмаган уразасын,
Калдырмаган намазын,
Бер ишетергә тилмереп
Тансык азан авазын.

Мең кат үлеп терелгән без,
Мең кат көлдән яралган.
Имансызлар арткан саен,
Бездә иман яңарган.


Кемнәр безгә кизәнмәгән,
Кемнәр безне сатмаган…
Ничек исән калыр идек –
Безне Алла саклаган.



*Бакый Урманче эшләгән Тукай бюсты янында ул заманның күренекле язучыларыннан бер төркем. Матбугат йорты. 1964 ел.*



*«Казан утлары» журналының 70 еллык юбилеена багышланган кичәдән бер мизгел. Уртада: композитор — Әнвәр Бакиров, Алмаз Монасыйпов. Г.Камал театры залы. 1992 ел.*



*Мостафин Рафаэль Әхмәт улы (1931-2011) — язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, журналист. 1965-1968 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшләде. Тууына — 85, вафатына — 5 ел.*

*Язучы Роза Мулланурова һәм «Сөембикә» журналында озак еллар бергә эшләгән каләмдәше Марат Әмирханов. 2010 ел. Бу айда Роза ханым гомер бәйрәмен каршылый.*





*«Казан утлары» журналы редакциясендә 17 ел хезмәт куйган язучы-прозаик Сәмига Сәүбәнова. Бу айда аның да юбилее. Каләмдәш хатын-кызларыбызны котлыйбыз!*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# СУГЫШЧЫ ӘДИП – САФТА

## *Хисам Камаловка 90 яшь*



«Каләм әһеленең, гомумән, иҗат кешесенең холык-фигыле, фикерләү үзенчәлеге, яшәү рәвеше аның әсәрләрендә» дигән сүзләр шагыйрь һәм прозаик Хисам Камаловка да тулысынча карый. Аның исемен телгә алдыкмы, аңыбызга иң әүвәл дәһшәтле сугыш күренешләре һәм афәтләре тәэсир иткәндәй була. Ул сугыш башланыр алдыннан гына җидееллык мәктәпне тәмамлый. Кырыгынчы еллар башында мондый белемгә ия булу – шактый җитди казаныш. Әмма аңа алга таба уку бәхете елмаймый. Унбиш яшьлек малай сугыш чоры үсмерләре җилкәсенә төшкән бөтен авырлыкларны күтәрешергә мәҗбүр була. А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Дүртәү» әсәрләрен укыганда, Нуретдин абыйның улы Хисам һәм аның яшьтәшләрен күргәндәй буласың. Ә инде сугыш елларының кыл уртасында аңа да кулына корал алу нәүбәте җитә.

*...Мин унсигез яшьтә*
*Зур сугышта йөрдем, гел утта.*
*Үкенсәң дә, үкенмәсәң дә шул:*
*Яшь чакларым үтте окопта.*
*Ниләр генә анда күрмәдем мин?*
*Кан-яшь түктем, көйдем ачынып.*
*Кешеләрнең күрдем бөеклеген,*
*Түбәнлеген күрдем кайсының,*

– ди ул «Көндәлдәге язулар» дигән шигырендә.

Хисам Камалов, сугышның үзәгендә кайнап, аның бөтен фаҗигасен кичергән кеше буларак, бу мәхшәр эчендәгеләрнең күңел дөньяларын тирән аңлаучы һәм белүче шәхес. Ул үзе гәүдәләндергән сугышчы образларына бер генә үлчәм белән, ягъни алар һичшиксез батыр рухлы гына булырга тиеш дип карамый. Бу М.Җәлилнең «Дүрт гөл» әсәрендә сурәтләнгәннәр белән чагыштырганда ачык күренә. «Кургаш ютәл» сибә-сибә немец танклары – «Юлбарыслар»ның килүе бер солдатның психикасына нык тәэсир итә, ул куркып кала. «Биреләм!» – дип кулын күтәрә... Х.Камаловта да, сирәк кенә булса да, шуңа охшаш күренешләрне очратырга мөмкин. Сугышчының да җаны бар бит. Аның да яшисе килә. Әйтик, латыш җирендә сугышканда, бер кичне фрицлар һөҗүмгә ташлана. Шунда «яшьтәш куркып артка чигенгән».

*Ташлап качкан позицияне ул, –*
*Бизгәк тотты гүя взводны,*
*Сугыш тынгач, бер штабист килеп,*
*Тегенең пагонын*
*Умырып ыргытты.*

Әлбәттә, әлеге штабист бу сугышчыны трибуналга бирү ягында. Х.Камалов әлеге егетне командирның сәяси эшләр буенча урынбасары яклап калганлыгын әйтә. Хәер, хәзер китереләчәк сүзләрне әйтүченең замполит булуы мәҗбүри түгел, бәлки гап-гади акыллы кеше булуы да мөмкин иде. Әмма ул вакытларда туры, гадел, кыю

фикерләрне парторглар, сәяси эшлеклеләр авызыннан ирештерү бер мода иде шул. Менә шундыйларның берсе болай ди:

*Мәктәпләрдә без тәрбия иттек,*
*Кыен булмас, диеп сугышта.*
*Киноларда дошман юк ителде,*
*Бүрек белән генә сугып та.*
*Моны да без онытмыйк, дус кеше,*
*Ачыбрак карыйк күзләрне.*

Ягъни кемнәрнеңдер күңелендә курку дигән «генерал» (Х.Камал сүзләре) утыра икән, моңа рәсми пропаганда да сәбәпче иде. Әйе, төрле чорларның мактанчыкларына сабак бу. Төп мәсьәлә – сугыштагы кешенең күңелендә. Әгәр кораллы кеше ни өчен көрәшкәнлеген йөрәге белән тоя икән, кан түгүенең мәгънәсен ачык аңлый икән, аны җиңү мөмкин түгел. Киресенчә булса, ул — кулына корал тоттырылган, әмма аптыраудан гаҗиз бер мәхлук. 1941-1945 еллардагы сугыш безнең яктан чын мәгънәсендә азатлык өчен канкоеш иде. Безнең кешеләр уртак җиңү бәрабәренә, чыннан да, могҗизалар күрсәтте. Монда, әлбәттә, замполитларның өлеше дә аз кермәде. Моны һич тә онытырга ярамый.

Х.Камалов сугышны сурәтләүдә ул вакытта әдәбиятта ныклап урнашкан юлдан китмәде. 1986 елда республикабызның Г.Тукай бүләгенә лаек булган «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» романнарында, аннан соң иҗат ителгән «Үлгәннән соң яздым», «Түләнмәгән күз яше» һәм башка әсәрләрендә ул сугыштагы кеше хәлен, бизәргә тырышмыйча, бөтен кырыслыгы белән, чынбарлыкка тугры калып язу юлын сайлады. Хаклы рәвештә «Ватан сугышы» дип аталган, асылда илебез халкының яшәү-яшәмәү мәсьәләсе хәл ителгән кырылыш хакында хакыйкатьне белергә теләгән кеше кулына Х.Камалов әсәрләрен ала. Боларны язучылык хыялы белән генә кәгазьгә төшереп булмый. Моның өчен кинәт арттан атып үтерелгән Мостафин кебекләрнең соңгы газапларын үз күзләрең белән күрергә, бөтен михнәтләргә тешеңне кысып түзәргә дә кирәк иде. Күңелдәге җәрәхәт төзәлми икән, ул гел сызлап, үзен сиздереп тора. Ә тәндәге җәрәхәтләр? Юк, алары да гомерлек булып чыкты. Хисам абый егерме яше тулганчы бер аягыннан мәхрүм кала. Замандашлары сөйләвенә караганда, Казан педагогия институтында укыганда, ул К.Маркс исемендәге урамда урнашкан тулай торактан Болак янындагы уку бинасына култыкса ярдәмендә җәяү йөри. Бауман урамындагы «Матбугат йорты»нда, редакциядә эшләгәндә, бинаның текә баскычларыннан менеп-төшеп йөрүләр мең газап була. Әнә шулай күңел һәм йөрәк җәрәхәтләренең әрнүе, бергә кушылып, кәгазьгә түгелгәндә, ничек итеп кырыс дөреслектән читкә тайпылырга мөмкин? Ул моны күз алдына да китерә алмый. Х.Камаловның сугыш турында язган әсәрләренең көче, тәэсир куәте әнә шунда.

Хәтерлим, Гариф Ахунов берничә тапкыр идарә утырышларында аңа «Халык язучысы» исемен бирү мәсьәләсен күтәреп карады. Аның төп дәлиле шул иде: Хисам Камалов бу әсәрләрен язу хокукын кан түгеп алды. Шуңа күрә аның язганнары – Олы хакыйкать. Шуның өстенә ул – чын мәгънәсендә сүз рәссамы. «Халык язучысы» исеменә барыбызга караганда да лаеклырак шәхес. Чын дөреслек тантана итсен дисәк, без киң күңеллелек күрсәтик, аның затлы иҗатын шушы зур исем белән бәялик! Әмма Язучылар берлегенең 1989-1999 елларда эшләгән идарәсе Г.Ахуновның мондый кайнар чыгышларын игътибарсыз калдыра килде. 1999 елда сайланган идарә, бу олы әдибебезнең тәкъдименә әйләнеп кайтты, 2001 елда Хисам Камаловка «Татарстанның Халык язучысы» дигән олы исем бирелде. Кызганыч, бу вакытта Гариф ага үзе бакыйлыкка күчкән иде инде.

Х.Камалов гомер буе халык, милләт тормышы белән яшәде. Ягъни, сугыштагы кебек, тыныч унъеллыкларда да гади, киң күңелле, кешелекле, әйләнә-тирәдәгеләргә кечелекле булып калды.

*Ник яшерергә,*
*Барлыгым шул инде:*
*Йөрмим шәп күренергә тырышып.*
*Исәп-хисап тотмыйм сөйләгәндә,*
*Югары бер постка елышып.*

Югары постка елышканнар үзләрен тормышның барометры дип исәпли алмый. Алар чын тормышны белми һәм, ни аяныч, белергә дә теләми. Чөнки бөтен кайгылары — яуланган урыннарын ныгыту, аякның икенчесе белән өскәрәк басу өчен җирлек әзерләү. Мондый чакта аларның күңелендә халык гаменә урын калмый. Х.Камаловның исә бар гаме – халык язмышы.

*Яшәп булмый гамьсез, тыныч кына,*
*Алга бара тормыш, алышына,*
*Бәяләүләр еш үзгәрә тора:*
*Яңалыклар баса каршыңа.*
*Яңалыкны кайчак сизеп булмый,*
*Аның яшерен, эчке көчләрен*
*Акылың белән болай аңлыйсың күк,*
*Консерватор була хисләрең.*

Бу фикерләр, әлбәттә, шагыйрьнең барлык кешеләргә уртак булган хасиятләрне гомумиләштереп әйтүеннән килә. Ә менә ил, халык гаме белән яшәгән каләм әһеле консерватор була алмый. Булса да, ул яхшы мәгънәдә генә. Ягъни халыкның затлы яшәү рәвешен, гореф-гадәтен, дини кануннарга нигезләнеп көн итү үзенчәлекләрен сыйдырган «консерваторлык»ны бары тик хупларга гына кирәк.

*Туган җирем, сиңа авыр булса,*
*Миңа да авыр һәрчак нигәдер.*
*Ни әйтсәң дә бер кузәнәгең мин,*
*Авыр була шуңа күрәдер.*

*Бәла килсә сиңа, көч җиткәнчә,*
*Мин җилкәгә алам барсын да.*
*Минем шәхси бәхетсезлекләрем*
*Тик чүп кенә аның каршында.*

Дөресен әйткәндә, Х.Камаловның шәхси бәхетсезлеге (сугышта сәламәтлегенә зур зыян килүе) җиңел итеп «чүп кенә» дип әйтерлек түгел. Әмма ул, ихтыяр көчен, эчке ныклыгын тагын да арттырып, тормышта лаеклы урынын тапты, үзен әдәбиятыбызның талантлы, олпат вәкиле итеп раслады.

*Яралангач,*
*Начар хәлем күреп,*
*Жәлләделәр әйбәт кешеләр.*
*Һәм үлемнән йолды алар жәлләп...*
*Күбрәк булсын шуның ишеләр!*

– дип, ул миһербанлы кешеләргә рәхмәтен әйтте. Юк, бу йомшаклык түгел, бәлки аның кешеләрне яратуы иде. Үз чиратында меңләгән кешеләр, Хисам Камалов әсәрләрен укып, күңелләренә ныклык, көч өстиләр, яшәешнең күп кенә якларын аның күзләре белән карап бәялиләр. Әдип күңелендәге хис-тойгылар, фикер байлыгы башкаларның да рухи хәзинәсе булып әверелә

Бу очракта без Х.Камаловның инде вакытында лаеклы бәя алган, авторына танылу китергән романнары турында сүз алып бармабыз. Аларга карата каләмдәшләре һәм меңләгән укучылары тарафыннан да тиешле карашлар үз вакытында белдерелә барды. Без бүген Х.Камаловның соңгы ун-унбиш елда, ягъни яшь ягыннан шактый өлкәнәйгәч иҗат иткән әсәрләренә игътибар итәргә булдык. Ни өчен дигәндә, алар басыла торалар, әдәбият сөючеләр укып баралар, әмма ни өчендер матбугатта әлегә нинди дә булса фикер әйтүчеләр бик күренми. Хәлбуки, автор тарафыннан бәян, истәлекләр, язмалар дип аталсалар да, аларның кайберләре жанр ягыннан сәнгатьчә эшләнгән повестьлар, хикәяләр дәрәҗәсендә дип саналырга хаклы. Олы яшьтә

булуына карамастан, әдипнең хәтере әйбәт, укучыларга әйтер сүзләре күп, тагын да мөһиме — әдәби осталыгы да үзе белән.

«Үлем куа килә» дип аталган язма, мәсәлән, гади генә итеп «фронт истәлекләре» дип тәкъдим ителгән (2004). Димәк, болар әдипнең үз күзләре белән күргән һәм чынбарлыкта булган хәл-әхвәлләр. Дөрес, алар 1988 елда гына, ягъни сугыш җиңүебез белән тәмамланганнан соң — 43 елдан соң язылганнар. Дүрт дистә елдан артык әлеге хәлләр фронтовик язучының калебендә йөргән, күңелен әрнеткән. Ниһаять, түзә алмаган, аларны кәгазьгә төшергән.

Әйе, кешелек тарихындагы иң канкойгыч бу Бөтендөнья сугышының язмышы нигездә безнең ил белән фашистлар очрашкан фронт сызыкларында хәл ителде. Шуңа күрә кайбер илләрнең җитәкче даирәләре, әлеге җиңү совет халкының каһарманлыгын һаман искә төшереп торганга, инде ул хәлләргә җиде дистәдән артык ел узды бит, дип, аларга ерак тарихтагы, кайнарлыгы суына баручы сәхифәләр буларак кына карарга омтылалар. Без исә, ул сугышның дәһшәтләрен, әле яңарак кына булгандай, күңелебездә яңартабыз, ата-бабаларыбызның, әниләр һәм әбиләребезнең гаять авыр шартларда җиңеп чыгулары белән ихлас горурланабыз.

Матур әдәбиятыбызда сугыш темасы әле һаман да яңа. Дөрес, сугыш кырларында турыдан-туры йөргән кешеләребез сафы сирәгәя бара. Әмма сугыш чорында үскән буын әле исән, алар да бу чорның байтак хатирәләрен күңелләрендә саклый. Фронтовик-язучылар күбрәк каһарманлыклар турында язуга өстенлек бирделәр. Г.Әпсәләмов, И.Гази, Г.Кутуй, А.Шамов, Ш.Маннур, С.Хәким һәм башка әдипләребезнең әсәрләрендә җиңү пафосы үзәктә торды. Бу шулай булырга тиеш тә иде. Чөнки ахыр чиктә кырык бишенче елның язында әлеге гаять куркыныч афәткә безнең ил җиңүле нокта куйды бит.

Шул ук вакытта утызынчы еллар ахырында хәрби хәзерлегебезне көчсезләндерүгә китергән, шуның нәтиҗәсендә сугышның беренче айларында җиңелү ачысын татуыбызга сәбәп булган хәлләрне татар әдәбияты тиешенчә чагылдыра алмады. Бу исә шул заманның вазгыятен сүз сәнгатендә тормышчан итеп ачу мөмкинлекләрен бик нык чикләде. Бу яктан татар әдәбиятында Хисам Камаловның соңгы унъеллыкларда язган әсәрләре шул чынбарлыкны булганынча сурәтләргә омтылу ягыннан аерылып тора. Моны без әлеге «Үлем арттан куа килә» дигән әсәрендә дә ачык күрәбез.

Биредә сүз кырык икенче елның җәй айларындагы фронт хәлләре турында бара. Пехота подразделениесе, безнең команда составының хәлне кирәгенчә бәяләп бетермәве нәтиҗәсендә, дошман тылында кала. Менә шул шартларда кемнең кем булуы күренә дә инде. Батальон командиры Томилин язмышын күрсәтү дәвамында әдип җитәкчелек составындагы кайбер кешеләрнең, хәтта аерым комиссарларның да чын йөзен ачып бирүгә ирешә. Без хәрбиләрнең сәяси күңел дөньялары өчен җавап бирүче бу төр җитәкчеләрнең бары тик дөрес сүзле, алдан күрүчән, кыен шартларда алгы сафта булучы намуслы шәхесләр итеп күрергә өйрәнгән. Х.Камалов сурәтләвендә алар арасында да куркак, үз җанын барыннан да өстен күрүче, кешеләр өстеннән әләк-чәләк оештыручы түбән җанлылары, ягъни очраклы кешеләр булганлыгын да күрәбез. Әлеге язмада аларның икесе турында сүз бара. Мизин дигәне алгы сызыктагы солдатлар окобына маңгаена корал терәгәч кенә бара. Аңа арттагы окопларга сыенып калу отышлырак. Теле белән ватанпәрвәрлек турында тегермән тарттыра, шул сүзләргә карата ихласлылыгын корал тотып раслау дигәндә, читтәрәк калуны мәслихәт күрә. Бу очракта Мизинны, комиссар түгел, бәлки гап-гади кеше итеп карасак, аның үз-үзен тотышындагы мондый халәтен аңларга да мөмкин. Аның да үзләре белән шартларны дөрес исәпкә алып идарә итәргә тиешле командирларның хәлне тиешенчә аңлап эш итмәүләре нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең корбаны буласы килми.

Шулай да Х.Камаловның төп игътибары кешеләр язмышы өчен җавап бирергә тиешле командирларның икесе – батальон командиры Томилин белән аның подразделениесендәге комиссар Красновларның чолганыш шартларындагы кешелек сыйфатларын күрсәтүгә юнәлә. Краснов, әлеге Томилин кебек командирларның эшчәнлекләрендәге сәяси хаталары булган очракта (юк икән – булдырып), аларның эш-хәрәкәтләренә төзәтмәләр кертеп, ягъни, үз сүзләре белән әйткәндә, «бераз йөгәнләп тоту өчен куелган». Автор аларның портретын да холык-фигыльләренә,

эчке дөньяларына туры килә торган итеп биргән. Томилин «урта буйлы, киңчә сөзәк иңле, саргылт чәчле башына пилоткасын кыңгыррак кигән, чыраенда карарлылык чагыла». Краснов «түгәрәк тук йөзле, үзен өстен куеп сөйләшүгә күнегеп килә». Икесе дә әлегә лейтенант кына. Болар — «сугышка чаклы, действительный хезмәттә бушка ашап, бушка киенеп, рәсми хәбәрдарлык буенча тормышны ал да гөл дип белгән» буын командирлары. Шуңа күрә илдәге гомуми хәлне дә алар әнә шулай җитешле, барысы да ал да гөл дип кенә белгәннәр. Хәзер, дошман басып алган җирләрдә бер урыннан икенче урынга, бер авылдан икенчесенә күчә-күчә сугышып йөргәндә, алар үзләре күз алдына китергәнгә бөтенләй капма-каршы чынбарлык белән очрашалар. Томилинның күзе колхоз идарәсе каршында тезелеп утырган балаларга төшә. «Гаҗәп, бер тавыш-тын юк, уйнамыйлар, буталмыйлар. Күзләрен тын гына идарәгә текәгәннәр. Бу ни хәл? Нишләп бирегә килеп тезелгәннәр?» Бер хатын аңлата: «Болар – әтиләре сугышта үлгән ятимнәр. Алар ач. Куллары кашык сабы юанлыгы гына. Нигә колхоз тәэмин итми дисезме? Иген уңмый, булганын кырып-себереп хөкүмәт алып бетерә, сугыш якынлаша башлагач, нәчәлникләр, партиецлар качып киттеләр...»

Үзе дә балалар йортында үскән, ашау мәсьәләсендә төрлесен күрергә өлгергән Томилинның бу күренешкә йөрәге әрни. Ул әлеге балаларның бер генә тапкыр булса да тамакларын туйдыру гамәленә керешә. Күңелендә кешегә хас сыйфатларның бер кыйпылчыгы гына булса да сакланып калган кешенең бу нияте табигый. Ә аның комиссар иптәше Краснов (дөресендә балалар турында үзе кайгыртырга тиешле кеше) кискен рәвештә Томилинның бу ниятен кире кага. «Йөрмә! Часть йөзенә кызыллык китермә», – ди.

Бу боерык рәвешендә әйтелгән, әмма иң гади мантыйкка да сыймый торган сүзләр, бәхеткә, Томилинны шәфкатьлелек адымыннан туктатып кала алмый. Ул, «Красновны тыңламау рәхәтлеге кичерә-кичерә» үҗәтләнеп, штаб тарафына юнәлә. Чарасына керешкәч, мөмкин булып тоелмаган адым да хәерлегә була ала икән. Бер рота кичке ашка килә алмаган, аларга тәгаенләп пешерелгән бер казан ботка шул килеш калган. Инде аны түгәргә дә җыенганнар. Шул рәвешле, бу ризык балаларга язган булып чыга. Авылның ачка интеккән олыларына да өлеш чыга. Комиссарның ролен бары тик кешеләргә карата кырыслык күрсәтү дип кенә аңлаучы Краснов хезмәттәшенең бу эшен хәрби тәртипләрне бозу дип аңлый һәм аның өстеннән «рапорт язам» дип куркыта. Аның каравы комиссар дигән бу бәндә хезмәт итә торган частенең символы саналган байракны саклау мәсьәләсендә, димәк, турыдан-туры сәяси бурычын үтәүгә битарафның да битарафы. Хәрби уставта язылганча, аның югалуы, бу очракта дошман кулына эләгүе – ул инде частьның да юкка чыгарылуы дигән сүз. Байракны саклау – иң әүвәл командир һәм әлеге сәяси эш өчен җавап бирүчеләр бурычы. Әмма, Х.Камалов сурәтләгәнчә, чолганышта калулары ачыклангач, боларның берсенең дә бу хакта гаме калмый. Байракны гап-гади старшина белән әлеге дә баягы Томилин гына кеше-кара күрмәстәй урынга яшереп куялар. Иң гыйбрәтлесе шунда: Красновка полк байрагын ташлап качканлыгы турында исенә төшергәч, ул, бернинди дә вөҗдан газабы кичермичә генә, «байрак минем җаваплылыкта түгел» дип котыла. Шул ук вакытта полкның таралып бетүендә дә үзенең кечкенә генә булса да гаебен күрми, барысына да Томилин җавап бирергә тиеш дип таба. Төп көчләргә барып кушыла алган очракта шушы хезмәттәше өстеннән шикаять язачагын искәртеп тора. Югыйсә, бер солдат авызыннан әйтелгәнчә: «Плен калганга без гаеплемени, баш командирлар ташлап качтылар бит. Без нишли алабыз?» Полкның шушы хәлгә дучар булуына, сүз дә юк, иң элек аның командиры җавап бирергә тиеш. Томилин батальон командиры гына бит. Һәм аның гаебе булу һич мөмкин түгел. Ул әле һаман да солдатлар арасында, ягъни үз урынында. Әмма аның күңеле тыныч түгел. «Үзебезгә чыга алсам да, миңа шикләнеп караячаклар, дигән уй килде Томилинга. Званиедән дә мәхрүм итүләре мөмкин. Ул шик куләймә кебек миңа гомер буе ябышып торачак».

Х.Камалов, шактый озынга сузылган шушындый экспозицияне тәфсилләп сурәтләгәннән соң, хикәяләүнең төп өлешенә күчә. Әлеге офицерлар икесе дә шактый җитди яралана. Красновның җәрәхәте аеруча җитди, ул хәтта мөстәкыйль хәрәкәтләнә дә алмый. Томилин аны өч мәртәбә үлемнән коткарып кала. Берсендә ветеринария медицинасы санитаркасының аны дәвалавына ирешә; икенчесендә совет чорында төрмәләрдә интеккән кеше тарафыннан буып үтерелү ихтималыннан коткара; ахыр чиктә, ниһаять, кеше түзмәстәй кыенлыклар аша үтеп, үзен куркыныч астына куеп, иптәшенең исән хәлдә үзебезнекеләр ягына чыгып җитүенә ирешә.

Бу вакытларда ара-тирә аның башына каршылыклы уйлар да килә. Ул Красновның кыен вакытларда үзенә елышуында эчкерлелек тә күрә. Красновның «яхшылыгыңны онытмам» диюенә каршы «бәладән котылуга онытачаксың» дип әйтүе шуннан килә. Шуңа карамастан, өстенә изге йөкләмә алгандай, Красновны коткаруын дәвам иттерә. Шуның белән үз үлемен якынайтканнан-якынайта бара. Чөнки Краснов, ниһаять, үзебезнекеләр ягына чыккач, чын йөзен күрсәтә, үзенең чолганыш шартларында да илгә тугрылык саклавын дәлилләү максатында, иптәше Томилинны батыра, ягъни полкның таркалуында гаепле кешеләрнең берсе итеп аны күрсәтә. Сугыш чорының кырыс кануннары нигезендә Томилин штрафбатка эләгә, һәлак була. Краснов исә, исән калып, соңыннан фирканең район җитәкчеләреннән берсе булып, һич тә вөҗдан газабы кичермичә, рәхәт кенә гомер сөрүен дәвам иттерә. Аның Томилинны гаепле итеп күрсәтүенең шәхси сәбәбе дә бар. Краснов сугышның иң хәлиткеч мизгелендә, авыруы турында ялган документ күрсәтеп, алгы сызыкка барудан, солдатлар белән бер сафта кулына корал алып һөҗүмдә катнашудан котылып кала. Моның шаһите булган Томилин кайчан да булса аны фаш итәр дип шикләнә, ягъни ул аның да шушындый адым ясавыннан курка. Моны булдырмас өчен, аны юлыннан алып ташлау иң ышанычлы юл дип саный. Укучы күреп тора, Томилинны яхшы күңеллелеге харап итә – үзенең антиподын белә торып исән калдыра. Башкача эшләү аның табигатенә каршы килә. Димәк, явызлык өстен булып чыга.

Каләм остасы Х.Камалов, шул рәвешле, жанрын «фронт истәлекләре» дип билгеләгән бу әсәрендә дә чынбарлыктагы хәл-әхвәлләрне сәнгатьчә камил кабул ителерлек образлар язмышы аша сурәтләп биргән. Бу – аның олыгайган көннәрдә дә үзенең язучы буларак казанышларына яңадан-яңа сәхифәләр өсти баруын күрсәтә. Бу әдипнең «Сугыш зигзаглары» әсәрендә (2011) тагын да ачыграк күренә. «Мин» авызыннан бәян ителгән вакыйгалар сугыштагы кешеләрнең әлегә без белеп бетермәгән хәлләрен күз алдына китереп бастыру ягыннан, шактый яңалыклар алып килү җәһәтеннән дә кызыклы. «Мин» вакыйгаларның башыннан азагына кадәр яшәү һәм үлем арасында чайкала. Шул ук командир-штабистларның булдыксызлыгы аркасында әсирлеккә тап булган «Мин»нең очраклылыклар тезмәсе чолганышында исән кала баруы маҗаралылыкны көчәйтә. Офицер икәнлеген яшереп, сугыш шартларында югалган Блюхер фамилияле солдатның документларын күрсәтеп, әсирләр исемлегенә совет немецы булып теркәлә, нәтиҗәдә Алмания паспортына да ия була. Димәк, аңа фашистлар кулы астындагы теләсә кайсы җиргә барып чыгу мөмкинлеге бирелә. Әмма «Мин» – чын мәгънәсендә совет иле патриоты. Шуңа күрә, беренче мөмкинлеге булу белән, үзебезнекеләр ягына чыга. Әлбәттә, кесәсендә немец паспорты булган кешегә бездә ышанмыйлар. Аның хакыйкатьне әйтеп бирүе дә нәтиҗәсез кала. «Без, – ди ул, – пленга төшүебезне абайламадык. Кем безне немец авызына илтеп тыкты, шул хыянәтче!» Әмма бу очракта да аны очраклылык коткара. Ягъни әсәрдә очраклылык тенденция булып әверелә. Моннан берничә ай элек үзе үлемнән коткарган капитан Малайчукны очрата. Аның ярдәмендә яңадан армия сафына баса. Дошманның аеруча куркыныч ут ноктасын юк итүгә уңышлы җитәкчелек иткәне өчен, өченче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Әнә шундый көтелмәгән очраклылыклар булмаса, ул йә немецлар тарафыннан, йә безнекеләр кулыннан күптән һәлак ителгән булыр иде. Чөнки, төрле эпизодларда күрсәтелүләренә караганда, теге як та, бу як та әсирләргә мөнәсәбәтләре ягыннан әллә ни аерылмый. Шулай да автор персонажлары авызыннан немецларда күпмедер дәрәҗәдә объективлык өстенлек итә дигән караш белдерә. Мәсәлән, одессалы Отто болай ди:

– Бездә бит сүз өчен дә утырталар. Немецта сүз өчен түгел, фәкать властька каршы килгән эш өчен утырталар.

«Мин» – җиңүгә ихлас өлеш керткән халык вәкиле. Х.Камалов андыйларга сокланып карый, аларның тыйнак батырлыкларын яратып сурәтли. Шундыйларның берсе, әлбәттә, Зинкель. Ул Ригадагы немецлар арасында үскән. Фашистлар Риганы алгач, аларның армиясенә, безнекеләр кушуы буенча, разведчик булып үтеп керә алган, сугышның буеннан-буена алар арасында булган. «Мин»нең совет армиясе офицеры икәнлеге фаш ителмәүдә, исән калуында да Зинкельнең хәлиткеч өлеше бар. Ул бу елларда алтмышлап кызыл командирны коткарып кала алган. Үз иптәшләрен

## РУХИ МИРАСЫБЫЗ ҺӘРЧАК ЮЛДАШ БУЛСЫН!

**Халкыбызның озын-озак үткән юлы, данлы да, фаҗигале дә тарихы бар. Ул күп гасырлар элек үк Евразия киңлекләрендә төрле дәүләтләр төзегән-тоткан, дөньяга үзенең сүзен ишеттергән, барлыгын таныткан. Әби-бабаларыбызның тормыш тәҗрибәсе, эчке дөньясы меңәрләгән мәкаль-әйтемнәрдә, бәет-дастаннарда, күңелләрне тетрәндерерлек һәм җилкендерерлек җыр-моңнарда, әдип-шагыйрьләребезнең үлемсез әсәрләрендә, газиз татар телебездә, географик атамаларда теркәлеп калган. Бу рухи кыйммәтләрне зиһенебез хәзинәсе, тереклегебез юлдашы итү безне әби-бабаларыбызның рухы белән якынайта, буыннар дәвамчанлыгын, бәйләнешен тәэмин итә, милли бөтенлегебезне, барлыгыбызны яшәтә.**

**Һәр адәм баласы, кем булуына карамастан, иң әүвәл үзенең холкы-фигыле, шәхси йөзе белән кызыклы. Һәркайсыбыз бертөрле булсак, дөньяның яме бетәр иде. Милләтләр белән дә шундый ук хәл. Үз-үзләренә ихтирамлы милли менталитетларын саклаган, күп гасырлык традицияләрен дәвам иткән халыкларның башка милләтләргә карата да күңелләре киң һәм мөнәсәбәтләре дустанә.**

**Бүтән кавемнәрнеке кебек, татарның да үз милли идеясе, милли кодексы бар. Ул бер дә катлаулы түгел, бик гади: тарихны, рухи мирасыбызны белү, элеккеге буыннардан килгән традицияләргә, иман-әхлакка тугры калу, туган җиреңне, туган табигатеңне, Идел-йортны ярату, башка кавем-илләргә ихтирами мөнәсәбәт. Төрле объектив-субъектив сәбәпләр аркасында, күп гасырлар дәвамында халкыбыз шактый таралган, сибелгән. Әмма тарихи чынбарлык шуны күрсәтә: үз халкының тарихи, төп яшәү урыныннан аерылып, читкә киткән, диаспорага әверелгән адәм балалары, кагыйдә буларак, иртәме-соңмы (еш кына ике-өч буын эчендә) башка кавемнәр арасында эри, ассимиляцияләнә, милли барлык буларак юкка чыга, үзгә милләтләр өчен чималга әверелә. Шуңа күрә безгә, нинди генә сәбәпләр булса да, мөмкин кадәр этник яктан оешып, үз милләттәшләребез белән гаилә корып, тарихи Ватаныбыз булган Идел-йортта яшәргә, эшләргә, укырга, гомер итәргә кирәк. Сабырлык — әйбәт сыйфат. Әмма безгә татарлыгыбызны, милли барлыгыбызны мескенәйтә, юкка чыгара торган, кирәгеннән артык сабырлыктан, түземлелектән котылырга да кирәктер. Башка кавемнәр кебек, без дә Ходай Тәгалә тарафыннан яратылган адәм балалары, безнең дә зур җиһанда, якты Кояш астында вакланмыйча, кол булмыйча ирекле яшәргә, үзебезчә тереклек кылырга тулы хакыбыз, табигый хокукларыбыз бар.**

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

сатучыны юк итүдә дә Зинкельнең роле булгандыр дип уйларга кирәк. Х.Камалов, чын ватанпәрвәрләргә бәя биреп, әсәрне болай тәмамлый: «Ватан сугышында нинди генә батырлыклар, үз-үзеңне аямыйча нинди генә фидакарьлекләр эшләнмәде! Нинди генә кан, җан, тир, хәләл көч түгелмәде! Очы-кырые юк андыйларның. Ни кызганыч, барысы да вакыт туфрагы астында күмелеп калды, югалды».

Әйе, әдип-сугышчы аларның онытылуларын теләми. Ул, кулыннан килгәнчә, хәл кадәри, шул фидакарьлекләр вакыт туфрагы астында күмелеп калмасын өчен, хәтер төпкелләрендәге вакыйгаларны, аларның каһарманнарын һаман да исенә төшерә, алар турында яңа буыннарга сөйли. Әйтик, «Сугыштан кайткан сөю» кыйссасы да (2013) шул ук вакыт чылбырына барып тоташа. Шәфкать туташы Надия белән смерш вәкиле булып хезмәт иткән Павелны да сугыш очраштыра. Әмма хатын-кызларга матур чәчәк итеп кенә караган, аны өзеп алырга үзенең хакы бар дип санаган бу ир сугышның буеннан-буена гыйффәтен саклап килгән татар кызын кыен хәлгә калдыра. Надия, шушы гаебен яшерү максатында, үзен яратып йөргүен абайлаган Мәгариф исемле егетне ире итүгә ирешә.

Сугыш рәсми төстә бетсә дә, чынлыкта әле совет иленең Польшага якын чикләрендә, Украинаның көнбатышында, Балтыйк диңгезе буендагы җирләрдә төрле коралллы бәрелешләр дәвам итә. Х.Камалов бу хәлләрне «Яңа шәһәрдә» (2015) бәянында да тасвирлый. Татар егете Сәлимнең латыш хуторында тыныч кына яшәп ятучыларны гомер иткән җирләреннән куып җибәрүдә катнашырга тиеш булуы аның тирән кичерешләре ярдәмендә сурәтләнә.

Шундый вакыйгаларның берсендә каты яраланган Мәгарифне дә язмыш хастаханәдә эшләүче шәфкать туташы Надия белән таныштыра. Казанга кайтып яшәп китәләр. Малайлары Артурның үзенеке булуына бөтен барлыгы белән инанган ир күңеленә шом салып, әлеге «күке» – Павелның бу якларга килеп чыгуы хәлне катлауландырырга тиеш булса да, Мәгариф балага булган аталык хисенә хилафлык китерми. Аңардагы мондый ныклы ышаныч Павелны да үз сүзләреннән чигенергә мәҗбүр итә. Вафат булган Надиянең баласын бүлешүдән мәгънә чыкмаячагын ныклап аңлаган Павел да әлеге «өчпочмактан» төшеп калырга карар кыла.

Мәгарифне Надиягә һәм баласына карата аек акыллы, нык үзәкле кеше итеп сурәтләсә дә, автор аның башка кайбер мәсьәләләрдә бу сыйфатының эзлекле булмавын да искәртә. Әйтик, әтисе бөтен күңеле белән Ислам диненә инана, аның таләпләре буенча яши. Мәгариф үзен хезмәт баскычында күтәрмәүләренең сәбәбен әтисенең җәмәгатьчелеккә дин белән мавыгуы билгеле булудан күрә. Шуның өчен миңа ышанып бетмиләр, дип уйлый. Ул еллар идеологиясе мохитендә яшәгән кеше өчен бу шактый җитди сынау. Шуңа күрә ул әтисенең җәмәгатьчелек алдында диннән баш тартуын таләп итә. Көн саен, ай саен әйтә торгач, аптыраган әтисе аның бу урынсыз гозеренә гел каршы килеп тора алмый, улы теләгәнчә эшли. Әмма бу хәл Мәгарифкә бәхет елмаюын тәэмин итми. Бердән, рухына зәгыйфьлек китерелгән әтисе җан тәслим кыла, икенчедән, ире белән баласын калдырып, хатыны Надия дә бакыйлыкка күчә. Чынлыкта сугыш вакытында совет идеологиясе генә түгел, кешеләр күңелендә тирән урнашкан изге дини хисләр дә яшәүчәнлекләрен раслады. «Сугыш зигзаглары» хатирәләрендә әйтелгәнчә, сәламәт акыллы кешеләрнең берсе дә әхлак нигезләре юкка чыгарылган немец фашистлары хакимлеге астында калырга теләмәде. Мондый омтылышның ныклыгын дини ышаныч та тәэмин итте. Иң хәтәр һөҗүмнәргә барганда, сугышчылар күңелләренә юлбашчыларның исемнәрен китерүдән бигрәк, Аллаһыны зекер иттеләр, иреннәрен әгузе-бисмиллаларын әйтеп хәрәкәткә китерделәр. Шунысы ачык: иман ныклыгы сугышта аеруча кирәк булган кебек, тыныч тормышта да бик мөһим. Ул – кешене гомере буена кеше итеп яшәтүче көч. Без моны фронтовикларның соңгы елларда матбугатта басылган күп кенә хатларыннан да ачык күрәбез. Х.Камалов исә үзе алар белән бергә шул хисләрне кичергән кеше, шуңа күрә ул сурәтләгәннәр ышандыра, аның әсәрләренә, шул ук солдат хатлары кебек итеп, инанып каравыбыз да шуннан килә. Ул – бүгенге көндә, фронтларны кичеп тә исән калган, шул хакта хакыйкатькә тугрылык саклаган каләм тибрәтүче берденбер әдип. Аңа саулык-сәламәтлек, алдагы елларда да каләменә ныклык һәм иҗади көч телисе генә кала.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**<br>
*филология фәннәре докторы, профессор*

# «МИН – МӘҢГЕ ТУТЫКМАС АЛТЫН ТӨРӘН!»

## *Ренат Хариска 75 яшь*

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге Республика премияләре, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис дигәндә, күз алдына халыктан чыккан, рус һәм европа культурасын үзенә сеңдергән, шигърияттә ялкынлы хис белән зирәк акылны берләштергән, әдәби символлар һәм кодлар белән эш итеп, поэтик фикерне фәлсәфи яссылыкта чишүче, туктаусыз эзләнүче, яңа формаларда даими рәвештә үзен сынаучы һәм табучы, башкалар арасында әллә каян аерылып торучы, киңкырлы зыялы шәхес күз алдына килеп баса. Әйе, аның һәр шигыре, шигыренең һәр юлы үзенчә, Ренат Харисча. Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким дә аның «Кайтаваз» җыентыгына сүз башы итеп куелган фатихасында болай дип яза: «Шагыйрьнең көче фикердә, хистә, яза торган предметның эченә, үзәгенә үтеп керә алуында. Шигырь тыгызлап тутырылган хисләр хисабына карап зурая, масштаб – уйлауның киңлегендә»[1] .

Ренат Харис дигән шагыйрьнең әсәрләре белән беренче танышуым урта сыйныфларда укыган чагымда булды. Җәйге каникул чорында, вакытны бушка аударып йөргән бер мәлдә, әтием аның «Алтын төрән» дигән җыентыгын кулыма тоттырды да: «Менә, улым, сиңа бер китап, укы!» – диде. Мин, сары битләрне әкрен генә ача-ача, тышлыгына сары кояш һәм аклы-каралы ялкын сурәтләнгән серле мәҗмуганы укый башладым:

*Җир сөрәм...*
*Гасырлар катламнарына үтеп керәм...*
*Туфракта Киек Каз Юлының тузанын күрәм...*

*...Мин җир сөрәм –*
*кеше язмышын бураznага һәм кояшка кушып үрәм.*
*Мин – мәңге тутыкмас алтын төрән!*
(«Алтын төрән»)

Менә кайда ул Сибгат Хәким әйткән үзәккә үтеп керү, яңалык эзләү, халыклар арасына дуслык буразнасы сызу!

*Карга бассам, кыш булам мин,*
*җәй булам, чәчәк тотсам.*
*Чор-дәверләр тамырына*
*әйләнәм, юлга чыксам.*

*...Чыкка кагылсам – Идел мин,*
*Иделгә тисәм – диңгез.*
*Бер карасаң – миллиардтан бер,*
*бер карасаң – һич тиңсез!*
(«Бар тырышканым»)

Менә шагыйрь нинди булырга тиеш икән! Бер формадан икенчесенә кереп, төрле илаһи әверелешләр кичереп кенә языла икән шигырь дигән тылсымлы сүрә! Имән турында үзеңне йөзьяшәр агач итеп тоймыйча; уй белән галәм караңгылыгына чуммыйча, космик киңлекләр хакында язып буламы? Һич юк! Ә Р.Харис җәлилченең һәрберсе булып шигырь яза, батырларның һәрберсе кичергән тән газабын үз тәнендә

[1] Хәким С. Һәр талант үзенчә килсен // Харисов Р. Кайтаваз: шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1969. – Б.5.

тоеп, аларның еллар аша вакыт чоңгылына уралып калган рухи ныклыгын күңеле белән сиземли («Җәлилчеләр»).

Ренат Харисның «акыллы» шигырьләрен укып, әсәрләнеп, ул әйткән фикерне үземчә шәрехләп, шактый уй өермәсендә йөрдем ул чакта.

Өлкән сыйныфларда укыганда, «Өянке» шигыре бәгыремә уелды:

*Өскә үсмәсен әле дип,*
*Баш ботагымны киссәң,*
*Мин бит як-якка үсәм!..*

*Киңлеккә китмәсен диеп,*
*Ян-якларымны киссәң,*
*Мин куелыкка үсәм!..*

*Куелыкка үсмәсен дип,*
*Ябалдашымны киссәң,*
*Мин тамыр якка үсәм!..*

*Бәгыренә чабыймчы диеп,*
*Казып тамырыма төшсәң,*
*Кабрең өстендә үсәм!*

Укытучыбызның: «Шагыйрь, бәлкем, өянке белән татар язмышын тиңлидер», – дигән сүзләре миңа җитә калды. Әлбәттә, бу без – татарлар, гасырлар дәвамында киселеп, туралып исән калган, Бөек Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыкларын тоткан әби-бабаларыбызның дәвамчылары! Менә шагыйрь киләчәк буынга ничек үтемле, кыска һәм тирән итеп милли тәрбия бирә! Без һич кенә дә кем икәнлегебезне, тарих юлында нәрсәләр кичергәнебезне онытырга тиеш түгелбез дигән милли идея үтә әлеге шигырьдә. Төрле яклап кыркылган өянке хәлендә дә без булганбыз, бар һәм булачакбыз!

Милли тематиканы, халкыбызның йөз аклыгын, кунакчыллыгын «Ак сөлге», «Сусап кил!» шигырьләре дәвам итә:

*Кайсына биек, кайсына*
*Бик җайлы бусагасы...*
*Ул ярата кунакларның*
*Дуслыкка сусаганын.*

Татар халкы – дуслык тарафдары, кояшны кара корым белән каплаучы тиранлык илчесе түгел.

Миллилек «Сабантуй», «Ат иярләү», «Ант суы», «Татарлар» һ.б.лар кебек зуррак күләмле әсәрләрендә – поэмаларында тагын да тирәнәя, дөньякүләм дәрәҗәгә, халыкара мөнәсәбәтләр кимәленә күтәрелә.

Ренат Харис – кырыктан артык поэма авторы. Һәммәсе дә бер очтан язылган әсәрләр түгел, арада төрлелек аеруча күп: поэма, драматик поэма, поэма-фантазия, хикәят, поэма-монолог, фронтовик монологы, эротик поэма... Еллар узгач, шагыйрь уртача күләмле шигъри әсәрләре белән зур күләмлесенә килә. Нәтиҗәдә, «Исемсезләр» шигырь-романы ярала. Әдәбият галиме Фәридә Хәсәнова: «Ренат Харис бу әсәре белән татар әдәбиятында яңа сүз әйтте, яңа заман һәм аның геройларын тудырды...» – дип яза .

Күренә ки, автор туктаусыз яңалык эзли, гадидән катлаулыга кызу темплар белән бара, чын мәгънәсендә җиң сызганып, җиде кат тирен чыгарып иҗат итә. Минемчә, чын халык шагыйре шундый булырга – фикер белән дә, тырышлык белән дә алдырырга тиеш.

Мәхәббәт лирикасында автор эротик поэма жанрына алынырга үзендә көч таба («Өч үбешү»). Дөрес, бу – татар халкы өчен ят, шул ук вакытта башка сыймастай оят күренеш кебек, ләкин табигыйлектән качып булмый. Әдәби югарылык турыдан-туры ялангач

натурализм итеп кабул ителә алмый, ә күңелдә фәкать матур хисләр генә калдыра. Өстәвенә, А.Пушкин, Г.Кандалый, Г.Тукайларның әлеге юнәлештә язылган әсәрләре безгә яхшы мәгълүм. Шуңа да Ф.Хәсәнова шагыйрьне Г.Кандалый традицияләрен үстерүчеләр сафына кертә, Р.Харисның мәхәббәт лирикасын хисләр энциклопедиясе дип атый.

Шагыйрь либретто, сонет, лирик пейзаж кебек жанрларда да каләмен сыный, үз сүзен әйтә; татар балалар әдәбиятын да матур шигырьләр, поэмалар белән баета:

*Төсле рәсем ясарга*
*Мәдинә бик ярата:*
*ясый гөлгә карап та,*
*ясый күлгә карап та,*
*чуерташка карап та,*
*һәм кояшка карап та...*
*Һич уйламастан, ялгыш*
*килеп чыга көнбагыш!*
(«Төсле рәсем»)

Хыялый, беркатлы, иҗади, табигатькә якын чып-чын бала күңеле әлеге кыска гына шигырьгә сыйган да беткән. Артык сүз кирәк түгел. Гомумән, Р.Харис сүзләргә бик талымлы, игътибарлы, аның әсәрләрендә һәр сүз үз урынында, артыгы юк, шуңа ул ясаган сурәт, ул тудырган һәр образ ачык, якты, конкрет һәм матур килеп чыга.

Р.Харис танылган җырлар авторы буларак та, дөнья әдәбиятының күренекле шагыйрьләренең әсәрләрен (Г.Державин, А.Пушкин, А.Ахматова, У.Шекспир, Г.Лорка, О.Сөләйманов, Н.Хикмәт һ.б.) татар телендә яңгыратуы белән дә игътибарга һәм ихтирамга лаек. Гавриил Державинны тәрҗемә итү өчен генә дә аз тырышлык соралмый:

*Океаннар тирәнлеген үлчи алган,*
*Барлый алган комнар санын, нурлар көчен*
*Олуг акыл табылса да бу дөньяда,*
*Сан табылмас, Аллаһ, Сине үлчәр өчен.*
*Яктылыгың нурларыннан Синең туган,*
*Синең рухың белән мәгърифәтле булган*
*Син язганны беркем дә үзгәрталмас.*
*Уй-хыяллар гына, ашып Синең катка,*
*Бөеклегең тирәнлекләренә бата,*
*Мәңгелектә мизгел эрегәндәй, Аллаһ!*
(Г.Державин. «Аллаһ»)


*Болгар. Кара пулат.*
*Ренат Харис рәсеме.*

Р.Харис – акыллы публицист та, рәссам да. Язган мәкаләләре төплелеге һәм фәннилеге белән аерылып тора. Рәсемнәре исә, үзе әйткәнчә, бармакларындагы рәссамлык хәтере белән бәйле. Ясаган сурәтләре шигырь юллары белән кушылып китә, бер-берсен тулыландыра, баета.

Аның дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак башкарган эшләре дә бихисап. Дәүләт Советында эшләгәндә, ул Татарстан Республикасының Дәүләт флагын, гербын, гимнын кабул итүгә әзерли, шуның нәтиҗәсе буларак, 2005 елда татар, рус һәм инглиз телләрендә «Татарстан символлары» дигән китабы дөнья күрә.


Күп каләм әһелләре иҗат итүне газаплану, интегү, иза чигү белән тиңли. Мин гел уйлый идем: иҗат газап китерә икән, нигә язып торырга, башка һөнәр тап та рәхәтләнеп, кинәнеп

яшә! Бернинди кыенлыгы юк бит. Бу яктан Р.Харис белән фикерләребез тәңгәл килде. Ул: «Иҗат итү газап булса, мин бер юл шигырь дә язмас идем, бер генә рәсем дә ясамас идем...

Алдыма ак кәгазь салсам, кулыма каләм алсам, мин иҗат ләззәте татыйм. Аһ! Тик гомерләр генә бер, дусларым, һәм кыска...» – дип яза .

Чыннан да, иҗат процессы каләм әһеленә ләззәт, рухи канәгатьләнү китерергә, яңа башлангычларга нигез булырга, биек үрләргә этәрергә, аны илһамландырырга, рухландырырга тиеш.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан якты дөньяга аваз салган халык шагыйре бүген 75 яшьлек гомер бәйрәмен каршылый. Узган гасырның 60нчы елларында үзенчәлекле сурәтләү алымнары, үзгә язу өслүбе белән татар әдәбиятына килеп кергән әдип «Поэзия» шигырендә:



*Аккош күле. Язучылар капкасы.*
*Ренат Харис рәсеме.*

*Никахлаштык яшерен генә...*
*Беркемнең фатихасын*
*сорамадым һәм алмадым...*
*Гомер буе туй ясыйм.*

*...Сер идең син, чыктың тышка*
*йөрәккә капкан уттай...*
*Безне мәңгелек яр итеп*
*никах укыды Тукай,*

– дип яза. Барысы да анык әйтелгән, Ренат Харис – үзен тулаем шигърият, әдәбият, сәнгать белән бәйләгән якты шәхес. Аның «мәңге тутыкмас алтын төрәне» озак еллар, бер дә туктамыйча, буразна салуын дәвам итсен, шул буразналардагы орлыклар шытым биреп, яңа әсәрләр тусын!

**Ленар ШӘЕХ,**
*филология фәннәре кандидаты*

***Редакциядән:***

*Бу айда 1982-1989 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булган Татарстан Республикасының халык шагыйре, Россия Федерациясенең Дәүләт, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, җәмәгать эшлеклесе Ренат Хариска 75 яшь тулды. Аны юбилее белән котлыйбыз! Каләмдәшебезгә саулык-сәламәтлек, иминлек-тынычлык, иҗат уңышлары, сәгадәтле гомер телибез!*

# УЧЛАРЫНДА УТЛЫ КҮМЕР...



Шагыйрь, әдипләр Хак Тәгаләнең Җирдәге тугры илчеләре дисәм, шаять, сүземне бәгъзе бер адәмнәр хупламас. Ил, халык мәгыйшәтендәге кырку борылышлар, яисә гавам башына төшкән бәла-казалар, әрнешле югалтулар каләм ияләренең йөрәкләрендә кайтаваз булып чыңлый, күңел станында сүз-хис итеп тукыла һәм шул әмәл белән язучы, кәтибләр халыкның «хиссияте миллия» дип аталган утта янмас, суда батмас, тутыкмас вә күгәрмәс рух хәятен кора дип әйтү инде кире каккысыз сүз булыр. Әмма, килешегез, әлеге искитәрлек гамәлне үтәү тик илаһиятле затлар кулыннан гына килә бит:

*Йөрәк моңга тулгач, нишлим инде.*
*Моңнарымны җиргә таратам.*
*Сагыш-газап, әрнү кичерсәм дә,*
*Фани дөнья, сине яратам.*

*Йөрәк моңлы булгач, нишлим инде,*
*Моң-дәрьялар аша җан атам.*
*Янам, көям, очкынланам, шашам,*
*Дөньяны мин шулай яратам.*

Әлеге юлларның авторы – танылган шагыйрә Рәзинә Мөхияр. Шунысы үтә кызыклы: Башкортстанның шигъриятле Базы буйларында гөлләр, чәчәкләр арасында үскән, җиләкле аланнарына сокланган, әче баланнарын татыган авыл кызының, Уфага килеп, фән, әдәбият-сәнгать юлына кереп китү шаһите мин. Октябрьнең 40 еллыгы исемендәге Башкорт дәүләт университетында ачылган өч айлык әзерлек курсы шәкерте, аннары бу уку йортындагы татар-рус бүлеге студенты сыйфатында ул әле һаман күз алдымда: дәрес, лекцияңне бирелеп тыңлый, күзләрендә яктылык, нур...

Хәзер уйлыйм, студенттагы әлеге чалымнар яшьлек дәрте, җегәр, белемгә сусау һәм иҗатка тартылудан гына калыкмаган. И, ул Хрущёв җепшеклеге алып килгән иркенлек рухын тою, Леонид Брежнев авызыннан ычкынган «Икмәк булса, җыр да булыр!» гыйбарәсенә таянып киләчәкне юраулар... Халык, рухы белән ныгып, хезмәткә, иҗатка тартылды. Башкортстан татары, болыт арасыннан чыккан кояшка тиңләп, бу елларны әле дә сагына...

Бездәге игенче, терлекче үзаллылык алгач, авыллар ныгый, матурлана төште. Туган телдә белем биргән мәктәпләр мәгърифәт нуры чәчә... Татар теле дәүләт теле хокукына ия булгач, милли театр, нәшрият эшли, әдәбият күтәрелә. Хәер, язучыларны да башкортка, татарга бүлгән юк. Мостай Кәрим дә, Нәҗәр Нәҗми дә, Әнгам Атнабаев та һәркайсы тугандаш кавемнәр өчен уртак, үз кешеләр бит... Әлеге чын демократик күтәрелеш елларында университеттагы милли бүлек һәм татар теле, әдәбияты кафедрасының абруе зур, югары булды. Монда иҗади түгәрәкләр гөрләп эшләде, әлеге уку йортыннан укытучы-педагоглар гына түгел, күпсанлы журналистлар, җырчылар, артистлар да тәрбияләнеп чыкты. Билгеле, университеттагы казанышлар җиңел генә килмәгән. Хәзер инде дөнья күреп, сарай интригаларыннан азмы-күпме хәбәрдар кеше буларак, яхшы төшенәм: алар ректорыбыз Шәйхулла Чанбарисов тырышлыгы нәтиҗәсендә туганнар икән. Гомәр Бәширов «Комиссар» исемле очеркында аның хакында гаҗәеп факт тасвирлаган. Ерак Көнчыгышта Япон самурайлары белән алышканда, полк комиссары Чанбарисов, рациянең җегәре чамалы икәнен белгәч, каршы яктагы телефонга татар кешесен утыртуны сорый һәм шуңа ирешкәч, ачык эфирга чыгып, мөһим хәбәрне бик тиз тапшыра алган зирәк комиссар. Ана теленең кадерен, кирәклеген тойган ректор Чанбарисов фәнни-педагогик мохиттә татар телен кысрыклауга, чикләүләргә юл куймады һәм, конституцион нигезләргә таянып, үз милләтенең хокуклары өчен көрәште. Ул чакта аның кебек аек карашлы, төпле акыллы гаярь ирләр татарда да, башкортта да байтак иде шул. Тик ил өстендә үзгәртеп кору,

суверенитет зилзиләләре уйнады. Кемнәрдер моны алкышлап кул чапты, мәйданнарга төрле төркемнәр чыкты. Әмма сүз ирегe дип тегене-моны кычкырудан яисә яңа берничә гәзит-журнал чыгарудан, провинциаль югары уку йортларында милли бүлекләр ачудан ни юаныч?.. Әлеге болгавыр көннәрдә башкорт татары рәсми тел хокукыннан язды. Ә тел бетсә, кавем үлә, рух сүнә…

Шагыйрәне формалаштырган мохит турында уйлануларым юкка түгел. Матур табигать хозурлыгы, якты кояш астында, киләчәккә зур өметләр белән башланып, инде караңгылыкка чума барган кавем хәяте милли гамьле Рәзинә Мөхияр иҗатында үз эзен салмый каламы соң? Тик искәртү кирәк, лирик жанр остасы һич тә сәяси лозунглар кычкырмас, публицистик пафоска бирелеп, кемнәргәдер нәгъръә ормас, аның чынбарлыкка мөнәсәбәтен иң элек лирик геройдан, аның күңел халәтеннән эзләргә кирәк. Әйтик, иҗатының башлангыч чорында язылган «Яктылыкка туя алмам» шигырендә ул иртән торып кояшка баккан сабый кебек ихлас:

*Бу дөньяның матурлыгын*
*Күрергә дип туганмын.*
*Һәр мизгелгә, һәрбер таңга*
*Сокланудан туймамын.*

*Якыннарны, дус-ишләрне*
*Зарлар белән күммимен.*
*Ак төсләрне табып яшим,*
*Караларын күрмимен.*

Мондагы лирик герой шулай фикерләп, үзен «туганда ук көлмәк киеп туган зат» рәвешендә тоя. Рухы да нык аның: *«Бөгеләм, менә сынам, дигәндә дә тураям…»*

Шулай да аклык, кояшлы яктылык, өмет белән сугарылган шигырьләр Рәзинә иҗатында күп түгел. Гоманымча, моның төп сәбәбе – Башкортстан татарының җанын кыйган парадоксаль хәл:

*Залимлектә телне саклый алдык,*
*Хәзер менә нинди көнгә калдык!*
*Демократлар хәзер телне кыса,*
*Берәм-берәм канун артка поса.*

*Аллаһыдан әманәт – тел саклау,*
*Җил-давылдан, өермәдән яклау.*
*Бетсә, кире кайтару бик авыр,*
*Ташлар булып тел каргышы явар…*

Шулай, халыкка хөрлек, иркенлек китерәбез дип башланган демократлар парады «Уян, халкым!» әсәрендә көтелмәгән ноктадан торып халык фаҗигасе итеп тамгалана. Хәзер лирик герой социаль иллюзияләрдән дә арынып, «сикәлтәләр, каршылыклар ерып, дөрес юлдан бару бик авыр» дигән кырыс нәтиҗәгә килә. Аның карашын бик еш тормыш-көнкүреш көйсезлекләре, ямьсез манзаралар җәлеп итә: *«Хәерчеләр тулган урамнарда / Байлар тоя микән бәхетне? / Тынгы тапмас беркем мондый илдә / Булган очракта да тәхетле»*. («Теләнчеләр»)

Рәзинә хәтта ил халкының чыраенда да ямь, матурлык тапмый: *«Рәссам Репин бурлаклары сыман / Өметсезлек, сыкрау йөзләрдә…»* («Мәскәү ягы»)

Һәм яңа байлар, манкортлар, маргинал затлар хуҗа булып өлгергән илдә каләм иясенең түбәндәге сорауга килеп чыгуы һич тә гаҗәп түгел:

*Милләтемне һәм телемне*
*Әхлагымны, динемне*
*Саклар өчен, яклар өчен*
*Кайда чара, йоласы?*
*Ниләр генә кыласы?!*

Сөендерә, үзе куйган авыр сорауга зирәк шагыйрә җитди җавап та таба белгән:

*Асылыма кайтам. Асылыма,*
*Каралыгың, дошман, син сылама!*
*Пычрак атып юлны капласаң да,*
*Юа-юа кайтам асылыма.*

Әйе, азатлык, хөрлек юлын бикләүчеләр белән генә түгел, ә үз-үзең белән көрәшеп тә асылыңа кайту, аны саклау ифрат авыр, кыен булса да, газиз телеңне, милләтеңне, тарихыңны имин яшәтүең – иң дөрес һәм ышанычлы юл.

Лирик геройның иҗтимагый йөзен тасвирлауда Мөхиярның Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Муса Җәлил, Хәсән Туфан кебек талантлар мәктәбен иҗади үзләштерүе күренә. Шагыйрәнең лирик герое хатын-кыз булгач, аның иҗатында мәхәббәт темасының да зур урын алуы табигый. «Кытыклана җанда сөю хисе», дип, Рәзинә укучысы белән ихлас булырга тырыша, хыялын да эшкә җигә:

*Төн җитүгә айга менәр идем,*
*Уең белән Айга менә алсаң.*
*Тотынышып Айда йөрер идек,*
*Төшләреңдә мине күрә алсаң.*

Әмма хыял – бер нәрсә, ә асыл – башка. Шагыйрә күңелендәге аймылыш аркасында мин шәхсән Мөхиярның лирик героен ике хатын-кыз заты итеп тойдым. Берсе – калада көн күрүче эмансипацияле һәм зыялы асыл зат. Үзаллы, мөстәкыйль, ир, гаилә дип тә бик көенеп тормый бу сылу. Хәтта аерылышу да үтә гадәти бер хәл бугай аңа:

*Мин китәмен синнән, үпкәләмә!*
*Учагымны озак сакладым,*
*Кирәкмәсен үзем белгән килеш*
*Сөюемне һаман акладым.*

Әйе, әйе, ялгышмыйм, бу фаҗигале гамәлдән гүзәл затыбыз чирканмый: *«Кит… / Әйтмәм, синсез яши алмыйм, дип, / Кит! / Җаның минем янда кала бит».*

Укучыга тетрәнергә генә кала, җансыз бу ир ничек яшәр?

Икенчесе, лирик геройның үз авызыннан әйтелгәнчә, түбәндәгечә алга баса: *«Авыл кызы – шәһәргә дә / Сыйдым инде, / Күңелемдә авыллыкны / Тыйдым инде. / Бер читлеккә бу җанымны / Куйдым инде…»*

Аның җаны, «Кайтсаң иде» әсәрендә әйтелгәнчә, авылда, туган җирендә үзен оҗмахтагыча сизә: *«Баш очымда таллар тибрәләләр, / Болыннарда җилләр – ярсу ат. / Әйтә кебек авыл: «Кайтсаң иде, / Йөрмәсәңче читтә зар сулап».* Янәсе, «монда барда безнеңчә, яшьләр тиешенчә, теле дә үзебезчә». Шагыйрә «Елмаюың калсын» шигырендә әлеге «үзебезчә»не ачыклый: *«Татар хатыннары сабыр булган, / Сабыр булган гомер-гомергә…»*

Әлеге эпитетка шәрехләү дә кирәкми. Иргә сыенган, аркаланган, хөрмәт иткән хатын-кыз хәләл җефетеннән башка ялгыз гомер итүне иң зур бәхетсезлек итеп санаган.

Шагыйрә аңында, лирик героенда бер-берсенә капма-каршы ике хатын-кыз тибы шәүләләнә, бу симбиоз герой дөньясында бәргәләнү, буталыш хасил итә. Рәзинәгә уйланырга кирәк, ул соңгы җыентыгын «Асылыма кайтам» дип исемләгән, димәк, ачыклау мөһим, әлеге алиһәләрнең кайсысы аның асылына якынрак һәм укучы җанына ныграк үтәрлек?

Асыл турында сүз чыккач, шуны да әйтим: Мөхияр чын асылының мөһим бер балкышын күз уңыннан ычкындырган. Ул бит титуллы фән кешесе, зур вазифа башкара торган педагог-студент халкын тәрбияли. Ник аңа шул кызыклы мохит кешесе булып ачылмаска? Татарның беренче шагыйрәләреннән булган Газизә Сәмитова борынгыда ук «Каләм» шигырендә гыйлем, мәгърифәткә мәдхия укыган иде: *«Кара савытта тора көмеш башлы җиз каләм, / Шул каләмнең хезмәте илә агарды бөтен галәм…»*

Ул яхшы аңлаган, мәчеткә йөреп, намазга утырып, вәгазь-нәсыйхәт укып кына милләтне алга җибәреп булмый. Милли хәяткә гыйлем үзләштергән, төрле-төрле телләр белгән, киң карашлы, зирәк акыллы затлар кирәк. Акча, байлык культы хөкем сөргән бүгенге җәмгыятьтә Г.Сәмитова каләме язганнарны искә төшерү һич тә зыян итмәс, шәт…

Каләм дигәч, Р.Мөхиярның каләм, стиль үзенчәлеге хакында да берничә сүз әйтик. Аның лирикасын күтәрә торган төп чара, һичшиксез, капма-каршы кую, ягъни антитеза алымы. Ул фәлсәфи фикерләүне алга сөргән шагыйрьләр өчен хас һәм мондый омтылыш Рәзинә иҗаты өчен дә ят түгел:

*«Сабырлыклар сары алтын», диләр,*
*Сары алтын никтер күренми.*

*Гомер буйларына сабыр итәм,*
*Кулым алтыннарга күмелми.*
(«Сабырмы соң йөрәк»)

«Моңым белән бәхетлемен» шигырендә дә халыктагы әйтем белән килешмәү бар. Моңлы бала бәхетсез була дигәннәр. Ә шагыйрә үзенекен раслый: «*Ник бәхетсез булсын моңлы бала? / Аның моңы бәхет түгелме?*» Һәм ул үз-үзенә тирән ышанып түбәндәге нәтиҗәне чыгара:

*Моңым белән бәхетлемен Җирдә,*
*Сагыш тулы җанда, моң тулы.*
*Җырларымны тезәм ап-ак җепкә,*
*Сандугачлар табар бу юлы.*

Шагыйрә күз үткерлегенә таянып, *«Кешене белер өчен бер пот тоз ашарга кирәк»,* дигән әйтемне дә шиккә ала:

*Кешеләрне аңлау өчен*
*Күпме тоз ашалып бетә.*
*Кайчагында... читтән генә*
*Күреп калу – шул да җитә.*

Күпләр өчен чәчәкнең иң гүзәл, хозур чагы – сабактан өзелгән мәл. Әмма «Кипкән букет» әсәрендә кулланылган антитеза чарасы сулып корыган гөлләмәне дә җанга якын, тансык итә:

*Чәнечкеле булсын, кипкән булсын,*
*Матурлыгы инде киткән булсын,*
*Җан өшеткеч кышкы бураннарда*
*Җылы җәйне сагындырып торсын.*

Сурәт янәшәсендә торып кына түгел, хәрәкәтне тасвирлаганда да уңышлы антитеза корып була икән:

*Алларыңнан үтеп киттем,*
*Танымадың син мине.*
*Танып үзең килсәң әгәр,*
*Танымамын мин сине.*

Килешегез, уйландыра, хисләндерә торган тасвирлар ясауга маһир бит Рәзинә! Каурый каләмен тиз арада танытып, үз сүзен кыю әйтеп, бүгенге татар поэзиясенең килешле бер бизәге булып тора безнең Башкортстан кызы. Үтә нечкә хисле, мәхәббәтле, гамьле җан, ә учларында куз-утлы күмер аның. Борынгы гадәт-йола буенча ут күршесенә учак дөрләтергә китергән:

*Уч төбемдә утлы күмер йөртәм,*
*Дөрләп тора, сүнми, сүрелми...*

**Сәгыйдулла ХАФИЗОВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Җамал Вәлиди исемендәге премия лауреаты,*
*Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы*

# ГОМЕРЛӘР КИЧКӘНДӘ



Гамил Афзал дигәндә, һәркем сүзсез генә елмаеп куядыр, һәркем диюем шуңа: ул — чыннан да халыкка иң якын торган, халыкның яшәү-тормыш итү рәвешләрен белгән, үзе дә гади халык белән иңгә-иң куеп, тау-ташлар актарып Магнитка шәһәрен корган, урман кискән, йөзләрчә вагонга йөк төягән-бушаткан, тынчу баракларда яшьлек гомерен кичергән кеше. Ачлыкны, кимсетелүне, гариплекне кичергән. Әмма табигате белән шат, көчле рухлы Гамил ага күз яшьләрен яшерә белгән, аһ-зарын да һәркайда сөйләп йөрмәгән. Гамил Афзал иҗатындагы юмор-сатира да, хәтта үпкәле шигырьләре дә барыбер өмет-ышанычка, оптимизмга корылган, аларда һәрчак рухи көч өстенлек итә. Аның әсәрләрен укыган һәркем үзенә таныш хис-халәт кичерә, теләгенә, борчуларына җавап таба. Ярты гасырдан артык гомер иҗат итеп, ул, милли әдәбиятыбызга бихисап зур мирас калдырып, арабыздан китеп барды. Бу мирас йөзләрчә еллар халкыбызның рухын тотып торуга хезмәт итәр әле...

Мин Гамил Афзалның социаль-әхлакый лирикасын, фәлсәфи лирикасын бик яратам... Ул — кыска шигырьләр остасы. Аның дүртьюллыклары, сигезьюллыкларының һәр юлы халыкчан әйтемнәр, мәкальләр булып яңгырый. Татар шигъриятендә кыска шигырьләр язу аеруча киң таралган.

Заман шагыйрьләре үз язганнарын аныкы белән чагыштырып та, аннан үрнәк алып та иҗат итә ала...

*Табигатьнең чәчәге дә — кеше, ерткычы да,*
*Табигатьнең патшасы да — кеше, корткычы да.*
*Урманында бүресе дә — кеше, сандугач та,*
*Үзе бай да, үзе ач та.*

Әмма Гамил Афзал иҗатының алтын баганасы — аның юморы һәм сатирасы.

Тоталитар режимлы җәмгыятьтә шул дәрәҗәдәге сатираны ничек рөхсәт иттеләр икән дә, һәм шул җәмгыятьне, аның түрәләреннән ачы көләргә Гамил ага үзе ничек җөрьәт итте икән? Күренекле галимнәрнең Гамил Афзал сатирасын Габдулла Тукай сатирасының дәвамы дип бәяләүләре һич кенә дә шагыйранә күпертү түгелдер.

*Төшенке чор, нәфис сәнгать артта,*
*Даһилар тумаган чагында,*
*Алыпсатар политика сата,*
*Хан буласы килә аның да.*

Әйе, Тукай, Такташ, Туфаннан соң ул бөтен халык тарафыннан шулай үз ителгән чын халык шагыйре булып тора да... Гамил Афзалның сатирасы үзе зур мәктәп.

*Агыйделнең аръягыннан*
*Замана баласы килә:*
*Укымый да, эшләми дә*
*Алга барасы килә...*

Мин аның янында берничә мәртәбә булып, аның белән сәгатьләр буе сөйләшеп утыруымны үзем өчен зур әһәмияткә ия вакыйга дип саныйм...

Ул үзе яшәгән егерменче гасырның тарихын нык өйрәнгән. Аның хәтеренә гасырның бөтен вакыйгалары тирән уелган, ул Николай патшадан башлап Горбачев-Ельциннарга кадәрге чор патшаларын, хөкүмәт кешеләрен, хәрбиләрнең биографияләрен һәм кылган гамәлләрен бик яхшы белә, алар турында сәгатьләр буе сөйли, аларның һәркайсына, тарихи күзлектән карап, үз бәясен бирә иде. Гомере буе Казаннан читтә яшәвенә карамастан, ул Казанда һәм Татарстанның шәһәр-районнарында булган барлык вакыйгалардан хәбәрдар булуы белән таң калдыра иде. Республикабыздагы әдәбият-сәнгать мохитен белеп торуын әйткән дә юк. Өенә алдырган бер кочак газета-журналны, күрәсең, җөмләсен дә калдырмый укып баргандыр, һәм аларда басылган бер генә әдәби әсәр дә аның игътибарыннан читтә калмый иде бугай.

Үзләрен күреп белмәсә дә, яшь иҗатчыларны да үзенчә барлап тора иде Гамил ага. Үземнең язганнарымны укып баруын ишеткәч, гаҗәпкә калдым. «Син, Мирза, шәп язасың, ә нигә гел үзең турында язасың? Гел «мин» диеп кенә язып булмый, башкалар турында да яз, әйтик, песиләр, этләр, чыпчыклар турында яз», — ди бу. — Бөҗәкләр турында язып та фикер, фәлсәфә әйтеп була бит!.. — Менә ничек үтемле итеп әйтә, киңәш бирә!

Мин аңа:

— Гамил ага, мин кош-кортлар, җәнлекләргә бик кагылмыйм, табигать күренешләре — күк-болытлар, чишмә-суларга күбрәк сыенам, — дигән булам. Ул исә:

— Анысын беләм, анысы әйбәт, боларына да игътибар ит, — ди. Яныбызда үз җаен табып, чәй әзерләп йөргән Нәфисә апа да аның сүзләрен хуплап куя: «Шулай кирәк», — ди. Баксаң, анысы да бөтен әдәби мохитне белеп-укып бара икән. Ә Гамил аганың бөтен иҗатын яттан beләдер кебек. Чөнки ул бит аларны тулысынча ташка бастыручы...

...Соңгы тапкыр 2003 елның февраль аенда булганмын икән янында. 4 февральдә. «Киек каз юлында» исемле шигырьләр җыентыгымны бүләк итеп, хәлләрен белеп чыкканмын...

Ишекне ачып керүгә үк тавышымнан таныды:

— Мирзамы ул? — диде.

— Мирза, — диде Нәфисә апа.

Түр бүлмәдән чыгып, Гамил ага үзенең ак, какча кулын биреп күреште... Залга үттек. Унбиш минутка гына керүем, ашыгам, дип, Нәфисә апага чәй дә куйдырмадым, ә үзем, сөйләшә торгач, ике сәгатькә якын утырганмын...

Мин утырдым, ул басып торды һәм сөйләде. Түгелде Гамил ага... Басып торуының сәбәбе — сул аягының тездән бөгелмәве. Ул утырганда нәрсәгәдер тотынып, башта урындыкның читенәрәк утыра да, сул аягы сузылып кала... Җаен табып, шуңа күбрәк басып та тора бугай:

— Егәр бетеп бара. Инфаркт дигән явыз килеп китте бит, әй. Шул явыз булмаса, дәрт җитәрлек әле юкса, — дип шаяртып алды ул. Һәм мине тагын бер кат гаҗәпләндерде бу: — Син, Мирза, өйләнгәнме әле, әллә һаман да буйдак йөрисеңме? — ди...

— Сез нәрсә инде, Гамил ага, минем өч балам, оныгым бар, — дим. — Без дә сезне куып барабыз, миңа 50 яшь тулды.

— Анысын да беләм, укыдым. Өйләнгән булгач, нишләп соң мәхәббәт турында бик аз язасың, сөю-мәхәббәт турындагы шигырьләрең бик күренми, мин сине әллә бу өйләнми торган кеше микән дип йөри идем, — ди картлач...

Нәфисә апа да:

— Сөю турында язарга кирәк, күбрәк язарга тырыш, — дип җөпләп тора.

— Менә бу китабымда мәхәббәт шигырьләре дә бар. Минем андый шигырьләрем дүртьюллыкларда, — дим.

— Дүртьюллыкларны Актаныш егете... Кем әле ул, исемен онытып торам, бик шәп яза, — ди Гамил ага.

— Фәнәвис Дәүләтбаевны әйтәсезме? — дим.

— Үзе, — ди... — Тик никтер соңгы вакытларда күренми... Әйт аңа, язуын туктатмасын, аның фикерләре төпле! — ди Гамил ага... — Үзең дә кыскаларны шәп җибәрәсең, бая әйткәннәрне дә исеңнән чыгарма, — дип үсендереп куйган иде Гамил ага ул чакта.

Үзләренең дә кызу эш өсте. Фоат Галимуллин телефоннан шалтыраткан. Татарстан Язучылар берлеге Халык шагыйрьләренең әсәрләрен туплап, аерым җыентыклар бастырып чыгарачак икән. Гамил Афзал аңа: «Минем шигырьләр 3 том булыр», — дигән. Нәфисә апа белән барлап чыкканнар да, шигырьләр үзләре генә дә 4-5 томнан артып китә икән. Фоат Галимуллинга кабат шалтыратып әйтәсе булыр инде, диләр...

— Бүрәнәнең юан башы Нәфисә апаңа төшәр инде, машинкада күпме бастырасы булачак, — диде Гамил ага.

— Куанычлы мәшәкать бит, — дидем мин үз чиратымда һәм, алар белән саубуллашып, Казанга юл алдым.

Такталачык — аның гомер бишеге. Ни хәл итмәк кирәк?! Үз туган ягында яшәргә туры килмәде шул аңа...

***

Ике су тегермәне төзеп, авылдашларын гына түгел, Әҗмәт, Гәрәй, Түмерҗә авыллары кешеләрен дә кинәндереп торган Гыймазетдинны, кулак ярлыгы тагып, гаиләсе белән авылдан сөрәләр. 9 яшьлек Гамил тормышның олы чынбарлыгы белән тәүге мәртәбә менә шунда очраша...

...1929 елда туган авылы Такталачыкка Казаннан агитпароход белән татар театры артистлары килеп төшә. Янгынчылар алачыгы янындагы мәйданда сәхнә корыштырып, спектакль уйный артистлар... Араларында баһадир гәүдәле авылдашы, тагын ун елдан үзе дә «халык дошманы» аталып, хөкем ителеп, Соловкида этләрдән талатылып үтереләчәк Исхак абзыйның малае Мохтар Мутин да бар. Спектакльдән соң концерт куялар. Концертта Мохтар Мутин:

— Иске тормыш үлә, Яңа тормыш килә, Яңа тормыш килә, — дип ялкынланып шигырь сөйли...

Тагын бер елдан авыл халкына сәяси аң өстәүчеләр белән Һади Такташ та килер. Ул да иске тормышны хурлап, яңа төзелгән «Таң» күмәк хуҗалыгына өметләр баглап, яңа тормышның таңы атачагына дан җырлар. Әмма бу вакытта «Иске тормыш элементы — Гыймазетдин кулак» таланып, авылыннан сөрелер... Әтисе, гаиләләре белән бергә булачак Халык шагыйре, 9 яшьлек Гамил дә мылтыклы кешеләр сагы астында Минзәләгә, аннан пароход белән Сарапулга, аннан этап белән Уралга озатылыр...

Шагыйрьнең тормыш юлына кагылышлы вакыйгаларны язганда, мәгълүм авторлар: «30нчы еллар башында авылда колхозлар төзелә башлагач, Гыймазетдин гаиләсе белән Магнитогорск төбәгенә күчеп китәргә мәҗбүр була», — дип язалар. «Мәҗбүр иттеләр», дип язарга инде өч дистә елга якын «рөхсәт ителүгә» карамастан...

Авылдашы, 1914 елда дөньяга килеп, гомере буе шунда яшәгән Гавас ага Мутин... Әйе-әйе, мәшһүр трагик Мохтар Мутинның туганнан туган энесенең малае, Гыймазетдинга кулак ярлыгы тагылуны да, бар мал-мөлкәте алынып авылдан сөрелүен, аларның Минзәләгә кадәр сак астында атлар белән алып кителүен үз күзе белән күргән кеше... «Мәҗбүр була» түгел, ә нигезеннән кубарып ташлана, талана... Ә 9 яшьлек сабый, аркасында штык очын тоеп, Минзәләгә кадәр ат арбасы артыннан йөз чакрым җәяү атлый... Бу әле газапларның башы гына... Күз күрмәгән чит җирләргә килеп, җәен дә тулысынча эреп бетмәгән җирне кәйлә-көрәк белән актарып, урман кисеп, йөзләрчә вагоннарны төяп-бушатып, илгә сугыш афәте килгәч, дүрт ел буена көне-төне тоташтан аягөсте, салкында снарядлар, бомбалар ясап, ачлы-туклы яшисе, салкын тидереп аяктан егылып, озак еллар түшәктә ятасы бар әле аның...

*Кырыс як, туң җиргә ятмый кар,*
*Җир соры, күк соры, көн ятим.*
*Җилкенә сап-сары яфраклар,*
*Яфрактай йөрәкне нишләтим?*

Әмма кешене тән саулыгы гына түгел, рухи саулыгы да кеше итеп яшәтә... Шәфкатьле кулларның, шәфкатьле җаннарның да җылысын алып савыга, аякка баса ул!.. Хак Тәгалә салган иҗат орлыклары дәррәү шытып чыгып, тамыр җәеп күкрәп үсеп китәләр. Сабаклары нык, төз, биек, башаклары тук аның иҗатының... Бу иҗатның олылыгын беренчеләрдән булып олуг шагыйрь Сибгат Хәким күреп ала, «Татар шигъриятендә Тукай аныклаган юлдан баручы», — дип бәяли ул Гамил Афзалның үзен.

Гамил Афзал иҗаты. Афзал шигърияте үзе бер хәзинә! Аның иҗатының үсеш чорларына кагылышлы язмаларда еш кына: «Таланты Әлмәттә ачылды, Әлмәт — аны, ул Әлмәтне үстерде», — дип язалар. Хак сүзләр, һичкем инкарь итмәслек сүзләр. Әмма Гамил Афзалны Хак Тәгалә үстерде. Ил-көндә шундый буталчык, болганчык бер дәвердә Хак Тәгалә аның җанының нурларын, моңнарын бөтен халыкныкы итәргә әмер кылган да... Шуңа да олуг бу иҗат! Аның гыйбрәтле, ачы язмышы белән үрелеп бар булган үлемсез иҗат!

***

Язмышлар... Кем генә рәхәт яшәгән соң ул чорда, диярләр... Без тарихта билгеле бөекләрнең нәсел-шәҗәрәсенә карарга өйрәнгән. Пушкиннар, Толстойлар — князь дә граф, граф та князь. Безнең татар бөекләре исә иң «күбе» мулла затыннан, вак сәүдәгәрләр затыннан. Дөньяга бәхетсез булып килеп, бәхетсез китәргә дучар кавем... Шулар арасында да дөнья бәһасе шәхесләр туа тора, дөньяга танылган эшләр кылып китә. Татарларда, хәер, татарларда гына түгел, урыс булмаган башка милләтләрдә дә шулай. Чуашлар бөек дип йөргән Миша Сеспельнең туып-үскән өен күргәнем булды. Иң хәерче татар кешесенең мунчасы кебек өйдә ач-ялангач яшәп, кыска гына гомерендә күпме гамәлләр кылган ул... Иң күп кыен ашаганы, әлбәттә, безнең Тукаебыз. Бөекләрнең бөеклеге гомерендә күпме газап чигүе белән бәяләнәме әллә?..

*Бу илдән сөрелгән кеше без*
*Болгавыр каһәрле заманда,*
*Кайтам мин иң изге төшебез —*
*Зиратка бер ятып еларга.*

Гамил Афзалның туган җирен сагынып яшәве сигезеннән-сиксәненә кадәр бер генә сәгатькә дә сүрелмәгәндер. Ни кызганыч, ул шул чыгып китүеннән (кубарылып куылуыннан) соң туган авылы Такталачыкка кайтып яши алмый. Ни кызганыч, ата-анасы, туган-тумача гомер иткән нигез тәмам юкка чыга. Алар яшәгән йорт сүтеп алына, авылны икегә бүлеп торган ерганак-чокырны аларның өе турысыннан буып... яңа юл төзиләр. Яңа юл аларның йорты, ишегалды аша үтә... Монысын кичерер дә иде Гамил ага... Бәлки кичергәндер дә. Әмма, илленче елларда Такталачыкка төпләнеп гомер итү теләге белән кайткач, аңа авылның ахмак түрәләре күз агы белән карыйлар: «Нигә кайттың, кулак калдыгы?» — диләр. Ай, ни оят... бу юлларны язу һәм үз якташларыңның шундый булуы.

Без хәреф таный башлаганда, шөкер, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин исемнәре акланган, аларның әсәрләре дәреслекләргә кертелгән иде... Дәреслекләрдә булмаса да, Гамил Афзалның китапларда, әдәби журналларда басылган сатирик шигырьләрен дә авыл китапханәсеннән алып уку мөмкинлеге бар иде... Әмма аның, сабыйның коточкыч репрессия корбаны булуын Такталачыкка йөреп укый башлагач, кышкы көннәрдә Гамбәрия апага фатирга урнашып, кунып кала башлагач белеп алдым. Гамбәрия апа Гамил аганың туганыннан туган апасы икән... Алар әниле-кызлы көнозын колхозда эшлиләр, озын төннәр буе йон язып, җеп эрлиләр... Дүрт почмаклы йорт уртасында киндер сугу станогы да эшсез тормый. Чүпрәк-чапракларны бөтереп-бөтереп станокка кертеп җибәрәләр дә, алардан менә дигән бизәкле идән паласлары килеп чыга торган иде. Өйнең алгы ягы өчен дип тә, өйалды, баскыч өчен дип тә тукыйлар иде җәймәне. Без, Балтач авылыннан Ясир Вәлиев белән (ул әле Гамбәрия апаларга, димәк, Гамил Афзалга да туган булып чыга) аларның кул эшләрен күзәтә-күзәтә дәресләр әзерли идек. Кызыксынып, «туку станогына» да утыра идек. Гамбәрия апабыз, бүгенге терминнар белән әйтсәк, «антисоветский» сүзләр дә ычкындырып җибәрә иде... Гамил Афзалның, үзенең әтиләренең талануы, авылдашларының миһербансызлыгы,

ашка таш атуларын гаепләп телгә ала иде. Мондый гаепләү, зарланулары минем өчен яңалык түгел. Чөнки үзебезнең өйдә дә Ерак Әбкәм белән Әнкәм (бездә Әнкәй ягыннан әби-бабайны Ерак Әбекәй, Ерак бабакай дип йөртәләр) андый «антисоветчинага» юл куялар иде. Ни өчен дигәндә, минем мөәзин Нурлыгаян бабамны да 1930 елны раскулачивать итеп төрмәгә ябалар, өч ай дигәндә Казан төрмәсендә атып үтерәләр дә, Архангель зиратына илтеп күмәләр... Әнкәм белән Гамбәрия апаның: «Коммунистларның күрәсе бар әле», — дигән сүзләре колагыма керсә дә, күңелемә үк үтмәгәндер инде... Пионер, комсомол «тәрбиясе» алып, хәтта үзем яшәгән районда комсомолларның баш вожагы булып биш ел эшләргә, коммунистлар партиясе сафында унике ел торырга, партия карарларын намус белән үтәргә туры килде миңа... Советлар хакимияте таратылгач, партия билетларын тапшырулар булды, мин тапшырмадым. Бу үзе бер тема. Болай үземә бәйләп истәлекләр яңартуым юкка түгел, Гамил ага белән сөйләшеп утырганда, ул Гамбәрия апа кебек бер дә «антисоветчы» булып сөйләшмәде. «Политик хаталар» җибәрмәде... Иллә мәгәр, Сталинның шәхес культы бөтен халыкка каза булуын ул шул вакытта ук аңлаган, чөнки «геноцид» дигән вәхшилекне үз күзе белән күргән, үз тәнендә тойган, үз йөрәге аша үткәргән шул ул...

*Монда бар да тигез:*
*син абзый, мин абзый...*
*иңне куеп иңгә,*
*Комсомоллар белән бергә*
*Кичәге кулаклар җир казый,*

— дип язуында олы киная ята... Сәяси киная...

90нчы елларда кинаяләп язуның кирәге калмады. Утызынчы-илленче еллардагы сәяси корбаннар, сыйнфый дошманнарны юк итүнең бөтен дөреслеген күрсәткән том-том романнар басылды. Репрессия корбаннары үзләре үк әсәрләрен язып, йөз елдан булса да табып алып бастырырлар әле дип җиргә яшереп күмеп куйсалар да, йөз ел көтәсе калмады. Хаклык өскә чыкты. Гамбәрия апа, Мөсәвәрә Әңкәмнәр әйткән көн килде... «Коммунистлар күрәсен күрде». Әмма аларны Себергә җибәрүче дә, төрмәгә утыртучы да булмады... Булмасын да... Изге китапларда: «Үч алу тыелмый, әмма үченнән чигенүчеләр Аллаһы тарафыннан мактала», — диелә бит әнә...

— Берсе дә рәхәт күрмәде, — дип искә ала иде Гавас ага Мутин да. — Утызынчы елларның актив комсомоллары, күмәк хуҗалык төзибез, тигез тормыш төзибез, дип йөрсәләр дә, хакыйкатьтә дистәләрчә гаиләләрнең тыныч тормышын туздырдылар, бөтен халыкны имансыз, котсыз иттеләр. Үзләре пычагым да кыра алмадылар. «Таң» колхозы белән гел читтән килеп идарә иттеләр. Дөрес, «Таң»ның мантып киткән чаклары да булды, әмма гел бурыч исәбенә. «Таң» тәмам таякка таянды да. Бу көнгә төшәргә тиеш идемени ул? Никадәр җире, болыны була торып...

Актаныш ягы гомер-гомергә тырыш игенчеләре белән танылган. Моннан йөз еллар элек, Октябрь түнтәрелешенә кадәр үк, Пермь якларыннан килеп, көздән язга кадәр, потына 6-7 тиен түләп, халыктан ашлык җыеп йөргәннәр. Татар Ямалы авылында җыйган ашлыкны, язын Агыйдел-Кама сулары җәелгәч, баржалар белән төяп алып китә торган булганнар. Бу эшләргә «күзәтчелек» итүне Гавас аганың әтисенең бертуганы, мәшһүр трагик Мохтар Мутинның атасы Исхак Мутин үтәгән... Исхакның үзенең дә Агыйделнең аръягында чәчүлекләре, болын җирләре булган... Ул — беренчеләрдән булып, Такталачыкта кызыл кирпеч сугу һәм яндыруны да оештырып җибәргән кеше.

Гавас агай, урыны оҗмахта булсын, бик борчыла иде авылның хәзерге хәленә... Колхозда беренче тракторны, беренче комбайнны да ул йөрткән. Сугышның беренче көненнән фронтка китеп, мотодесантчы булып, гел алгы сызыкта, дошман тылында диверсияләр оештырып йөргән. 1945 елның 24 июнендә Мәскәүдә Җиңү парадында да мотодесантчы булып катнашкан ул.

Сугыштан җиңүче булып, күкрәк тулы орден-медальләр белән кайтса да, аның күңелендә гомере буе олы борчу яшәгән... Мохтар Мутин турында белгәннәрен сорашып, аның янында сәгатьләр буе утырганнарым булды. Бер очрашуда ул гомере буе күңелен тырнап торган шул вакыйганы сөйләп, түгелеп алды...

1944 елның мартында аларның мотодесант батальоны, Сивашны кичеп, Кырымны штурмларга әзерләнә. 8 марттан алып 13 мартка кадәр коточкыч буран котыра. «Кырымда зәһәр җилле, карлы-яңгырлы кап-кара көннәр торды, — диде ул. — Инде һөҗүм белән керәбез дигәндә, немецлар Кырымны калдырып киткән булып чыкты.

13 март таңында Джанкой шәһәрендә (ул безнеңчә Җанкай буладыр инде) тревога белән уяттылар. Тиз генә шәһәрнең вокзалына барып, тимер юлны өч километр озынлыкта тар тыкрык (коридор) калдырып оцепление ясадык. Беркем берни аңламый... Шулай ике сәгатьләп басып торгач, бала-чага, карт-коры, хатын-кызларның елау-ялварулары, кубарылып этләр өргәне ишетелде... һәм бераздан тар тыкрык буйлап солдатларның штыклары астында котлары качкан шул халыкның вокзалга таба куып китерелүе күренде... Бер атна буена Кырым татарларын көчләп эшелоннарга төяп, туган җирләреннән сөрделәр. Бер атна буе вокзалда оцеплениедә тордым... Шул сабыйларның, хатын-кызларның куркыныч күз карашлары бер генә дә хәтердән чыкмый», — дип көрсенепләр сөйләгән иде Гавас ага... Инде әйткәнемчә, тугыз яшьлек Гамилнең туган авылыннан мылтык астында сөрелүен нәкъ шул күренеш белән тиңли иде Гавас ага...

Гавас ага үзе дә күптән гүр иясе. Ул «Таң» колхозының беренче комбайнчысы булган. Бу колхоз крестьяннарның күмәк хуҗалыгы дип атала хәзер. Әйткәнемчә, совет чорында таякка калса да, үзгәртеп корулар, базарга керүләр дәверендә акрынлап атлап китте ул. Ныгыды... Авылның булдыклы, эш сөючән егетләре күмәк хуҗалыкта да, аерым үзал булып та җирдә иген игәләр, тораклар төзиләр, гаилә коралар, ишәяләр...

Әйе, Гамил ага үзенең Ил халкын дошман күргән һәм мең газапларга салган милләтләр атасының миллионлаган корбанының берсе булуын аңлый һәм авылының ахмак, комсыз түрәләренең төп палачның йомышчысы икәнлеген дә төшенгәндер... Шуңа да әсәрләрендә авылдашларына үч галәмәте юк. Авылын — гомер бишеген мәңге сагынып яши ул.

*Мылтык белән куган идең мине,*
*Мөлкәтемне талап, туган ягым.*
*Сөргеннәрдә каргамадым сине,*
*Ватан диеп, сагынып кайттым тагын.*

Соңгы елларда «Рухият» фонды бастырып чыгарган «Гомер кичүләре» җыентыгы аның үзенең гомер кичүләре, халкының гомер кичерүләре булып яңгырый... Менә таулар, урманнар аша поезд чаба. Тәгәрмәчләр шакырдавы ил буйлап туган йортыннан аерылганнарны санап бара кебек...

Әнә тар тәрәзәдән күренгән ярым ай... Адашып кергән нурында сабыйның күз яшьләре күренеп ала...

«Гомер кичүләре» — бик тә мәгънәле, бик тә уйчан, бик тә кинаяле һәм хисләргә бай җыентык. Гамил ага бу җыентыкны үзе дә бик яратты! Әлеге китап турында олуг галимнәребезнең, әдипләребезнең бәяләмәләрен дә ишетәсе килгәндер... Бер килүемдә ул: «Мирза, бу китапны сиңа бүләк иткән идем инде. Менә тагын ике китапка кулларымны куеп, теләкләр яздым: берсен Актаныштагы минем шигырьләрне сәхнәдән сөйләүче Мәгыйскә бирерсең, берсен тагын үзеңнең иң якын кешеңә бирерсең», — диде.

***

Гамил аганың 80 яше тулу көнен Әлмәттә дә, Актанышта да бик зурлап билгеләп үттеләр. Әлмәттәге кичәдә Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, мәдәният министры Илдус Тарханов, Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Казаннан, Чаллыдан, Әлмәтнең үзеннән бик күп язучылар һәм сәнгать әһелләре, җитәкчеләр, җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Актаныштан район хакимияте башлыгы, Такталачык авылыннан якташлары килгәннәр иде... Кичәдә Гамил Афзал бик канәгать булып утырды. Республика җитәкчеләренә, Әлмәтлеләргә, Актанышлыларга рәхмәт сүзләре әйтте.

Ә Актанышта үтәчәк кичәсенә ун көн кала хакимият башлыгы Энгель Фәттахов үзенең урынбасарлары белән аның өенә килде. Нәфисә апаның пилмәннәре белән сыйланып, бик озак кунак булып, күптәннән белгән якын танышлар кебек сөйләшеп

утырдык... Күптән түгел генә каты авырып алуга карамастан, Гамил аганың кәефе күтәренке иде. Үз шигырьләрен укып күрсәтте, һәркайсыбызга китапларын язып бирде, бергәләп фотога төштек. Гамил ага Актанышта узачак кичәгә, бик теләсә дә, кайта алмавын әйтте.

Хакимият башлыгының: «Үзем килеп алам, үзем китереп куям», — дигәненә дә, шаярта төшеп: «Инфарктган соң ерак юлга чыгу уен эш түгел, кешегә мәшәкать ясавым бар», — дип җавап кайтарды.

Әйткәнемчә, Әлмәттәге кичәнең икенче көнендә Актанышта юбилей тантанасы үтте. Гамил ага үзе бара алмаса да, ике кызы һәм Кырымнан кунакка кайткан туганы килделәр.

Бәйрәмгә ныклап әзерләнгәннәр иде Актанышлылар. Такталачык авылына кадәр асфальт юл салынды, урамга да асфальт юл түшәлде. Һәркайда чистарту, буяу-агарту эшләре башкарылды, күпләп агач утыртылды, чәчкә түтәлләре ясалды. Авыл Мәдәният йорты өр-яңадан сипләнде.

Юбилей тантанасы аның туган авылында башланды да. Казаннан, Чаллыдан ике дистәгә якын язучы килеп җитте. Үзәк урамда Мәдәният йорты каршында олы җыен җыелды. Соңыннан шушында ук ул урамга Гамил Афзал исеме бирелгәнлеге игълан ителде. Урта мәктәптә халык шагыйренең музей бүлмәсе барлыкка килде. Гамил аганың кызлары Рушания белән Роза Такталачыкта үзләренең моңарчы бер дә күрмәгән туган-тумачалары белән очраштылар, әтиләренең авылдашларының, гомумән, Актаныш халкының, Гамил Афзалга булган бихисап зур ихтирамын һәм горурлануларын күреп сөенделәр.

Кичен район Мәдәният йортында районның барлык авылларыннан әдәбият сөючеләр, укытучылар, җитәкчеләр җыелды. Кичәдә Гамил Афзалның «Гомер кичүләре» китабы буенча эшләнгән театральләштерелгән тамаша күрсәтелде. Зал тын да алмыйча Гамил Афзал шигырьләрен тыңлады, гыйбрәтләнде, тәэсирләнде һәм истә калганы тагы шул булды: хакимият башлыгы Энгель Нәвап улы Фәттахов Гамил Афзалга багышлап әйткән сүзләрендә: «Бу юбилей кичәбез, бөек якташыбызны зурлау белән беррәттән, аның алдында такталачыклылар һәм районадашлар исеменнән баш иеп гафу сорау да булып кабул ителсен иде!» — диде. Рәсми дәүләт кешесе тарафыннан беренче тапкыр гафу сорау, шөкер, Гамил агага барып ирешге.

Гамил ага кабул иткәндер, авылдашларын, якташларын кичергәндер дип ышанасы килә...

Гамил ага турында истәлекләрне яңартканда, аның гомер юлдашы Нәфисә апа турында әйтми үтү гаделсезлек кенә түгел, гөнаһ та булыр иде.

Әйткәнемчә, Гамил аганың вафатыннан соң да аның гаиләсе белән багланышларыбыз өзелмәде. Инде Язучылар берлеге рәисе булып сайлангач, Әлмәттәге эш сәфәрләремдә аларга керергә, хәл-әхвәлләрен белешергә тырыштым...

Бер керүемдә Нәфисә апа сырхаулап тора иде. Аяклары авыртуын әйтте дә: «И, зарлануым гына инде. 70кә җитеп килгәндә авыртмаган җир булмас», — дип куйды. Мин авызымны ачып калдым. Нәфисә апа төс-биткә бик карт күренмәсә дә, аңа инде күптән җитмешләр тулгандыр дип уйлый идем. Баксаң, ул Гамил агадан унсигез яшькә яшьрәк икән... Менә сиңа кирәк булса. 37 яшьлек карт егет 19 яшьлек яшь-яшь кызга өйләнгән булып чыга түгелме соң? Гаҗәпләнүемне аңлап, Нәфисә апа ничек итеп Гамил ага белән танышуларын, өйләнешүләрен, Әлмәткә килүләрен, абзыйның әдәбияттагы беренче иҗат үрнәкләре хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ул сөйләгәннәр үзләре бер сага булырлык, күп серияле фильмнар төшерерлек...

...Гамил ага Магнитогорскида коточкыч авыр шартларда хезмәт куеп, үтмәс сырхауга сабыша. Аны инде савыкмас, диләр.

Кая барып сыену тапсын? Башкортстанның Калтасы районы Шәрип авылына тормышка чыгып гомер сөрүче бертуган Сәлимә апасы янына илтәләр аны. Илтәләр, чөнки Гамилнең аяклары йөрми башлаган була... Апасы аны үзенә сыендыра. Халык медицинасында булган бөтен им-томны кулланып дәвалый. Көн-төн Аллаһыдан сорап догалар укый. Гамилнең хәле бик әкрен үзгәрә, күп айлар дәвамында ятакта үлем белән тартыша ул. Апасы, колхоз эшенә чыгып киткәндә, күршеләрендәге үсмер кыз Нәфисәгә, өйгә кереп караштырып чык, ул-бу булса (ягъни үлә калса), килеп әйтерсең,

ди. Нәфисә күрше абыйсының хәлен көн дә шулай белеп тора башлый. Аннан соң аны күрше апасы белән бергә тәрбияләп савыктыра, аякка бастыра. Мәрхәмәтле җанда мәхәббәт уяна. Алар кавышалар. Менә бу үзе бер каһарманлык. Фәнис абыйның Нурсөясе, Хисам абыйның Розасы күз алдына килеп баса. Әллә булачак Халык шагыйрьләренең шундый авыр сынауларга дучар ителүен һәм алар янында изгеләрдән-изге җаннарның булачагын Аллаһы үзе ирештергәнме?

Нурсөя, Нәфисә, Роза апаларның изгелегенә һәйкәл булып җырлар, поэмалар, повесть-романнар язылыр әле, шәт.

Бу урында һич тә тыйнаксызлык булмас, әлеге изге җаннар исемлегенә мин үземнең газиз Әнкәмне, репрессияләнгән Нурлыгаян мөәзин кызы, ике аяксыз сугыш гарибе Әткәйне утыз сигез ел буе тәрбия кылган унбер бала анасын — Мөсәвәрә Әнкәемне дә кертәмен.

Нәфисә апа белән Гамил агага хас уртак сыйфатлар да күптер, мөгаен. Нәфисә апа да «телгә беткән», сөйләме юморга бик бай... «Гамил аганың беркайда да басылмаган язмалары калдымы?» — дип соравыма: «Калды, бик күп алар... Мин бит ул үзе «менә боларны басарга ярый» дигәннәрен генә машинкада бастырдым. Әле өченче көн генә амбар кенәгәсен (ул шундый зур дәфтәргә язган) актарып утырганда, күп кенә басылмаган шигырьләрен таптым. Менә берсен сиңа да укыйм әле... Ни язган, юләр», — дип сөйләнә-сөйләнә, кенәгәне ачып укып күрсәтте:

*Урысларның хатыннары*
*Кәбестәне эш итә...*
*Татарларның хатыннары*
*Утыра да печ итә...*

«Нәрсә инде бу?» — дип көлә-көлә яшьләнеп алган иде Нәфисә апа.

— Туксанынчы еллар башында кибетләр шыр-шәрә калды, — дип, хәтерен яңарта Нәфисә апа. Гамил абыйга чыгып йөрмә дисәм дә, барыбер хәрәкәт кирәк дип кибетләргә барып тора иде. Ветеран булса да, инвалид булса да, чиратсыз берни алмый иде... Кешеләрнең сөйләшүләрен тыңлагандыр, күзәткәндер инде... Бер көнне ит кибетеннән ике сыер койрыгы, чәкән башлары төяп кайтты бу... Без инде ачлык күрмәгән кеше түгел... Шуннан утырды да менә бу юлларны язды:

*— Урра, чәкән-койрык килгән,*
*Бу мөлкәтне кая куярлык?!*
*Этлекме бу диеп, кытлыкмы дип*
*Исең-акылыңны җуярлык...*

— Соңгы юлларын укымыйм, бирмим дә, — ди Нәфисә апа. Шуннан шул: язды да конвертка тыгып, «Чаян» журналына адреслап, миңа почта тартмасына илтеп салырга кушты... Мин урамга чыктым, почта тартмасына салмадым... И көтәбез «Чаян» журналын, и көтәбез. Килми генә... Ул шулай онытылып калды, ә кулъязмасы бар. Ул моңарчы андый «чүп-чарларны» бастыру ягында түгел иде бит. Мин шуңа да почтага салмадым.

— Гамил абыеңны бик сагынам. Шигырьләрен укыйм да төне буе аның белән сөйләшеп чыгам. Аның шигырьләрен баса-баса әдәбиятны аңладым. Үзен аңладым, изге җан иде.

Нәфисә апага түземлекне, сабырлыкны мулдан биргән шул Хак Тәгалә. Якты көндә гарип ирен, өч баласын тәрбия кылсын да, төн утырып машинкада кулъязмаларын бастырсын әле. Үзләренекен генә бастырасы түгел, Әсрар Галиев тә, Җәмит Рәхимов та, хәтта яшьләр дә китереп тора кулъязмаларын...

Бу юлларны язганда ирексездән башка шундый уй килеп керде: каләм әһелләре — әдипме, шагыйрьме, журналистмы — киләчәктә ни нәрсә турында язсалар да, үзләренең әсәрләрендә Нәфисә, Нурсөя, Роза, Мөсәвәрә исемле хатын-кызларның образларын фәкать изге итеп кенә сурәтләсеннәр иде...

Тагын бер кабат тыйнаксызлыгым өчен кичерүегезне сорап, үземнең «Кысыр Гариф» исемле поэмамда «салкын сугыш» гарибе Гарифка тугрылыгын саклап көтеп

алган, аны үтмәс сырхаудан йолып калган кәләшенә дә Нәфисә исемен бирдем. Аның Гарифны сихәтләндерүе турында язганда, гел Нәфисә апаны күздә тоттым. Нәфисә апа, рәнҗемәгез инде, зинһар, мин Сезнең адашыгызны бала табу, бала сөю бәхетеннән мәхрүм иттем поэмамда. Ни хәл итмәк кирәк, чыны шулай булгач…

Гомер кичүләре… һәркем тәкъдирендә… һәркемнең үзеннән соң кылган эшләре һәм аның үзе турында нинди дә булса истәлек кала. Гамил Афзал яшәгән канлы, газаплы XX гасыр инде үзе тарихка күчте, ә ул кичергән гомер исә һаман да дәвам итә. Ул кабаттан яшәрер, өлкәнәер һәм гел шулай кабатланып торыр. Чөнки ул кичергән гомер — безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез, рухыбыз, иманыбызның аерылгысыз бер өлеше.

***

*Илле бул да җирле бул,*
*Җире юкның аты юк,*
*Атлы бул да затлы бул,*
*Аты юкның заты юк,*
*Көче юкның хакы юк.*

Гамил Афзалның вафаты хәбәрен Казанга күчеп эшли башлаган җәйге бер иртәдә җиткерделәр. Кичекмәстән юлга чыктым. Әлмәтнең драмтеатр бинасында халык бик күп җыелган иде. Әлмәт үзе исән чагында да кадерли белде шагыйрьне. Соңгы туен да зурлап үткәрде…

Башкортстаннан күченеп килеп, Әлмәттә гомер кичергән, милли әдәбиятыбызда тирән эз калдырган Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликовларның исемнәрен мәңгеләштерү буенча да игътибарга лаек гамәлләр кылдылар алар…

Гамил ага Афзалның исемен мәңгеләштерү, аның исемендәге әдәби премия булдыру турында Башкортстан Язучылар берлеге рәисе, Башкортстанның Халык шагыйре Равил Бикбаев «Шагыйрьнең дөньяга икенче тапкыр тууы Башкортстанның Калтасы районы Шәрип авылы белән бәйле, әйдәгез, ике республика өчен Гамил Афзал исемендәге әдәби премия булдырыйк, ел аралаш Уфада һәм Казанда, Актанышта, Әлмәттә, Калтасыда аның исемендәге фестивальләр оештырыйк», дигән тәкъдимебезне хуплап кабул иткән иде.

Ни кызганыч, бу теләгебез әлегә яртылаш кына үтәлде. 2010 елда Татарстан Язучылар берлеге һәм Актаныш муниципаль районы хакимияте гамәлгә куйган әдәби премия әлегә Татарстан язучылары өчен генә… Үзебезнең теләгебезне ут күршеләребезгә тагын бер кат җиткерү кирәктер, һәрхәлдә, ул тугандаш әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләрне дә, милли әдәбиятларыбызны үстерүгә дә этәргеч ясар иде. Аты нинди бит, аты — Гамил Афзал — затлы ат — затлы исем!!!

Халкыбызга Мохтар Мутин, Гамил Афзал, Минтимер Шәймиев, Әлфия Авзалова кебек асыл уллар-кызлар биргән Актаныш ягы да бу елларда үзенең икенче яшьлеген, җитлегү чорын кичерә кебек…

Район кырларында мул иген үсә. Актаныш игенчесе дигән мәртәбәле исем, дан кабаттан кайтты туган төбәккә. Актанышта татар мәдәниятенә, әдәбиятына, сәнгатенә зурлык китерерлек өметле яшь буын үсеп килә. Олуг шагыйребезне мәңгелек дөньяга озатканга бер ел тулу алдыннан язылган шушы хатирәләремне һәм тәэсирләремне кабат карап, тулыландырып, шуларны, хөрмәтле укучыларым, сезгә җиткерәсем килгән иде.

**Мөхәммәт МИРЗА**
*Актаныш—Әлмәт—Казан*

# Гамил Афзал

## Мәңгелек гамь

Наратлар тирбәлә, каеннар гөж килә,
Яңгырга микән лә, давылга микән?
Бер яңалык көтеп күңелләр җилкенә,
Шатлыкка микән лә, кайгыга микән?

Бабай туңып ята, малай туып ята,
Кемдер көлеп ята, кемдер белеп ята.
Гөлләр шиңеп ята, көзләр килеп ята,
Мәңгелек гамь йөри туган якта.

Сөйләшер-сөйләшмәс, эндәшер-эндәшмәс,
Ваемсыз, тәкәббер, караңгы чырай,
Ясалма көлүең бушка да кирәкмәс,
Кардәшлек, якынлык бирмәсен Ходай!

Әллә кай заманда әйткән бер ишан:
– Патшага ышанма, Аллага ышан!
Мин уйлап торам да улыма кушам:
– Түрәгә ышанма, халыкка ышан!

## Ачы язмышлар

Ул елларда һәркем туган якта
Күз яшьләре белән бит юган.
Идел буе ачтан үлгән чакта
Якты өмет белән кем туган?!

Күзләрдә моң булган, маңгайда сыр,
Алабута баскан бусага.
Бәлки мин дә кирәк булганмындыр,
Бер елмаер өчен булса да.

Намус качты илдән, иман качты,
Бәйрәм итте заман ялгышлары.
Җан өстенә Дәҗҗал булып басты
Корбаннарның ачы язмышлары.

Елмаючы кирәк, чорны аңлап,
Күзе тонган кызыл мәхшәрдә.
Күпме мөмкин, илне-көнне алдап,
Ялган иман белән яшәргә?!

Кем гаепле? Без гаепле инде, –
Күзе тонган кара сарык булдык.
Әллә Намус, әллә Иблис көлде, –
Ялган диңгезендә гарык булдык.

## Яңгырлы көз

Өстәл тулы гәҗит, киштә тулы китап,
Күңел бармый эшкә, илһам килми һич тә.
Кемдер алга киткән, кемдер калган артта.
Дөрес бардыммы дип, күңелдә шик арта.

Алга бару кыен, туктап артка кара,
Юкмы туры бер юл, юкмы бүтән чара?
Кайда синең кәгъбәң, кайда нурлы кыйблаң?
Көзге яңгыр ява, шаулый кара урман.

Көзге яңгыр ява көзге шыксыз кичтә.
Гомер үтеп бара, даһилык юк һич тә.
Кайда кояш чыга, кайда кояш бата –
Бөтен күкне каплап соры болыт ята.

Дымлы, салкын һава, үзәннәрдә томан,
Һаман яңгыр ява, һаман шаулый урман.
Кемдер алга киткән, кемдер дошман булган,
Ямьле чорлар үткән, шомлы шаулый урман.

Шундый инде безнең озын гомер юлы:
Мәшәкатьләр тулы, борчылулар тулы.
Космонавтлар әйтә: «Тереклек юк Айда».
Даһи шагыйрьләрнең васыятьләре кайда?

Алга бар, ди Тукай. Алла бар, ди мулла,
Бу газаплы юлда, бу каһәрле юлда.
Бүләк бирмәсеннәр, рәхмәт димәсеннәр
Синең арттан килер иманлы нәселләр!

## Батыр песи

Үлгән арыслан янында песи күкрәк кага:
– Мин кыю демократ идем, буйсынмадым аңа.

Дөньяны куркытып торган мәрхәмәтсез тиран,
Менә мин аның янында горур басып торам…

Ул элек хуҗа каршында поднос тотып торды,
Берәр калдык сөяк алып, рәхмәт укып торды.

Иртә-кичен, баш өсте дип, койрык болгап торды,
Түбән карап, сыртын ялап, мактау уйлап торды.

Хәзер арыслан янында песи күкрәк кага:
– Мин аның белән көрәштем, буйсынмадым аңа…

***

Кеше исән чакта – мактамадым,
Кеше дөнья куйгач хурламадым.
Ак күбәләк кебек җан җилпенде,
Куштаннарга кушылып җырламадым.

Шаулап-гөрләп үткән ул көннәрнең,
Иблисләрен күрдем, изгеләрен.
Бизмәннәргә салып тигезләдем,
Күктән йолдыз тоткан мизгелләрем.

## Асылыңа кайту

Үзгәрергә кирәк, диләр, үзгәрергә,
Давайте, үзгәрик, диләр, бергә-бергә,
Кызыл уйнаш дәверләре артта калды,
Акыллырак булу кирәк хәзер безгә,

Үзгәрергә кирәк, кардәш, үзгәрергә!
Саф үзеңчә шат яшәргә өйрәнергә,
Иске заман хурлыгыннан төзәлергә,
Бозыклыктан асылыңа кайтыр заман,

Уйланырга кирәк, кардәш, эзләнергә,
Үзгәрергә кирәк безгә, үзгәрергә!
Иманлылар кыю басып үргә менә,
Бәхет бар ул Идел-Урал үрләрендә,

Астан кисеп, өстән ямап тормый гына,
Асыл хуҗа булыйк әле туган җиргә,
Үзгәрергә кирәк безгә, үзгәрергә!
Иман булсын туганнарның күзләрендә,

Сафлык булсын алсу-алма йөзләрендә,
Болыннарда чәчәкләр дә төрле-төрле,
Язлар саен, көзләр саен төрләнергә,
Үзгәрергә кирәк безгә, үзгәрергә!

## Инкыйразга каршы

Инкыйраз, дисең син, мелла Гаяз,
Син акыллы егет булгансың.
Бездә бәхет көткән көннәр аяз,
Оныклар да яшәр бездән соң.

Без бик урау-урау юл урадык,
Бирешмәдек эссе-салкынга.
Дога кылып кына утырмадык,
Һөнәр дә бар бездә, акыл да.


Һай, залимнәр безне кисте-асты,
Кемнәр кызганыр да юатыр?!
Йокы качты, халык күзен ачты,
Мескен булып торгач дүрт гасыр.

Үткән хәсрәтләргә нокта куеп,
Билне буып чыгыйк ярышка.
Имин еллар теләп дога кылыйк,
Иман да бар илдә, намус та.

Мин дә кайтам, илдә кем бар, дисәң,
Эш табылыр, иптәш, сиңа да.
Кол Гали дә, «Идегәй» дә исән,
Тукай да бар әле дөньяда.

Ирек, бәхет юрап таңнар аткан,
Ил корабы йөзә диңгездә.
Мең ел гомер иткән уртак ватан –
Үги ана түгел ул безгә.

# «КЫР КАЗЛАРЫ ОЧЫП УЗАРГА...»



Рәшит абый Әхмәтҗанов белән без күпмедер вакыт абый белән энекәш кебек аралашып яшәдек: берара күршеләр булдык, «Казан утлары» журналында бергә эшләп алдык. Ул әле минем беренче редакторым да: «яшь язучылар белән эшләүче» бер агай «син ялгыш юлда йөрисең» дип, студент елларында язганнарымны юкка чыгаргач, Рәшит абый аларны укып, хуплап, алга таба иҗатка ымсындырган иде. (Ул, гомумән, якын күргән кешеләрен үсендерергә-канатландырырга-күтәрергә ярата иде. Үзе какча гәүдәле генә булса да, Фәнис ага Яруллинны әллә ничә тапкыр фатирына туры мәгънәсендә күтәрешеп менгәнен күпләр белә.) Озын сүзнең кыскасы: «Яшьлектән хат» дигән шигырьләр китабым, аның фатихасы белән, яшьлек кайнарлыгында язылып инде суына башлаганнан соң булса да – 25 ел узгач – дөнья күрде.

Ә безнең танышу күпкә элегрәк – мин Казанга укырга килгәч үк булган иде. Аның сеңлесе Сания белән имтиханга керәбез, ә Рәшит абый белән минем Шамил абыем (Маннапов), ут йотып, без чыкканны көтеп торалар. Миңа ул чакта Луиза апа белән аларның тимер юл вокзалына якын (Чернышевский урамында) торган куышында да булырга туры килгәләде. Бервакыт хәтта берме, икеме яшьлек кызы Ләйләне карарга ышандырып, Рәшит абый җәһәт кенә үз йомышлары белән йөреп-әйләнеп кайтты...

Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» китабына «Татарстан яшьләре»ндә басылган рецензиям шуңа күрә «Өч очрашу» дип аталган иде. Беренче очрашу – танышкан вакытыбызда, икенчесе – аның мәшһүр Тукай клубында канатланып-очып шигырь укуын тыңлаганда, ә өченче очрашу – менә шушы затлы китап булды. (Бу – әдәби тәнкыйть өлкәсендә беренче тапкыр каләм сынап каравым иде.)

Шуннан бирле мин Рәшит абыйның һәр шигырен диярлек яттан беләм, аларга бәя биргән булып, аның иҗаты хакында язылганнарны кабатлыйсым килми...

*Әллә инде кыр казлары кайта,*
*Яктылыклар арта бу якта.*
*Онытмагыз –*
*Казлар канатында*
*Очып киткән сөю елата.*
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
*...Зәңгәр күзләреңдә – зәңгәр һава,*
*Кыр казлары очып узарга...*

Соңгы ике юл инде менә кырык елдан артык күңелемнән китми. Чөнки университет коридорын бер башыннан икенчесенә кадәр иңләгән «Әдәби сүз» стена газетасын чыгаруга мәсъүл (җаваплы) кешеләрнең берсе буларак, мин аның иҗатчы кызларыбызга багышланган санына аншлаг итеп шул юлларны элдерткән идем.

Рәшит Әхмәтҗановның тормыш һәм иҗат юлын кыскача булса да бүгенге укучының исенә төшерик.

Билгеле булганча, ул 1941 елда Баулы районы Татар Кандызы авылында туа. Авыл мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, төзүчеләр әзерләү училищесында укый, аны тәмамлагач, нефть районнарында һәм Әлмәт шәһәрендә ташчы булып эшли. Аннары Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кереп, 1969 елда аны тәмамлап чыга һәм башта

Мәдәният министрлыгында сәнгать эшләре буенча инспектор, аннан соң «Яшь ленинчы» һәм «Татарстан яшьләре» газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1980 елдан вафатына кадәр ул «Казан утлары» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире иде.

Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләре матбугатта 50 нче елларның ахырында күренә башлый, һәм ул, 1959-1961 елларда «Азат хатын», «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында басылган шигъри бәйләмнәре белән, әдәби җәмәгатьчелектә кызыксыну уята. Университетта укыганда ук «Хыялларым үзем белән» дип аталган беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә, укучылар тарафыннан җылы каршы алына. Алда телгә алынган «Ак канатлар» җыентыгында якты идеалларга табынган, халкының киләчәгенә ышанган яшь кешенең уйланулары һәм кичерешләре тасвирлана. Аның иҗатын үз иткән Хәсән ага Туфан «Өметләрне аклады» дигән, төп фикере исеменнән үк аңлашылып торган мәкаләсендә аңа беренче булып фатихасын бирә. Гомумән, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында «туфанилык» ачык ярылып ята – беренче чиратта, ул халык иҗатыннан килүче образлар, тәгъбирләр һәм аһәңнәрдә чагыла. Сибгат Хәким, Гали Хуҗи кебек олпат шагыйрьләр яшь каләмнең табигый сәләтен һәм шигырьләренең тормышчанлыгын билгеләп үтәләр, аны яңа иҗат табышларына рухландыралар. Шагыйрьнең «Ак каеннар», «Гомер чишмәсе», «Җан яктысы», «Йөрәк бәйрәме», «Алмалы җәй», «Кавышыр көн», «Ачлык мәйданы» һ.б. шигъри китаплары, гәрчә кайбер каләмдәшләре хаклы искәрткәнчә, күрәкараучы тәнкыйтьчеләр «обойма»сына үзе кермәсә дә, гади һәм гадел укучы мәхәббәтен яулый. Аның аерым китаплары һәм тулаем иҗаты турында төрле елларда матбугатта сүз әйткән Р.Батулла, Роберт Әхмәтҗанов, Ф.Яруллин, Ф.Баттал, А.Хәлим, М.Әгъләм һ.б. әдипләребез, шигырьләренә нечкә лиризм, образлар байлыгы, шигъри интонацияләрнең кискенлеге хас, алардан халык иҗатына хас моң-сагыш саркыла, яңача яңгыраш төсмерләре биреп, халык телбизәкләреннән оста файдалана, аларга тыйнаклык һәм җыйнаклык, садәлек хас, аның лирик каһарманы әхлакый сафлыгы, холык-фигыленең бөтенлеге белән истә кала, дип билгеләп үтәләр. «Шигырь китапханәсе» кебек абруйлы сериядә чыккан «Моңлану» җыентыгына сүз башы язган Равил Фәйзуллин аның иҗатына тулаем бәя бирсә, вафатыннан соң «Рухият» нәшриятында дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»енә кереш сүз авторы Марсель Галиев, шагыйрьнең тормыш юлын, холык-фигылен – балаларча ихласлыгын һәм җитди җорлыгын үзенә хас сурәтле-җанлы итеп тасвирлаудан тыш, иҗатының төп хасиятләрен дә ача.

*...Мин агарам – һаман агарам –*
*Күренмидер хәтта күз карам.*
*Шулай узар минем гомерем.*
*Бөтен гомеремә бер гөлем*
*Син генә бит. Димәк, иртәгә*
*Миңа тагын юлга китәргә –*
*Утка яга-яга төннәрне,*
*Озайтырга синең көннәрне...*

Тугрылыклы «аккош мәхәббәте» турында, Хәсән Туфаннан соң, шулай фәкать Рәшит Әхмәтҗанов кына яза алгандыр сыман.

Алда телгә алынган китаплар арасында миңа «Алмалы җәй» ни өчендер аеруча якын. Ул – Рәшит абыйның бишенче китабы. «Бишенче» дип аерып әйтүем шуңа: башка күп кенә кордашлары әдәбият бусагасына балалар өчен язган беренче «бишек җырлары» белән аяк бассалар, Рәшит Әхмәтҗанов әлеге җыентыгына тәҗрибә туплаган шагыйрь булгач кына алынырга җөрьәт итә. Кызы Ләйлә, «блондин»ы Айдар (сабый чагында аксыл чәчле улын ул, яратып, шулай атый иде) өчен язгангамы икән, аның бу китабы гаҗәеп ихлас, җыйнак, уйнак һәм бер үк вакытта фәһемле, тәрбияви вазифалы шигырьләрдән тора. (Сүз уңаенда әйтергә кирәк, ул чакта әле яшь рәссам Лилия Золондинованың да «йомры, йомшак» рәсемнәре китапның шулай еллар буена хәтердә калырлык булуына, яңадан-яңа буыннарны үстерешүенә ярдәм итә.) Әгәр игътибар беләнрәк тыңласаң, аның балаларга атап язган шигырьләрендә дә халыкчан зирәклек, олылык, олпатлык аһәңнәрен ишетәсең:

*Бергәләп җырлыйк «Туган тел» җырын,*
*Кечкенә чакта җырлаган кебек.*
*Һавада — кояш, җирдә туган тел*
*Булмаса әгәр, зурайммас идек...*

Өземтәләр күбәеп китсә дә, тагын берсен китерми уза алмыйм:

*Җиңелмә сүздә, җиңелсәң,*
*Җиреңне дә дауларлар.*
*Юкка гынамыни җирдә*
*Чичән булган бабаңнар.*

Хәтеремдә әле: энҗе бөртегедәй ялтыраган, йөрәк кебек тибеп торган, учка сыярлык җыйнак лирик шигырьдә ат уйнаткан Рәшит абыйның поэма жанрында да көчен сынап карыйсы бик килә иде. «Исәннәр моңы» дигән беренче поэмасында ул, үз шигъри стиленә хас җыр, риваять, әкият алымнарын да кулланып, сугыш һәм тынычлык, заман агышы һәм хәтер, мәхәббәт һәм нәфрәт кебек мөһим мәсьәләләрне күтәрә һәм туган авылының рухи яшәешен күз алдына бастыра. Шуннан соң басылган берничә поэмасы арасында, әлбәттә, «Аучылар кибетендә» һәм «Бишташ» шагыйрьнең һәм тулаем татар шигъриятенең зур табышы булырга лаеклылар.

Алда әйткәнемчә, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатының чын бәһасен белгән каләмдәшләре аның турында байтак яздылар. Аларга өстәп, «зәңгәр күзләрдәге зәңгәр һава»дагы бер генә якты ноктага игътибар иттерер идем, ул да булса, шагыйрьнең канатлары – аккошлар, кыр казлары, сандугачлар очкан биеклеккә ашып, күңел күзе белән ерак араларны, ерак гасырларны иңләп очуы.

*Кораб китте еракларга, зур юлларга,*
*Карыйм күздән югалганчы шул якларга.*
*Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,*
*Чит җирләрдә каерыла пар канатлар.*

Яки:

*Талларга качты сандугач –*
*Мин аны эзлиммени?*
*Сандугач керде күңелгә –*
*Җырламый түзиммени?!*

Әлбәттә, аның «кош»лары илсез-җирсез түгел, алар сайрап кына тормый, ә, тигезсез булса да, көрәш мәйданына чыга, гавамны тетрәндерерлек итеп оран сала. Бу урындагы кинаям Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» дип исемләнгән поэмасына төбәлгән.

Әсәрдә шагыйрьнең, милләтпәрвәр көрәштәшләре белән ил азатлыгын хаклап һәм яклап, 14 көн буена Ирек мәйданында ачлыкта утырулары, шунда кичергән уй-тойгылары урын ала. Әлеге поэма, халкыбызның үткәнен һәм киләчәген йөрәге аша уздырып, аның горурлыгын, үзаңын уяту омтылышы белән сугарылган, милләт һәм тел язмышы өчен чын күңелдән янган Рәшит Әхмәтҗановның җан авазы, бөтен иҗатына сөземтә булды: *«Мәйданда – догалы читекләр, / Мәйданда – дагалы итекләр...»* Ә.Закирҗановның җиңел кулы белән, «Ачлык мәйданы» татар баласы укырга тиешле 100 китап исемлегенә кертелгән иде. Хаклы рәвештә!

Рәшит абый «төзәтеп булмаслык» оптимист иде. Әмма: *«Мин җылытам әле, дөньям, сине, / Җаным суынганчы җылытам...»* – дип, ил гаме белән янган йөрәге ярылып, моннан егерме ел элек ул мәңгелеккә китеп барды.

Күңелләрдә калган шәхес, кабатланмас олы иҗаты белән татар шигъриятенең биек мизгелен тамгалаган Рәшит Әхмәтҗановны укучылар һәм каләмдәшләре генә югары бәяләп калмады, ул «Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, Язучылар союзының Гаяз Исхакый исемендәге бүләгенә лаек булды.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

## Рәшит Әхмәтҗанов

### Татар теле

Мин — халкыңның теле.
Сине эзләп,
Канга батып беткән хәтере.
Бәлки, сиңа «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин — бар, мин — тере!

Нигә, балам, юллар уртасында
Башмагыңа карап баш идең?
Чукынмадыңмәле? — Җиде бабаң
Васыятен тапшырыр идем.

Күзләреңә төшкән күләгәне
Таратыйммы диеп мин килсәм,
Кипкән иренеңдә ярылып яткан
Сүзләреңдә әле мин исән:

«И син, телем, әнкәм, җанкисәгем,
Истәлегем, исән көннәрем!
Сабый чакларымда бишегемне
Тирбәтергә нигә килмәдең?»

Мин коллыкта әле. Илемдә дә
Алтын сүзләремә юк кадер.
Дөньядагы исәннәрем белән
Исәнләшә алмыйм мин хәзер.

Мин — барыбер диңгез! Бөтенегез
Аягөсте басар, шауласам.
Эзләреңә энже-мәрҗән сибәм,
Дулкын бәрелгәндә аумасаң.

Минем мәрҗәннәрдә җиде бабаң
Васыяте шулай җемелди.
Җем-җем иткән утка таба китсәң,
Әбиләрең шулай җеп эрли.

Нурларымны ятлар җыеп ала,
Капчыгына сала — кимеми.
Өзелмиләр, чуалмыйлар алар —
Безнекеләр шулай җан бирми!

Кил син, балам,
Кер син кочагыма —
Уйлый күрмә илдән китәргә.
Исән чакта — бүген исәнләшик,
Соң булуы мөмкин иртәгә.

Исәнләшик.
Мин — халкыңның теле,
Кылыч телгәләгән хәтере.
Сиңа мине «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин — бар, мин — тере!

## Синме?

Өстә калганмы дөньяның вак-төяге, —
Тамырларның кочагында кем сөяге —
Беләсеңме?

Агачларның нигә соң ул асты икән,
Әллә үзе кискән агач басты микән —
Белмисеңме?

Бар кешегә бәхет даулап яшәгәнме,
Һәм бар кеше бер кешегә таш бәргәнме —
Белмәдеңме?

Безнең дә бит чак-чак исән калды башлар, —
Таш бәрүдә мәргән булды замандашлар —
Беләсеңме?

Кочар икән безне кайда, кайсы тамыр,
Безне яшел яфраклардан кемнәр таныр —
Улым, синме?

* * *

Кемнәр кая китеп бара, кем кала?
Бәхет кемдә, кайгыларны кем ала?..

Менә шундый көзге моңсу көннәрдә
Фәкыйрегез яши башлый гөлләрдә.

Сагыш уты сулыйм – гөлләр яшиләр,
Күзләрендә яшь зарланып дәшмиләр.

Җилфер-җилфер килә-килә җил көлә,
Алда нинди көннәр көтә – кем белә?

Капшый җанны, барлый канны – ни кирәк?
Кит әле, җил, мин гөл түгел, мин – йөрәк!

Алдан сайлап чәчәкләрнең акларын,
Берәм-берәм өзгәли яфракларын.

Күчә зәңгәр чәчәкләргә аннары,
Чират көтеп тирбәлә кылганнары...

Уңнан килә, сулдан килә... өзгәли, —
Китәр вакыт җитте инде сезгә, ди.

Беләм, җилләр барын өзеп алачак,
Дүрт-биш яфрак кына исән калачак.

Менә шулай көзләр килгән көннәрдә
Өзгәләнеп яши башлыйм гөлләрдә.

***

*Миләшләрең һаман ут сымандыр...*
*К. Б.*

Белә торып минем хәлләремне,
Ник сорыйсың: һәрбер бөредән
Ут бөркелгән... Җаным сүнеп бара,
Бер-бер артлы болар терелгән.

«Миләшләрең һаман ут сымандыр...» —
Утка алып керә бу сорау.
Янмый гына утта,
бер минут та
Мөмкин түгел башны асрау.

Юкка дисең мәллә бу миләшләр
Чыгып йөгергәннәр урманнан:
Ярый синең ак шәл иңнәреңдә,
Боларга бит утлар уралган.

Сагышлардан сулыш алалмыйча,
Ничә тапкыр йөрәк туктады, —
Ярый әле сулышымны буган
Бөҗраларны өзә утлары.

Утны йотып җибәрергә мөмкин,
Ярым искә төшкән чагында.
(Ул бит йөрде кылыч сагында гел,
Көч күп иде ятлар ягында.)

Утка охшап торган миләшләрнең
Яфраклары тора өстәлеп.
Баш исән дә... Мин шул үз ярыма
Тик Сөюдән калган истәлек.

# ЯЗМЫШ ЙӨРТӘ КЕШЕНЕ

Татар сүз сәнгате төрле мәүзугъта, биниһая бай өслүбтә иҗат иткән исемнәргә ярлы түгел. Саный, атый китсәң, искитмәле. Берсенә татарның рухи дөньясы, аңа гына хас сыйфатлары якын булса, икенчесен олы язмышлы шәхесләр үзенә җәлеп итсә, өченчесенә бөтен илаһи матурлыклары белән авыл якын була, дүртенчесен холкыбызны, яшәү рәвешебезне кискен үзгәрткән шәһәр тормышын аңларга омтылыш ялкынсытса, барысын да уртак, үзәккә җыйган, йөрәкне телгәләүче бер төбәк бар – ул татар халкы язмышы. Милләтебезнең бүгенге халәте, киләчәге, телен (димәк ки, үзен) саклап кала алуы өчен борчылмаган язучы юктыр. Ә инде бөтен тормышын, барлыгын, сәләтен, матди вә рухи көчен татарларны дөнья буйлап барлап йөрүгә багышлаган һәм сәяхәтнамә дип аталган борынгы жанрга яшәү көче өргән каләм иясе дип Тәүфикъ Әйдине (1941-2001) атасак, зур хата булмастыр. Тормыш юлына, биографиясенә күз салсаң, барысы да гадәти кебек: Мәскәү өлкәсенең Шатура (шул сүзне әйтүгә, торф күз алдына килә) районы Туголесский Бор исемле эшчеләр посёлогында туган Тәүфикъның балалык һәм яшьлек еллары Апас районының Түбән Балтай, Олы Бакырчы авылларында үтә, әти-әнисе белән ерак Омск өлкәсенең Азов районында да яшәп ала. Белемгә тартылуы үсмерне Алабуга китапханә техникумына алып килә. Белгечлеге аны китап укырга, дөньяны танырга өйрәтә булса кирәк. Техникумны уңышлы тәмамлагач, яшь белгеч Апас районының Урта Балтай авылында 1957-1960 елларда китапханә мөдире булып эшли. Шул чорда ул татар һәм дөнья әдәбияты белән таныша, шәхес буларак өлгерә. Үзендә иҗади дәрт, омтылыш, вулкан кебек бәреп чыгарга әзер эчке көч тоеп, Казан турында хыяллана башлый. Ләкин анда аны, рәхим ит, Тәүфикъ энекәш, дип, берәү дә көтеп тормый. Куе бөдрә чәчле, уртачадан озынрак буйлы, чандыр гәүдәле егеттән башка да китапханәчеләр буа буарлык икән башкалада. Эшче куллар җитешми. Төзелештә, гади ташчы булып эшләүчегә, тулай торакта урын да табыла. Акрынлап таныш-белешләре, аңа хәерхаһ кешеләр дә килеп чыга, аны милициягә эшкә алалар. Урта белемле, тыйнак вә үҗәт егет тиздән милициядә эшли башлый. Анда эшләп алуы иҗатына таяныч ноктасы – тормыш материалы бирә. Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан тәүге, иң күләмле әсәре – «Боҗра» (1978) бәянының нигезендә шунда эшләгәндә күңеленә сеңгән күзәтүләр, мәгълүматлар, интригалар ята.

Әгәр Тәүфикъ милициягә эшкә урнаша алуыннан канәгать калып, шунда төпләнеп, югары дәрәҗәләр алып, зур пенсиясенә чаклы шунда хезмәт иткәндер, дип уйласагыз, бик нык ялгышасыз. Ул һаман эзләнә, атаклы «Оргсинтез» берләшмәсендә әүвәл слесарь, аннары аппаратчы вазифаларын башкарып ала да, рухына, күңеленә якынрак мохит эзләп, мәктәпкә укытучы булып урнаша. Һөнәрен алыштыру өчен алшартлар да өлгергән була. Ул, китапханә көллияте биргән белемнең генә җитешмәвен аңлап, Казан дәүләт дәрелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Шул чорда Т.Әйди исеме газета-журналларда күренә башлый, бигрәк тә «Яшь Ленинчы»да «үз кеше» булып китә. «Инешләр Иделгә кушыла» (1971) исемле күмәк җыентыкларда хикәяләре, язмалары, мәкаләләре басыла. 1973 елда, инде югары филологик белемле егетне, Халык иҗаты йортына методист итеп чакыралар.

1982 елда аның тормышында киләчәге өчен ифрат мөһим вакыйга була, басылган хезмәтләре өчен Тәүфикъ Әйдине Татарстан язучылар берлегенә әгъза итеп алалар. Шул чордагы берлек рәисе Гариф Ахунов, иҗатын бәяләп, үзенә тирән ышаныч белдереп, аңа әдәби киңәшче (консультант) вазифаларын үтәүне тапшыра. Яшьләр иҗаты белән якыннан танышу, өлкән сүз осталары белән аралашу, милләтенә файдалы кеше булу теләген гамәлгә ашыру өчен, нәзари әзерлегенең сайрак булуын аңлавы аны 1983-1985 елларда Мәскәүнең ике еллык Югары әдәби курсларына алып килә. Нәкъ шул чорда Т.Әйди

үзенең язмышын, киләчәген язучылык һөнәре белән бәйләргә дигән ныклы иманга килә. Шактый тупланган тормыш тәҗрибәсе, төрле оешмаларда эшләве, бер яктан, чынбарлыкны иңләбрәк, психологик нечкәлекләре, төрледән-төрле бизәкләү чаралары ярдәмендә күләмлерәк әсәрләр язарга мөмкинлек бирсә, икенче тарафтан, аны ил һәм дөнья буйлап, бастырыксыз салам кибәнедәй сибелеп, таралып утырган, мәгәр эшчән, сабыр, моңлы вә тыңлаучан, әмма хокуксыз милләтенең, теленең язмышы, татар кавеменең киләчәге борчый. Тормышның бит әле Тәүфикътан гына тормаган кагыйдәләре бар: гаилә корасы, балалар үстерәсе, аларны матди кирәк-ярак белән тәэмин итәсе бар. Әүвәл ул «Казан утлары» журналының проза бүлеген җитәкли, аннан аны «Татарстан» журналына баш мөхәррир урынбасары итеп чакыралар. Киләчәген әдәбияттан башка күз алдына да китерә алмаган Тәүфикъ, гомеренең кыскалыгын сизенгәндәй, тематик диапазонын киңәйтә барып, иҗатын төрле юнәлешләрдә үстерә һәм фани дөньяда яшәешенең соңгы чорын тулысынча әдәби хезмәткә, бигрәк тә, чит илләрдә, Россиядә яшәүче татар диаспораларын өйрәнеп, халкыбызның асыл балаларын эзләп табып, барлап, язма-басма сүзе аша дөньяга танытуга багышлый. Табигый сәләтен төрле жанрларда сынап карый.

## I

1991 елда Т.Әйди үзенең иң күләмле, катлаулы фабула канвалы, холык-характерларының тулырак ачылуы белән үзенчәлекле, сәнгатьлелек җәһәтеннән шактый камил «Елан угы» романын язып чыга. Сүз большевиклар хакимиятенең үз гореф-гадәте, җае, көнкүреше белән яшәп яткан Бохара әмирлеген юк итеп, җирле халыкка көчләп Бохара Совет республикасын тагуы турында бара. әлеге темага Т.Әйди кебек үткен күзле, очкын каләмле, милли мәнфәгатьләр өчен көрәшеп яшәгән кешенең алынуы урынлы һәм вакытлы иде. Чөнки ул – бу якларда булгалаган, анда яшәүче халыкларның теленнән, йолаларыннан хәбәрдар зат.

Тарихи темага мөрәҗәгать иткән каләм иясе ике чынбарлык белән эш итә: тарих катламы һәм бүгенге көн вазгыяте. Теләсә кайсы чорны үзәккә алган әсәр нигез сорауга җавап эзли: каһарманның эшчәнлеге тиреләк, мохит омтылышларына җавап бирәме, алдынгы карашны алга сөрәме, әллә тәртәгә тибәме? Дөрес, «Елан угы» әсәрендә Урта Азия халкының азатлык, мөстәкыйльлек өчен көрәшен, рәсми оешмаларның «басмачылык хәрәкәте», дип кенә бәяләүләренә ышаныбрак иҗат итү сизелә. Язучы стереотип, һәрдаим колакларга, күңелләргә сеңдерелеп килгән мәгълүматларга артык ышанып, дөресрәге, ул чорда чын тарихны яшереп тоту сәбәпле, Бохара әмиренең мөстәкыйль дәүләтен һәм үзен саклап калу өчен, төрмәләрдән чыгарылган кешеләрне, җинаятьчеләрне коралландыруын хата, зур ялгыш дип саный.

Әлбәттә, бүгенге көн күзлегеннән бәяләгәндә, киләчәктә татарлар яшәгән төбәкләрне, чит илләрне аркылыга-буйга иңләячәк, совет хөкүмәтенең аз санлы халыкларны буйсындыру, акрынлап юкка чыгару сәясәтен аңлаячак һәм большевизмны күрә алмаячак Т.Әйдине ул чорда рәсми пропагандага, социализмга артык ышануда да «гаепләп» булыр иде. Язучы «Елан угы»ның сюжет төзелеше турында уйланып, күренекле әдибебез Г.Ибраһимов ачышларына иҗади таянып, хәтта аның отышлы алымнарын дәвам иттерүен дә яшерми. Классикның «Тирән тамырлар» романы «Фәхрине үтереп ташладылар», дигән атаклы җөмлә белән башланып китә дә, фабула җебе шуңа бәйле рәвештә үстерелә, сәбәплелек бәйләнешләре каһарманнар язмышында ачыла. «Елан угы»нда да шуңа якын алым кулланыла. Алдынгы карашлы, һәрьяктан килгән, уңай каһарман, комиссар Шиһабетдиновны чит, ят, кысынкы бүлмәдә үле килеш табалар. Шуннан, детектив жанр кануннары буенча, китә тикшерү, эзләү, үткәннәрне искә алу, төрле төркемнәр арасындагы көрәш, маҗаралар мозаикасы...

«Елан угы»ндагы каһарманнарны сурәтләүдә ачык төгәл буяулар, ак һәм кара төсләр өстенлек итә. Үзәктән җибәрелгән, инкыйлаб эшенә ихластан бирелгән хәрби комиссар Баһаветдин Шиһабетдинов, аның ярдәмчесе, теркәү бүлеге башлыгы Фарукҗан Байкучатовлар аек акыллы, ифрат намуслы, Ленин эшен, Мәскәү хакимияте әмерен уздыручылар буларак сурәтләнәләр. Бохара әмирлеге белән көрәштә аларга ярдәмгә тартылган Рахманкол, Симиниев, Әминевлар, төрлесе-төрле холыклы, каршылыклы карашлы кешеләр, коммунистлар алып килгән яңалыкны «аңлап бетерми» яисә иҗтимагый-сәяси үсешләрендә «артта» калган затлар кебегрәк сурәтләнә. Автор ике

төркемгә дә үз бәясен көчләп такмаска, вакыйга-хәлләрне ничек бар, шулай күрсәтү тарафдары булып калырга тырыша. Бу — аның уңышы.

Халыкның өстән төшерелгән сәясәтне – большевизмны кабул итмәвен «басмачлар хәрәкәте» дип кенә бәяләү Ш.Усмановның «Памирдан радио» исемле маҗаралы бәянында да сизелә. Т.Әйди мондый берьяклы аңлаудан китәргә тырыша. Тулаем алганда, «Елан угы» романы – хәзерге чорга шактый четерекле, катлаулы мәүзугъны камил сюжет төзелеше, каһарманнарның килеш-килбәте, эчке дөньясы, чит бер мохитне этнографик күзәтүләр, тормыш-көнитеш ваклыклары аша сурәтләве белән сәнгати әһәмиятен югалтмаган әсәр.

Сәяхәтнамәләр, юлъязмалар, күзәтүләр дөньясына башы-аягы белән кереп чумганнан соң да, Т.Әйди күләмлерәк әдәби жанрлардан читләшми. Бай тормыш тәҗрибәсе шуны таләп итә.

Нинди җир ул Ватан? Сатлыклар кемнәр? Татар хәрбиләре ни өчен Советларга каршы Германиядә оештырылган легионга керә? Әсирләрнең алман хәрбиләре белән бәйләнешләре нинди була – әнә шушы сорауларга җавап эзләгән «Иблискә ришвәт» романы 1995-1996 елларда иҗат ителә. Әсәр Алманиягә әсирлеккә төшкән татарларның язмышын үз эченә ала. Укымышлы, совет хакимиятен күралмаган тоткыннарны берләштерүче уртак сыйфатлар: алар барысы да үз юлларын сайлый алмый икеләнә. Кайсы империянең җиңүе татар милләте өчен отышлырак? Ничек исән калырга? Хәлимәләр, Саматлар өчен әсирлек вакытлы күренеш. Алар мөмкинлек туугач монннан качып, туган илләренә кайту турында хыяллана. Көнчыгыш министрлыгында хезмәт иткән, укыган, гыйлемле Янгураз һәм Шәмсирләр киләчәкләрен Германия белән бәйләп карыйлар. Алар СССР яшәгәндә татар милләтенең киләчәге юклыгына инаналар, үзләре әйткәнчә, «иблисләр» идарә иткән империягә кире кайтсалар, гомерләренең төрмәдә түкәнәчәген дә бик яхшы беләләр. Вакыйгалар геройларның максатка ирешү, исән калуга омтылышлары белән үрелеп үсә. Төп каһарман Янгуразны гына алыйк. Ул берьюлы ике алман кызының башын әйләндерә. Җитәкче даирәләр белән элемтәсе булган Софи исемле хатын да, яшь алман кызы Рина да аңа исән калу, киләчәктә чит илдә ныгу, канат җәю өчен кирәк. Әсирлектәге Хәлимәне дә ул күз уңыннан ычкындырмый. Иң соңгы чиктә Сталин идарә иткән илгә кайтырга туры килә икән, коммунистлар идеологиясенә тугры кыз аны коткарырга тиеш. Автор бик оста алымнар белән эш итә. Ул милләтче, татар халкының киләчәге өчен борчылган, укымышлы, үткән тарихыбыздан хәбәрдар, тормыш шартлары күпкә яхшырак Германияне өстен күргән һәм монда яшәп кенә татар милләтенә ярдәм итеп була дип фикер йөрткән Янгуразның һәр адымын хуплый кебек. Шул ук вакытта ул туган илен өзелеп сөйгән, нинди генә авыр шартларда да шунда яшәүне бар нәрсәдән артык күргән, үз милләте – татарлар турында сөйләшүгә караганда, интернациональ дуслыкны өстен күргән Хәлимәнең эчке халәтен дә аңлый. Совет гаскәрләре Германия чигенә якынап барган саен, роман геройларының хис-кичерешләре, кыйблалары үзгәрә. Баштан ук үз сүзендә нык торган Янгураз, Шәмсир кебекләр кыйблаларына тугры кала. Самат, Рәмзи ишеләр кисәк үзгәрә, милләт сүзен кулланудан тыела, үзләрен аяп калу өчен алман ягына чыккан татар әсирләренә каршы фетнә оештыра башлый. Саматның Янгуразга һөҗүме шуңа дәлил. Совет гаскәрләре Германиягә кергәч, Хәлимәләр, Саматлар аларга кушыла. Ул вакытта үзләрен газиз ватаннары түгел, Сталин төрмәләре көтүен күз алдына да китерә алмыйлар... Алман гаскәрләре чигенә барган саен, җитәкчеләренең сәясәте дә тәгаен ачыклана. Аларга үз башлары гына кадерле, татар әсирләренә булган хөрмәт – вакытлы гына күренеш, сугыш алманнарның җиңүе белән тәмамланса, татарларның язмышы төгәл билгеле түгел. Аларның да алманнарга кол булуы бик ихтимал. Шәмсирнең Янгуразга әйткән сүзләрендә үз дәүләте булмаган милләтләргә кайда да бер кояш икәнлеген аңлау сизелә. «Өметләребез акланмады сыман, туганкай. Бердән, без итәгенә ябышырга тырышкан җан да Иблис бугай. Икенчедән, безнең өчен аеруча күңелсезе – бу Иблис беренче Иблистән көчсезрәккә охшый», – ди ул. Шулай да татар милләте күтәреләчәк әле. Моның өчен Янгуразлар бар. Ул икенче бер иблискә ришвәт бирә башлаган икән, әлбәттә, тагын бер иблис идарә иткән илгә кире кайтмаячак. Димәк, аңа лагерьны какшату көрәшен дәвам итәргә язмыш үзе куша. Рухны изеп тора торган бер генә көч тә мәңгелек түгел. Вакыт укмашканны тарката, сибелгәнне җыя, тарих сәхнәсенә яңа күренешләрне, яңа каһарманнарны күтәрә. Т.Әйдинең «Иблискә ришвәт»

романы Бөек Ватан сугышына милли күзлектән бәя бирү, шул чордагы татар әсирләре тормышын тасвирлау ягыннан үзенчәлекле вә кыйммәтле.



*Тәүфикъ Әйди улы Айнур белән этнографик экспедициядә. Молдавия, 1985 ел.*

«Бозра» кыйссасында авторның милициядә эшләү чоры чагылыш тапкан дигән идек. Ул – «Тасманур» заводыннан бер тонна көмеш урлаучыларны эзләп тотуны үзәгенә алган детектив әсәр. Игътибарын тулысынча диярлек шушы җинаятьне тикшерүгә юнәлтеп, автор бу эшнең шактый катлаулы төс алуын, аңа тотынган геройлардан бик күп эзләнү, уйлану, криминалистик осталык соравын күрсәтә. Әйтергә кирәк, әсәрдә җинаятьләрне ачу эшенә романтик караш белән полемикага керү сизелә. «Кайберәүләр уйлаганча, җинаятьчене тотар өчен ах-ух килеп, машинадан машинага утырып куа бару, җәрәхәтләнгәнче көрәшү генә җитми. Андый маҗаралар бөтенләй булмаска да мөмкин», – диелә анда. Шушындый фикердән чыгып, автор ялтыравык маҗаралылыктан качарга тырыша, җинаятьне ачуның прозаик ягына күбрәк игътибар итә кебек. Караклар төркеме белән каршылыкка кергән өлкән тикшерүче Айбулат Байчурин үзе дә аздан гына аларның корбаны булмый кала. Нәҗибә Габдуллина, Җәмил Гайнуллинны һәм Айбулат Байчуринны берләштергән ясалма мәхәббәт өчпочмагы төенләнештән чишелешкә кадәр озата килә. Нәҗибәнең асылда Җәмилләр белән бер караклар төркеменнән булуы һәм тикшерү эшләрен ялган эзгә төшерү өчен үзенә күптәннән гашыйк Айбулат белән мәхәббәт уенын башкаруы әсәрне маҗаралы итә.

Күп жанрларда иҗат иткән әдип кайбер әсәрләрен тәмамларга өлгермәде. Аның яртылаш язылган хезмәтләренең берсе – моңарчы беркайда да басылмаган «Ак җилкән» әсәре. Анда 20-30-50нче елларда системалы рәвештә юк ителгән милли интеллигенция һәм алардан соң килгән «югалган буын» язмышы, һәм дә «курпы» булып калыккан яшь милли хәрәкәт хәлләре тасвирлана. Т.Әйдинең бу әсәре дә, һичшиксез, татар әдәбиятын яңа тема белән баеткан булыр иде...

## II

Роман-бәяннарының, уңышлы хикәяләренең заманча яңгырашын таныган хәлдә, Т.Әйди талантының документаль проза, сәяхәтнамә, очерк, мәкалә, юлъязма кебек «кече» жанрларда тирәнрәк ачылуын әйтергә кирәк. Җир шарының төрле төбәкләренә таралып, берәүгә дә таянмыйча, теләнмичә, хәер сорашмыйча, үз көнен хәләл көче белән үзе күргән татар балаларының язмышы һәрдаим Т.Әйдинең игътибар үзәгендә. Аның күпсанлы чыгышларын, фронттагы шикелле, төрле шартларда язылган мәкаләләрен гаҗәеп бай тарихлы, мәгәр дәүләтчелегенең кадерен белеп, саклап кала алмаган татар халкының, теленең язмышы, киләчәге турында борчылуын бер үзәккә – Милли идея тирәсенә туплый. Татар халкын ул бер чыгышында да төрки дөньядан аерып карамый.

Т.Әйдинең бу юнәлештәге эзләнүләре беренче мәлдә аңлау һәм яклау тапмавы аны сайлаган юлыннан тайпылдыра алмый. Совет чорында тугандаш төрки халыклар, төрле кыйтгаларда яшәүче татарлар, аларның гореф-гадәтләрен, телләрен, матбугатларын кысу турында язу тыелган булса да, Т.Әйди якты көннәренең киләчәген алдан сиземләп, кан кардәшләренең тормышын өйрәнүен, кәгазьгә теркәвен дәвам итә һәм, форсат туугa, аларны бастырып та чыгара. Әдипнең бай мирасын өйрәнгәндә, шул хәтлесе дә ачыклана: аның иң яратып, күңелен, җанын биреп эшләгән жанры – сәяхәтнамә.

Татар язма традициясендә сәяхәтнамәнең тарихы ерак гасырларга барып тоташса да, әдәбиятның документаль һәм шәхси башлангычлары бердәмлегендә туган бу төре XIX, XX гасыр башында гына тулы мөстәкыйльлек ала, җанлана, үсеш кичерә. Шиһабетдин Мәрҗани («Рихләте Мәрҗани»), Заһир Бигиев («Мавәраэннәһердә сәяхәт»), Фатих Кәрими

(«Аурупа сәяхәтнамәсе», «Кырым(г)а сәяхәт» һәм «Истанбул мәктүбләре»), Садри Максуди («Англиягә сәяхәт») һ.б. юлъязма-сәяхәтнамәләре ярдәмендә татар җәмәгатьчелеген яңа җирләр, яңа мәдәниятләр, төрле шәхесләр белән таныштыра. Совет елларында әлеге жанрның үсешенә М.Мәхмүтов, Р.Фәйзуллин, М.Госманов, Х.Бәдретдинов һ.б. җитди өлеш кертсәләр дә, үткән йөзнең соңгы чирегендә Т.Әйди белән Мөхәммәт Мәһдиев яңа сулыш өрде. Фикерләү киңлеге, һәр шәйне милли ихтыяҗ таләпләренә буйсындыру әдәби осталыкны, жанр кысаларын баетуны, төрләндерүне таләп итте.

Чит илләргә чыгып йөрү мөмкинлеге ачылганчы, Т.Әйди Россиянең татарлар күпләп яши торган төбәкләре белән кызыксына, төрле оешмалардан командировкалар алып, күп очракта үз исәбенә, Идел-Урал регионын айкап чыга, «үзгәртеп кору» сәясәте игълан ителеп, тоталитар режим какшый башлагач, чит җирләрдә яшәүче татарлар тормышы белән танышу мөмкинлеге туа. Әдип Германия, Кипр, Болгария, Румыния, Төркия, Эстония, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан һ.б. төбәкләрдә урнашкан татар диаспорасы тормышы белән якыннан танышып, һәр сәяхәтеннән үзенчәлекле язмышлы, талантлы шәхесләрне барлап, гомумән, милләттәшләребезне тәэсирләнеп, яратып, еш кына хискә бирелеп сурәтли. Җөмләдән, «Исәнме, Гагаузстан» язмасы күпләр өчен бер ачыш булды. Ул вакытта әле, СССРның кайсыдыр бер почмагында, рус, молдаван арасында кысылып яшәү сәбәпле, христиан динен кабул иткән төрки-татар кавеме барлыгын ишетеп кенә белә идек. Бу халыкның Молдова вилаятендә көн күреп, татар теленә якын үз шивәләрен саклап, аз санлы булсалар да, үз мәнфәгатьләрен яклый белүче, ифрат горур милләт икәнлеген, Казан татарларына тартылуларын Т.Әйди аңлатып, ачып бирде. Язучы гагаузларның азатлык өчен көрәшенә теләктәшлек белдерүен дә яшерми.

Сәяхәтнамәче үз «канаты», ярлыкавы астына алган янә бер халык – эстоннар. Шулай ук аз санлы халыкның үзен мөстәкыйль милләт итеп саклап калу өчен җан атып, көрәшеп, матбугат, мәгариф мәсьәләләрен хәл итеп яшәвен күпләр, шул исәптән башка милләт арасында югалып калу куркынычы янаган татар халкы өчен дә үрнәк итеп китерә «Кечкенә дә төш кенә» сәяхәтнамәсендә.

Җир йөзендә бер миллионлап кына саналган горур халык үз мәгариф системасын, югары уку йортларында бар фәннәрне үз туган телләрендә укытуны саклап кала алган. Үз лөгатьләрендә чыга торган журналларының абруен югалтмас өчен, һәр зыялы һәм хәлле эстон кимендә бишәр данәгә язылырга тиеш була. Бу халыкның мөстәкыйльлеген югалтмау сәбәпләрен дә аңлатып бирә әдип. Балтыйк диңгезе буенда яшәүче мәмләкәтләр, шул исәптән эстоннар, дәүләтчелекләрен, безнең белән чагыштырганда, озаграк саклый алды, шуңа да бәйсезлек рухы күңелләренә ныграк кереп калган. Аннан соң, алар империя үзәгендә яшәми, күршеләре дә демократик илләр, һәркайчан Аурупадан ярдәм сорый алалар. Кыскасы, дип нәтиҗә ясый Т.Әйди, безгә ул халыктан күп нәрсәгә, беренче чиратта, үзебезне милләт буларак саклый алуга өйрәнерлек үзенчәлек-сыйфатлар шактый, ди автор.

Бер сәяхәтнамәсендә дә ул гади күзәтүче, күргәнне кәгазьгә теркәүче дәрәҗәсендә калмый. Т.Әйди – аналитик фикерле, һәрнәрсәнең нигезенә, төбенә төшәргә омтылучан шәхес. Алман иленә сәяхәте нәтиҗәсендә язылган «Йөртә безне язмышлар» сәяхәтнамәсендә ул, Беренче һәм Икенче Бөтендөнья сугышы нәтиҗәсендә, шунда төпләнеп калган татарлар язмышын үзәккә ала. Әсирлеккә төшкәннәрнең берише, Сталин репрессиясеннән куркып, туган илләренә кайтмасалар, арада совет хөкүмәтенең сәясәтен кабул итмәгәннәре дә була. «Азатлык» радиосында эшләүчеләр халыкка дөрес мәгълүматлар бирү рухы белән яшәп, туган илләрен сагынып көн күрә. Биредә аның сәяхәтнамәләре белән чәчмә әсәрләре арасындагы тематик, фәлсәфи-этик якынлыкны ассызыкларга кирәктер. Аерым алганда, «Йөртә безне язмышлар» үзенең дәвамын «Иблискә ришвәт» романында таба.

Болгариядә, Румыниядә, Польшада күптәннән тирән тамырлар җибәреп, үзләренең татарлыкларын, диннәрен сакларга тырышып, матур гына тормыш корган гаиләләр, араларыннан үсеп чыккан күренекле шәхесләр турында әдип «Дунай буендагы кардәшләр» сәяхәтнамәсендә сокланып та, шул ук вакытта ачынып та яза. Болгариядә төрки халыкларның җәберләнүе, Румыниядә Дабруҗа төбәгендә көн күргән төрек-татар кешеләренең эзәрлекләнүе, гаепләнүе, телләренең, диннәренең кысылуы, Молдовадагы гагаузларның изелүе, үз ирекләре өчен көрәшкә күтәрелүе безнең татар халкы өчен дә

бик таныш вакыйгалар түгелме? Т.Әйди әнә шул халыклар тормышыннан мисаллар китереп, суверенлык дәрте белән яна башлаган милләттәшләрен, әйтерсең, булачак авырлыкларга алдан ук әзерләгән.

Кипрның төрекләр яшәгән һәм идарә иткән өлешенә багышланган «Оҗмах утравы»н искә төшерик. Әйди каләме тудырган манзара үзенең гади матурлыгы белән таң калдыра, сокландыра. Төрледән-төрле чәчәкләргә күмелеп, җылы диңгез уртасындагы утрауда эссе җәйнең, зәмһәрир суыкларның нәрсә икәнен дә белмәгән бәхетле халык яши. Ошбу сәяхәтнамәсендә язучының төрки дөньяның яшәешенә, булмышына караган концепциясе тулы көчкә ачыла. Аның уенча, төрки кавемнәрне язмыш бер-берсеннән берникадәр аерса да, алар вакытлыча, төрле якларга таралышсалар да, бер ана балалары кебек, киләчәктә якынаерга, берләшергә тиешләр. Т.Әйди иҗатында «Оҗмах утравы» искәрмә түгел, ул барлык сәяхәтнамәләрендә, юлъязмаларында диярлек төркиләрне, аеруча төрле кыйтгаларга сибелгән татарларны үзенә сыйдырган, хыялында яшәгән бәхетле илне тасвирлый.

Әлбәттә, язучы чит илләрдә көн күрүче милләттәшләребез язмышын, көнкүрешен сурәтләү белән мавыгып китеп, Россиядә яшәүчеләр турында да онытмый. Чит ил татарларының ярдәменә өмет итеп, үз хокукларыбыз өчен көрәшүдән тукталмыйк, дигән фикерне уздыра Т.Әйди «Идел тамагында» язмасында. Ошбу сәяхәтнамәдә сүз олы елгабыз Иделнең диңгезгә койган җирендә, Әстерхан каласында, өлкәсендә көн итүче милләттәшләребез язмышы турында бара, язучыны әлеге төбәктә яшәүчеләрнең туган телләрен, татарлыкларын югалта барулары борчый. Автор заманында бу якларда мөстәкыйль ханлык, Әстерхан каласының инкыйлабка хәтле мәдәни үзәкләрнең берсе булуын искә төшерү аша, шул тарафларда яшәүчеләрнең милли хисләрен уяту рухы белән юлга чыга.

Без, аның мирасын өйрәнүчеләр, Тәүфикъ Әйди феноменының асыл нигезләрен аңларга омтылабыз. Бер яктан, ул – шул ук совет чорында тәрбия алган шәхес – марксизм тәгълиматы өстенлек иткән мәктәптә, техникумда, югары уку йортында белем-сабак алган. Шул кысаларда калып, ата-анасы, табигать, Ходай Тәгалә биргән үткен каләмле, очлы күзле прозаик, өстән кушылган сәясәтне уздыручы журналист булып калса да, аның исеме югалмас иде. Теләсә кайсыбыз, күпме генә шәхси мөстәкыйльлегебез турында сафсата сатсак та, социалистик реализм богауларыннан котылу җиңел түгел иде. 60нчы елларның Хрущёв җепшеклеге тудырган мөмкинлекләр, хәтта «Метрополь» алга сөргән хыяллар да Т.Әйдигә тар, чикле күренде. Чөнки ярым-йорты демократия җилләре битләрне кытыкласа да, әле тимер киртәләр алынмаган иде. 80нче еллар ахырында, бигрәк тә 90нчы елларда аның хыялында Җир шарында яшәүче барлык татар, хәтта төрки халыкларны «берләштергән» Милли идея туа, һәм аны тормышка ашыруга омтылу аның яшәү мәгънәсенә әверелә. Шул хыялы әдипне төбәктән төбәккә, илдән илгә, кыйтгадан кыйтгага йөртә. Аңа бу бурычны бәрәү дә йөкләмәгән, кушмаган, ул – Т.Әйдинең вөҗдан, намус эше. Шул ук вакытта әдип, язмаларыннан күренгәнчә, хыялый кеше. Халыкның якты киләчәгенә ышанычы аның яшәешенә дәрт, дәрман, өстәмә көч, каләменә илһам канатлары куя. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Тәүфикъ Әйди – хыял күге гөмбәзендә патшалык итеп, барлык татарларны барлаучы, үсендерүче булып, өмет һәм көрәш тарихыбызга кереп калган олы шәхес. Күренекле язучы Аяз Гыйләҗев аны «татарның асыл улларының берсе», дип атаса, Нурихан Фәттах «милләт һәм тарих алдында йөзе ак, вөҗданы пакь язучы, журналист һәм көрәшче», дип бәяләсә, Барлас Камалов «татарларны барлап йөрүче» булуын ассызыкласа, Мәхмүт Әхмәтҗанов, аның вафатыннан соң, «халкым сине онытмас, Тәүфикъ туган», дигән нәтиҗә ясый. Әйткән сүзебез кәгазьдә калса, мәгънәсе ахирәткә дога булып барсын!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ЯСАЛМА ТРАГЕДИЯ

Шофёрлар галәмендә машина тәгәрмәчен алыштыру – гадәти шөгыль. Ул әледән-әле кабатланып тора, аның үз тәртибе, кагыйдәсе бар, моңа инде агай-эне күнегеп, ияләшеп беткән. Эш шулай үз җае белән бара бирә. Хәбир Ибраһимның «Фазыл» *(«Мәдәни җомга», 2016, 29 гыйнвар)* хикәясендә дә сүз автобус көпчәген алыштыру турында бара, ләкин бу очракта бер тоткарлык килеп чыга. Әсәрдә сурәтләнгәнчә, тәгәрмәчнең бер гайкасы борылмый икән. Аны борып чыгару автосервис өчен хәл ителмәслек проблема түгел, әлбәттә. Ачкычка, әйтик, тимер торба кидереп, сабын озайтсаң, әллә нинди тыгыз борылган гайка да «ә» дигәнче күндәм генә кузгалып куяр иде. Ләкин автор персонажларны уйлап эш итүчән, зирәк итеп сурәтләми. Аңа, төп шөгыльне туктатып, башка якка борып җибәрергә, катлауландырырга кирәк. Автобус шофёры эретеп ябыштыручы Фазылга болтны автоген белән кисәргә куша. Көпчәк алыштырганда, болтлар гадәттә кузгатылмый. Бик хәтәр, дуамал киңәш бу. Тискәре нәтиҗәсе алдан ук күренеп тора. Ул төп эшне башкаруга ярдәм итми, аңа комачаулый гына. Кискәч, запас тәгәрмәчне куеп булмаячак. Төзек инвентарьны бозуга берәү дә рөхсәт итмәячәк. Ут-ялкын күреп, пожарниклар ашыгып килеп җитәчәк. Ләкин Фазыл боларның берсе белән дә исәпләшми, киңәш-табыш итми, гадәти эшкә тотынган кебек, ил-көндә күрелмәгән хәвефле чарага керешә: «Шактый озак маташты ул шул каһәр суккан болт белән». Бу очракта автосервис эшчеләренең сизгерлек-уяулыгын, кагыйдәне төгәл үтәүләрен тасвирлау, күрәсең, автор тарафыннан каралмаган.

Ут белән эш итүнең нәтиҗәсе баштагы фаразга караганда да аянычрак төс ала. Әсәрдән күренгәнчә, кызган тәгәрмәч кыршавы, атылып чыгып, Фазылның маңгаен яра, аны дөм сукыр итеп калдыра. Көпчәк тә алышынмый, ут-ялкыннан, билгеле, бөтенесен көтәргә була. Тик аның әсәргә килеп керүе генә нигезле түгел. Гайканы кузгату әмәлен ташлап, тузга язмаган хәвефле шөгыльгә күчү укучыны ышандырмый. Ул сюжетка мәҗбүрият, ихтыяҗ буенча кушылмады, ясалма рәвештә барлыкка килде. Тәгәрмәч алыштырам дип берәү дә автогенга барып тотынмый. Персонажлар үзләренә афәт чакыралар.

Күңелгә тагын да ныграк йогынты ясау нияте белән булса кирәк, хикәядә бер-бер артлы аңлаешсыз михнәт, кыенлык күренешләре тезелеп килә. Иң әүвәл утыз градус салкында, ачы җил ажгырып торганда, сукыр бәндәнең җылы өеннән чыгып китүе гаҗәпкә калдыра. Андый чакта сау-сәламәт кешеләр дә өйләрендә утыруны мәслихәтрәк күрәләр. Автор Фазылның хәләтен эч пошу, ялгызлыктан тую белән аңлата. Ләкин ялан кырда адашып калу перспективасы эч пошуны баса ала микән соң! «Аягына яңгырлы, былчырак көннәрдә кия торган салкын эчле күн итек кия. Җитмәсә (ашыгудан, күрәсең! – Ф.Х.) муенына шарф чорнарга да оныткан«. Әмма нинди гамәлгә өлгерергә тырышуы ачыкланмый. Ашыгыч эше күренми. Әсәрдә аның кая баруы, нинди максат белән кузгалуы турында бер сүз дә әйтелми. Тик «авыл башын узып, кырга чыктым, ахры, дөрес бармыйм» дип уйланулары гына билгеле. Ә дөресе кай тарафта? Җитмәсә «юка бияләйләр каядыр очкан», ди автор. Фазыл үзе салмаса, алар беркая да оча алмый, салкында алюмин таягын ялан кул белән тотуның нәрсә икәнен ул бар кешедән дә яхшырак белә бит. Хикәядә аның «тынгысыз» бияләйләрен очырту турында түгел, аларны тырышып саклавы, әйтик, бауга тагуы хакында язу урынлырак булыр иде кебек. Нишләп салган ул аларны? Бу турыда укучы хәбәрдар түгел.

Фазыл кырда барган җиреннән, һәлакәткә таба юнәлгәндәй, инеш буена, буа янына килеп чыга. Буа рәшәткәләр белән әйләндереп алынган. Ул шул рәшәткәләргә тотына. Үзе ул рәшәткәнең эчке ягында булса кирәк. Тышкы ягына чыгарга тырышуы сизелми. Автор раславынча, инештән агып төшкән су утыз градус салкында да туңмый икән. Фазыл, таеп, шул суга килеп төшә. Әллә соң буа шушы бахырны кабул итәр өчен туңмады микән, дигән сәер сорау тугандай була. Бүтән аңлатма бирелми.

**Фәрит ХАТИПОВ,**
*филология фәннәре докторы*

# ОЛУГ МАКСАТКА МӘГАРИФ АША КИЛИК

*«Татар – нинди кодрәтле сүз!*

*Телләр хасиятендәге һәр сүзнең сулышы, кан әйләнеше, җан тибрәнеше бар...*

*Татар – бөркет сүз. Җиле – җиһанда, эзе – җирдә...*

*Татар ... Бу исемдә – йодрыкланган яшен йомгагы.*

*Ана сөте белән кергән ихтыяр көче, үлмәс горурлык, аянычлы хәтер, гарасатлы заманнар кайтавазы сыйган аңа»*. Боларны шигъри телле, татарның кемлеген белгән генә түгел, аның тирәнгә, тормыш мәшәкатьләренә күмелеп калган җанын тойган, шул тоюны тәэсирле һәм мавыктыргыч стиль аркылы укучыга җиткерә алу сәләтенә ия Марсель Галиев «Рух» китабында *(Казан: Татар.кит.нәшр., 2005)* яза. Гадәттәгечә, матур яза, дөрес яза. Татар турында образлы итеп, тарихны гомум иңләп яза. Әйе, шундый булган безнең халык. Дәүләтчелеге булганда. Әмма *«бу җиңүчән халыкның гаҗәеп батырлыкларын данга күмәргә тарихчылары булмаган. Күпме үлемсез казанышлары онытылырга дучар ителгән. Татарлар тарафыннан без белмәгән күпме мәмләкәтләргә нигез салынган! Бу гаярь халык, беркайчан да җиңелмәсенә ышанган хәлдә, вакытлы дан белән мавыгып, үзенең үткәндәге җиңүләрен мәңгеләштерү турында уйлап та карамаган»*. М.Галиев француз философы Шарль Лум Монтескьёның бу сүзләрен шул ук китабында китерә. Ярар, тарихта, димәк, шанлы вә данлы булганбыз. Ә хәзер? Хәзер бездә «татар» исеменнән тыш нәрсә калган? Калган. Тел калган, шул үткәннәрне юксыну авазы булып моң калган һәм үзенчәлекле яшәеш калган.

*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкаддәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!*

– диюе белән, ягъни, территориаль бүленешне аңлаткан ил чикләре җимерелсә дә, дөньяга мөнәсәбәт, үзара бәйләнеш, үзенчәлекле яшәеш калыр диюе белән Дәрдемәнд мең кат хаклы! Әйе, бары татар гына атна ахырында авылга ял итәргә дип түгел, эшләргә дип кайта. Бары без генә май бәйрәмнәрен өй юарга дип көтәбез; бары безнең авылларда гына бәрәңге бакчасын «аны ничек буш калдырасың инде», дия-дия утыртып бетерәләр...

Яшәеш дигәндә, мин санап үтелгәннәрне генә күздә тотмыйм. Менталитет, милли холык-фигыльне тасвирлап бетерү мөмкин дә түгелдер. Әдипләребез һәрберсе аның бер ягын алып тасвирлаган, үзенчәлеген ачкан. Әдәбият, мөгаен, шул сыйфатларны туплаган банктыр. Шул вакытта гына ул чын мәгънәсендәге әдәбият була аладыр. Мәсәлән, Г.Ибраһимов «Яшь йөрәкләр» әсәрендә татар никрутларын (солдатка алынучыларны) менә ничек сурәтли – бу да безнең яшәешнең, безнең халыкның элеккеге данлы үткәненең бер чагылышы: *«Монда кем генә юк! Иң әүвәл күзгә чалына татар никрутлары. Арада төрле кием, төрле кыяфәт булса да, болар күвәзлектә [көязлектә] һәммәсе уртак иде. Булардан һичбере гади киемдә түгел. Бар да ясанган, чибәрләнергә тырышкан. Арада бигрәк купшылары да бар: бүгенге һаваның зәһәр суыгына карамыйча, бу купшы егетләр, эш өчен тегелгән, җылы, ләкин прастуй туннарын, тула чикмәннәрен ташлап, өстләренә бишбилле җылтыр кара бишмәт киеп, никрутлык хөрмәте өчен генә алынган кырык тиенлек бәйләм бүрекне маңгайга кырын салганнар. Такыр баш өчен, колак ут кебек яна, ләкин аңа илтифат итми, чөнки күвәз. Җылтыр*

*кара бишмәтнең бер кесәсеннән кызыл өстенә ак дебет белән эшләнгән, икенчесеннән көрзәк өстенә сары белән чигелгән ике кулъяулыкның салынып торуы егеткә тагын бер аерым күвәзлек бирә... Муенда ак шарф. Аның бер очын алга, икенчесен артка салса, менә сезгә тирә-якны шаккатырырлык купшы егет, ыспай никрут!»* Бу – татарлар. Дәүләт киткән, ләкин кан, кан һәм Дәрдемәнд әйткән сөт калган бит! Бөтен халыкларны дер селкетеп торган заманнар геннар хәтерендә, «мин булдырам!» дип яшәгән чаклар һаман канда уйный, шул, Г.Ибраһимов язганча, «күвәзлеккә», ягъни көязлеккә этәрә. Ләкин мондый мин-минлек, әгәр ул эшләр, гамәлләр белән тәэмин ителмәгән булса, тыштан ялтырау, әтәчлек кенә булыр иде. Нәрсәгә таянып шулай купшылана, нәрсә аркылы үзенең тирә-юньдәге халыклардан, заманча итеп әйтсәк, текәрәк икәнен белә татар? Беренче чиратта, белемле һәм гыйлемле булуы, әйләнә-тирәдә үзе белән көн итүче шундый ук халыклардан укый-яза белүе белән аерылып торуына нигезләнә. Әйе, әйе, ул чорлар өчен һәм бүгенге көн өчен дә хәреф тану, сәвәтле (грамотный) булу бик зур күрсәткеч. Теләсә кем моны булдыра алмый, ә татарлар булдыра. Шуңа күрә Карл Фукс татарлар турында: «...этот, уже более двух веков покорённый, и ныне развеянный между русскими, народ, так удивительно умел сохранить свои обычаи, свои нравы и народную гордость, точно как бы они жили отдельно...» – дип яза «Казанские татары» *(Казан, 1991)* хезмәтендә.

Г.Ибраһимов та татар яшәешенең үзенчәлеген көязлектә генә күрми, халкыбызда киң таралыш алган белем-мәгърифәткә зур игътибар бирә.

Әдипнең 1914 елда язып тәмамланган, яңадан совет чоры таләпләренә яраклаштырылып, үзгәртелеп, 1934 елда дөнья күргән «Безнең көннәр» романы бар. Бу гади роман гына түгел, бу – XX йөз башы татар иҗтимагый тормышының энциклопедиясе. Монда төрле сыйныф яшәеше, төрле катлам вәкилләренең сәяси карашлары, революциягә мөнәсәбәте, төрле партияләрнең эшчәнлеге – кыскасы, иҗтимагый яшәешне тәэмин итүче һәр күренеш чагылыш тапкан. Романда шулай ук мәктәп-мәдрәсә, шәкерт күтәрелешләре, аларның эшчәнлеге яхшы күрсәтелә. Беренче эш итеп, татар тормышында, татар яшәешендә генә очрарга мөмкин булган, гыйлемне милләт казанышы буларак бәяләгән һәм гомерен шуңа багышлаган типларны, образларны күздән кичерик. Шундыйларның берсе – Нигъмәт казый.

Шуны искәртик: XX йөз башы татар зыялылары арасында, хәер, татар гына түгел, руслар арасында да, социалист яки революционер булып уйнау үзенә күрә бер мода саналган. Кыскасы, хөкүмәтне, самодержавиене тәнкыйтьләү, аңа каршы көрәшүче булып күренү егетлекнең бер сыйфаты исәпләнгән. Әлеге кызыклы фактка, сәер психологиягә тарихчылар да игътибар итә. Мәсәлән, Вадим Кожинов «Правда сталинских репрессий» *(Мәскәү, 2008)* китабында болай дип язган: *«...напомню, что В.В.Розанов в 1912 году писал: «У француза – «наш старый Фриц». Только у прошедшего русскую гимназию и университет – «проклятая Россия». Как же удивляться, что всякий русский с 16 лет пристанет к партии «ниспровержения» государственного строя»*.

Нигъмәт казый да – үз чорының баласы. Ул «озын буйлы, таза гәүдәле, киң җилкәле...

*Бу – элек иске, кадим мәдрәсәдә хәтле кятеб кылып [укуны тәмамлап], ничә еллар усал казый булып торган шәкерт. Шул заманнан аңа «казый» сүзе кушамат булып калган. Мәдрәсәнең югары сыйныф шәкертләре, башка һәркайдагы кебек, монда да хәлфә – хәзрәт, байлар яклы булалар. Ләкин Нигъмәт казый аерым юл алды, сыйныфташларыннан аерылып, шәкерт хәрәкәте эченә кушылды. Шуның өчен аңардан: «Ат азгыны тайга ияр!» – дип көләләр. Ләкин ул моңа карамый, сыйныфташлары эчендә дошманлыкка каршы, урталар, түбәннәр арасында җитәкче, көрәшче, ышанычлы иптәш булып санала».*

Күргәнебезчә, ул да үзенә күрә бунтарь. Ләкин шунысын да искәртик: бик сирәкләр генә профессиональ революционер булып киткәннәр. Еллар үткән, еллар белән яшьлек, яшьлек белән мавыгулар да үткән... Олыгайган саен кичәге «социалистлар» җитдиләнгән, уйлар, омтылышлар да күптән җиргә төшкән. Ләкин татарлардагы татар гаме бетмәгән. Кичә генә «Ат азгыны тайга ияр» дип тамгаланган, шәкерт чуалышларында иң актив катнашучы Нигъмәт казый да роман ахырына таба үзгәрә. Ул русча укыган, учительлеккә имтихан тоткан, атасы үлгәч, авылга кайткан: *«...кайта да эшкә тотына. Учитель дә була, кооператор да була... Аз гына вакыт эчендә «Ярдәм» җәмгыяте», «Укучыларга ярдәм җәмгыяте», «Җәмгыяте хәйрия» ирләр мәктәбе, кызлар*

*мәктәбе ачып бетергән, кайберләрен ачарга хәзерлекләр күргән. Боларны сөйли дә үзе мәҗлес тутырып шаркылдап көлә:*

*– Мин шулай, җәмгыять ачам да үзем рәис булам. Хәзер бөтен өязне җәдит мәктәпләр белән тутырып барам. Тик менә земство бик кара, хөкүмәттән бер тиен дә ярдәм ала алмыйбыз. Һәммә мәктәпләр тик халык җилкәсендә генә бара...»*

Юк, бунтарьлыгын туктатмаган Нигъмәт казый, ләкин омтылышларын закон һәм әхлак кысаларына керткән. Халкын гафләттән – битарафлыктан йолып алу өчен, мәгарифне корал иткән. Татар мәгърифәтчесенең юлы һич кенә дә урыс социалисты юлыннан җиңел түгел.

Әйткәнемчә, романдагы вакыйгалар XX йөз башында, төгәлрәк булсак, 1905 ел алдыннан һәм аннан соңгы берничә елда бара. Монда эсер Давыт Урманов, большевик Гәрәй Солтан, тагын әллә кемнәр бар. Исламия мәдрәсәсе, аның шәкертләре, шәкерт кузгалышлары, ислах сорап күтәрелгән яшьләрнең хәлфәләр һәм мөдәррисләр белән бәрелешләре зур урын алып тора. «Полиция нәрсә өчен?», «Мәдрәсә яшьләре», «Нигъмәт казый», «Кояш чыкты, нур балкыды» кебек бүлекләр тулысынча шәкертләр кузгалышын тасвирлауга багышланган.

Патша хөкүмәтенең татар мәгарифе үсешенә киртәләр коруы хакында күп язалар, шуңа күрә бу мәсьәләгә тукталып тору кирәкмидер. Налогын түләгән, солдатын биреп, шушы ил гражданины саналып яшәсә дә, татар мәктәпләре дәүләттән бер тиен дә ала алмый, алар бары тик шушы юлда армый-талмый хезмәт итүче фидаи җаннар һәм акчаларын кызганмаучы хәлле кешеләр хисабына гына яшәгән. Мондый меценат һәм иганәчеләр ярдәменә көн күрүнең шулай ук катлаулы халәт икәнен әйтергә кирәк, чөнки акчасын биргән бай мәктәп яки мәдрәсәнең аның ихтыярынча яшәргә тиешлеген таләп итәргә хокуклы булуын белә һәм, әлбәттә, төрле холыктагы кеше бар. Акча беркемгә дә күктән яумый, сәүдәләр дә һәрвакытта гөрләми, шуңа күрә былтыр юмартланып шактый гына акча тамызган татар бае быел әллә нинди сәбәпләр табарга, матди ярдәм күрсәтүдән баш тартырга мөмкин. Әмма бит уку процессын туктатып, эшне ярты юлда калдырып, балаларны урамга чыгарып җибәреп булмый.

Шуңа күрә мөдәррисләрнең – уку йорты җитәкчеләренең – хәле көнләшерлек түгел, алар ике, хәтта өч ут арасында. Бер яктан – самодержавие, икенче яктан – меценатларга бәйлелек, өченче яктан – ислах, ягъни реформалар таләп итүче яшьләр, шәкертләр. Яшьләр исә максималист, аларның кан кайнар, алар хәзер үк, бүген үк үзгәреш таләп итәләр: *«Сөләйман Сәйфуллиннан соң берничә шәкерт аякка баса. Болар да мәдрәсәне, хәзрәтне, байны сүгәләр. Хәлфәләрен канэчкеч, залимнәр, мөстәбидләр дип, ялган әче сүзләр белән сыйфатлыйлар да:*

*– Без изелдек, безне изделәр, инде уаныргa вакыт. «Алма пеш, авызыма төш», дип яту ярамый. Татар шәкерте, күтәрел, ислах флагы белән көрәшкә чык, издермә үзеңне!» – дип, сүзләрен бетерәләр».*

Әмма шунысын искәртик: шәкертләр үзләрен изелгән санасалар да, чын изелгән кеше мондый күтәрелешкә сәләтле була алмый. «Рабы немы!» – ягъни коллар телсез була, алар эндәшми, ләкин татар шәкерте хакында, әсәрдән күренгәнчә, һич кенә дә алай дип әйтеп булмый. Болар – заман таләпләрен аңларлык дәрәҗәдә дөньяви фәннәр укыган, демократик рухта тәрбияләнгән кешеләр. Бары шундый яшьләр генә реформа кирәклеген аңлый, җәмгыять каршында үзләренең җаваплылыгын таный. Юк, изү булмаган, чын изү булган җирдә, әйтик, бүгенге Төньяк Кореяда, мондый күтәрелешне күз алдына да китерү мөмкин түгел.

Ә кемнәр тәрбияләгән соң алдынгы карашлы яшьләребезне? Һәр шәхеснең теләгән белдерү мөмкинлеге булган демократик рухтагы уку йортларын кемнәр оештырган?

Менә Г.Ибраһимов кайнар башлы яшьләр тарафыннан «Ач калудан куркасыңмы?» дигән сүзләр белән хаксызга рәнҗетелгән Исламия мәдрәсәсе мөдәррисе Гали хәзрәтне ничек тасвирлый: *«Ул үзен егерме ел гомерен төрле-төрле мәдрәсәләрдә гыйлем алу юлына биргән кеше дип карый. Русиядә Казан, Кышкар бетерде. Аннан татар сәүдә кәрваны белән Бохарага барып, җиде ел хөҗрәдә ятты. Аңа канәгатьләнмичә, Мәккә, Мәдинәгә, аннан Истанбул, Мисырга барды»*. Бу урында мин, чигенеш ясап, «татар!» димичә булдыра алмыйм. Кайсы халык укыйм дип шулхәтле тырышлык куя?! Гадәттә, гыйлемгә омтылышның классик үрнәге итеп Ломоносовны күрсәтәләр, имеш, ул җәяүләп

башкалага барып җиткән, имеш, бер кереме булмаган килеш, үз көче белән укыган. Соң, җәмәгать, теләсә кайсы татар шәкерте үткән юл бит ул! Ломоносов үз дәүләтендә әле ул, аннан соң, белүемчә, әтисе дә гади балыкчы түгел, сату-алуны оештыручы, бүгенгечә әйтсәк, менеджер булган. Ломоносов чыккан төньяк өлкәләр белән дә җайга салынган сәүдә юллары була, башкалага даими рәвештә диңгез продуктлары ташып торалар. Ә Сәмәрканд, Бохара арасында үз тәвәккәллекләренә таянган кәрваннар гына йөргән, Истанбул, Мәдинә исә – бөтенләй чит мәмләкәтләр. Андагы татар шәкерте – чит ил гражданины, менә ул инде баласын бары тик үз көченә таянып кайгырта алган. Үз илендә, үз телендә, үз кешесе булып белем алган Ломоносовтан аерма зур шул безнең татар егетенең!

Гали хәзрәт юлы – типик татар укымышлысының гыйлем алу юлы, өзлексез эзләнү, үзеңдә мөмкинлек булмаганга, чит мәмләкәтләргә барып уку юлы. Аңа берәү дә стипендия түләми, өйдән килере дә чамалы, ул эшләп укырга, булган акчасын кысып тотарга мәҗбүр. Шундый михнәтләр белән алган белемен Гали хәзрәт, шәхси мәнфәгатьләрендә файдаланып, берәр мәдрәсәдә тыныч кына укытып яки мулла булып – ә аны иң бай мәхәлләгә бишкуллап кабул иткән булырлар иде, татар халкы гыйлемле кешене югары бәяли – яши алыр иде. Ләкин… XX йөз башы – милли аң үсеп, күтәрелеп, күрелмәгән биеклекләргә ирешкән чор, һәм үзен татар зыялысы санаган һәркем аның алгы сызыгында булуны үзенең бурычы санаган. Гали хәзрәт әнә шундыйлардан: «*Шуннан*, – дип дәвам итә әдип аны сурәтләвен, – *ул үзе иске, кадим мәдрәсәләргә дошман киселде, монда, Руссиягә кайтты, Мисыр, Истанбулның яңа мәдрәсәләре кебек мәдрәсә торгызмак булып эшкә тотынды. Юктан башлады, либерал татар капиталистлары ярдәме белән менә шундый зур биналар салды (яңа мәктәп салуның нинди зур эш икәнен уйлагыз! – Г.Д), хәерчеләнеп акча җыйды, Истанбул, Мисыр күргән яңа тип мөгаллимнәр китертте. Динне, гарәпчәне яңача укытты. Тәфсир, хәдис, гарәбият өстенә риазыят, табигыят, татар теле, рус теле дәресләрен арттырды. Ләкин ничек кенә тырышса да, заманны куып җитә алмады. Ничек кенә яңа програм дисә дә, уянган татар шәкертенең күңелен канәгатьләндерә алырлык бер мәдрәсә ясый белмәде. Ул киң күңелле булырга тырыша, шәкертнең сүзсез бозау булуын яратмый, аларда тәнкыйть көче уянуга карышмый, авыр сүзләрен дә күтәрә иде*».

Бары тик бишектән үк, «шәкерт булып китәр бу!» дип көйләп үстергән, кызларының бирнәсенә китап салган, «…белеме бар – меңне егар», дип яшәгән татар халкында гына була ала мондый педагоглар. Һәм, әйтергә кирәк, Гали хәзрәт ялгыз түгел, Аллага шөкер, тагын бар андыйлар. Ялгышларына абынып, изге максатка баручыларның тагын берсе – Кәрим Гайфи. Кем ул? Ул – укырга омтылышын милләте ярдәмендә тормышка ашырган, Истанбулда, дөньяви мәктәптә белем алган яхшы ук әзерлекле яшь укытучы. *«Әгәр Төркиядә калса, фән дөньясында яхшы урын тотарлык галим булып чыгуында шик ителми иде. Әгәр үзе теләсә, Төркия хөкүмәте тарафыннан Европага укырга җибәрелгән, аннан бетереп кайткач, Төркиядә профессор булып калачак иде».*

Сәләтле татар баласын чит илдә – әмма үзебездә түгел! – бәялиләр, үсәргә мөмкинлекләр булдыралар. Дөрес, үз милләте дә бәяли, чөнки аны Төркиягә, остазы Шәймәрдан мулланың димләве буенча, мәхәллә бае Кәмал хаҗи җибәрә. Мондый күренеш, ягъни мәгарифкә, сәләтле балаларга ярдәм татарлар арасында киң таралыш алган була. Әйтик, Р.Әмирхан мондый мәгълүмат бирә: *«Дөньяви белемне алга сөрү тарафдарлары арасында Әхмәд һәм Гани Хөсәеновлар, Шакир һәм Закир Рәмиевлар, фабрикант Акчуриннар, Үтәмешевлар, Әҗемовлар һ.б. эре кәсепчеләр, сәүдә һәм сәнәгать эшмәкәрләре, алыпсатарлары була. Шушы җирлектә милли меценатлык чәчәк ата. Татар рухи мәдәниятен легендар төстә химая кылучылар арасында шул ук борадәрән Хөсәеновлар, бигрәк тә Әхмәд Хөсәенов (Әхмәд бай) дан казана. Алар мәчетләр төзү, мәктәп һәм мәдрәсәләр ачу эшенә йөзәрләгән сум акча сарыф итәләр, дистәләгән уку йортларын, мөгаллимнәрен үз хисапларына асрыйлар, үз акчаларына иң сәләтле шәкертләрне чит ил югары уку йортларына, стажировкаларга җибәрәләр»* .

Кәрим Гайфи, бәлки, Төркиядә дә калган булыр иде. Калса да гаепләрлек түгел, мондый перспектива кемне кызыктырмас. *(Калып, төрек мәдәниятен яңа исемнәр белән баетучылар да булган. – Г.Д.)*. Ләкин Төркиянең үзендә дә милли күтәрелеш, яңарыш дулкыны мәйданга килгән вакыт, мәмләкәтнең алдынгы карашлы кешеләре

дөньякүләм фикер йөртеп, төрки кавем, төрки кардәшлек хакында уйлана башлаган вакыт, шундыйларның берсе Әхмәд Мидхәт аңа болай дип киңәш бирә: «Син, балам, Русиягә кайт. Русия мөселманнары синең хезмәтеңә тагы да артыграк мохтаҗлар. Кем артык сусаган булса, суны иң элек шуңа бирергә кирәк».

Россия мәгариф министры А.Н.Шварцның 1908 елны дәүләт оборона проектына язган отзывындагы: *«Необходимо неуклонно отстранять всякие притязания инородцев на какую бы то ни было обособленнось и национализациию школы. Руководящим началом должна быть единая русская государственная школа, на всех её ступенях и для всех без исключения инородцев империи»*, – дигән сүзләренә татар мөгаллимнәре булган Гали хәзрәтләр, Кәрим Гайфиләр нәрсә белән җавап бирә алганнар соң? Эш, үз-үзеңне аямау, рәсми карьера, шуңа бәйле рәхәт тормыштан баш тарту хисабына халыкка хезмәт итү белән генә… Бу юлның ләззәте дә, михнәте дә күп. Реалист булыйк: ләззәте – рухи, милләтеңә хезмәт итүдән канәгатьлек алу. Ә михнәтенә килсәк, аны матди дәрәҗәдә тоеп булырлык, сизелерлек: монда ачлы-туклы тормыш та, полиция һәм жандармерия эзәрлекләве дә, максималист яшьләрнең кимсетүләре дә, җәмгыятьнең консерватив өлешенең каһәрләүләре дә. Санап бетерә торган түгел. Бигрәк тә Россиядә, бигрәк тә XX йөз башындагы тотрыксыз иҗтимагый тормышта үзләрен бары тик педагогикага багышлаганнарга кыенга туры килә. Чөнки ике нәрсә – дин һәм мәгариф – иң консерватив өлкәләр, алардагы реформа һәм яңарышлар бик авырлык белән бара, дин һәм мәгарифтәге төшенчәләрне үзгәртү – кешеләрнең аңын, дөньяга мөнәсәбәтен үзгәртү ул.

Укытам, шул эшчәнлегем белән милләткә хезмәт итәм дип кайткан Кәрим ялкынланып эшкә тотына: *«Кәрим Гайфинең ачык, кискен, тулы якты дәресләре һәммә шәкерт өчен, тамактан үтмәслек начар сулар белән җитлеккән чакта, кинәт саф тау елгасына барып чыккандагы кебек әсәр итеп җибәрде. Бер атна эчендә ул шәкертләрнең иң сөекле остазы булып китте».* Ләкин илдә дулкын – революция дулкыны. Революция исә бар нәрсәне җимерү, искеме-яңамы, яхшымы-начармы – бар нәрсәне инкарь итү дигән сүз. Революция авантюристларга, бүгенге көн белән яшәүчеләргә, радикалларга юл ача, ата белән улны, ана белән кызны баррикаданың ике ягына ташлый. Җәмгыятьнең күнегелгән тормыш рәвешен яклаучыларны ул дошман дип игълан итә, андыйларны читкә тибәрә йә бөтенләй юк итә: *«Кузгатылган һәрбер дулкын, күтәрелгән һәрбер көрәш мөгаллим Кәрим Гайфине шәкерт ялкыны белән капма-каршы куя торган булып китте. Ул бөтен көче белән мәдрәсә яшьләре эчендәге бу хәрәкәтне туктатырга, дулкынны басарга, ялкынны сүндерергә теләде. Яңа фәннәр, яңа программалар турында шәкертнең үзенең сугышып йөрүен гаҗәп бер начарлык итеп каршы алды. Ул шәкерт җыелышында да, идарәдә дә ачык куйды:*

*– Шәкертнең вазифасы – укымак, укымак, укымактыр. Шәкерт укысын! Гыйлем алсын. Ә фикер, тәнкыйть аңардан шул алган гыйлемнең мәҗбүри нәтиҗәсе рәвешендә үзе килеп чыгар. Шәкерт укудан, гыйлемнән башканы белмәсен! – диде».*

1905 ел вакыйгалары самодержавиене күпмедер ташламалар ясарга мәҗбүр итсә дә, бу хәл озакка бармый. Тиздән реакция башлана, Дума таратыла, яшь татар матбугатына һөҗүм башлана, ислах сорап гауга куптаручыларның сафларын да туздырып ташлыйлар. Вакыт Нигъмәт казый, Гали хәзрәт, Кәрим Гайфи кебек тыныч юлдан, мәгърифәт юлыннан барып, максатка ирешергә омтылучыларның хаклы булуын күрсәтә.

«Артың белән киртә җимерә алмассың» – халык моны колонизациядә яшәү шартларындагы яшәешне күздә тотып әйтә. Рус социалистлары алар үз илләрендә, алар яшәү шартларын үзгәртүне генә күздә тота. Безгә исән калырга, милләт буларак сакланып калырга кирәк. Бүгенге шартларда да, XX йөз башында да, аннан алдарак гасырларда да бу – мәгариф җилкәсенә төшкән йөк. Безгә, Сингапурдан килеп лекция укыган бер галим әйткәнчә, горизонталь түгел, ә вертикаль үсешкә, ягъни интеллектуаль үсешкә омтылу, шуның аркылы милли үзаңның фәнни концепциясен булдыру шарт. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай кирәк.

**Гомәр ДАУТОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ҮТКӘННӘРГӘ ХИСАП ТОТКАНДА



Холкым белән мин шактый ук дуамал, үзсүзле, дөньяга тәнкыйди карашлы кеше. Үземә кадәр Язучылар берлеге рәисе булып эшләгән кешеләргә карата мин һәрчак дәгъвалы була килдем, эшләреннән йөз процент разый түгел идем. Инде менә үземнең башкарган эшләрем өчен җавап тотар көн килеп җитте. Миңа калса, нидер эшләдем кебек, беркем дә элеккеге рәисләргә караганда начаррак эшләдең бит дип әйтмәстер шикелле тоела. Ләкин дүрт ел ул шактый кыска, бик тиз үтеп тә китә икән. Әле алда эшләнмәгән эшләрем калды, кызганыч, әгәр икенче срокка сайланмасам, аларны беркем дә башкармаячак дигән бер үкенеч күңелне тырный. Иң кызганычы, минем кешеләргә карата ышанучан, беркайчан да, беркемнән дә җитәкче булып эшләү тәрбиясе алмаган булуым, киресенчә, һәрнәрсәне үзем башкарырга, үзем эшләп чыгарга өйрәнгән кеше булуым нәтиҗәсендә күп кенә авырлыклар, кыенлыклар кичерергә туры килә. Шуның аркасында эшкә дә зыян килә, уйлаган, ниятләгән күп кенә планнар тормышка ашмый кала. Язучылар берлегенең сайтын ачтык. Ләкин интернетның бөтен мөмкинлекләреннән файдаланырга ирешеп булмады. Язучыларның тавышларын яздырып калу, башкарган эшләребезнең аудио, видео язмаларын эшләү мөмкинлеген файдалана алмадык. Сайтыбыздагы күп кенә папкалар буш тора. Хәзер гәзит чыгарам дип тә азапланасы юк, интернетны гына тиешенчә файдаланырга кирәк. Аның аша бөтен дөньяга чыгу, танылу мөмкинлеге зур. Кызганыч, без әле бу яктан артта калган. Электрон гәзитләр, китаплар, китап кибетләрен, язучыларның блогларын ачу – барысы да алда торган дүрт елда башкарылырга тиешле эшләр.

Үткән дүрт елда җәмгыятьтә язучыларга, әдәби иҗатка мөнәсәбәт  нык үзгәрде, начарланды. Һәм ул бүген тагын да начарлануга таба бара. Миңа бу дүрт елда шактый йөрергә, төрле республикаларда булырга, язучылар белән аралашырга туры килде. Һәм мин шуны күрдем: язучыларга карата иң хәерхаһлы булган республика – ул безнең Татарстан. Без моның өчен Президентыбызга зур рәхмәт әйтергә тиешбез. Мин моны һәр чыгышымда әйтә киләм. Дөрес аңларга кирәк, бу һич кенә дә Президент алдында ярхшатлану түгел, киресенчә, әдәбиятыбызга, язучыларыбызга шундый мөгамәләне саклап калу өчен тырышу. Бүген безнең хәлдәге язучылар берлеге бер генә җирдә дә юк. Без элек Башкортстандагы каләмдәшләребез белән ярыша идек. Хәзер мактана алабыз – алар безгә караганда шактый кыен хәлдә. Ләкин моның белән мактанырга һич тә ярамый, чөнки бу начар үрнәк иртәгә безгә дә килеп җитәргә мөмкин. Күршеләребез Чувашстан язучылары дүрт берлеккә таркалып, дәүләттән бер тиен акча алмыйча, чын мәгънәсендә иҗтимагый оешмалар булып яшәп яталар. Яшәп дип әйтү дөрес үк тә түгелдер, бәлки. Марий Элда да яшиләр. Удмуртларда да шул хәл. Якутиядә ике берлеккә таркалып, үзара уртак тел таба алмыйча яшиләр. Күптән түгел бездә гагаузлар булып китте. Аларда да шул ук хәл. Безне күреп исләре китеп, дәүләт нәшриятында түләүсез китап чыгаруыбызга, күпмедер гонорар да алуыбызга көнләшеп киттеләр. Кавказ республикаларында берлекләр сакланып калган, ләкин дәүләттән финанслану күпкә начар. БДБ илләреннән

Казакъстан белән Азәрбайҗанда гына хәлләр ярыйсы. Төрекмән, кыргыз, үзбәк, таҗик илләрендәге иҗат берлекләрендә, Мәскәүдә дә хәлләр шәптән түгел. Мәскәү, Санкт-Петербург язучылары инде узган гасыр ахырыннан бирле иҗтимагый оешмалар булып, взнос һәм эшмәкәрлек белән шөгыльләнү хисабына көн күрәләр. Үзен СССР Язучылар берлеге варисы дип санаучы МСПС (Халыкара язучылар берлекләре бергәлеге) белән башка берлек-оешмалар арасында чирек гасыр инде тарткалаш бара. Бу язучыларга карата халыкта һәм җитәкчелектә тискәре мөнәсәбәт уята.

Шөкер, китап нәшриятыбыз эшләп тора. Кызганычка каршы, әсәрләребезне тәрҗемә итеп, дөньяга чыгару, үзенең былтыргы еллык юлламасында Президент Рөстәм Нургалиевич әйткән интеграция мәсьәләсе әле безнең алда «күтәрелмәгән чирәм» булып кала бирә. Алдагы дүрт елда бөтен көчне шушы максатка туплау бурычы тора. Ниһаять, сүздән эшкә күчү вакыты җиткәндер. Бу эшнең планын төзеп, Президентка мөрәҗәгать итсәк, ул безгә ярдәм итмичә калмастыр дип уйлыйм. Әдәбиятны дөньяга чыгару — ул республиканы да танытуның бер юлы.

Совет чорында шактый киң алып барылган юнәлеш – халыкара аралашулар. Башка республикалар, төбәкләр белән алмаш әдәбият-сәнгать көннәре үткәрү. Бу да Россия халыклары арасындагы дуслыкны ныгытуга һәм шул төбәкләрдә көн итүче милләттәшләребезгә ярдәм күрсәтүгә хезмәт итә торган үтемле чараларның берсе. Моның шулай ук Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез арасыннан сәләтле яшьләрне эзләп табуда, аларга әдәбиятка килүдә ярдәм итүдә әһәмияте зур булачак. Безгә бу юнәлештә дә эшне активлаштырырга кирәк. Башка төбәкләрдә яшәүче каләмдәшләребез дә бүгенгә кадәр игътибардан читтә калып килде. Бу хатаны танырга һәм төзәтергә вакыт җиткәндер.

Менә шушы эшләрне киләчәктә башкару кирәклеген искәрткәннән соң, узган дүрт ел эчендә башкарган эшләребезгә күзәтү ясарга, хисап тотарга күчсәң дә мөмкиндер.

Безнең Уставта Берлекнең төп максаты язучыларга югары сәнгать дәрәҗәсендә булырлык әдәби әсәрләр иҗат итүдә булышлык күрсәтү дип билгеләнә. Бу максатны тормышка ашыру өчен төп бурыч – язучының иҗат белән шөгыльләнүе өчен стимул булдыру, иҗатка кызыксындыру тудыру. Кызганычка каршы, язучы хезмәте өчен түләү, гонорар бик түбән. Шуңа күрә без язучыга хезмәткә стимул тудыруның иң үтемле чарасы – ул иҗади конкурс үткәрү дип таптык. Беренче елда ук без Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән килешеп, авыл тормышын чагылдырган проза әсәрләренә конкурс игълан иттек. Авыл язмышы — милләт язмышы да. Шуңа күрә мондый конкурсны үткәрү бик әһәмиятле иде. Беренче елда конкурс шактый зур теләктәшлек тапты, шактый гына әсәрләр – 8 роман, 26 повесть һәм 34 хикәя язылды. Әлбәттә, конкурста барлык әсәрләр дә җиңүче була алмый. Һәр жанр буенча өчәр генә җиңүче билгеләнде. Конкурс алга таба да дәвам итте. Ләкин язучыларда кызыксыну беразкимеде. Нәтиҗәдә, икенче елда 4 роман, 12 повесть һәм 11 генә хикәя иҗат ителде. Мин үзем бу да начар түгел дип саныйм. Авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов белән килешү нигезендә конкурс әле дә дәвам итә.

Безнең Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән, гомумән, әйбәт мөнәсәбәттә яшәвебезне ассызыклыйсы килә. Ел саен көзге кыр эшләре вакытында авылларга, игенчеләр, терлекчеләр янына чыгу Марат Готыф улының турыдан-туры фатихасы белән эшләнде.

Язучыларыбыз ел әйләнәсендә районнардан кайтып керми. 2014 — Мәдәният елында да, 2015 — Әдәбият елында да, язучыларыбыз район җитәкчеләренең махсус чакырулары белән, халык, җәмәгатьчелек белән очрашуларда йөрделәр. Бигрәк тә Арча, Балтач, Мамадыш, Азнакай, Актаныш, Мөслим, Баулы, Әлмәт, Саба, Спас, Буа, Кайбыч районнары башлыкларына язучыларга, әдәбиятка хәерхаһлы мөнәсәбәттә булганнары өчен рәхмәт әйтәсе килә. Арча районы башлыгы Илшат Габделфәрт улы Нуриев хәтта үзләрендә туып үскән язучыларны җыйнап, Арча районы язучыларының үз якташлык җәмгыятен төзергә дә батырчылык итте. Без моны хуплыйбыз һәм башка районнарда да язучыларга шундый мөнәсәбәт булуын телибез.

Язучыларыбызның иҗади активлыгын арттыруга китергән икенче бер конкурс – ул төрки телле илләр язучылары арасында үткәрелгән М.Кашгарый исемендәге халыкара хикәяләр конкурсы булды. Монысында да язучыларыбыз актив катнашты. Чаллыда

яшәүче каләмдәшебез Айгөл Әхмәтгалиеваның «Капка» хикәясе 13 төрки ил әдипләре арасында икенче урынга чыкты. 2015 елда драматурглар арасында үткәрелгән Халдун Төнәр исемендәге конкурста да татар язучылары иң активлардан булды. Татарстаннан барысы 21 драма әсәре җибәрелгән иде. Җиңү генә башка илләр драматургларына елмайды.

Язучыларыбызның иҗат активлыгын көчәйтү буенча «Казан утлары», «Идел» журналлары да максатчан эшли. «Казан утлары» журналы редакциясендә кыска бәяннар конкурсына 29 әсәр килде. Аларның 17се журналда басылып чыкты.

2014 елда Президентыбыз Рөстәм Нургали улыннан күренекле тарихи шәхесләребез турында романнар иҗат итү өчен махсус заказ алу язучыларны иҗатка тартуда соңгы 30 елда союз тормышында күрелмәгән матур эш булды. Нәтиҗәдә: Айгөл Әхмәтгалиева — беренче татар хатын-кыз артисты Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Рөстәм Галиуллин күренекле дин галиме Таҗетдин Ялчыгол турында романнар яздылар. Ркаил Зәйдулла — Казан ханлыгының соңгы дин башлыгы Кол Шәриф, Галимҗан Гыйльманов — бөек татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабич  һәм Ләис Зөлкарнәй шагыйрь һәм алтын приискалары хуҗасы Дәрдемәнд турында роман язу белән мәшгуль. Соңгы өч язучының эшләре бераз озаккарак сузылды. Алар моны күренекле шәхесләр турында роман язуның бик авыр эш булуы белән аңлаталар. Роман язучыларга шактый гына күләмдә гонорар түләнде. Алар бу әсәрләрне быел тәмамлап чыгар дигән өметтә калам. Бу эшнең шулай озакка сузылуы алга таба да яңа заказлар алуны тоткарлый. Әлеге романнарны китап итеп бастырып чыгару да, төрле телләргә тәрҗемә иттерү дә бөек шәхесләребезне дөньяга танытуда зур эш булыр иде.

Берлек Уставында Союзның төп максатларының берсе итеп язучыларның социаль хәлен кайгырту мәсьәләсе күрсәтелә.

Берлектә 337 язучы исәптә. Шуларның 220се – пенсионерлар. Бу бик зур сан. Пенсионер икән, димәк, социаль яклауга, ярдәмгә мохтаҗ. Кайчагында безгә бөтенләй уйламаган, көтмәгән кешеләр ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Кызганыч, бүгенге көндә әдәби фондыбыз юк дип әйтерлек. Дөресрәге – исәпкә бар, санга юк.

2013 елдан без Президент ярдәме белән пенсионерларга ай саен субсидия биреп барабыз. Беренче ике елда ул берәр мең сум, былтыр азрак булган иде. Быел да былтыргы күләмдә булачак. Халык язучысы, Халык шагыйре исемен йөрткән язучыларга 10ар мең сум субсидия бирелә. Шулар өстенә, без ел саен инвалид язучыларга матди ярдәм күрсәтеп киләбез. Өйләренә барып, хәлләрен белешәбез. Ел саен Өлкәннәр көнендә пенсионерларны җыеп, чәй мәҗлесе үткәрәбез. Сигезенче мартта хатын-кызларыбыз өчен чәй мәҗлесе үткәрү гадәткә керде. Ураза тоткан каләмдәшләребез өчен ифтар ашы үткәрдек. Корбан бәйрәмендә корбан ите өләштек. Төркиянең Казандагы консуллыгы белән берлектә төрек телендә белем бирүче мәктәп укучылары үткәргән ярминкәдән кергән акчага инвалид язучыларыбызга пакетлар алып тараттык. 2013 елда 30 язучыбызга, калган елларда да, аерым гариза белән мөрәҗәгать иткән язучыларга матди ярдәм күрсәтелде.

Язучыларга сәламәтлекләрен ныгыту өчен мөмкинлекләр тудырыла. Без моның өчен хөкүмәтебезгә, Мәдәният министрлыгына  рәхмәт әйтәбез. Соңгы дүрт елда 70тән артык язучыбыз — «Васильево» шифаханәсендә, 30лап каләм әһеле «Бәкер» шифаханәсендә дәваланды һәм иҗат белән шөгыльләнде.

Соңгы дүрт елда 29 язучыбыз безнең арадан китте. Соңгы елларда берничә тапкыр татар зиратына барып каберләрне чистарттык, өмәләр үткәрдек. Алдагы елларда традициягә кергән изге эшне, каберләргә таш һәм һәйкәлләр куюны дәвам иттердек. Әхсән Баян, Туфан Миңнуллин, Әхмәт Гадел, Адлер Тимергалин, Госман Садә, Рөстәм Мингалим, Миргазиян Юныс, Дания Гыймранова, Владимир Корчагин, Флүс Латыйфи каберләренә ташлар куйдырдык.

Язучыларыбызга ел саен Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге тарафыннан әдәби премияләр бирелә. Ел саен берәр язучыга 50 мең сум күләмендә – Гаяз Исхакый, 30ар мең сум күләмендә – Һади Такташ, Фатих Хөсни, Җамал Вәлиди, Абдулла Алиш исемендәге премияләр бирелә, 2015 елдан Туфан Миңнуллин исемендәге премиянең күләме  50 мең сум булды. Болардан тыш «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең «Рухият» рухи яңарыш фонды тарафыннан инде ун ел буена бирелеп килә торган

Саҗидә Сөләйманова исемендәге премиябез бар. Ел саен 30ар мең сум күләмендә өч төп премия, 10ар мең сумлык өч кызыксындыру премиясе һәм гуманитар югары уку йортларында укучы 10 студентка стипендияләр бирелә. Былтыр премияләрнең күләме 50 мең сумга кадәр күтәрелде. Язучыларыбызга күрсәтелгән мондый ярдәм өчен, шулай ук ел саен чыгарып килә торган китаплары өчен «Татнефть», аның «Рухият» фонды җитәкчелегенә ихлас рәхмәтләребезне белдерәбез. Болардан тыш Шәйхи Маннур исемендәге премия өчен — Мамадыш, Гамил Афзал исемендәге премия өчен Актаныш районнары җитәкчеләренә рәхмәтләребез зур.

Соңгы дүрт елда дүрт язучыбыз – Нәбирә Гыйматдинова, Вахит Имамов, Клара Булатова, Газинур Морат республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Фоат Садриевка, Нәбирә Гыйматдиновага — «Татарстанның халык язучысы», Зиннур Мансуровка, Лена Шагыйрьҗанга — «Татарстанның халык шагыйре» исемнәре бирелде.

Халыкара масштабтагы премияләргә дә тукталып үтәргә кирәк.

2000 елдан бирле Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге тарафыннан бирелә торган Г.Державин премиясенең рус телле язучыларыбызның иҗатын стимуллаштыруда әһәмияте зур. 2010 елдан бирле Россия Әдәби фондының да бүләге булып саналган бу премия быелдан үзенең статусын үзгәртә. Ул ике министрлык – Татарстан Республикасы Мәдәният һәм Юстиция министрлыкларының һәм Россия Әдәби фондының премиясенә әверелә. Премиянең матди фонды да ике йөзәр меңгә җитәчәк.

Мин бүген 2015 елда «Литературная газета»ның ел саен бирелә торган, «Золотой Дельвиг» премиясе лауреаты булуга ирешкән Ренат Харисны да котлыйм!

Менә инде өченче ел рәттән безнең яшь шагыйрәләребез Россия-Италия «Белла» үзәгенең «Косание Казани» номинациясендә «Белла» халыкара шигъри премиясенә лаек булып киләләр. 2014 елда бу премияне Луиза Янсуар алган иде, былтыр бәхет Чаллыдан Лилия Гыйбадуллинага (Сираева) елмайды. Ә быел «Белла» премиясенә Йолдыз Миңнуллина лаек булды.

Ике корылтай арасында Муса Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясенә дүрт яшь язучыбызның лаек булуын да билгеләп үтәсе килә. Бу олы бүләк 2013 елда Рүзәл Мөхәммәтшин белән Ленар Шәехка, 2015 елда Рөстәм Галиуллин белән Луиза Янсуарга бирелде. Яшь каләмдәшләребезне котлыйбыз, аларга алга таба да иҗатта зур уңышлар теләп калабыз!

Сүзебез акрынлап яшьләребез иҗатына кереп бара. Яшьләр белән эшләү, яшь алмаш тәрбияләү — Язучылар берлегенең төп һәм максатчан алып бара торган эш юнәлешләренең берсе. Яшьләр – берлекнең өмете һәм киләчәге. Былтыр мин Берлектә яше 35кә җитмәгән 35 язучы бар дип санап йөри идем, быел исә аларның исәбе 20гә генә калган. Бер ел эчендә унбиш яшь язучыбыз 35нең теге ягына чыккан. Ә бит соңгы дүрт елда берлеккә кабул ителгән 43 язучының 16сы – яшьләр. Әйе, сафларыбыз картаюга бара. Шуңа күрә яшьләр белән эшләүгә игътибарны тагы да арттырасы, көчәйтәсе бар! Югыйсә, нәрсәдер эшләргә дә тырышабыз кебек. 2013 елның 7-8 ноябрендә Башкортстан Язучылар берлеге белән бергә яшь язучылар семинары уздырдык. Башкортстаннан — биш башкорт һәм биш татар, Татарстаннан шулай ук биш яшь язучының иҗаты тикшерелде. Берничә яшь язучыбызга китапларын бастырып чыгару өчен юллама бирдек. 2014 елда үткәрелгән Республика иҗат берләшмәләре җитәкчеләре семинары да яшь иҗатчыларны барлау, аларга ярдәм итүдә эзсез узмады. Бу семинарлар нәтиҗәсендә Римма Шәехова, Людмила Аланлы, Лениза Вәлиева, Фидаил Мәҗитов, Булат Ибраһимов, Эльвира Һадиева, Фәнил Гыйләҗев кебек яшь язучылар берлегебез сафларын ишәйтте.

Яшьләрне берлеккә алу гына аз, аларның иҗатын пропагандалау, халыкка, дөньяга таныту буенча да максатчан эш алып барыла. Казан шәһәре мэриясе, аның мәдәният үзәге ярдәмендә, «Аксёновфест — 2015» фестивале кысаларында 22 яшь шагыйребезнең әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп, «Антология современной татарской поэзии» дигән исем белән Мәскәүдә бастырып чыгаруга ирештек. Менә дүрт ел инде Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәктәп укучыларының иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү максатында «Илһам» конкурсы оештырыла. Конкурста

ел саен меңгә якын бала катнаша. Быел исә аларның саны өч меңгә якынлашты. Иң яхшы дип табылган әсәрләр аерым китап итеп чыгарыла. Конкурска йомгак ясау Г.Тукайның туган көне алдыннан Камал театрында, «Пирамида» мәдәни күңел ачу үзәгендә үткәрелде.

Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән берлектә оештырылган «Иделем акчарлагы» конкурсының да яшь талантларны ачуда әһәмияте зур. Былтыр ул 15нче тапкыр уздырылды. Соңгы елларда Берлеккә кабул ителгән яшьләребезнең күбесе шушы бәйгедә катнашып каләм чарладылар. Былтыр «Иделем акчарлагы» конкурсында Гран-при алган Алмаз Мансуровка күптән түгел Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы таныклыгы тапшырылды.

Яшьләр белән эшләү җәһәтеннән былтыр Габдулла Тукайның туган көне алдыннан үткәрелгән Халыкара төрки яшь язучылар фестиваленең әһәмияте гаять зур. Бу форумда Россия төбәкләреннән, БДБ илләреннән һәм Төркиядән, җәмгысе 14 илдән 22 яшь язучы катнашты. Алар остаханәләрдә, семинарларда үзара фикер алышты, тәҗрибәле язучыларның киңәшләрен ишетте, үзара аралашты һәм дуслык элемтәләре урнаштырды.

Бу урында мин Берлегебезгә Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез арасыннан язучыларыбызның бөтенләй диярлек килмәвен әйтеп үтәргә тиешмендер. Соңгы дүрт елда без Берлеккә Башкортстаннан Рифкать Рысаев белән Хисаметдин Исмәгыйлевне, Казакъстанда яшәүче кардәшебез Равил Гозәеровны гына кабул иттек. Алар да инде яшьләре 60ның аргы ягына чыккан абзыйлар. Дөрес, Башкортстанда яшәүче татар егетләренең иҗаты белән уртак семинарыбызда таныштык. Ләкин алар безнең Берлеккә түгел, ә Башкортстан Язучылар берлегенә керүне хуп күрделәр кебек. Эстәрлетамакта Вәрис Акбашев атлы бер егетнең матур гына әсәрләр иҗат итүен беләбез. Без бүген чит төбәкләрдә яшәүче каләмдәшләребез белән тиешенчә эшләп бетермибез дә бугай. Алар белән системалы, планлы рәвештә аралашу юк. Иҗатларына тиешле бәя бирелми, кимчелекләрен күрсәтеп, ярдәм итәсе иде бит. Алдагы елларда бу эшне башларга кирәк, быелгы көздә үк чит төбәкләрдә яшәүче каләмдәшләребезне Казанга җыеп, иҗади остаханә үткәрүне планга кертергә кирәк дип уйлыйм. Монда читтәге яшьләрне берлеккә тарту, китапларын чыгару мәсьәләсен дә карарга кирәк.

Шул ук вакытта Язучылар берлегенең иҗади элемтәләр урнаштыру, чит төбәкләр һәм илләрдәге коллегалары белән хезмәттәшлекне активлаштыруга омтылуын билгеләп үтәргә кирәк. Моның бер юнәлеше фестивальләр булса, икенче юнәлеше – тәрҗемә китаплары чыгару. Былтыр шулай ук дөньяның 22 иленнән 100ләп шагыйрь катнашында үткән XI Төрки шагыйрьләр фестивале игътибарга лаек. Моның ише зур форумнар Советлар Союзы таркалганнан соң әле беренче тапкыр үткәрелде булса кирәк. Гомумән, соңгы дүрт елда кардәш әдәбиятлар арасында 25-30 ел буе өзелеп торган элемтәләрнең кабат урнаша башлавын билгеләп үтәр идем. Азәрбайҗан, Казакъстан, Башкортстан язучылар берлекләренең 80 еллык юбилейларына чакырылуыбыз, Башкортстан, Чувашстанда яшәүче каләмдәшләребез белән аралашуларның ешаюы, уртак семинарлар, фестивальләр шуның дәлиле. Төркия Язучылар берлеге һәм Евразия Язучылар берлеге арасында элемтәләр матур гына башланып киткән иде. Кызганыч, дәүләтләр арасында килеп чыккан киеренкелек безнең элемтәләргә бераз киртә салды. Ләкин моның уртак килешүләргә, әдәби элемтәләргә зыяны тимәс дип ышанасы килә. «Тюрксой», Төркиянең Казандагы консуллыгы белән эшчәнлек дәвам итәр дип өметләник.

Азәрбайҗаннан тарихчы-язучы Юныс Угыз белән очрашу да төрки әдипләребез арасындагы элемтәләрнең ныгый баруына бер дәлил. Бу очрашуда шулай ук азәрбайҗан шагыйре Әкбәр Гошалы катнашты һәм ул яшь шагыйрьләребезнең шигырьләрен азәрбайҗан теленә тәрҗемә итеп, Бакуда бастырып чыгару турында килешү төзеде. Тукаебызның туган көне алдыннан бу китапны күрү бәхетенә ирештек. Габдулла Тукайның 130 еллыгы уңаеннан аның 130 шигырен төрекчәгә тәрҗемә итеп, китабын Төркиядә бастырып чыгару турында «Ауразия» Язучылар берлеге рәисе, «BENGU» нәшрияты башлыгы Якуб Өмәруглы һәм «Кардәш каләмнәр» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Али Акбаш белән килешү төзелгән иде. Бу китап та Тукайның туган көненә безгә килеп иреште. Шулай ук «Кардәш каләмнәр» журналының апрель саны

тулысы белән Тукайга багышланды. Бу санны әзерләүдә төрек дустыбыз Фатих Кутлу зур хезмәт куйды. Аңа рәхмәтләребез зурдан. Фатих, гомумән, татар язучыларының әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итеп, Төркиядә китап итеп бастырып чыгару буенча зур эш башкара. Аның тәрҗемәсендә 6-7 китап дөнья күрде инде. Хәзер ул Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында»сын тәрҗемә итү белән мәшгуль.

Язучыларыбызның казакъ теленә тәрҗемә ителгән хикәяләр китабы моннан 37 ел элек Лирон Хәмидуллин тарафыннан әзерләнеп дөнья күргән булган. Былтыр казакъ дусларыбыз белән килешү нигезендә 36 татар прозаигының хикәяләре Алматыда казакъ телендә «Татар әңгәмәләре» дип аталган китап булып басылып чыкты. Калмык шагыйре Эрдни Эльдышев Тукай шигырьләрен калмык теленә тәрҗемә итеп җибәрде. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» Сайлыкма Комбу тәрҗемәсендә Тывада, Валери Тургай тәрҗемәсендә Чабаксарда, балкар шагыйрьләре тәрҗемәсендә Нальчикта басылды. 2013 елда Чувашстанның халык шагыйре Юрий Семендер 123 татар шагыйренең шигырьләрен чуваш теленә тәрҗемә итте, нәтиҗәдә «Тутар поэзиясе кашале» дигән җыентык дөнья күрде. Былтыр шулай ук Юрий Семендер тәрҗемәсендә Җәүдәт Сөләйманның шигырьләре чуваш телендә һәм үз егетләребез тәрҗемәсендә рус телендә аерым китаплар булып басылды.

Без дә төрки кардәшләребез алдында бурычлы булып калмадык. Дүрт ел эчендә кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның «Повестьлар»ы, авар шагыйре Рәсүл Гамзатов, балкар Муталип Беппаев, Башкортстанның халык шагыйре Марат Кәримов, казакъ әдәбиятына нигез салучыларның берсе Магҗан Җомабаев, казакъ шагыйрьләре Нурлан Оразалин, Галим Җайлыбай, авар шагыйре Могамед Ахметовның (безнеңчә Мөхәммәт Әхмәтов) китаплары, карачай-балкар шагыйрьләренең «Мәңгелек тау илендә» дип аталган күмәк җыентыгы татар телендә дөнья күрде. Татарстан китап нәшрияты Башкортстан китап нәшрияты белән килешү нигезендә 1994 елдан бирле ике халык язучыларының алмаш китапларын чыгара. Бу елларда нәшрият шулай ук үзбәк шагыйре Чулпанның, кыргыз Омар Солтановның китапларын татарчага тәрҗемә иттереп чыгарды. Татарстан хөкүмәтенең махсус карары нигезендә Россия халыклары әдәбиятыннан берничә язучының әсәрләрен татарчага тәрҗемә иттек һәм китапларын чыгардык. Алар арасында Кайсын Кулиев, Валерий Тургай, Егор Загребин, Вячеслав Ар-Серги, Гавриил Державин, Максим Горький һәм якут язучысы Василий Яковлев (Далан) әсәрләре бар.

Лилия Газизова, Наил Ишмөхәммәтов, Ихтияр Гаязов, Алёна Кәримовалар Мәскәүдә, Молдовада, Эстониядә, Франциядә, Бельгиядә үткәрелгән тәрҗемәчеләр форумнарында катнаштылар. Лилия Газизованың «Окно в сад» дигән китабы Румыниядә румын телендә, Польшада поляк телендә басылып чыкты.

Без Мәскәү, андагы төрле берлекләр белән дә элемтәдә торырга тырышабыз. «Антология современной татарской поэзии» җыентыгын тулысынча Мәскәү шагыйрьләре тәрҗемә итте. «Державин» премиясенең бер номинациясен Россия Әдәби фонды тапшыра. 60тан артык язучыбыз – Россия Язучылары берлегенең (Союз Российских писателей) әгъзалары. «Литературная газета»ның баш мөхәррире (президенты) Юрий Поляков ике ел элек Казанда булып, безнең белән очрашты, Россиядәге әдәби процесс хакында үзенең карашын бәян итте, фикерләре белән уртаклашты. Гомумән, Россия язучылар оешмалары җитәкчеләре бездән көнләшеп, безгә кызыгып яши һәм элемтәдә булырга тырыша. Безнең Берлек Язучылар берлекләренең халыкара берләшмәсе (МСПС) әгъзасы булып тора. Мин шул берләшмәнең башкарма комитеты әгъзасы. Кызганычка каршы, Мәскәүдә язучыларның бер иш даирәләре арасында МСПСка карата тискәре мөнәсәбәт яши. Бу Мәскәүдә Переверзин чыгара торган «Литературная Россия» һәм Поляков чыгара торган «Литературная газета» басмаларының бер-берсенә мөнәсәбәтендә бик яхшы күренә. Россиядә язучыларга, язучы хезмәтенә тискәре караш яши. Һәм бу карашның уңай якка үзгәрмәве дә бик мөмкин. Соңгы вакытларда булган кайбер вакыйгалар шуны күрсәтә. Ике ай элек кенә МСПС бинасы тирәсендә җәнҗаллар кубу — шуның бер мисалы.

Без үз ягыбыздан рус язучыларына, үзебездәгеләрне әйтеп тә тормыйм, Россиянең күренекле язучыларына карата ихтирамлы мөнәсәбәттә яшибез. Ел саен Г.Державин, А.Пушкин, В.Хлебников, М.Цветаева, С.Аксёнов, Н.Лобачевский фестивальләрен һәм

укуларын үткәреп торабыз. М.Лермонтовның юбилеен билгеләп үттек, В.Высоцкийның туган көнен үткәрүдә катнашабыз, Л.Гумилёвның туган көнен һәйкәленә чәчәкләр салып билгеләп үтәбез. Чистай музей-тыюлыгы үткәргән әдәби форумнар безнең язучылардан башка узмый. Аксаков, Солженицын юбилейларын зурлап үткәрергә җыенып йөрибез. Үзебезнең рус телле язучыларыбыз да игътибардан читтә калмый. Бүген Берлектә 70ләп рус телендә язучы бар. Алар башкалар кебек үк барлык мөмкинлекләрдән файдалана.

Берлегебезнең узган XVII корылтаеннан соң без заманча төзекләндерелгән, җиһазланган бинада эшли башладык. Иң әүвәл аппаратта эшләүче һәр хезмәткәрне компьютерлы итү бурычын куйдык. Безгә бу эштә ТР авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министры Марат Готыф улы Әхмәтов ярдәм итте. Ул биргән 200 мең сум акчага һәр хезмәткәр өчен персональ компьютер сатып алдык, принтерлар, ксерокслар, ноутбуклар, фотоаппарат һәм башка кирәк-яраклар юнәттек. Интернетта үз сайтыбызны ачтык. Элек секретарь, машинистка һәм бухгалтерия хезмәткәрләре генә компьютерда эшләсә, ярты ел эчендә аппараттагы һәркем компьютер белән эш итә, интернетка керә белә башлады. Үзебезнең матбугат үзәген ачтык. Тик бер проблема бар, шушы көнгә хәтле матбугат үзәгендә күзен йомып та эшли белә торган журналист таба алмыйча интегәбез. 10 кеше алмаштырдык, рәтлесен таба алган юк. Тормыш дүрт ел эчендә шулкадәр нык үзгәрде, әгәр без интернетны тиешенчә файдаланырга өйрәнмәсәк, тагын бер-ике елдан заманнан тәмам артта калачакбыз. «Электрон китап», «Интернет кибет» дип сөйләгәндә, без надан һәм кыргый затлар булып калачакбыз. Бәябез иске бер тиен булачак.

Яңа бинага күчкәч, безгә «Таиф» җәмгыяте зур ярдәм күрсәтте, коридорларга, бүлмәләргә җәелгән келәмнәр – шушы компания җитәкчесе Альберт Кашаф улы Шиһабетдиновның бүләге.

Яңа бинабызда музей оештыра башладык. Моның өчен дә, әлбәттә, акча кирәк иде. Һәм безгә эшне башлап җибәрү өчен «Рухият» рухи яңарыш фонды җитәкчесе Рөстәм Нәбиулла улы Мөхәммәдиев ярдәм кулын сузды.

Яңа бинага күчкәч, безнең эшчәнлегебезнең канәгатьләндерә торган бер ягы шул булды, һәм бу эш безнең халык, җәмәгатьчелек арасында күпмедер дәрәҗәдә абруебызны күтәреп җибәрде, ул да булса – Тукай клубы. Без дүрт ел эчендә клубыбызда йөз егермедән артык кичә үткәрдек. Язучыларыбызның юбилей кичәләре, туган көннәре, китап тәкъдим итүләр, кызыклы кешеләр белән очрашулар, семинарлар, фестивальләр, һәртөрле форумнар… Мин аларны исемләп санап тормыйм. Алар язучыларның күз алдында, аларның катнашында үтте. Һәр атнаның җомгасында нинди дә булса әдәби-музыкаль кичә үткәрү ул хәзер традиция генә түгел, эш нормасына әверелде. Кичәләр өчен, аз булса да, махсус акча алуга ирештек. Кичәләр халык, әдәбият сөючеләр, җәмәгатьчелек арасында зур популярлык казанды. Безне шунысы канәгатьләндерми: классик әдипләребезнең, милләтебезнең бөек шәхесләренең дә олы юбилейлары бары тик шушы клубта гына үткәрелә башлады. Ә бит андый зур кичәләрне, алдагы еллардагы кебек, Камал, Тинчурин, Җәлил театрлары, Филармония кебек зур залларда, күп аудитория җыеп үткәргәндә начар булмас иде, бу чараларның әхлак тәрбиясе бирүдә әһәмияте зур булуын онытырга ярамый. Бу мәсьәләне мин Президент алдында да күтәреп карадым. Кызганыч. Безнең хәтта Җәлил юбилее да Тукай клубы масштабында гына үтте. Фатих Әмирхан, Каюм Насыйри, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим… Саный китсәң, шактыйга җыела. Болар бит татар милләтен бар итүче, татар милләтен, халкын дөньяга танытучы татар әдәбияты корифейлары. Ә бит күп акча да кирәкми.

Ике корылтай арасындагы эшчәнлегебезгә йомгак ясаганда, шулай ук күңелдә канәгатьсезлек тойгысы калдырган берничә җитешсезлек бар. Без «Татарстан — Яңа гасыр» телевидениесе (ТНВ) белән эшчәнлегебезне уртак тел табып оештыра алмадык. Анда бүген кайбер үзгәрешләр бара, язучыларга карата да мөнәсәбәт уңай якка үзгәрер дип өметләник. «Татмедиа» агентлыгы белән дә шул ук хәл. Кызганычка каршы, соңгы елларда әдәби басмалардан кала матбугаттан, радио-телевидениедән язучылар читләштерелде. Алар үзләренә якын җибәрмиләр, язмаларыбызны басмыйлар, язучылар белән махсус әңгәмәләр,«түгәрәк өстәл»ләр оештырмыйлар, фикерләрне

ишетергә теләмиләр. Радио-телевидениедә чиле-пешле яза торган, телне аннан-моннан гына белгән, сәясәттән читтә торган журналистлар армиясе барлыкка килде. Бигрәк тә төрледән-төрле радиостанцияләрдә хәл аяныч. Россиядә, дөньяда гаять җитди сөйләшүләргә азык булырлык вакыйгалар бара. Ләкин телевидение бу хәлләргә карата язучының мөнәсәбәтен халыкка, телевизор караучыларга җиткерү турында уйлаудан ерак тора. Шәхсән үзем эшли башлагач ук, шундый тапшырулар кирәклеге хакында телевидение җитәкчелегенә дә, «Татмедиа» җитәкчелегенә дә мөрәҗәгать итеп карасам да, минем сүземә игътибар бирүче табылмады.

Матбугатта басылган язмалар һәм әдәби әсәрләр өчен түләү, гонорар мәсьәләсе дә һаман хәл ителмичә кала бирә.

Вахит Имамов килгәннән соң, «Мәдәни җомга» гәзите дә язучылар берлеге эшчәнлеген яктыртып барудан читләште.

Шулай да чыгышымны мондый төшенке тонда тәмамлыйсым килми. Чөнки үткән дүрт ел эчендә зур залларда юбилей кичәләре үткәрү бәхете дүрт-биш язучыбызга гына елмайса да, без 2013 елда Әлмәт Татар дәүләт драма театры бинасында Әлмәт Язучылар бүлегенең 60 еллык юбилеен, 2015 елда Чаллының «Энергетик» мәдәният сараенда Чаллы Язучылар оешмасының 35 еллыгын һәм 2014 елда «Корстон» комплексында Татарстан Язучылар берлегенең 80 еллыгын, төрле кыйтгалардан килгән кунаклар катнашында, зурлап билгеләп үттек. Бу мөмкинлекләрне тудырган өчен без, әлбәттә, Президентыбызга, хөкүмәтебезгә зур рәхмәтле.

Чыгышымның ахырында минем Татарстан Язучылар берлеге белән кулга кул тотышып, иңгә иң куешып дигәндәй эшләгән оешмаларга, кешеләргә рәхмәт сүзләре җиткерәсем килә. Иң элек Татарстан Мәдәният министрлыгына зур рәхмәт, безне гел күз уңында тотып, ярдәм итеп, эшчәнлегебезне алып баруда хәтта җитәкче рольне үз кулларына алган өчен. Икенче зур рәхмәтебез «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенә, аның Рөстәм Нәбиулла улы Мөхәммәдиев җитәкләгән «Рухият» рухи яңарыш фондына, аның эшләрен алып баручы Флёра Әбелмәгъдан кызы Шәйхетдиновага. ТР Премьер-министры урынбасары — мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттаховка рәхмәт. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгына, ТР Премьер-министры урынбасары, министр Марат Готыф улы Әхмәтовка. Бик зур рәхмәтләребез Татарстан китап нәшриятына, аның тәҗрибәле мөхәррирләренә, корректорларына, барлык хезмәткәрләренә. Зур рәхмәтләребез Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты директоры Рәдиф Рифкат улы Җамалетдиновка. Шулай ук Галиҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелегенә, Ким Мөгаллим улы Миңнуллинга, Татарстан Фәннәр академиясенә, Татарстан Милли китапханәсенә рәхмәтләребез чиксез.

Бу оешмалар, бу халык белән безнең эшчәнлегебез тыгыз бәйләнгән. Алар безгә кирәк булган кебек, язучылардан башка аларның эшчәнлеген дә күз алдына китерүе кыен. Шуңа күрә, Наҗар Нәҗми җырындагыча, «Бер-беребезгә без кирәкбез икән, юкка түгел, юкка түгелдер». Бездән башка әле дөнья бармый. Димәк, дөнья әле язучы сүзенә мохтаҗ.

**Рафис КОРБАНОВ,**
*Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе*

# ТУКАЙ ОЧЫРГАН КАРЛЫГАЧЛАР: ГЫЙФФӘТ ТУТАШ

1914-1915 елларда шигырьләре Гыйффәт туташ исеме белән басылган һәм әдәби җәмәгатьчелекнең бик югары бәясен алган Заһидә Бурнашева язмышы үтә дә гыйбрәтле. Ир-егетләрнең шактые инкыйлабтан соң да иҗат мәйданында калса да, кызларыбыз тормыш сынауларын авыррак уза. Бер яктан, рухтагы үзгәрешләр, икенче яктан, иҗтимагый барыштагы борылышлар, бигрәк тә үз алларына куйган максатхыяллары үзгәрү аркасында, иң талантлы дигәннәре әдәбият мәйданыннан китә. Шулар арасында Гыйффәт туташ һәм Гыйффәт тәхәллүсләре белән билгеле Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева да бар. Ул — милләтебез тарихына киңкырлы шәхес – шагыйрә, прозаик, публицист, партия һәм җәмәгать эшлеклесе буларак кергән данлыклы кызыбыздыр.

Гыйффәт туташ 1895 елда Рязань өлкәсенең Әҗе авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Татар сүз сәнгатен яхшы белү өстенә, русча иркен аралашкан кыз чит әдәбият үрнәкләре белән яхшы таныш була. Тора-бара үзе дә шигырьләр язуга керешә. Кызның иҗат эше белән шөгыльләнүе ата-анасына ошамый. Аның әсәрләрен, китапханәсен яндыралар һәм үзен өйдә бикләп тота башлыйлар. Әлеге хәлләр әдәби җәмәгатьчелектә зур ризасызлык тудыра. Иҗаттан аерылуны үлемдәй күргән кыз туган йортыннан кача, һәм шул хакта хәтта матбугат та язып чыга. Иң кызыгы шунда: бу качуны ата-анасы: «Патшага каршы кешеләр оешмасында эшләү өчен, авылдан китә...» – дип аңлата. Элек шикаять эчтәлеген чынга алмыйлар, махсус куркыту дип аңлаталар иде, ә бит шагыйрәнең соңрак большевиклар тарафдары булуы да, коммунистлар партиясенә озак еллар үтә бирелгәнлеге, альтруистларча хезмәт итүе дә хатта хакыйкать барлыкны дәлилли.

З.Бурнашева үзенең аянычлы язмышы хакында киң җәмәгатьчелеккә шушы рәвешчә хәбәр итә: «Минем гөнаһсызлыгымны, языксызга вә залиманә бер сурәттә түктерелгән күз яшьләремне күрә торып та, минем залимнәр тырнагы арасында чытырдавымны ишетеп тә, миңа Әҗе тарафыннан бер мәрхәмәт иясе чыгып, үзенең шәхси мәнфәгатьләрендән, шкурасындан вөҗдан вә инсаниятне артык күрүче табылмагач, үземнең рәнҗетелгән йөрәгемне, мәзлуманә түгелгән яшьләремне матбугат аркылы милләткә аңлатып, үзенең хаксызга җәберләнгән вә уку юлында бу кадәр җәһәннәм газаплары күргән бер кызын химайәгә милләтне чакырам»[1] . Хаттан өзек кенә дә заманына күрә кызның үтә кыюлыгын, эшчәнлегенең, беренче чиратта, милләт язмышына юнәлтелгәнлеген күрсәтеп тора. Татар дөньясының алдынгы көчләре шагыйрәгә барлык яктан, шул исәптән иҗади планда да ярдәм кулы сузалар һәм «Гыйффәт туташ шигырьләре» исеме астында аның бер-бер артлы өч җыентыгын бастырып чыгаралар. Милләттәш хатын-кызларының аянычлы тормышын үтә реалистик һәм җанга үтемле сурәтләр аркылы тасвирлаган әлеге әсәрләр шул заман укучысы арасында гаять зур популярлык казана.

Заһидә Бурнашева вакытлы матбугатта бераз соңрак басыла башласа да, өлгергән каләм иясе икәнлеге тәүге шигырьләреннән үк күренә. Шагыйрәнең унҗиде-унсигез яшьлекләргә хас самими, омтылышлы иҗатында олыларга хас тәҗрибәлелек төсмерләнә. Бу аңлашыла да, үз яшьтәшләреннән белеме, кыяфәте, тәрбиясе белән аерылып торган туташ ул. Заһидә туташның әдәбиятка зур әзерлек белән килүен, камил язуын, унҗиде-унсигез яшьтә үк иҗат иткән әсәрләрендә дә олыларга хас үткенлек, утырган акыл күренүен, катлаулы тормыш тәҗрибәсенең чагылуын егерменче гасыр башының күренекле әдәбият белгечләре С.Рәхмәти, Н.Гасрый һ.б. да таный.

Шагыйрәнең тәүге әсәрләре әдәбиятка яңа аяк баскан Тукайныкыларга инде

[1] Бурнашева З. Мәрхәмәт наменә бер үтенеч // Өмет йолдызлары / Төзүче: Гайнуллин М. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1988. – Б.212.

ниндидер күләмдә тартым. Шул ук вакытта остазы дип сайлаган Тукай шигырьләре кебек, З.Бурнашеванықылар да образларга бай, инде төрле форма һәм стильләрдә иҗат ителгән. Әлбәттә, чор шартларына бәйле рәвештә, аларга кайвакыт, әсәрнең сәнгати эшләнгәнлегенә зур зыян салмый гына, үгет-нәсихәтчелек килеп керә. Шагыйрә алга таба, Тукай кебек үк, традицион символиканың мәгънә чикләрен киңәйтүгә, татар сүз сәнгатен оригиналь образ-фикерләр белән баетуга ирешә.

Гыйффәт туташ әсәрләренең Тукайныкылар белән охшашлыгы, беренче чиратта, тематика һәм проблематикада, шул яссылыкларга караган мотивларда чагыла. Оригиналь иҗатчы буларак танылса да, З.Бурнашеваның Тукайны шактый нык кабатлаган шигырьләре дә байтак. «Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый», – дип белдерә Тукай. Аның артыннан ук Гыйффәт туташ: «Ярты төн. Мин йоклый алмыйм. Сызлый җан. Бәгърем көя», – дип дәвам итә, әмма алга таба шигъри йомгакны башка якка чорный. Аның лирик герое, үзен һәм халыкны янәшә куеп: «Халык йоклый. Мин аны бу газаплардан чыгарырга изге юл эзләп ятам», – ди.

Тукай шигъриятен халык авыз иҗаты да орлыкландырганны яхшы беләбез, аның милли көйләргә битараф булмавы шигырьләре һәм публицистикасы аша ачык мәгълүм. Заһидә иҗат иткән лирик миннең күңел кылларын да «Милли көйләр» тибрәндерә («Милли көйләр», «Милли көй»). Әлеге шигырьләрдә автор шулай ук халык җырларына милләтнең «дәрте, уе, акылы, йөрәк сагышы» салынганлыкны, шуңа күрә күңелгә үтеп кергәнлекләрен әйтә.

Шагыйрәләр мәхәббәт темасында бер төсле, шагыйрьләр икенчерәк ачылырга тиеш кебек, әмма XX гасыр башында иҗат иткән Тукай белән Гыйффәт туташ бу темада да шактый якыная. Гыйффәт туташның «лирик мин»е, Тукайныкы кебек, яшерен мәхәббәт утларында яна, тик тыштан гына сиздерергә ояла.

*Син күрерсең бу кешене: күп вакыт уйный, көлә, –*
*Ул, шулай итеп, хәләте рухын яшермәкче була.*
*Белмичә, «уйный», диләр, эчтән ниләр уйлаганын;*
*Сизмиләр – чыкмый төтен тышка – мәхәббәттә янганын!*

– ди Тукай «Гашыйк» әсәрендә.

*Сөям яшьрен генә, эчтән фәкать, белдермимен бер дә.*
*Суыклык күрсәтәм тыштан, туры килсәк икәү бергә:*
*Богаулыйм күкрәгемдә яшьренеп торган сөюемне.*
*Дия алмыйм, бер күрү өчен җилкенүемне,*
*Батырлык итми көчсез күзләрем, тиз иеләләр җиргә,*
*Ахыр тизрәк: «Эшем бар» , – дип китәм, әйтәлмим бер сүз дә,*

– дип эченнән көя Гыйффәт туташның оялчан һәм кыюсыз лирик герое да. Шагыйрә әсәрләре аша да безнең күз алдыбызга мәкаләләрдә, истәлекләрдә тасвирланган, бигрәк тә Ф.Әмирхан сурәтләгән Тукай образы килеп басадыр кебек. Әгәр З.Бурнашеваның лирик мине Г.Тукайныкына холкы белән соң дәрәҗәдә охшаган икән, димәк, иҗатчыларның рухият-хиссиятендә дә охшашлыклар байтак.

Тукай ачкан мәхәббәт темасында сагыш-моңга да, зарга да, күтәренке пафоска да урын җитәрлек. З.Бурнашеваның сөю шигырьләре арасында шатрак тондагылары күбрәк. Мәсәлән, «Ул»да шагыйрә бөтен дөньясын зур бер күтәренкелек белән сөйгәненә бүләк итә – «юлына ташлый». «Кызу дәртләр» шигырендә без «ялкынлы дәртләр белән» ашкынган каһарманын күрәбез. Әлеге әсәрләр инде башка иҗатчы шагыйрьләр тәэсирендәрәк иҗат ителгән. Ике шагыйрь дә бер нәрсәдә үзара бик якыная: мәхәббәт – Тукай өчен дә, Заһидә өчен дә – сулары мәңге саекмас илһам чишмәсе. Гомумиләштергәндә, аларның бу темага язылган шигырьләренең төп фикере – әнә шундый.

З.Бурнашева идеалдагы геройларны ир-ат арасыннан инде тапкан, ул аңа иҗатта һәм тормышта ярдәм кулы сузучылар, җандаш дуслар, милләтпәрвәрләр, бөтен булганнары белән әсир итәрлек җанашлар – бу хакта ачык белдергән әсәрләре дә

бар («Күк иркәсе, сөйлә син аңарга» һ.б.). Мәхәббәттәге идеалы аның йолдызларга омтыладыр:

*Карыйсың йолдызга син, йолдызым,*
*Йолдыз күзең теләп йолдызга.*
*Мин дә карыйм аңар төннәр буе,*
*Синең шәүләң булгач йолдызда.*

Ике шагыйрь иҗатында да мәхәббәткә лаек әлеге йолдызлар еш кына тормыш каршылыклары аша уза, җиргә төшерелә, булган матурлыгын югалта. З.Бурнашева хатын-кызларның шул замандагы хәле турында ачынып яза, җәмгыятьтә тотарга тиешле урыннарын билгели; аларның гаиләдә кол булуына каршы төшә; барысын да ир-атка тиң итеп күрергә тели.

Гыйффәт туташ, Габдулла Тукайга ияреп, үз хыялындагы заман кызларын яшьләр арасыннан күзли һәм кайвакыт шулай ук алдана. Алай да өметен тәмам өзми, йокыдагы туташ-ханымнарны уяту һәм үзгәртү хыялы белән яши. Аерым әсәрләрендә ул караңгылык дөньясында юл күзләгән татар кызы образын иҗат итә («Ул»). Г.Тукай, кызларга мәхәббәттән этәрелеп китеп, мәгъшукасын шулай ук идеалда ничек күрергә теләвен сурәтли.

Каләмдәшләр иҗатында милләтпәрвәрлек проблемасына шактый урын бирелгән. Г.Тукай каләм ияләрен һәрдаим халыкка хезмәт итүче сыйфатында күрсәтә: мәсәлән, «Мөхәрриргә» шигырендә, наданнар сүксә дә, милләткә хезмәт ит, фикерен уздыра һәм «наданнар» сүзе астында икейөзле мулла-мөәзиннәрне күздә тота. Инде З.Бурнашева иҗатыннан бер мисал: *«Армый эшләрмен, дим, халкым өчен, / Мулла-мөәзин тиргәп сүксә дә.»* («Өмидләрем»)

З.Бурнашева белән остазы арасында якынлык әдәби зәвыкларында да күзгә ташлана. Гыйффәт туташ Тукай укыган шагыйрьләрне укый, сөя, татарчалаштыра. Болар: Лермонтов, Пушкин, Кольцов. З.Бурнашева тәрҗемәләреннән мисалга Кольцовның «Юл», «Яшь килен зары» шигырьләрен китереп булыр иде. Шулай да алар арасында иң кызыклысы – Заһидә Бурнашева ирекле тәрҗемә икәнлеген билгеләп узган – Пушкинның «Любил я Вас» шигыре:

*Сөйдем Сезне. Минем утлы мәхәббәт сүнмәгән, бәлки,*
*Хәзер дә минем күңелемдәдер яки калыр мәңге.*
*Сөйдем Сезне өмедсез һәм дә яшьрен сөю белән –*
*Кайчан курыккан, йә көнләшкән булып, эчтән көю белән.*
*Сөйдем Сезне, багышлап Сезгә моңлы җырларымны мин,*
*Тырыштым тик чыгармаска эчемнән утларымны мин.*
*Сихерле, назлы таң ак нурларын сипкәнче һәр төнне*
*Йомалмый керфегем, ятсам да, йөредем Сезгә сер бирми.*
*Сөйдем, бәлки, сөярмен һәм сөйсеннәр үзгәләр Сезне –*
*Мәхәббәт тәңре алдында бит һәркем чүгәр тезне!*

З.Бурнашева, нәкъ Тукай кебек үк, Пушкинның мәхәббәт шигырьләрен үз итә. Күргәнебезчә, шулай ук төгәл тәрҗемә юлыннан китми, ияреп язуны, шигырьне киңәйтүне хуп күрә. Гыйффәт туташның Лермонтовтан файдаланып язган шигырьләре дә, Тукай сайлаган тәрҗемәләр кебек, — мәхәббәтнең өметсезлеккә төшерүе, аның тиңсезлеге, кешенең бары тик якты дөнья белән хушлашканнан соң гына дөньяви мәхәббәттән арына алуы хакында. Әйтик, аның «Ямансу да, күңелсез дә» шигыре Лермонтовның «И скучно, и грустно» әсәреннән этәрелеп китеп иҗат ителгән һәм аның рухын шактый отышлы тудыра; тәрҗемә дип аталмавы да шигырьне икенче телгә төгәл күчереп булмау аркасында гынадыр дип уйлыйм:

*Ямансу һәм күңелсез! Юк бирәү дә,*
*Биреп кулны, ачы кайгың сөйләргә.*
*Теләкләр!.. Ни табыш мәңге теләүдән,*
*Гомергә зарлы, моң көйләр көйләүдән?!*
*Үтә яшьлек!.. Сөяргә?!. Әйтче, кемне?*

Әлеге өзек Лермонтовта шушы рәвешчә яңгырый:

*И скучно, и грустно, и некому руку подать*
*В минуту душевной невзгоды...*
*Желанья!.. Что пользы напрасно и вечно желать?..*
*А годы проходят – все лучшие годы...*

Ике шагыйрь дә бер үк каләм ияләрен укый, тәрҗемә итә икән, йә аларның зәвыгы бер-берсенекенә туры килә, йә булмаса иҗатын үзенә өлге итеп алганы икенчесенекен тулаем кабул итә, башка әдәбиятларны өйрәнүдә остазына юлкүрсәткеч кебек карый. Шулай да, гомумән алганда, Заһидә Бурнашеваның үз йөзе бар, бер үк русча әсәрләрне кабул итү, аңлауда аерымлыклар да чагымлана. Ике автор башкарган тәрҗемәләрне укыганда, мәсәлән, төрле чикләрдәге ассоциация, күзаллаулар туа.

Рус әдипләре арасыннан мәктәпне Заһидә, үзләштергән белеменә, Тукай иҗатына таянып сайлый һәм кемне кыйбла иткәнен «Минем мәктәбем» шигырендә ап-ачык күрсәтә, һәм Тукайдан нәрсәгә өйрәнүен дә язып уза:

*Тукай абый: «Һаман, һаман алга бар, – ди, –*
*Юлда манигъ күрсәң, тибеп аудар аны,*
*Яшь шагыйрьгә курку, өркү харам ул», – ди.*
*Күтәрергә куша биек авыр тауны.*

Югарыда куштырнаклар эчендә бирелгән юллар Г.Тукайның «Бер татар шагыйренең сүзләре» әсәреннән үзгәртеп алынган:

*Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,*
*Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам;*
*Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,*
*Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам.*

Шигырьнең соңгы икеюллыгында З.Бурнашева Тукайның иң якын дусты булган Ф.Әмирханның «Яшьләр» пьесасындагы геройларын искә ала: *«Чын көрәшкә чыккан яшьләр – Газиз, Йосыф. / Кул сузалар: «Ятма, – диләр, – куркып, посып»*.

Үз чорының шактый кызыклы каләм иясе Мәрьям Мөхетдиния «Габдулла Тукаев әдәбияты» мәкаләсендә: «Күп шагыйрьләр, тормышның бер генә ягын көйләүләре белән, хәят агымыннан аерылган бер зәгыйфь зат тойгысын бирәләр», – дип белдерә һәм хәтта Тукай иҗатларын яхшы белгән Тютчев, Фет кебекләрне генә түгел, остазы һәм тиңдәше күргән Лермонтовны да бер моңда гына иҗат итүчеләр рәтенә кертә, һәм гаять тә кызыклы шушындый нәтиҗә ясый: «Безнең бүген искә төшерә торган милли шагыйребез Тукай тормышның бер генә кылында чиртми». Ә бит Заһидә Бурнашева да хәятның һәр ягын җырлап калырга омтыла.

XX гасырда бик күпләр Г.Тукай вафатыннан соң, урынын нәкъ менә Заһидә Бурнашева алыр дип фаразлаган була. Әйтик, Сәхи Рәхмәти «Гыйффәт туташ мәктүбе мөнәсәбәте илә» язмасында: «Киләчәктә Габдулла әфәнде урынын тотачагы өмид ителгән Заһидә туташ», – дип белдерә. Кызганыч ки, остазын югалтуны авыр кичергән, инкыйлабтан соң партия эшенә нык бирелгән, чорның аяусыз изүе аркасында рухи сынган шагыйрә бу өметләрне акламый, үз чоры шигърияте алдына куелган бурычларны үтәгән шикелле, поэзиядән китә. Алга таба аның аз күләмдә язган поэтик әсәрләре дә романтик рухын, тәэсири мөмкинлекләрен, элеккеге хис-кичереш көчешләрен, образлылыгын, Тукай каләменең көченә тиңлеген югалта. Ул инде Тукайны искә алу уңаеннан язылган «Хатирә» мәкаләсе белән генә бер ялтырап ала.

*Дәвамы бар*

**Рифә РАХМАН,**
*филология фәннәре кандидаты*

*Язучы һәм тәрҗемәче, фронтовик Афзал Шамов (1901-1990) – татар әдәбиятында оригиналь хикәяләр һәм повестьлар авторы буларак танылган әдип. Аның повесть һәм хикәяләре татар әдәбиятының сәнгатьчә югары дәрәҗәдә эшләнгән матур үрнәкләре булып санала.*

*Күптән түгел тууына 115 ел тулган язучының әлеге хикәясе журналыбызда 1945 елның 5нче санында – Бөек Җиңү уңаеннан басылган иде.*



Афзал
Шамов

# ДУСТЫМ КАБЕРЕ ЯНЫНДА

ХИКӘЯ

*Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган дустым Насих Җәгъфәровка багышлыйм.*

*А. Ш.*

Өч ел.

Бу өч ел эчендә минем яшь йөрәгем нинди генә кайгыларны, нинди генә шатлыкларны һәм нинди генә дулкынлануларны кичермәде, ләкин минем беркайчан да, беркайда да бүгенгедәй дулкынланганым, бүгенгедәй тирән хискә бирелгәнем юк иде. Ул болай булды:

Көрәш юлы безне яңадан Литва җиренә алып керде. Алай гына да түгел, без моннан өч ел элек үзебез сугышып үткән участокка килеп чыктык. Бу участокны башлап рота командиры гвардия өлкән лейтенанты Камалов танып алды.

Безнең подразделение, немецларны куып килеп, бер көн эчендә дүрт авылны, дистәләрчә хуторларны азат иткәннән соң, элмә, өрәңге һәм башка шундый яфраклы агачлар белән капланган шушы биеклеккә туктады. Без шунда ук казынырга керештек. Минем взвод моннан өч ел элек казылган, кар-яңгыр сулары белән ашалып беткән, саеккан һәм үлән баскан окопларны тирәнәйтергә дә өлгермәде, Камалов мине үз янына чакырып алды.

Ул, иске, җимерек окоп өстенә терсәкләрен салып, яшь карама ботаклары арасыннан немецлар оборонасына таба текәлеп карап тора иде. Мин сүзсез генә аның янына барып бастым. Ул берникадәр вакыт шулай, минем килүемә игътибар итмәгәндәй, карануында дәвам итте.

— Күрәсеңме? — диде ул аннары, кулы белән алга таба күрсәтеп.

Мин каранырга тотындым. Немецлар белән ике ара ерак түгел иде. Анда, сирәк кенә аксыл чәчәк белән капланган уйсулыкта, яңа гына актарылган снаряд

чокырлары күренә, немец үләксәләре аунап ята. Бер читтә, юл буенда, тәртипсез сибелгән ватык арбалар тирәсендә, немецларның яндырылган бер танкасы әкрен генә пыскып, сүнеп бара. Ә немецлар урнашкан урман артында, еракта-еракта, бүген нигәдер аеруча кызарып, офык итәкләрен кансуландырып, моң гына булып кояш баеп килә. Көне буе ике яктан да дәвам иткән каты атышлар басылган һәм табигать ничектер тынып, талгынланып калган иде.

— Күрәсеңме? — диде Камалов, кабатлап.

— Нәрсәне?

Ул миңа таба гаҗәпләнеп күтәрелеп карады:

— Тирә-юньне. Таныш түгелмени?

Мин бертөрле дә таныш нәрсә күрмәдем. Аннары ул, окобыннан чыгып, мине биеклекнең көнчыгыш ягына алып китте һәм тар гына елга буенда утырып калган дүрт-биш йортка төртеп күрсәтте:

— Ә бу авыл танышмы?

Шунда гына мин тирә-юньне танып алдым.

— Судекяй түгелме соң бу?

— Нәкъ үзе.

Юк, бу авылны, аның тирән, салкын сулы тар гына елгасын минем беркайчан да, бервакытта да онытасым юк.

Без икебез дә берникадәр вакыт шул авылга таба тынып карап тордык. Бу вакыт без икебез дә бер нәрсә турында уйлый идек, һәм икебезнең дә күңелләребездә безне бик озак вакыт борчыган, безгә тынычланырга ирек бирмәгән вөҗдан газабы әкрен генә уяна, үзенең нечкә, үткен тырнакларын безнең йөрәкләребезгә яңадан батыра иде. Шуның белән бергә, безнең күз алдыбызда, моннан өч ел элек булып үткән сугыш картиналары да үзенең бөтен дәһшәте, бөтен куркынычлыгы белән ачылганнан-ачыла бара иде.

... 1941 елның июль ае иде. Безнең дивизия, каты сугышлар белән чигенеп, моннан 10-15 километр чамасында көнчыгыштарак оборонага күчте. Ә без, өч татар егете, өч сугышчы, старшина Шәйхетдинов, ул чагында әле өлкән сержант булган Камалов һәм мин, дивизия командирының турыдан-туры кушуы буенча, дошман тылында разведкада калдык. Без урман арасында, олы юллар буенда өч тәүлек яшеренеп күзәтеп яттык, бу тирәдә яшәүче кешеләр белән очраштык, дошманның көче, аның нинди участокларга туплануы турында бик кыйммәтле мәгълүматлар җыйдык.

Төнлә үзебезнең якка чыккан вакытта, шушы тирән, салкын сулы тар елга буенда, һич тә көтмәгәндә, бер төркем немецлар белән кара-каршы очраштык. Без алардан ничек кенә булса да сугышсыз качып котылырга, эзебезне югалтырга тырышып карадык, ләкин булмады. Алар безне шушы елганың дугаланып килгән бер почмагына кысрыклап керттеләр.

Без, уңайрак урын сайлап, үләннәр арасына постык, фашистлар якынлашалар, — төнге зәңгәрсу караңгылыкта аларның карачкыл шәүләләре аермачык күренә иде. Алар егермедән артык иде.

— Безнең бурыч сугышу түгел,— диде безгә старшина Шәйхетдинов, пышылдап кына. — Җыйган материалларны бик тиз генә кайтарып җиткерергә кирәк. Ә хәзер, күрәсез, безгә коралны ходка җибәрергә туры килә.

Бераздан соң без бер автоматтан, ике винтовкадан залп бирдек. Нәтиҗә начар булмады. Ләкин немецлар, саннары кимүләренә карамастан, килүләрендә булдылар.

Ике арада атыш башланып китте.

Без, артык нәрсәләребезне ташлап калдырып, елганы кичтек. Бәхетсезлеккә каршы, без үзебезнең арт якта да карачкыл шәүләләр күреп алдык. Алар безне ауларга, тотарга телиләр иде.

Шәйхетдинов обстановканы бик тиз үлчәп алды. Ул үзенә хас тынычлык, салкын канлылык белән ашыкмый гына әйтте:

— Безнең беребез монда калырга тиеш. Немецларны тотып торырга. Ә икебезгә — бик тизлек белән мәгълүматларны кайтарып җиткерергә. Задание үтәү — бөтенесеннән дә кыйммәтрәк. Аңлашыламы?

— Кем кала? — дидем мин, калырга хәзер булып.

Шәйхетдинов сүзен дәвам итте:

— Мин калам. Карышмаска. Мин сезгә хәзер үк китәргә приказ бирәм. Мәгълүматларны ничек тә кайтарып җиткерергә. Хушыгыз.

Һәм ул безнең икебезне дә ашыгыч кына кочып үпте. Аннары, якын итеп, җылы итеп, аз гына дулкынланган тавыш белән әйтте:

— Калу турында сорамагыз, дусларым. Мин сезгә караганда картрак һәм тәҗрибәлерәк. Сез яшь әле. Аннары бу эштә минем кулым да ныграк. Ялгыз килеш мин ничек тә кайта алам.

Без киттек. Без, немецларга сиздерми генә, ераклашканнан-ераклаштык. Елга буендагы атышлар, төрле урыннарга күчеп, шактый дәвам итте. Гранаталар шартлады.

Без кайтып җиттек. Мәгълүматларны тапшырдык. Алар, без уйлаганча, бик кыйммәтле мәгълүматлар булып чыктылар.

Ләкин безнең дустыбыз кайтмады. Без аны һәр көнне, һәр сәгатьтә, хәтта һәр минутта өметләнеп көттек. Әмма безнең өмет чаткыларыбыз көннән-көн сүрелде. Ахыры, бер көнне ул тәмам сүнде.

Бер атнадан соң, чолганыштан кайтучы берничә иптәшебез белән бергә, Судекяй авылының бер крестьяны да безнең якка чыкты. Шул крестьян безгә, елга буендагы атышлардан соң, немецларның Судекяй авылында бер яралы совет сугышчысын бик каты газаплап үтерүләрен сөйләде. Аның бу сүзләре безнең күңелдәге соңгы өмет чаткыларын да сүндерде. Сүндерде генә түгел, алар аны үскәннән-үсә барган вөҗдан газабына әверелдерде.

— Ник аның үзен генә калдырдык, — дип газапландым мин.

— Ник үзен генә калдырдык?

Бу газапны мин Камалов күзләрендә дә күрдем. Ул да шундый ук эчке әрнүләр белән яна иде.

Нәкъ шул көннәрдә Шәйхетдинов исеменә бер хат килде. Камалов белән икәү без аны ачып укырга булдык. Хат эченнән открытка зурлыгындагы бер фоторәсем килеп чыкты. Ул рәсемгә дустыбыз Шәйхетдиновның хатыны һәм аның берсеннән-берсе кечкенә булган өч баласы төшкән иде. Балалар аналары янына, күгәрченнәр кебек, тезелешеп утырганнар һәм үзләренең күзләрен безгә таба текәгәннәр. Аларның гөнаһсыз күзләрендә, йөзләрендә шатлыктан башка бернәрсә дә юк иде. Алар ул көнне үзләренең яңа киемнәрен кигәнгә һәм рәсемгә төшү бәхетенә ирешкәнгә шатланган булсалар кирәк. Ә гади генә киенгән, чәчләрен урталай ачып, иңбашына ак шәл салган урта яшьләрендәге хатынның күзләрендә исә рәсем аша да сагыну, аны юксыну моңнары аңкып тора иде.

Бу рәсемгә без берсүзсез калып карап тордык. Ул минутта безнең ничектер бер-беребезгә эндәшергә, рәсем турында нәрсә булса да әйтергә көчебез юк иде. Шат, гөнаһсыз балалар алдында, бөтен тормыш авырлыгын үз җилкәсенә алып калган ана каршында без икебез дә үзебезне гаепле һәм җаваплы сизә идек.

Аннары без хатны укыдык. Хат озын түгел иде. Ләкин ул баштан алып ахырына кадәр өзелеп сагыну белән, чиксез мәхәббәт белән, кеше күңелендә булуы мөмкин булган җылы хисләр белән тулган иде. Без сагынуларның чиксезлегенә, мәхәббәтнең көчлелегенә, җылы хисләрнең тирәнлегенә хәйран калдык.

«Бәгърем, сөеклем! — дигән иде ул хатынын бер урынында. — Күзалмам,

үзеңне саклый күр, сабыйларың өчен, аннары сине өзелеп сагынучы, сөюче, кабергәчә сиңа турылыклы булырга сүз биргән иптәшең өчен саклый күр. Без сине көтәбез. Җиңеп кайтуыңны көтәбез. Балалар һәр көнне иртә белән йокыларыннан: «Әти!» — дип уяналар, кичләрен синең турыда сөйләшә-сөйләшә йокыга китәләр. Бик сагыналар алар сине, юксыналар. Кайчакларында төннәрдә алгы бакчадагы миләш ботаклары җил белән тәрәзәгә килеп бәреләләр. Мин урынымнан сикереп торам, өметләнеп, тәрәзәгә сарылам. Аннары яланаяк килеш кенә капка төбенә йөгереп чыгам. Син кайткансың шикелле тоела. Мин сине менә шулай зарыгып көтәм, бәгърем...»

Камалов хатны укып бетерде һәм аны рәсеме белән бергә яңадан конверт эченә тыгып куйды. Бу минутта аның бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде, аннары ул, тамак төбенә утырган төеренең чишелеп китүеннән куркып, үз-үзе белән дә көрәшә иде.

Шәйхетдинов хатынының шундый сагыну белән тулган берничә хатын алдык. Хәтта аңа иптәшенең хәбәрсез югалуын әйтеп, аның тирән кайгысын уртаклашып җавап язганнан соң да, ике хаты килде. Ул иренең югалуына ышанмый, кайчан да булса бер аның безнең янга, үз подразделениесенә, аннары үзенең семьясы, балалары янына кайтачагына өметләнә иде.

Ул хатлар безнең әрнүләребезне яңартканнан-яңартып тордылар.

Ахырда хатлар тукталды. Айлар, еллар узды. Без каты оборона сугышлары белән Москва янына кадәр чигендек. Аннары, һөҗүмгә күчеп, яңадан Калинин өлкәсен, Белоруссияне үттек һәм Литва җиренә килеп кердек. Бу өч ел эчендә без үз башыбыздан бик күп кайгыларны, бик күп хәсрәтләрне кичердек, үлем белән бик күп мәртәбәләр күзгә-күз очраштык һәм сугыш кырында үзебезнең каныбызны койдык.

Башыбыздан кичерелгән дәһшәтле көннәр, авыр еллар дустыбыз турындагы әрнүләрне, борчылуларны да үзләре белән бергә алып киттеләр. Безнең күңелләребездә аңа карата бары тик чиксез хөрмәт һәм олылау гына калды...

Менә бүген, сугышлар белән яңадан Литвага, Судекяй авылы янына килеп чыккач, безнең күңелләребездәге борчулы уйлар әкрен генә яңадан кузгала һәм үскәннән-үсә башлады. Бу минутта без икебез дә узган көннәр ихтыярында, аның безнең яшь йөрәкләребездә калдырган әрнүле көчләре тәэсирендә идек.

— Менә без кая килеп чыктык, — диде Камалов, уйчанланып. — Кем уйлаган бит. Өч ел. Бик авыр еллар. Бу өч елның миңа һәр сәгате, һәр көне елдай озын булып тоелды. Ә бүген артка, узган көннәргә әйләнеп карагач, әйтерсең, ул кичә генә булып үткән. Әй, гомер, гомер!..

Мин аңа бертөрле дә җавап бирмәдем. Узган гомер миңа да, үзенең авырлыгына, газаплылыгына карамастан, шулай тиз үткән шикелле тоела иде.

Камалов безнең күз алдыбызда яткан тар елгага һәм елга аръягындагы авыл хәрабәләренә караган килеш сүзен дәвам итте:

— Судекяйга бүген ничек тә барып чыгарга кирәк. Бәлки, анда кем дә булса калгандыр. Белүчеләр булуы ихтимал.

Камалов берникадәр вакыттан соң авылга таба китте. Мин окобымда калдым. Ә ул көчәйгәннән-көчәя барган кичке эңгер-меңгер эченә кереп югалды.

Ул анда ике-өч сәгать чамасы булды. Бу сәгатьләр миңа ничектер бик озак, бик озак булып тоелдылар. Мин, вакытны үткәрү өчен, берничә мәртәбә постларны тикшереп чыктым һәм окоплар буйлап йөреп үттем. Аннары, яңадан үз урыныма кайтып, аны көтәргә тотындым.

Ниһаять, Камалов кайтты.

— Йә, ничек, таптыңмы? — дидем мин, аны күреп алу белән үк.

— Таптым.

Мин аның гаять дәрәҗәдә дулкынланган икәнен хәрәкәтеннән һәм ашыгыч кына әйтеп ташлаган шушы бер сүзеннән үк сизеп алдым.

— Теге крестьян сөйләгәннәр дөрес булганмы?

— Дөрес булган. Барысы да дөрес булган.

Мин аннан яхшылабрак, җентекләбрәк сорашырга теләгән идем, ләкин ул, соңыннан сөйләргә булып, батальон командиры янына китте.

Бераздан без җиде егет — бу подразделениеда Шәйхетдинов белән бер вакытта хезмәт итә башлаган, аны яхшы белгән җиде сугышчы — окопларыбыздан бер сүзсез генә чыгып, үсеп торган игеннәр арасындагы сукмак буйлап кыр казларыдай тезелешеп, Судекяй авылына таба киттек.

Алгы кырыйда сирәк кенә атышлар дәвам итә. Тирә-юньне яктыртып, һавага өзлексез рәвештә ракеталар күтәрелә, җир өсте буйлап, дугаланып, эз калдыргыч пулялар оча. Аларның кайберләре, йолдызларга үрмәләргә теләгәндәй, күгелҗем күккә таба күтәреләләр һәм барып җитә алмыйча кинәт сүнәләр. Кай минутларда безнең баш очларыбыздан снарядлар сызгырып үтә, һәм алар, җир өстенә төшеп, ут чәчеп гөрселдәп ярылалар.

Төн — җилсез. Агачлар, үләннәр, барлык үсемлек дөньясы, кинәт туган бу атышуларга һәм шау-шуга гаҗәпләнгәндәй, тынып калган. Аяк астына чык төшкән. Аның дымлы, аз гына салкынчалыгы безнең итекләребез, ботинкаларыбыз аркылы үтеп керә. Ябышкак, чәнечкеле үләннәр, безнең белән бергә барырга теләп, шинель итәкләребезгә ябышалар, аннары, ычкынып, яңадан җиргә ятып калалар. Тирә-юньдә атышлар баруга, шау-шуга карамастан, ниндидер вак кошлар өзеп-өзеп сызгырып, сайрап алалар. Кайдадыр, сазлыкта булса кирәк, ялгыз тартар моң гына, хәсрәтле генә итеп, сузып-сузып кычкыра.

Күк йөзендә йолдызлар җемелди. Еракта,карачкылланып торган, әллә урман, әллә тау өстеннән моң гына булып тулган ай карый.

Һавадан ачы төтен исе, дары исе һәм саз исе аңкый.

Елганы үттек. Тугайлыкка барып чыктык. Таныш бу җирләр, таныш миңа! Алар минем күңелемә мәңге-мәңге онытылмаслык булып сеңеп калганнар.

Менә авыл. Яндырылган йортлар урынында шомлы булып, карачкылланып, мичләр, морҗалар тырпаеп торалар. Без теткәләнеп, тапталып беткән бер бакча аша үтеп, авыл уртасына, анда-санда утырып калган ялгыз йортлар янына барып чыгабыз.

Урамда, җимерек каралтылар, үсеп торган агачлар арасына йөкләр туктаган. Часовойлар, төннәрен йокысыз үткәрергә тиеш булган сугышчылар очрый. Алар безне эндәшеп каршылыйлар һәм күз карашлары белән озатып калалар. Без арбалар, алларындагы азыкларын пошкыра-пошкыра ашаучы атлар арасыннан үтәбез. Подвал шикелле казылып эшләнгән бер таш бина янына барып туктыйбыз.

Камалов, безне калдырып, подвалга төшеп китте һәм ул аннан берничә минуттан ниндидер бер карт белән килеп чыкты. Башына эшләпә, өстенә кыска пиджак кигән, яланаяклы, урта буйлы бу карт безне, үзе белән ияртеп, авыл читенә алып китте.

Берничә минуттан инде без авыл читендәге бушлыкта, ялгыз үсеп торган бер каен төбендә басып тора идек. Җирдә кечкенә генә калкулык. Аның өстен чирәм баскан. Чирәм өстендә кем тарафыннандыр куелган, ләкин инде шиңеп беткән чәчәк бәйләме ята.

— Иптәшләр, — диде Камалов, аз гына калтыранган, дулкынланган тавыш белән, — менә ул монда күмелгән. Монда йоклый…

Без, сүзсез-нисез генә, каскаларыбызны салдык һәм башларыбызны идек. Камалов сүзен дәвам итте:

— Без бүген, өч елдан соң, каты көрәшләрдән соң, яңадан монда килеп чыктык

һәм үзебезнең сугышчан дустыбызның каберен эзләп таптык. Аның тормышының соңгы сәгатьләрен һәм аның ничек һәлак булуын беләсебез килә безнең. Бабай, — диде ул, картка карап, — аның ничек үлүе турында сөйләп бир син безгә.

Бабай, үзенең эшләпәсен салып, аны ике кулы белән учлап тотып, нәкъ минем янда басып тора иде. Аның тулган ай яктысында көмештәй җемелдәп күренгән чал чәчендә, юка һәм тар сакалында, аз гына чыгып торган бөкересендә ниндидер, тел белән әйтеп аңлатып бетереп булмый торган ягымлылык һәм картларча күркәмлек бар иде. Мин аңа карап, бу минутта нигәдер үземнең әтиемне һәм Шәйхетдиновның атасын хәтерләдем. Шәйхетдиновның атасын минем бервакытта да күргәнем юк. Шулай да ул миңа бу минутта шушы чал чәчле картка охшыйдыр шикелле тоелды.

Карт сөйләргә керeште. Ул русчаны начар белә иде. Ләкин без ул әйтәчәк фикерләрне аның сүзләреннән генә түгел, аның интонациясе, аның торышыннан һәм аның барлык хәрәкәтләреннән дә аңлап алдык.

Елга буендагы төнге атышлардан соң, немецлар яраланган старшина Шәйхетдиновны шушы авылга алып кайтканнар һәм аннан сорау алырга керешкәннәр. Ләкин Шәйхетдинов аларга бертөрле дә җавап бирмәгән. Шуннан соң аны ике немец кулларындагы резина таяклары белән аңыннан яздырганчы кыйнаганнар. Егет егылган, озак аунап яткан. Аңына килгәч, немец офицеры аннан тагын сораган:

— Иптәшләрең кайда синең? Кая киттеләр алар? Нинди мәгълүматлар алып киттеләр?..

Егет җавап бирмәгән.

— Юк, — дигән ул аларга нәфрәт белән, — мин сезгә, фашист этләргә бертөрле дә җавап бирәчәк түгелмен!.. Мин — совет сугышчысы! Мин иптәшләремне, Ватанымны сатмыйм!..

Шуннан соң аның кулларын, аякларын каерганнар, колагын кискәннәр, бер күзен чыгарганнар, кыздырылган тимер белән аркасына биш почмаклы йолдыз ясаганнар. Шулай да фашистлар аннан берничек тә җавап ала алмаганнар. Безнең дустыбыз, совет сугышчысы старшина Шәйхетдинов искиткеч әрнеп, газапланып һәлак булган, ләкин ул үзенең Ватанына, антына тугрылыгын бер генә минутка да, бер генә секундка да онытмаган, совет солдатының намусын, аның горурлыгын соңгы сулышына кадәр саклаган.

Гитлерчылар аның гәүдәсен кырга чыгарып ташлаганнар. Күмәргә рөхсәт итмәгәннәр. Төннәрнең берендә батыр егетнең мәете югалган. Аны кемнәрдер менә шушы ялгыз каен төбенә яшеренеп, хөрмәтләп һәм олылап күмгәннәр.

— Корыч йөрәкле егет, — дип атаганнар аны литвалылар.

Шулай ук кемнәрдер бәйрәмнәрдә безнең корыч йөрәкле дустыбыз каберенә, немецларга күрсәтми генә, чәчәкләр дә сала башлаганнар. Немецлар һәм аларга сатылган түбән җаннар, ачулары килеп, сүгенеп, кабер өстендәге чәчәкләрне алып ташлаганнар, чәчәк бәйләмнәрен салучы билгесез кешеләрне кулга алулар, җәзалаулар, хәтта атып үтерүләр белән куркытканнар. Ләкин куркытуларның файдасы булмаган. Немецларга үч итеп, икенче төнне үк кабер өстендә яңа чәчәкләр пәйда булган. Менә хәзер дә аның кабере өстендә, тулган ай нурлары астында, картның сүзләренә шаһит булып, бер бәйләм чәчәк ята.

Чал чәчле карт безгә менә шуларны сөйләде. Без җиде егет, җиде сугышчы, аның салмак, ләкин аз гына гыжлап чыккан картларча тавышын сулуларыбызны да алмыйча тыңлап тордык. Мин дустымны, аның кеше җаны күтәрә алмаслык газапларны, әрнүләрне күтәрүен, үзен әкияттәге баһадирларча горур һәм батыр тотуын, дошман алдында тез чүкмәвен һәм күз яше күрсәтмәвен бөтен нечкәлекләре белән күз алдыма китердем.

— Без барыбер җиңәчәкбез!.. Хакыйкать безнең белән!

Аның соңгы минутларда әйтелгән шушы сүзләрен мин бик ачык, бик ачык ишеткәндәй булдым. Әйтерсең, ул безнең алдыбызда басып тора һәм безне шулай сүзләр белән көрәшкә, алга, дошман өстенә барырга чакыра иде.

Картның сүзләрен тыңлаганда, кай секундларда минем тәннәрем чымырдады, кай секундларда бөтен тәнем йә салкын, йә кайнар тиргә батты. Ә үзем, тамак төбенә өерелеп килгән төерчекнең ычкынып китүеннән, кинәт кычкырып җылап җибәрүемнән куркып, кулымдагы каскамны бөтен көчем белән чытырдатып кыстым. Ирексездән килгән күз яшьләремне, иптәшләремә күрсәтмәскә теләп, йоттым.

Без һичбер командасыз, берәү дә әйтмичә, корыч йөрәкле дустыбызның кабере алдына тезләндек.

— Дустым! — диде Камалов, бик нык дулкынланып. — Без синең каберең янына үзебезнең соңгы сәламебезне җиткерергә, сиңа булган чиксез хөрмәтебезне, олылавыбызны белдерергә килдек. Без сине өч ел буенча күңелебезнең түрендә сакладык. Моннан соң инде синең батырлыгың безне көрәшкә, дошман өстенә алып барыр, ул безнең рәхимсезлек һәм үч алу байрагыбыз булыр. Синең исемеңне, синең батырлыгыңны без гомеребезнең иң соңгы минутына кадәр онытмабыз. Без, синең дусларың, коралдаш иптәшләрең, кабер туфрагыңны үбеп, ант итеп әйтәбез: без синең өчен, синең һәр тамчы каның өчен, һәр бөртек чәчең өчен дошманнан үч алачакбыз. Үч, үч, үч!..

Камалов шул сүзләрне әйтә-әйтә, кабер туфрагын өч мәртәбә үпте. Без дә, шул ук сүзләрне кабатлап, аның изге туфрагына үзебезнең җилдә, кояшта ярылган иреннәребезне тидердек.

Аннары без, көрәкләребезне алып, беребезгә бер сүз эндәшмичә, Һәркайсыбыз бердәй уйга батып, кабер туфрагын тигезләп күтәрдек. Һәм чәчәкләр җыеп килеп, аны чәчәкләр белән күмдек.

Ул арада карт өенә кайтып китте һәм аннан ак киндергә төргәләгән бер әйбер алып килде. Кабер янында туктап, ул аны ашыкмый гына чиште. Аның эчендә груша агачыннан ышкып, сырлап ясалган, бик матур биш почмаклы бер йолдыз ята иде.

— Бу йолдызны мин куркынычлы көннәрдә ясадым, — диде карт, безгә таба карап. — Мәгез, алыгыз. Корыч йөрәкле егеткә минем бүләгем булсын! Мин сезнең киләчәгегезне белдем. Кояш Москва ягыннан чыга, дидем мин. Хакыйкать алар ягында…

Берничә минуттан без, дустыбызның кабере белән саубуллашып, үзебезнең окопларыбызга таба киттек. Бу вакытта инде күк йөзе алсуланган, табигать уянган, көнчыгыштан, Москва ягыннан, әкрен генә, мәһабәт кенә булып, алтын нурларын сирпеп, кояш чыгып килә иде.

*Май, 1945 ел. Германия*

---

**Төзәтү**

«Казан утлары» журналының быелгы 3нче санында, 107нче биттәге рәсем астын түбәндәгечә укыгыз: «Бер төркем журналист-язучылар һәм сәнгать вәкилләре Татарстан телевидениесе студиясендә. Алдагы рәттә, сулдан уңга: Заһид Хәбибуллин, Кәүсәрия Котдусова, Венера Ихсанова, Мәхмүт Хөсәен, Әнәс Хәсәнов; басып торалар: Хәмзә Зарипов, Роберт Батуллин. Үткән гасырның 70нче еллары».

# ЯРАТЫП КИТҮ



Еллар аны әйтерсең лә урап узган... Һаман да шул ук нәфис буй-сын, нур чәчеп торган елмаюлы күзләр, җиңел-җитез адымнар... Үз бәһасен белгән хатын-кыз гына тормыш ваклыкларына бирешми, еллар каршысында баш имичә, вакыт белән гармониядә яши ала. Хак Тәгалә сине, башкалардан өстен куеп, талант югарылыгына күтәргән икән – баш ию сине яраткан, сине рухландырган, талант икәнлегеңне таныган тамашачың, халкың алдында гына булырга мөмкиндер. Андый горур, рәхәт баш июләр аның тормышында аз булмаган. К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы гына да сәхнәдә биш йөз тапкыр уйнала. Флёра-Сәрвәр биш йөз тапкыр Сәрвәр булып яши, Сәрвәр булып үлә. Флёра Хәмитованың иң беренче роле – К.Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә Мөршидә. Тик тамашачы аны актриса буларак Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә Сәрби роле аша ача. Мөлаемлыгы, рольне үзенеке итеп кабул итә белүе тамашачыда үзенә карата ышаныч тудыра. Артистканың гаҗәеп матур тавышы, моңы аңа «Ак калфак»та Хәмдияне, «Зәңгәр шәл»дә Мәйсәрәне уйнау мөмкинлеге бирә. Тик артист гел бертөрле генә рольләрдә уйный икән – ул аңа бик тиз ияләшә, анда эзләнү, үсеш тукталып калырга, тамашачы өчен дә, үзе өчен дә кызыксызга әйләнә башларга да мөмкин. Режиссёр М.Сәлимҗанов әнә шуны күздә тотып, алдагы рольләренә капма-каршы булган, К.Тинчуринның «Американ» сатирик комедиясендә Дилбәр ролен бирә. Тамашачы бу образ аша үз-үзен генә яратучы, тышкы кыяфәте белән үк тискәре фикер уятучы кызны күрә. Н.Асанбаевның «Канат җәйгәндә» спектаклендәге Мәрьям образында Ф.Хәмитова үзенең инде өлгереп җиткән артистка икәнен раслый ала. Болардан тыш әле тамашачы яратып калган, М.Әмирнең «Тормыш җыры»нда – Халидә, «Миңлекамал»ында – Гайни, Д.Вәлиевнең «Үзеңә хыянәт итсәң»дә – Гөлсем, Т.Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү»ендә – чая Саҗидә һәм башка тагын дистәләгән рольләр. Соңгысы исә сәхнәдә 600 тапкыр уйнала! Артистка һәр ролен яратып искә ала. Н.Исәнбәтнең «Зифа»сындагы Кәләмсә роле турында сүз чыккач кына: «Нишләптер Кәләмсә – минем җанга, мин аның җанына үтеп керә алмадым. Әллә Камская уйнаганын сокланып караганым булгангамы, күз алдыма ул килә дә баса», – ди, бераз моңсуланып. Ниһаять, Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е... Күпләр хыялланган Мәйсәрә... Һәр чорның, һәр артистканың үз Галиябануы, үз Мәйсәрәсе. Флёра Хәмитованың артистка буласы, Мәйсәрәне уйныйсы язмышына язылган, күрәмсең. Әле мәктәптә укыганда ук Сәйдәшнең, фәрештә канаты белән кагып узгандай, хорда җырлаучы дистәләгән бала тавышы арасыннан аерып, сабыйның аркасыннан кагып: «Бәгырь, син әле Мәйсәрәне уйнаячаксың», – дигән сүзләре теләкләр кабул була торган бер вакытта әйтелмәгәндер дип кем әйтә ала! Ышанмый кара син шуннан соң язмышка! Тик Ходай Тәгалә, каршысына ике юл куеп, адәм баласына сайлау мөмкинлеге дә бирер ди. Язмыш юлыңның кайсын сайлыйсың – монысы инде синең үзеңнән тора. Казан шәһәренең 51нче урта мәктәбен тәмамлагач (Ф.Хәмитова 1936 елның 2 маенда Казанда туа), укытучы булу теләге белән педучилищега укырга керә.



*К.Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар».*
*Исмәгыйль — Н.Әюпов,*
*Сәрвәр — Ф.Хәмитова.*

Мәктәптә укыганда ук аңа «Отелло»ны карау мөмкинлеге туа, укытучылыкка барса да, ул вакытта алган тәэсирләр, сәхнәнең сихри көче кызның күңелен һаман да алгысытып, җилкетеп тора. Тагын язмыш дими ни дисең – 1956 елны Мәскәүгә Щепкин исемендәге театр училищесына студентлар җыюлары турында игълан күрә, өстәвенә педучилищедагы мөгаллиме Вәли Хаҗиев та: «Җырлый беләсең, бии беләсең, сөйләмең матур», – дип кызга канатлар өсти.

Һәр буын иҗат кешеләре – әдәбияттамы ул, сәнгатьтәме – үзләре белән ниндидер яңалык алып киләләр. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел! Моны чор, буыннар алмашы үзе үк таләп итә. Заман башка, тамашачы башка. Аңа үзгәреш, үзгәлек кирәк. Мәскәү хәтле Мәскүдә укып кайткан яшьләрдән күпне таләп итәргә Г.Камал исемендәге академия театрының да, тамашачының да хакы бар. Театрны театр иткән әйбер – бердән, актёрлар булса, икенчедән, репертуар. Ә безнең халык хисле, самими. Сәхнәдә аңа саф мәхәббәт, тугрылык, гаделлек сурәтләнсен. Ф.Хәмитованың Мәйсәрәсе дә, Сәрвәре дә, Хәмдиясе дә – әнә шундыйлардан. Актриса героинясы белән шулкадәр гармониядә яши ки, хәтта ул «Сүнгән йолдызлар»ның ничек башланып китәсен, ничек итеп Сәрвәрнең көлә-көлә сәхнәгә йөгереп чыгасын режиссёр Марсель Сәлимҗановка үзе тәкъдим итә.

Төп рольләрне уйнау – һәр артистның хыялы. Күмәк рольләрдә генә йөрер өчен беркем дә артист булырга ул кадәр омтылмыйдыр, һәркемнең кешеләр хәтерендә калырлык образ тудырасы килә, шулай булмаса, синең артистлыгыңны вакыт җилләре бик тиз юкка чыгарачак. Күп хатын-кыз актрисалар хыялланган Мәйсәрә роле, бер караганда, җиңел генә – җырлы-биюле роль кебек кенә тоелса да, һәркем аны үзенчә тудыра. Флёра Хәмитованың Мәйсәрәсе, ятим бала булуына карамастан, шат күңелле, кешеләргә ышанучан, тормышны яратучы, дуслары белән яхшы мөгамәләдәге тыйнак-сөйкемле татар хатын-кызларының үрнәк образы. Моңлы тавышы җырлы-музыкаль драмаларда уйнаганда режиссёр өчен чын мәгънәсендә табыш була. Кайбер артистлар тудырган образлар үзе сәхнәдән киткәнче үк тә онытыла. Аның Мәйсәрәсе, Сәрвәре әле һаман да күпләрнең хәтерендә.

Китү дигәннән… 24 ел буе сәхнәдә йолдыз булып балкыган бер чорында ул театрдан китәргә карар кыла. Кемдер моны яшь, чибәр героиняларны гына уйнаган актрисаның өлкәннәр роленә алынасы килмәүдән дип уйласа, кемдер исә (репертуарның да яңа әсәрләргә кытлык чоры булып ала) аның амплуасына туры килерлек рольләр булмаганлыктан дип тә гөманлый. Ни сәбәпле икәнен бер Ходай Тәгалә һәм дә үзе генә беләдер. Артистның сәхнәдәге язмышы режиссёр кулында, дисәләр дә, ул аны үзенчә дә хәл итә ала. Киткәненә бәлки әле сөенеп кул чабучылар да булгандыр. (Алкышларның андый төре дә була!) Театр дөньясы – аллы-гөлле утлар балкышы, көчле алкышлары белән генә түгел шул ул! Әнә бит, атаклы сатира остасы Гамил Афзал «Театрда» дип исемләнгән шигырендә нәрсә ди: «Халык китә, утлар сүнә, тынып кала бу кичәләр. Ак Фәрештә, Кара Елан бергә утырып чәй эчәләр». Әйе, сәхнә артында да тулы бер тормыш. Сәхнәнең ал ягында автор тудырган язмышны сурәтләсәң, янәшәдә үк табу-югалтуларга, әрнү-газапларга уралган үз тормышың. Сәхнә әйләнә-әйләнә дә ирең булган кеше – Дилүс Ильясовны – Х.Вахитның «Кайда соң син?» әсәрендә Шәүкәт,

сине Сәрия итеп тә куя. Күңел сәхнәсенең иң түрендә татар театрының атаклы артисткасы – каенанасы Гөлсем Камская! Фаҗигале язмышка ия булган, 1934-1936 елларда академия театрында режиссёр булып эшләгән каенатасы Гали Ильясов. Теләсә, теләмәсә дә көндәшенең һәр адымына күз ташларга мәҗбүр булган (соңыннан исә аралары җылына), күпләрне дер селкетеп торган Гәүһәр Камалова... Артист буларак үсүең шәхси тормышың белән дә бәйле икән, инде син шундый талантлар арасына килеп кергәнсең икән, кем әйтмешли, талантлы булмаска просто хакың юк! Әле иртән генә, яшәештәге кайбер мәсьәләләрне хәл иткәндә үпкәләшеп чыгып киткән ирең белән кичкә инде син бер-берсен өзелеп яраткан парлар ролен башкарырга тиеш буласың. Иртәнге кәеф тә, тавыш интонациясе дә биредә чагыла алмый. Сәхнә кануннары аяусыз! Театрда кавышып, аннан аерылышып та бер-берсен өзелеп сөйгән ярларны уйнаган парларны да күрде тамашачы. Сүз дә юк, Дилүс Ильясов белән унҗиде ел бергә яшәлгән тормышында нинди генә хисләр кичерелмәгәндер. Талантлар каршылыклы була, дибез. Ике талант иясе бер түбә астында, бер сәхнәдә дә булса... Хатынына соклану белән бергә күпмедер дәрәҗәдә көнләшү дә булгандыр, бәлки... «Бу турыда хәзер, еллар узгач, кайта-кайта уйланам. Юкса без Наил Әюпов белән «Сүнгән йолдызлар»ны уйнаганда, сәхнә читеннән генә карап торыр идеме? Наил-Исмәгыйльнең кочагына сыенып бетеп ярату аңлатуым күңеленә тими калмагандыр. Театрда артист булса да, өйдә ир бит ул. Үзе исә тел белән түгел, күз карашы белән генә дә тискәре мөнәсәбәт сиздермәде, киресенчә, мине нәрсәдәндер саклаган кебек иде, Мәйсәрәне уйныйсы көнем булса, балаларга артык шаулашмаска куша иде», – дип искә ала Флёра Хәмитова ире, балаларының атасы, Татарстанның халык артисты Дилүс Ильясовны. Тамашачы исә тиздән Флёра ханымның аңа багышланган фотоальбомын күреп сөенәчәк, бу да мөнәсәбәтләрнең зурлыгы, игътирам, хөрмәт турында сөйләмиме?



*Т.Миңнуллин. «Диләфрүзгә дүрт кияү». Галим — Д.Ильясов, Саҗидә — Ф.Хәмитова.*

...Т.Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә» спектакльләрендә уйнаса да, соңгысы – «Хушыгыз»да уйнарга туры килми аңа... гәрчә әлеге әсәр аның үзе турында булса да! Бәлки, тулаем ук та түгелдер, тик Флёра Хәмитованың театрдан киткәндә, ачынып: «Хушыгыз!» – дип әйтүе авторга әлеге әсәрне язарга этәргеч бирә. Спектакльне күз яшьләре аша караганда, нинди хисләр кичергәнен ул үзе генә белгәндер...

Театр белән хушлашса да, әлеге яратып китү аны сәнгать дөньясыннан еракка алып китми. Кайчандыр, әле иҗатының гөрләп чәчәк аткан бер чорында, әбиләр роле ят тоелса да, барыбер уйнарга туры килә аңа ул рольне дә. Тик ясалма картайтылган, гримнар ярдәмендә тарттырылып китерелгән өлкәнәю түгел инде бу «Яланаяклы кыз» телеспектаклендәге Дилбәрнең дәү әнисе! Үз яшенә, эчке халәтенә туры килүче, оныклар белән ике арада була торган җылы, мөлаем мөнәсәбәтне тудыручы дәү әни ул биредә. Чын безнеңчә, милли дәү әни!

...Сәхнә әйләнә-әйләнә дә аны тагын язмышына язылган юл башына – укытучылыкка кайтарып куя. «Һөнәрле – үлмәс» дип тиккә әйтми шул халык. Менә 32 ел инде ул Казан дәүләт мәдәният институтында, Әухәдиев исемендәге Казан музыка көллиятендә булачак сәхнә осталарына сәхнә теленнән һәм актёрлык осталыгыннан дәресләр бирә. Әйе, еллар аны чынлап та урап уза, ахры. Аңардагы энергиягә, хәтер ныклыгына, һәр



*Ф.Хәмитова үзенең студентлары белән.*
*Казан дәүләт мәдәният институты, 2016 ел.*

туган көнгә сөенеп яшәвенә сокланмый мөмкин түгел. Студентлар белән эшләгәндә, татар шигърияте – аның өчен төп җирлек. Шигърият аша ул аларга телебезнең байлыгын, матурлыгын ачарга ярдәм итә, яратырга өйрәтә. Туган телне начаррак белүче шәһәр балалары да яннарында Флёра Харис кызы кебек остаз булганда югалып калмый. Һәрдаим яшьләр арасында булу, аңа чынлап та вакыт агышын сиздерми, чыгарылыш арты чыгарылыш, бәйге арты бәйгеләргә студентларын әзерләргә көч-куәт биреп тора. Татар әдәбиятының күренекле шагыйрьләре Н.Дәүли иҗаты буенча «Бәхетлеме кеше дөньяда?», И.Юзеевның «Шагыйрьләр нигә картаймый?», Р.Фәйзуллинның «Сәйдәш», «Гадиләргә гимн» һәм башка олуг шагыйрьләрнең әсәрләре буенча куелган әдәби-музыкаль композицияләр, бүгенге көндә әзерләнүче «Тукайча татар кодексы», Г.Исхакый әсәре буенча «Тормышмы бу?» дип аталган әдәби композицияләрне әзерләү студентлар белән араны тагын да якынайта, аларда иҗади фикер йөртү сәләтен арттыра. Студентлары арасыннан Зөһрә Шәрәфетдинова остазы турында менә нәрсәләр ди:


«Флёра апа Хәмитова безне Казан музыка көллиятендә актёрлык осталыгы серләренә төшендерә. Ул ягымлылыгы, самимилеге, таләпчәнлеге белән башка педагоглардан аерылып тора. Ишекне ачып керүгә, безне елмаеп каршы ала. Репетицияләр вакытында гел әйтә килә: «Сәхнәдә артист халыкны үзенең күз карашы белән җәлеп итәргә тиеш, күзләр бик күп нәрсәләрне сүзсез генә аңлатып бирә», — ди. Ул безгә һәрдаим акыллы киңәшләр бирә, дөрес аралашырга, төз, матур йөрергә өйрәтә. Нинди генә ярдәм сорасаң да, кире борып җибәрми... Аның белән әни белән сөйләшкән кебек сәгатьләр буе гәпләшеп утырырга була... Репетиция барганда тавышланып утыручылар булса, бер тапкыр күзгә карап ала да, җиңелчә генә ачуланып, рәхмәт дип әйтеп куя торган гадәте дә бар әле... Флёра апага кечкенә генә яхшылык эшләсәң дә, аннан ихлас рәхмәтләр ишетәсең. Кәефе булмаса да, авырса да, башын беркайчан да аска иеп йөрми. Флёра Хәмитова чын мәгънәсендә абруйлы, тәҗрибәле, зыялы шәхес».

Чынлап та, сәхнә теле буенча анда укыганнар сәхнәдә башкалар арасында аерылып торалар. Сөйләмнәре ачык-аңлаешлы, басым, сулыш алулары, татар орфоэпия кагыйдәләре урынлы, дикцияләре төгәл. Сөйләмендә ул үзе дә сүзгә шулкадәр сак карый – сүзләрнең әңгәмәдәше күңеленә ята торганын, матурын кулланып сөйләшкәне сизелеп тора. Кайчандыр «Татарстан» радиосында ул алып барган «Тел күрке – сүз» тапшыруларын да искә төшерсәк, Татарстанның атказанган артисткасы Флёра Хәмитованың ана телебезне никадәр яратуын, зурлавын күрә алабыз. Бүгенге көндә дә телгә – сәнгатькә чын күңелдән бирелгән, милләт балалары дип аталырлык шәхесләр тәрбияләп калдыру. Бирсен Ходай!

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА,**
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

# ИЗГЕ СӨТКӘ НИ ҖИТӘР?

*Ни газизрәк – бу Ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкаддәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!*
*Изге сөткә ни җитәр!*
*Сөт калыр, Ватан китәр.*
Дәрдемәнд



Искиткеч тирән фәлсәфи фикер иясе, шагыйрь Дәрдемәнд куйган бу сорауда гаҗәп тирән мәгънә ята. Изге сөт ул буыннар җебе белән бәйләнгән, татар кавеменең мәңгелек чыганагы. Ул мөкатдәс, кан белән сугарылган, татарның тарихи хәтерен, гүзәл сыйфатларын, җыр-моңын, шатлыгын да, кайгы-хәсрәтләрен дә үз эченә сыйдырган. Татарның мәңгелеген барлыкка китергән гамәл ул. Аңа тиңдәш бернәрсә дә юк.

Ни газизрәк, Ватанмы әллә туган кавемме? Дәрдемәндкәчә мондый сорауны берәү дә куймый. Чөнки Ватанның газизлеген һичкем дә инкяр итми, киресенчә, аңа һәрвакыт дан җырлана. Шагыйрьнең үзе өчен дә Ватан хисе якыннан-якын, газиз. Шунлыктан ул кавеменә өстенлек биргән өчен Ватаныннан гафу үтенә сыман.

*И туган илнең һавасы,*
*Рәнҗемим, зинһар, күтәр,*
*Рәнҗемим, зинһар, күтәр.*

Нилектән аңа туган кавем газизрәк? Чөнки ул — мәңгелек, ә Ватан — вакытлы гамәл. Ул була да, бетә дә. Бер Ватан урынына башкалары барлыкка килә, «исә җилләр, күчә комлар... бетә эз».

Моның сәбәпчесе — төрле дәверләрдәге татар кавеме. Ул мең еллар кысасында дистәдән артык ватан-дәүләт булдырган һәм аларны тарихи хәтеренә сеңдереп, изге сөт аша буыннан-буынга күчереп, үзенең дәвамчылыгын тәшкил иткән. Аны дәүләти халыкка әверелдергән.

Кавем чын-чынлап газиз. Чөнки ул, гасырлар дәверендә утны-суны кичеп, тарихта чарланган. Аның кан белән сугарылган изге сөте үз эченә татарның бөтен барлыгын сеңдергән. Монда мөкатдәс кавемнең бөеклек һәм коллык чорлары да, барысы да бар. Анда — Колшәриф хәзрәт һәм аның белән бергә дошманга каршы Казан өчен ваемсыз сугышта баһадирларча шәһит киткәннәр дә, Сөембикәнең фаҗигале язмышы да, кавеменең күкрәк киереп, үз-үзләрен аямастан хан сараен дошманнан сакларга чыккан һәм шунда һәлак булган кызларының да эзләре калган. Әнә шул каһарманлык изге сөт аша татарга буыннан-буынга күчә килгән. Бу изге сөткә ни җитсен?!

Татарның холкы, гореф-гадәтләре, түземлек, сабырлык кебек күркәм сыйфатлары сеңгән монда. Болар, гомумән, аның күңел байлыгын тәшкил итә. Монда аның аһ-зары да, кайгы-хәсрәтләре дә, шатлыклы мизгелләре дә — барсы да бар.

Аларның күбесе бетмәс-төкәнмәс җәүһәрләр тезмәсе рәвешендә халык иҗатына күчкән, җыр-моңга әверелгән. Татар моңы — ул үзе шаккатырдай бер могҗиза. Ул гади музыка яки төрле көйләр җыелмасы гына түгел. Бу төшенчәнең башка бер телгә

дә тәрҗемәсе юк. Ул үз эченә халыкның эчке кичерешләре белән бергә бай тарихын да сеңдергән. Анда — тарихыбызның яңгырашы, дөньяны таң калдырырдай аһәңе. Анда — табигатьнең үз моңы, курайга сеңеп калган дала тынлыгы һәм яңгырашы. Ул үз эченә татарның бөеклек чорын да, кан-яшь коеп яшәгән коллык дәверен дә туплаган. Кыскасы, аның искиткеч гүзәллеген табигать һәм тарих бергәләп барлыкка китергәннәр.

Әйе, изге сөткә ни җитә? Һични дә җитми шул!

Кытайлар, японнар, гомумән, Ерак Көнчыгыш халыклары аны әнә шул могҗизавилыгы сәбәпле кабул иткәннәрдер, күрәсең.

Бервакыт безнең тарих факультетында стажировка үтүче кытай профессоры Чянь-Бин: «Ә бит бездә сезнең музыкагыз. Без аны сездән алып, бөтен Ерак Көнчыгышка тараттык, япон утрауларына кадәр җиткердек», — дигән иде.

Бу чыннан да шулай. Профессор Марсель Бакировның хезмәтләрендә Кытай императорларының төркиләр янына, аларның көйләрен язып алу өчен композиторлар җибәрү фактлары күрсәтелгән.

Ни гаҗәп, ләкин хакыйкать шундый ки: шушы төрки моңны бөтен тулылыгы белән тик татарлар гына саклап калган. Аны Алтай якларыннан Казан тирәсенә килеп урнашкан кабиләләр алып килгәннәр дип фаразлана. Шулайдыр. Дәрдемәнд моны нәкъ шулай тоемлаган, шуның өчен аңа дан җырлаган.

Шушы ук тоемлау Тукайга да хас булган. Бала чагында урман буенда ат көткән вакытларында Сәйфетдин вә Гайнетдиннәрнең учак кырыенда «җырлаган җырлары һәм дә моңлы күңелләреннән чыккан хиссият утлары минем йөрәгемә тәэсир итәләр иде», бу «җырлаулар» минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар», — дип язган ул, тарихыбызны тоемлап. Менә шуның өчен дә ул халык иҗатына, аның җыр-моңына гашыйк булган. Аны тыңлаганда «аркадан каннар йөгерә» дип язган ул. Һәм укучыларын аның «алтынын коймаска» өндәгән. «Халык моңнары» рисаләсендә шагыйрь милли моңнарыбызны халыкның тарихи хәтере рәвешендә күзаллый. Әйтерсең лә аның җанына һәм тәненә тарих үзе сеңгән!

Моңыбызның тарихыбызны эченә сеңдерү сыйфаты шагыйрьнең «Милли моңнар»ында бигрәк тә ачык тасвирлана. Берәү (бу берәү дигәне «Болгар» номерларындагы күршесе шагыйрь Сәгыйть Рәмиев) җырлый, ә шагыйрьнең күз-алдына чал тарих килеп баса. Әйтерсең лә аның үз күңеленнән дә «сызылып-сызылып» милли хисләр сугарылган әнә шул җыр чыга. Гүя ул җырчыга кушылып үзе дә җырлый, халкыбыз тарихын күз яшьләре белән диярлек барлый, җырчы белән бергә үзе дә «өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә татар күңеле ниләр сизгәнен». Бу — шагыйребезнең эчке дөньясына сеңгән изге сөт гамәле. Аңа ни җитә!

Шикләнмичә әйтә алам, моңыбыз эзеннән китсәң, татар тамырының борынгы бер очына чыгачаксың. Нәкъ Тукай язганча. Алар — бабаларыбыз тарафыннан калдырылган «иң кадерле вә бәһале бер мирас» һәм «халкыбыз күңелендә «һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф раушан көзгеседер».

Татарлар, күрәсең, моңнан яралгандыр. Моң, эчке кичерешләр чыганагы буларак, тышка ыргыла, халык иҗатына әверелә. Һәм шул рәвештә гүзәл шигъриятебезнең барлыкка килүенә дә сәбәп була.

Татарлар моң иясе генә түгел, шигъри халык та. Ул тудырган иҗат шулай ук тирән тамырлы. Татар күңелендә моң шигърияткә үрелгән һәм шуның нәтиҗәсендә кавемнең үз җырлары барлыкка килгән.

Җыр-моңның телебезгә иксез-чиксез йогынтысы булуы шиксез. Мөгаен, беренче төрки аваз шул моңнан барлыкка килеп, телебезне тел итүгә үз өлешен кертkәндер дә. Болар, игезәкләрдәй, гүзәлләр, аерылмас мәңгелек гүзәл юлдашлар.

Тел адәм баласының җанына ана сөте аша кереп урнашкан. Аны юкка гына «ана теле» димиләр. Тел ачылу дигән төшенчә нәкъ шуңа ишарә. «Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән». Ана кеше моң аша баласының Аллаһы Тәгалә биргән туган телен ача. Ә әбисе мавыктыргыч әкиятләр белән аны баланың күңелендә ныгыта, анда матур итеп урнаштыра.

Болар барысы да — изге сөт җимешләре. Аңа ни җитә! Алар безнең искиткеч зур

хәзинәбез. Бүген безгә, ни кызганыч, шуларны аңлап, күңелебездә ныгытып яшәү җитми. Шушы хәзинәне бөтен тулылыгы белән саклый алмыйбыз. Хәтта ки күп вакыт аңламастан гомер кичерәбез.

Бүгенге җырларның күбесе бернинди мәгънәгә ия булмаган сүзләр тарафыннан әсирлеккә алынган. Алар тик булыр-булмас такмаклар гына. Җырчылар заманындагы кебек чын талантлар арасыннан берәмтекләп түгел, массакүләм рәвештә «фабрикалардан» чыга. Алар күп һәм бергәләшеп, ярыша-ярыша, ата-бабаларыбыздан калган хәзинәбезне телгәлиләр. Ә чын мәгънәсендәге милли җанлы җырчыларга татар эстрадасында урын юк. Алар бар. Аллага шөкер, әле Зөһрә Сәхәбиева, Флёра Сөләйманова, Искәндәр Биктаһиров, Мирсәет Сөнгатуллин, Рафаил Ильясов кебек затлы җырчыларыбыз, моң сакчылары бар. Алар яшьләр арасында да бар. Аларга тик тиешле игътибар гына җитми. Аларның тавышлары радио һәм телевидение аша бик сирәк яңгырый[1]. Ярый әле ГТРК татар радиосында аларны еш ишетергә була иде. Инде хәзер аның да һәммә кешегә ирешердәй дулкыны юкка чыкты.

Миллилек, милли моңнар сагында торучы эшен бик тә уңышлы алып баручы «Тәртип FM» радиосы халкыбызның куанычы булып тора. Ләкин ул бердәнбер.

Кайберәүләр, яшьләргә андый иске җырлар кирәкми, димәкче булалар. Нигездә исә бу рәвешләр акча сугу фабрикасын гына хәтерләтә. Бәлки, бу — изге сөтебезнең әчи башлавыдыр? Алла сакласын!

Ә бит бүгенгеләрнең бурычы буыннан-буынга күчеп, баетыла килгән җыр-моңыбызны түкми-чәчми киләчәк буыннарга җиткерүдән гыйбарәт. Татар моңын гаҗәеп сәләтләре белән камилләштереп, милләтебезнең үзенә кайтарып бирүче Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Заһит Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова, милли моң белән сугарылган композиторларыбыз! Бүген андыйлар бармы? Кемнәр һәм кайда аларның дәвамчылары? Алар бар, юк түгел, тик аларга да мәйдан бирелми.

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.*

Тукайның бу шигъри юлларын халык җәүһәрләрен саклап калуга өндәү итеп кабул итәргә кирәк. Тормышта уен-көлкегә дә, халык иҗатындагы кебек үк, урын булмый тормый. Ләкин Тукай, аларны һич кенә дә инкяр итмәстән, һәрвакыт диярлек халык күңелләрен кузгата, аның нечкә кылларын тибрәтә торган көйләргә өстенлек биргән.

Телебезгә карата да шундый ук мөнәсәбәт булырга тиеш. Татар теле бүген бик авыр чорын кичерә. Ул дәүләти тормыштан гына түгел, хәтта гаиләләрдән дә китеп бара. Ана телләрен белмәгән балаларның саны артканнан-арта тора. Шәһәрләрдә генә түгел, авыл урамнарында да рус авазлары күпләп яңгырый. Әгәр элегрәк әбиләре шәһәрдән кайткан оныкларын татарчага өйрәтә торган булсалар, хәзер, киресенчә, оныклары әбиләрен русча сөйләргә өйрәтә.

Без кайвакыт телебез дәүләт теле булды дип инанабыз. Ләкин чынбарлык бөтенләй башкача. Гәрчә телләр турындагы закон һәм аны гамәлләштерү турында матур итеп язылган программалар булса да. Болар барысы да әлегә «кәгазьдә бар, гамәлдә юк»лар шул.

Дәүләт теле ул дәүләтнең үз халкы белән аралашу теле була. Ләкин андый тел бездә бер генә, ул да булса — рус теле. Эш кәгазьләре тик шушы телдә генә төзелә, Дәүләт Советы да сессияләрен тик рус телендә генә алып бара. Бер-ике депутатның мөнбәргә менеп татарча чыгыш ясавы тик ниндидер бер экзотика рәвешендә генә кабул ителә. Чиновниклар, аның хәтта татар исемен йөрткәннәре дә, үз телләрендә сөйләшә алмый. Кайберләренең русчалары да чамалы гына, кем әйтмешли, ташка үлчим.

Ә бит үткән гасырның егерменче елларында, хөкүмәт башында Кашаф Мохтаров утырган заманда, татар телен дәүләтләштерү шактый уңышлы башкарыла башлый.

[1] FM 99,2 ешлыгы бу. — *Ред.*

Документлар, өстән төшкән кәгазьләр ике телдә була. Русларны татарчага өйрәтү системасы җәелдерелә. Ике телне дә белергә тиешле чиновникларның исемлеге төзелә башлый. Ләкин бу гамәл бик кыска гомерле була шул. Партия органнары аңа сикереп чыга алмастай киртә хасил итәләр. Мохтаров хөкүмәттән сөрелә.

Без бүген руслар татар телен өйрәнергә теләми дип лаф орабыз. Ә алар бездән көләләр. Ничек инде, сез үзегез үз телегезне белмәстән, башкаларны аңа күндерергә тырышасыз, башта үзегез өйрәнегез, диләр.

Монысы да хак, ләкин бүгенге авырлыкларның төп сәбәбе — телебезне өйрәнүгә хаҗәт юклык. Күпләргә ул гомумән кирәкми. Хаҗәтлек исә — шушы телне белми яшәү кыенлыгы. Татар теленә ихтыяҗ булса, әгәр дә ул чынлап дәүләт теленә әверелсә, башкалар да татарчаны үзләштерергә мәҗбүр булырлар иде. Үзебез дә аның язмышына бүгенгедәй битараф булмас идек. Әнә бит, ихтыяҗ булгач, яшьләр ныклап инглиз телен үзләштерәләр.

Заманында телебезгә хаҗәтлек булганлыктан, 1303 елда Рим шәһәрендә көнбатыш сәяхәтчеләре өчен махсус рәвештә «Кодикус куманикус» дигән сүзлек булдырыла. Шушы сүзлектәге җөмләләр, әйтемнәр нәкъ бүгенгечә яңгырыйлар. Сәүдәгәрләргә сәфәргә чыкканда татар телен белгән тәрҗемәчеләр алырга тәкъдим ителә.

Инде күпләргә мәгълүм сәүдәгәр Афанасий Никитин, әгәр дә татар телен белмәгән булса, сәяхәтен Йосыф исеме белән кылмаган булса, төрки Газневидлар династиясе идарә иткән Һиндстанга кадәр барып та җитә алмаган булыр иде, барып җитсә дә, исән-имин иленә кайтып җитә алуы бик тә шикле булыр иде. Һәм үзенең «Хождение за три моря» әсәрен «рус жиреннән дә гүзәлрәк җир юктыр» кебек татар җөмләләре белән бизәмәгән булыр иде. Монысы да юкка түгел, аның рус укучылары да татар телен яхшы белгән. Менә бу — телгә ихтыяҗлык мисалы.

Телебез — дөньяның иң кирәкле дип саналган ундүрт теле арасында һәммә төркигә дә аңлашыла торган бердәнбер тел. Бу аның заманында татарның бөеклек чорында дөньяда тоткан урынының чагылышы. Ул XIX гасырга кадәр Россиянең Көнчыгыш белән аралашу теле яки дипломатик кулланыштагы тел булган.

Нигә бүген дә аны шушы рәвештә файдаланмаска ди? СССР таркалгач, аннан чыккан Шәрекъ республикаларында рус теленә ихтыяҗ әллә ни булмагач, аны белүчеләрнең саны кими. Киләчәктә һәммә үзбәк, кыргызны, төрекмән һәм казакъны русчага өйрәтеп бетереп булмаячак. Ә татар теле аларга якын һәм аңлаешлы.

1992 елны миңа Бишкәктә кыргыз корылтаенда катнашырга туры килде. Анда чыгышымны татар телендә ясадым. Сүземнең ахырында корылтайны алып баручы ул замандагы Кыргызстан Президенты Акаевка Татар конгрессы эмблемасы төшкән сәгатьне тапшырганда, болай дидем: «Әскәр Акаевич, бу сәгатькә су үтми, ул утта янмый. Дуслыгыбызга да су үтмәсен, ул утта да янмасын! Бу сәгатьне кулыгызга такканда, аны дуслык вакытына куегыз!» Залда утыручылар чыгышымны алкышларга күмделәр. Чөнки телебез аларга аңлаешлы, һич кенә дә ят түгел иде.

Ике ел рәттән Ашхабадта, Халык хуҗалыгы институтында, төрекмән балаларыннан үз телләрендә имтихан алырга туры килде. Алар миңа төрекмәнчә сөйли, ә мин аларга татарча. Бик яхшы аңлаша идек.

Телебезне гамәлгә кертү өчен шартлар юк түгел. Аларны хәрәкәткә китерер өчен бары тик максатчанлык һәм сәяси ихтыяҗ гына кирәк.

Форсаттан файдаланып, динебезнең яшәешебездәге урыны хакында әйтеп үтү дә урынлы булыр дип уйлыйм. Чөнки ул һәрвакыт, бигрәк тә коллык чорына күчкәч, милләт сакчысы була килгән. Әгәр дә 1552 елдан соң татарлар исән-имин калган икән, моңа бабаларыбызның канына сеңгән Ислам дине сәбәпче. Ул, дәүләтебез беткәч, ханнарыбыз юкка чыккач, күп морзаларыбыз сатылгач, халкыбызның бердәнбер терәге, бердәнбер таянычы булып кала. Ул безне чукындыру, руслаштыру афәтеннән коткара.

Динебез бүген дә, һич кенә дә гади булмаган шартларда, миллилегебез сагында булса иде!

Аллага шөкер, яшьләребез күпләп дингә тартыла, мәчетләргә йөри, намаз укый. Тик менә шунысы бераз күңелне тырный: мәчетләребездә, бигрәк тә шәһәрләрдә, рус теле хөкем сөрә. Кайбер муллалар вәгазьләрен русча укыйлар. Имештер, монда башка милләт

вәкилләре дә бар. Булса бит, булсын, бик яхшы. Ләкин алар безнең тәртипләребезгә буйсынырга тиеш. Мәчеткә йөриселәре килә икән, татарча өйрәнсеннәр. Рус әйтмешли, в чужой монастырь со своим уставом не ходят.

Муллаларыбызның балалар белән эш алып барулары да, мәктәпләр белән бәйләнешләр да әлегә тиешле кимәлдә түгел. Дөрес, уңай мисаллар юк дип әйтеп булмый. Менә берничә мисал.

Чувашстанның Тукай авылындагы милли яшәешне дин әһелләре урнаштырган. Колхоз беткәч, җирле халык үзләренең пай җирләрен ниндидер бер вакыф рәвешендә мәчеткә тапшыра. Мәчет каршында Иҗтимагый Совет барлыкка килә һәм ул авылдагы бөтен эшләрне җитәкли. Шунысы да кызык: Совет сайлаулы рәвештә төзелми, анда кем тели, шул керә. Составында җирле идарә рәисе дә, мәктәп директоры да һәм абруйлы яшьләр дә бар.

Балалар беренче сыйныфка барыр алдыннан мәдрәсәдә әзерлек үтәләр, гарәп хәрефләрен танырга, догалар һәм намаз укырга өйрәнәләр. Авылда бала саны арта барганлыктан, мәктәптә урын җитми. Шунлыктан мәдрәсә аларга үз бинасындагы компьютер һәм башка техник чаралар белән җиһазланган классларны файдалану мөмкинлекләрен бирә. Гомумән, монда бик уңышлы һәм файдалы эш алып барыла.

Моңа охшаш мисаллар юк түгел. Әйтик, Лениногорск районының Кирлегәч һәм Керкәле авылларында, Балтач районының кайбер авылларында эш шушы рәвештәрәк бара. Тик болар әле тик мисаллар гына. Ягъни калкып килә торган шытымнар гына. Имамнарыбыз бу эшкә ныклап тотынсыннар иде.

Мөфтиебез Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм татарлар күпләп яшәгән төбәк имамнары аны ныклап җәелдерер дигән өмет бар. Саратов, Самара, Төмән, Ульяновск шәһәрләре имамнарының эшчәнлекләре, шөкер, шушы юнәлештә.

Шулай була күрсен иде. Динебез бүген дә миллилегебезне, гореф-гадәтләребезне саклау юлында булсын иде.

Тел һәм моң кавемнең күңелендәге яки эчке дөньясындагы иң мөкатдәс һәм иң нечкә кыллары икәнлегендә бернинди шик юк. Ләкин алар кеше күңелендәге үзләре белән тулы гармониядә булган башка бихисап тойгылар, кичерешләр белән бергә саклана. Күңел — адәм баласының үзе белән генә яши торган дөнья. Монда әйтелмәгән һәм әйтергә теләгән сүзләр дә, үпкә һәм рәнҗешләр дә, төрле рәвештәге кичерешләр дә — барысы да бар. Ул хәтта сер капчыгы да әле. Боларның бөтенесен әйтеп бетерү мөмкин дә түгел. Алар күп вакыт тел һәм моңның камертонын хәтерләтә. Эчке кичерешләр моңыбызның теге яки бу төрлесен адәми затның кәефенә туры китереп дәшәләр сыман. Әгәр ул ниндидер шатлык хисләре кичерә икән, аның эчке дөньясыннан шуңа тәңгәл көй барлыкка килә. Әгәр дә инде аны ниндидер нәрсә борчый икән, үзеннән-үзе шуңа хас моң туа. Яхшы кәефле чакта кайвакытны кешене көне буе диярлек бер моң озатып бара. Болар кычкырып көйләү түгел, алар күп вакыт кешенең үзе генә ишетә торган эчке көйләү, җырлау. Аның эчке дөньясы бары тик үзе өчен генә моңлана. «Моңлы бала түгел идем, миңаниләр булды икән!»

Ләкин кешенең эчке дөньясы үз кичерешләре белән генә яшәми. Бу дөнья һәрвакыт аның тышкысы белән хәбәрдар, гармониядә яши. Алар бергә аның күңелендә халык язмышы хакындагы борчылуга әвереләләр.

Дәрдемәнд, гамәли тормышта Закир Рәмиев, гомере буе халкы өчен, аның язмышы өчен ут йотып яшәгән. Рәмиевләр тапкан малларыннан аның яшәешенә өлешләрен кертә торган булганнар. Милли-азатлык хәрәкәтенә дә шактый күп алтыннарын сарыф иткәннәр. Революциядән соң бу байлыклар юкка чыга.

Шагыйрь соңгы көннәрен кысынкылыкта үткәрә. Авырый. Аның хәлен белергә килгән Зәки Вәлидигә: «Мине капиталларымның юкка чыгуы түгел, милләтем язмышы борчый», — ди. Вәлиди истәлекләрендә: «Миңа аның белән саубуллашканда башы астында йомшак мендәр түгел, ә каты таш кебек тоелды», — дип яза.

Шагыйрь кавеменең яшәү көче, миллилеге сагындагы изге сөте өчен борчылып киткән фани дөньядан. Әчемәсме ул, сыйфатын җуймасмы, ил зәхмәтләре аңа кагылмасмы? Ул мәңгелеккә шушы гамь белән китеп барган.

Аңа Ватанга караганда туган кавеме газизрәк булган. Ул рус империясенең дә

мәңгелек түгел икәнлеген күзаллаган. Һәм үзе исән чагында ук «бу Ватанның» китә башлавын күргән. Ә сөт? Ул калырмы?

Иң зур теләге шушы булса да, заман зилзиләләре аны читләтеп үтүенә, күрәсең, тулы ышанычы булмаган.

Чыннан да, бервакыт динсез калдык, телебезгә, милли яшәешебезгә куркыныч туды. Сөтебез, әчемәсә дә, шактый сыегайды.

Татарстанның ниндидер рәвештә җөмһүрият буларак аякка баса башлавы, кавемебездә Ватаны кайтуына өмет тудырды. Шушы ил корабыбыз, бата-чума булса да, алга баруын дәвам итә. Суверенитет Декларациясен кабул итү, референдум үткәреп, аның нигезен ныгыту сөтебезнең шактый куәтле икәнлеген күрсәтте. Республикабызны галәмгә горур республика сурәтендә танытты. Аның бүгенге көнне башкалар өчен мисали рәвештә яшәве, илдәге федератив хәрәкәтне әйдәп баручы булуы шулай ук моңа көчле дәлил булып тора.

Башкалар егылганда, сыгылганда да, республикабыз бирешмәде. Россия республикаларын Үзәк белән Шартнамәле яшәү рәвешеннән биздерделәр, башлыкларын Президент атамасыннан ваз кичәргә мәҗбүр иттеләр. Татарстаныбыз бердәнбер шартнамәле республика булып калды. Президент атамасын әлегәчә лаеклы саклый килә. Исемне бетерү җисемне бетергәнлеген аңлап эш итә. Аны саклау мөмкинлеген халыкара танылган үзбилгеләнү хокукы, Россиянең шуңа нигезләп төзелгән Конституциясе, 2007 елны Үзәк белән яңартылган Шартнамә тәшкил итәләр.

Хәтәр җилләр исә тора. Украинадагы хәлләр нәкъ шул хакта сөйли. Явыз көчләр татар җанын сорап, аны упкынга сөйри.

*Чыкты җилләр,*
*Купты дулкын, —*
*Ил корабын җил сөрә!..*

Әмма татар корабы, бернигә дә карамастан, «җилкәнен киргән», «төн вә көндез» «юл ярып» алга бара.

Татар кавеме Ватанын кайтару юнәлешендә, аның изге сөте — хәрәкәттә. Аңа тупланган сыйфатлар татарга юлдаш, милләткә һәрвакыт көч, куәт, дәрт һәм дәрман биреп тора! Изге сөткә ни җитә!

**Индус ТАҺИРОВ**

**Редакциядән:**

*24 майда Индус Ризак улы Таһировка 80 яшь тула. Индус ага — күренекле тарихчы. Татарстан Фәннәр академиясе академигы. Аның хезмәтләренең шактый өлеше Татарстан һәм татар тарихына карый. Ул — җәмәгать эшлеклесе дә. Бөтендөнья татар конгрессын оештыручыларның берсе булган һәм Конгрессның башкарма комитетына аның беренче көненнән алып ун ел буена җитәкчелек иткән кеше.*

*Индус агага бабалары кебек озын гомерле булуын, яңадан-яңа казанышларга ирешүен телибез.*

# *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# С

**СӘГЪДИ** (псевд., тулы исеме Мөслахетдин Әбу-Мөхәммәт Габдаллаһ Сәгъди Ширази) (1203-1210 арасы, Иран Шираз ш. — 9.12.1292, шунда ук), фарсы шагыйре, фарсы һәм таҗик әдәбияты классигы. Фарсы һәм гарәп телләрендә язган. Псевдонимы Сәгъди ибн Зәңги (1195-1226 елларда хакимлек итә) исеме б-н бәйле. Аның ярдәме б-н С. Багдаттагы «Низамия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1220 еллар урталарыннан Шәрекъ илләренә сәяхәт кыла, Мәккәгә хаҗга бара, дини-әхлакый вәгазьләр б-н чыгышлар ясый. Берничә елдан Ширазга кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда ялгызлыкта яши. С.нең төп әсәре — «Бөстан» (1257). Әсәр идеаль хаким нинди булырга тиеш дигән фикерне чагылдырган хикәяләр, притчалардан (гыйбрәтле хикәя) тора. Шагыйрь хакимнәрне гади кешеләргә карата кешелекле булырга чакыра, гаскәр башлыклары һәм чиновниклар гадел булырга тиешлеген искәртә, югыйсә хакимнең киң күңеллелеге һәм игелеклелеге зыян гына китерергә мөмкин. «Гөстан» (1258) исемле чәчмә һәм тезмә формада язылган притчалар китабы патшалар тормышы һәм дәрвишләр холкы, эндәшмәүнең һәм аздан да канәгать булуның өстенлеге, мәхәббәт һәм яшьлек, тәрбияләү һәм аралашу кагыйдәләре турында сөйли. Китап юмор б-н сугарылган, аның төп идеясе — җәмгыятьтә яшәү нигезе итеп акыллылыкны һәм аек акылны мактау. Ике әсәр дә Шираз хакиме Әбү-Бәкер ибне Сәгъдигә багышланган. Моннан тыш аларда авторның тормыш вакыйгалары һәм маҗаралары, аның сәяхәтләре һәм күзәтүләре тасвирлана. С. ш.у. лирик шигырьләр язган, «Панднамә» («Нәсихәтләр китабы») исемле чәчмә трактат авторы дип тә фаразлана. С. әсәрләре татар халкының укымышлы өлешенә таныш булган, алар буенча мәдрәсәләрдә фарсы телен өйрәнгәннәр, аларга низезләнеп нәзирәләр язылган. «Гөстан» С.Сараи тарафыннан тәрҗемә ителгән («Гөлестан бит-төрки», 1391). Бүтән тәрҗемәләр дә мәгълүм, мәс., Мөхәммәд Сәет Җәләлнеке (1915).

Әсәр.: Избранное. Душ., 1954.

Әдәб.: Холмогоров М. Шейх Мослихутдин Саади Ширазский и его значение в истории персидской литературы. К., 1865; Гулистан: Критический текст. М., 1959; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993.

*Х.Миңнегулов*

**СӘГЪДИЕВ** Рәдиф Нәҗип улы (17.7.1957, Казанда туган), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005). Казан театр уч-щесын (1981) һәм Казан ун-тын (1993) тәмамлый. Хезмәт биографиясен 1981 елда Әлмәт татар драма т-ры актёры буларак башлый. 1984тән Татар драма һәм комедия т-рында: актёр, гастрольләр оештыру буенча менеджер (1989дан). 1998дән — Казан татар яшь тамашачылар т-ры менеджеры. 2000-05тә — ТР Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге җитәкчесе. 2005-07дә — «Казан утлары» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире. 2007дән Татар драма һәм комедия т-рында җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча директор урынбасары. 2014тән «Безнең мирас» журналында — бүлек мөхәррире. «Финляндиядә рәхәт, ди» драмасы (1989 да Чаллы татар драма т-рында куела), «Сынган беләзек» мелодрамасы (1996да Татар драма һәм комедия т-рында куела), «Яз галәмәте» комедиясе (1998дә шунда ук куела), балалар өчен «Гүзәл Аппаксылу» пьесасы (2001дә Казан татар яшь тамашачылар т-рында куела), «Ирләр яуга киткәндә» тарихи драмасы (2003), «Канга буялган алтыннар» (1990) һәм «Каргыш» (1992) детектив повестьлары, «Ике кояшлы дөнья» (2002) фантастик һәм «Ирдәүкәләр» (2008) исемле тарихи-мавыктыргыч романнар авторы. Ф.Хөсни (2011) һәм Д.Сираҗиев (2012) исем. премияләр лауреаты.

Әсәр.: Гүзәл Аппаксылу. К., 2013.

Әдәб.: Зәйдулла Р. Җан хөрлеге // Мәдәни җомга. 2007. 20 июнь; Гайнуллина И. Артистлыктан язучылыкка // Сәхнә. 2007. Сент.-окт.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

*13 апрельдә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, аның урынбасары Рамил Ханнанов, бүлек мөхәррире Фәнил Гыйләҗев һәм журналның апрель санында басылган «Бибимәмдүдә» бәянының авторы, язучы Марат Әмирханов Балтач районының Салавыч һәм Югары Субаш авылы мәктәпләрендә очрашуларда булды, район башлыгы Рамил Нотфуллин белән күреште. Алар шулай ук Сасна Пүчинкәсенә барып, Г.Тукайның әнисе Бибимәмдүдә каберен зиярәт кылып кайтты.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

## Бибимәмдүдә абыстайны зиярәт итәргә баргач

Юл читендә көчек калды күз атып,
Аһ, шул көчек куйды җанны кузгатып!

Шул көчектәй калган нәни Апуш та
Әнкәсенең җеназасын озатып.

Тау башыннан чишмә чыккан ургылып,
Юл ташлары калган җандай убылып.

Нәни Апуш шул урамнан узгандыр,
Җил-суыктан тәпиләрен туңдырып.

Кул сузымы Сасна – Субаш арасы,
Бүлеп тора бары Күшет елгасы.

Шул елгага тамгандыр ла Тукайның
Иң әүвәлге ачы шигъри күз яше.

Башны идек, дога кылдык бу көндә
Олуг шагыйрь әнкәсенең кабрендә:

«Аллаһ разый булсын синнән мәңгегә,
И, пәйгамбәр әнкәседәй Мәмдүдә!»

*Сасна Пүчинкәсе,*
*13 апрель, 2016 ел.*



*Бибимәмдүдә абыстай каберен зиярәт кылу.*



*Балтач районы башлыгы Рамил Нотфуллин белән очрашу вакытында. Илфак Ибраһимов (сулда) һәм Марат Әмирханов (уңда).*



*Без киләсе көнгә каршы кичтә Сасна Пүчинкәсе авылына төшә торган асфальт юлны бәреп чыккан чишмә.*




*Югары Субаш мәктәбе укучылары һәм укытучылары белән.*

Ф.Гыйләҗев фотолары.

*«Казан утлары» – 1000нче саны Татарстанда гына түгел, Рәсәйдә дә беренче булып чыккан озын гомерле әдәби журнал. Киләсе елның маенда аңа 95 яшь тула. Шул юбилейга барышлый без күп элегрәк чыккан «журнал җименнән» яңа буын укучыларын да «авыз иттермәкчебез».*

*Язмаларны бирүдә хронологик тәртип сакланмас. Бу – май саны булганга, «юбилей сериясен» сугыш елъязмачысы Г.Әпсәләмовның документаль язмасы белән башлап җибәрергә булдык.*

Габдрахман
Әпсәләмов

# КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕМНӘН*

## Карелия фронты

**1942.**

**19 апрель.** Финнар бертуктаусыз аталар да аталар. Уң флангта аларның станковый пулемёты, сулда — буыла-буыла эре калибрлы пулемётлары йөткерә. Алда автоматлар зәңгәр һава җәймәсен ерткалыйлар.

— Эчләре поша, менә аталар! — ди Мишков, ярым русча, ярым украинча. Ул минем отделениемдә наводчик. Булган егет. Дошман уты астында аптырамый. «Әнием мине бер тапкыр тудырган, бер мәртәбә үләрмен. Мин, иптәш сержант, үлемнән курыкмыйм», ди ул. Аның әтисе, әнисе һәм хатыны немецлар кулында. Исәннәрме, юкмы — билгесез. Мишков алар өчен бик борчыла. Шул хакта сүз кузгалса, яисә без туган җирләрдән хатлар алсак, ул йә читкә борыла, йә бер якка китеп утыра да башын ия. Җанлы, уенчак күзләре моңсуланалар…

Бүген ул землянкабыз алдында постта тора. Өстендә шинель, башында корыч каска, билендә патроннар, гранаталар.

— Төнлә, ичмасам, курыкканга күрә аталар, ә көндез ни пычагыма тырылдыйлар, — ди ул, сүзен дәвам итеп, үзе һаман да тирә-якны күзәтә. Землянкадан замполит Крамник, наводчик Алексеев, Коваленко чыгалар. Бергәләп, ату тавышларына колак салабыз.

— Азимут 270 — станковый пулемёт. Азимут 180 — эре калибрлы пулемёт, — ди Николай Коваленко. Замполит, компасын кулына алып, геонтрны тавыш ягына бора.

— Дөрес, — ди ул һәм геонтрны кояшка юнәлдереп вакытны билгели. — Сигез туларга унбиш минут. Завтракка барырга вакыт.

Сержант Степанов ике сугышчы белән завтрак алырга китә. Ә без яңадан землянкага керәбез, чөнки тышта бергә җыйналырга, кычкырып сөйләшергә рөхсәт ителми. Финнар бездән күп булса 250-300 метрда. Безнең якта тавыш-фәлән ишетелсә, пычкы чыңласа, хәзер атарга тотыналар.

17 сәгать. Ячейкадан связной Юнгов һәм Дудин килделәр. Приказ: барыбызга да юлга әзерләнергә. Иптәшләр арасында җанлану. Кая?

17 сәгать 36 минут. Без хәзер. Наводчиклар миномётларын, икенче номерлар

* Өзек бирелә.

— лотокларын аркаларына астылар. КПдан лейтенантны күтәбез. Ул килә һәм яңа приказны белдерә — минем һәм сержант Степановның отделениеләре аерым боерыкка кадәр монда кала. Лейтенант үзе дә безнең белән кала. Башкалар, помкомвзвод старшина Калабухов кул астында, хәзер үк юлга чыгалар. Бер-беребезнең кулларын кысышабыз. Аннары алар китәләр. Без калабыз. Озаккамы?

**20 апрель.** Безнең взводның яртысы чыгып киткәнгә, гадәттәге тәртип үзгәрде. Төнлә замполит белән миңа, алмаш-тилмәш, секретта торырга туры килде. Әгәр дә финнар безнең участокта үзгәреш барын яисә частьларның алмашуларын сизсәләр — тынычлык күрсәтмәячәкләр. Шуңа күрә бу төнне без беребез дә йокламадык. Коралланып, киенеп, һәр минут хәзер булып тордык. Дежурный Степков унбиш минут саен постларны тикшерә торды. Төн буенча финнар ак ракеталар чөйделәр, пулемёт, автоматлардан аттылар. Куе зәңгәр күктә әледән-әле трассир пуляларның якты койрыклары сузылып торды. Ләкин оборона сызыгын чыгарга маташучылар булмады.

Иртән, сәгать сигез тулып тугызынчы. Иптәшләр шаярталар.

— Тирә-якта диңгез, диңгез уртасында бер утрау, ул утрауда без.

Укчыларга алмаш килде. Озакламый безгә дә килергә тиеш. Мин землянкабыз каршындагы ак каенга сөялеп, ашыга-ашыга блокнотыма шушы юлларны сызгалыйм:

— Һаман язасың икән, сержант, — диде Степанов, минем яныма килеп. — «Бишйөз»[1] дә безнең ничек яшәвебезне язгансыңдыр бит. Без монда бары егерме көн яшәдек, шул вакыт эчендә бер генә фин да матур «Бишйөз»нең туфрагына аяк басарга батырчылык итмәде, көндезен дә, төннәрен дә без сакта идек. Монда пуля яисә мина кисәге тимәгән бер генә агач та юк. Син сөялгән ак каенда кичә мин унлап пуля эзе санадым.

Безнең янга лейтенант Иващенко килде. Ничәнче көн инде, аның йоклаганы юк. Матур йөзе сулган, зәңгәр күзләре эчкә батканнар.

— Егерме минуттан мине уятыгыз, — диде ул һәм землянкага кереп китте. — Бары 20 минут!

Без кичкә каршы гына кузгалдык. Вакыт гаҗәп әкрен үтте. Элек шундый җыйнак, ямьле, җылы булган землянкабыз — хәзер шыксыз, буш, салкын. Тимер мичне кичә үк алып киттеләр. Иптәшләр нарларга сузылып, «Катюша»ны әкрен генә җырлыйлар. Замполит башлый, аңа Степанов, Мишков, лейтенант кушылалар.

...Мин алдан барам. Юл йомшарган, каралган, аяклар бата. Сазлыклар су белән капланган калку урыннарда җир ачылган. Алга киткән саен хәтергә нык сеңгән таныш урыннар арттарак кала баралар. Менә бу үрдә без беренче мәртәбә дошман уты астына эләккән идек. Менә шушы нарат төбендә мин, тегендәрәк — старшина Калабухов, сержант Озетков ятканнар иде. Менә монда, сазлык читендә, сержант Степановның группасы обед алып кайтканда, фин автоматчыларының уты астына эләккән иде. Аларның урман эченә борылып киткән эзләре хәзер дә бар әле.

Төн. Һаман барабыз. Күктә яңа туган айның көмеш урагы асылынып тора. Юл бормалана. Ай әле уңда, әле сулда кала. Искиткеч арылды. Аяклар чак-чак кына атлыйлар. Лямкалар җилкәләрне кисә, винтовка иңбашны талдыра. Менә алда утлар күренеп китә. Сак кына якынлашабыз. Бераздан үзебезнең обозга очрыйбыз. Минем яныма Катапкин йөгереп килә.

— Сержант, саумы?

— Катапкин, синме? Йә, эшләр ничек?

— Ничек дип әйтергә... Менә, мордвача әйткәндә, безнең ташпулат, русча әйткәндә — салаш. Урман белән торкан, күк белән япкан.

— Безнекеләр еракмы?

— Юк. Моннан бер километрда гына.

[1] Оборонада безнең взвод урнашкан урын «Пятисотка» дип атала иде. Аның иңе һәм буе 500 метр иде.

Бу бер километр — бер түгел, биш булгандыр, әй. Барабыз, барабыз, һаман җитеп булмый. Ниһаять, туктадык. Калабухов безне каршы алды. Кечкенә генә салаш. Уртада учак янып тора.

— Рәхим итегез, иптәшләр!

Озак та үтмәде, кайнар аш һәм икмәк китерделәр. Тәүлектән артык ашаган юк иде, күз ачып йомганчы котелокларны ялт иттердек. Тагын берничә минуттан соң иптәшләр учак тирәсендә бер-берләренә сыенып йоклыйлар иде инде. Мин, арудан күз алларым караңгылануга карамастан, блокнотымны чыгарып, язарга тотындым...

**22 апрель.** Урман шаулый. Җил. Яңгыр катыш кар ява. Салаш эчендә учак янса да, салкын. Тамчылар тама. Без инде яңа салаш эшләү турында планнар корабыз. Ләкин планнар гамәлгә ашырылмый кала. Яңа приказ. Ярты сәгатьтән моннан да китәбез. Кая?

Тиз-тиз генә ашадык. Капчыклардагы бөтен артык әйберләрне бушаттык. Мин, хәтта йөрәгем әрнесә дә, моңа кадәр саклап килгән барлык хатларымны учакка ташладым. Хәзер минем янымда бары комсомол билетым һәм көндәлек дәфтәрем генә калды. Аңардан үлгәндә дә аерылмам.

Тар сукмакта рота тезелде. Лейтенант Шканов приказны аңлата.

— Бүгеннән без һөҗүм итә башлыйбыз... — ди ул. Сугышчыларның йөзләре яктырып китә. Сафларда хәрәкәт, җанлану. «Бу көнне без күптән көтә идек!»

Батальон штабы янында туктап торганда, Нәбиуллинны очраттым. Безнең ике арада булган дуслык Мари урманнарында, Суслонгерда башланды һәм Карелиянең карурманнарында да дәвам итә. Мине күргәч тә ул йөгерә-йөгерә яныма килде һәм каты итеп кулымны кысты.

— Ну, Әпсәләм, әйткән идем тагын бер күрешербез дип, тәки күрештек. Моннан соң да күрешербез әле.

— Әлбәттә.

— Һөҗүмгә диген? Исән бул, туган. Мин — обозда. Обозның эше башкарак бит.

Очсыз-кырыйсыз урман, урман. Сапёрлар эшләгән юл буенча меңнәрчә сугышчылар, повозкалар, артиллерия, поход кухнялары агыла. Миңа, нигәдер, бүтән җирдә һич тә кеше калмагандыр шикелле тоела. Кояш бер күренә, бер болытлар астына кача. Яңадан җепшек кар ява башлый.

Инде караңгы төшеп килгәндә, билгеләнгән җиргә килеп җиттек. Алда артык юл юк. Бары сукмаклар гына. Без биек бер нарат төбендә. Учак ягарга рөхсәт ителми. Ансыз да финнар безнең хәрәкәтне сизгәннәр булса кирәк — бертуктаусыз батальонный миномётлардан сиптерәләр. Ләкин миналар безгә зарар итмичә, сулдарак, ак фонтаннар ясап, сазлыкта ярылалар.

Безгә кайнар аш китерделәр. Аягүрә генә ашадык. Төнлә һөҗүм башланырга тиеш. Безнең миномётный взвод 4нче укчылар ротасына беркетелде.

Замполит безне үз янына җыйды һәм әзрәк дулкынланган тавыш белән:

— Дусларым, — диде, — тиздән һөҗүм итә башлыйбыз. Безнең күбебез өчен бу һөҗүм беренче зур сынау. Онытмагыз, сугышта бер-береңә ярдәм итү безнең закон.

Киттек.

— Шауламаска. Тәмәке тартмаска. Бер-береңнән калышмаска. Отделение командирлары отделениеләре алдыннан баралар.

Караңгы. Тавыш-тын юк. Хәтта ай да күренми.

**23 апрель.** Төн үтә, таң сызыла, ә һөҗүм һаман башланмый әле. Разведка туктаусыз хәрәкәт итә. Финнарның ныгытмаларына якын ук шуышалар. Анда җиде рәт тимер чыбык. Тимер чыбыклар алда миналанган. Финнар нык күзәтү алып баралар. Разведчиклар белән бергә барган сапёрлар тимер чыбыкларны кисә алмыйча кире кайталар. Ахырда командование финнарның бу ныгытмаларына икенче яктан һөҗүм итәргә карар кыла һәм без яңа урынга күчәбез.

Обед вакытында безгә хатлар китерделәр. Мин берьюлы ике хат алдым — әниләрдән һәм М... дан. Шатлыгым эчемә сыймый. М...ның хаты ахырында шигырь дә бар...

Никадәр мәхәббәт, никадәр җылылык, никадәр гаделлек бу юлларда! Бәгърем, рәхмәт, мең рәхмәт үзеңә. Ышан, кабахәт дошманнарга каршы көрәшкән чакта минем кулым калтырамас. Туган илемне, сине никадәр көчле сөйсәм, гитлерчы бандитларга шулкадәр рәхимсез булачакмын. Бер генә секундка да шикләнмә.

**24 апрель.** Ялтырап кояш күтәрелә. Төнлә һәм иртән кар яуды. Хәзер биек наратлар ак шәлләр бөркәнгән, башларына асыл ташлар белән бизәлгән ак шлемнар кигән кызлар шикелле, соклангыч матурлар. Күк йөзе зәп-зәңгәр һәм чиксез тирән. Карга карасаң, көчле яктылыктан күзләр камаша...

Политруклар листовкалар тарата. Мин аларның берсен алам һәм нарат төбенә утырып укыйм: «...Товарищи! Настал момент разгрома и уничтожения немецко-финских банд и на Кестенгском направлении». Онытылмас минутлар!

Безнекеләр һөҗүм итә башладылар. Озакламый без дә кузгалачакбыз. Әгәр дә бу сугышта мин һәлак булсам, коммунист дип санагыз. Туган илем, матур туган илем. Никадәр мин сине яратам! Син мине үстердең, син мине кеше иттең. Синең изге туфрагыңны кабахәт дошманның шакшы итекләреннән таптатмабыз. Үлем яисә җиңү! Изге җиңү!

Һөҗүм. Билдән кар ерып алга барабыз. Пулемётлар, автоматлар такылдый. Сызгырып килеп, миналар ярыла. Безнең лейтенант кайдадыр алда. Мин Положенковны һәм Маркеловны гына күрәм. Алар артыннан үземнең отделениемны алып барам. Әледән-әле артыма борылып карыйм да кулымны изим. Мишков, Пидсадный һәм Горбачёв шул ук секундта яткан урыннарыннан сикереп торалар да йөгерә башлыйлар. Алда сазлык аркылы тар сукмак сузыла. Сукмакның ике ягы да финнар тарафыннан миналанган. Шул тар сукмак буенча без урман белән капланган үргә ыргылабыз. Анда — дошман. Аны бәреп чыгарырга кирәк. Яралылар, үлекләр очрый. Үзәккә үтә торган ыңгырашулар ишетелә, йөрәк атлыгып тибә, күзләр яна, тамак кибә. Алга! Алга!

Кинәт миннән берничә метрда гына мина ярыла. Мин су белән тулган чокырга ташланам. Аркама кар һәм туфрак коела. Башымны күтәрәм. Снаряд чокырында Пидсадный ята.

— Исәнме?

— Исән.

Финнар чигенәләр. Без беренче биеклекне алабыз. Ватылган ДЗОТлар, актарылган землянкалар, туракланып ташланган наратлар...

Финнар утларын көчәйтәләр. Яраланган сугышчылар егылалар. Без ятабыз һәм шуыша башлыйбыз. Кинәт Положенков кычкырып җибәрә. Мин аның янына шуышам.

— Кай җирең?

— Иңбашым...

Мин аның аркасыннан миномётын алам, шинелен, фуфайкасын салдырам. Мина кисәге аның киемнәрен тишеп чыккан, ләкин тәнен зарарламаган.

— Бернәрсә дә юк. Тизрәк киен. Миномётыңны мин үзем алам.

Чабабыз. Сержант Озетковны куып җитәм.

— Сержант, миномётыңны ал.

— Положенков кайда?

— Хәзер килеп җитә...

Мин аңа берничә сүз белән эшнең нәрсәдә икәнен аңлатам да лейтенант янына йөгерәм.

— Товарищ лейтенант, всё в порядке, — дим.

Дошман икенче үрдә. Ара — 500-550 м. Шул үргә каратып миномётларны корабыз. Наводчиклар бер-бер артлы кычкыралар:

— Миномётлар сугышка әзер!

**25 апрель.** Сугыш кызганнан-кыза. Икенче биеклек өчен ярсулы, канлы көрәш бара. Ату тавышлары бер генә минутка да тынмый. Югалтулар шактый. Мин ара-тирә иптәшләргә күз салам. Берәүнең дә йөзендә курку күрмим. Күзләрендә бары чиксез нәфрәт кенә яна. Менә безнең яратканыбыз зәңгәр күзле лейтенант Иващенко. Дошман уты астында ул нинди тыныч. Автоматы белән ул көрәшнең иң кызу урыннарына килеп керә. Һәрвакыт алда, һәрвакыт күтәренке күңелле.

**26 апрель.** Сугыш һаман дәвам итә. Без көне-төне алгы сафта. Шунда ашыйбыз, атышлар әзрәк тынган арада шунда ук, нарат төбендә, черем итеп алабыз. Финнар бетәселәрен сизгәнгә нык каршы торалар. Ләкин, ничәмә генә рәт тимер чыбыклар артына качып, бишәр, алтышар накатлы ДЗОТлар, землянкаларга яшеренсәләр дә, барыбер аларга үлем. Бүген булмаса иртәгә. Кызыл сугышчыларның ярсуын һичнәрсә тоткарлый алмаячак. «Дошманның ут-нокталарын юк итәргә!» — дип лейтенант безгә приказ бирә. Миномётларыбызның утларын корректировать итәр өчен штаб начальнигы белән мин алга китәбез. Финнарның тимер чыбыкларына 50-75 м. җитмичә, уңай урын сайлап, ятабыз. Безне күреп алалар һәм пулялар бызылдап баш өстеннән үтәләр. Мин җиргә ныграк сыенам. Берничә минут үтә. Ату туктый. Мин башымны чак кына күтәреп карыйм: безнең миналар дошман окоплары алдында ярылалар.

— Дистанция больше 50, — дип команда бирәм. Икенче минутта миналар окопларны актара башлый.

— Беглый огонь!

Дошманның ут нокталары берьюлы тыналар. Шул минуттан файдаланып, безнең сапёрлар тимер чыбыкларга якын ук киләләр һәм аларны кисәргә тотыналар. Ул арада финнарның батальонный миномётлары ата башлый. Безнең миномётлар кинәт атудан туктыйлар. Нәрсә булды? Мин ОПга[2] йөгерәм. Килсәм, ни күзем белән күрим, лейтенант Иващенко, безнең сөекле лейтенантыбыз, помкомвзвод старшина Калабухов, сержант Степнов яраланганнар. Мин лейтенант янына тезләнәм.

— Иптәш лейтенант... — дим, артык сүз әйтә алмыйм, күземә яшьләр килә.

— Вот я и отвоевался, Абсалямов, — ди ул әкрен генә һәм өсти: — Син минем урыныма каласың... ОПны алмаштырыгыз.

Чирек сәгатьтән соң безнең миномётлар яңадан ут ачтылар. Мин бер ОПдан икенчегә күчә-күчә: «Лейтенант өчен!» «Старшина өчен!» «Сержант өчен!» — дип кычкырам.

Яралыларны санчастька алып киткән иптәшләр кире кайттылар. Старшина санчастька җитмичә үк җан биргән. Алар аның комсомол билетын гына алып кайттылар. Мин аңа бик озак карап тордым һәм әкрен генә:

— Хуш, безнең старшина!.. Онытмабыз. Үч алырбыз... — дидем. Кичкә таба финнар икенче биеклектән дә чигенә башладылар. Тимер чыбыклар күп җирдә өзгәләнгән, актарылган иде инде. Укчылар хәл иткеч көрәшкә — атакага хәзерләнәләр. Алар белән бергә без дә хәзерләнәбез. Ләкин миңа бу минутларны күрергә туры килмәде. Кинәт, миннән ике-өч метрда гына мина шартлады, һәм шул ук секундта мин сул аягым буйлап җылы кан акканын сиздем...

*«Совет әдәбияты». 1942 ел, №7*

[2] ОП – огневая позиция.

Ак җилкән

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

*«Танылган шәхесләребез хәзер шундый да бит, ә менә бәләкәй һәм үсмер чакта нинди булдылар, ниләр кыландылар икән? Белербез!» — бу сәхифәне 2010 елның 3нче санында әнә шулай дип ачып җибәргән идек. 2012 елгы 1нче санга кадәр бәләкәй Туфан, Разил, Зилә, Шәрәфи, Сәхәби, Батулла, Гаташ, Алмазларны белдек. Сәхифәнең «икенче сериясендә» дә бар әле беләселәрегез!*

# БӘЛӘКӘЙ ЗӨЛФӘТ

### Яшел бишек



Олыгайган саен инана барам – авылда туып-үсеп, яшәргә калага киткән кеше, нинди генә гыйлем алмасын, нинди генә уңышларга ирешмәсен, барыбер тулысынча бәхетле була алмыйдыр. Алай гына да түгел, без, уналты-унҗидедә авылдан чыгып китүчеләр, бәхетсез дип әйтсәм дә ялгыш булмас, чөнки авылдан аерылдык, әмма шәһәр кешесе дә булып җитә алмадык.

Түбән Камадан безгә таба сузылган юл башта Балчыклы урманына алып керә, урманны чыккач, күз алдына искиткеч гүзәл күренеш килеп баса: уң якта — Сарсаз тавы, аның итәгенә тияр-тимәс Зәй елгасы Камага кушылырга ашыгып ага, сул якта — Келәтле тавы, түр якта — Шәрбикә калкулыгы. Һәм тирә-якның һәр тарафында урман. Бу хозурлыкның нәкъ уртасында урнашкан минем туган авылым Шәңгәлче. Балчыклы урманы яныннан караганда, ул яшел бишектә тирбәлә шикелле. Кайткан саен сокланам, горурланам – мондый табигать тагын кайда бар соң?!

Табигате шушындый ямьле булганга, Шәңгәлчедән затлы кешеләр чыккандыр. Безнең авылда өч очучы туып-үскән – икесе «ТУ-154» самолётында очкан затлар, берсе – Дәүләтшин Разим – хәрби очучы, утыз яшендә полковник, истребительләр эскадрильясе командиры булган егет. Сәхәбиев Әнәс – танк заводының генераль директоры урынбасары. Корабль капитаннары икәү, берсе — Совет чорында Владивостоктан Америкага йөргән корабль капитаны. Алжирда француз телендә югары математика укыткан Әхмәтов Сәүбән дә безнең авылдан. Опера җырчысы Рафаэль Сәхәбиев, шагыйрь Хәниф Хөснуллин, «Мунча ташы» театры артисты Гамил Әсхәдуллин һәм тагын юристлар, укытучылар, табиблар, бухгалтерлар, инженерлар. Менә шундый авыл ул безнең Шәңгәлче. Шәңгәлче урта мәктәбендә депутат Разил Вәлиев, сәхнә остасы Алмаз Хәмзин укыганнар.

Кайберәүләр: «Мәктәбегез, укытучыларыгыз шәп булгандыр сезнең», – диләр. Җиде йөз илле бала иде мәктәптә мин укыганда. Укытучылар да затлы иде.

Әйе, очучылар, капитаннар, математиклар үсүдә мәктәпнең роле зурдыр. Ләкин иң беренче чиратта, бу табигатьнең үзеннәндер. Табигать яраткан бу затлы шәхесләрне табигать тибрәтеп үстергән үзенең яшел бишегендә.

Алар күкләргә очтылар, планета буйлап сәяхәт иттеләр, ләкин, иманым камил,



аларның һәрберсе туган туфрагының җылысын сагынып, Зәй суларына сусап яшәгәндер, үз авылында туып, шунда үсеп, туган нигезендә яшәп, актык сулышын да шул яшел бишектә алучылар бәхетлерәк дип уйлыйдыр.

## Урысча өйрәнеп кайткан

Әбиемнең сул як күршеләренә каладан «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырттылар. Аларның Равия исемле алты-җиде яшьлек кызларын сукыр эчәгенә операция ясарга алып киттеләр. Без күрше-күлән балалары Равиянең кайтуын түземсезлек белән көттек. Ничек булганын, ниләр кичергәнен сөйләтәсебез килә бит. Операция дигән сүз үзәкләрне куыра, кала бездән унбиш чакрымда гына булса да, ул безгә чит-ят дөнья, ә инде андагы бүлнистә хирург пычагы астына яту бөтенләй коточкыч хәл булып тоела. Тирә-якка даны таралган хирург Фатыйх Миңнебаевич (аны «Патих Минибаеч» диләр иде авылда) үзе ясый икән операцияне дигәч, Равиянең ата-анасы да, күршеләр дә, хәтта без бала-чага да бераз тынычландык, әлбәттә.

Менә Равияне, операциядән соң бүлнистә күпмедер яткач, алып кайттылар. Үзгәргән Равия. Бераз эреләнгән. Безнең сорауларга теләр-теләмәс кенә җавап бирә. Һәрвакыт ачык йөзле, кыты-кыты көлә торган күрше кызының аз сүзлеләнеп, борынын чөебрәк кайтуының сәбәбе тиздән аңлашылды. Русча сөйләшергә өйрәнеп кайткан икән ул. Беркөнне гадәттәгечә сыерлар сауганнан соң, минем әбинең капка төбендәге утыргычка күрше хатыннары җыелды. Равия әнкәсе Гаян апаның алдында утыра. Кемдер шунда әйтеп куйды:

– Равия русча өйрәнеп кайткан дип ишеттек...

– Әйе, – ди Гаян апа. — Йә кызым, русча әйтеп күрсәт әле.

Шунда Равия горур кыяфәттә:

– Скурый пумыщ, – диде.

– Тагын нинди русча сүзләр отып кайттың, — дигәч, Равия:

– Патих Минибаеч, – дип җавап бирде.

## Батый хан һәм Патыйха

Авыл үзәгендә урнашкан кибет каршында ялгыз карчык яши, йортның албакчасы буена сузылып яткан бүрәнәдә һәрвакыт ирләр утыра. Кемдер кибеттән чыккан кешедән башын төзәттерүне өмет итә, кемдер дөнья хәлләрен белер өчен чыгып тәмәкесен көйрәтеп утыра, кемдер аралашыр өчен шунда килә торган иде. Алар тирәсендә бала-чага да чуала. Чөнки олыларның сөйләшүе һәрвакыт кызык, әллә кайчан булган әкәмәт вакыйгаларны, галәмәт хәлләрне беләсең, бала башың белән белмәгән-аңламаган бик күп нәрсәләргә күзең ачыла.

Бер тапкыр шулай өлкәннәрнең сөйләшкәнен тыңлап, бүрәнәнең иң очында утырам. Минем белән янәшә Хәсән абый бүрәнәнең теге башындарак утыручы агайның тарихи-сәяси фикерләрен дикъкать белән тыңлый. Теге агай монгол-татарларның Русияне яулау чоры турында белгәннәрен сөйли. Хәсән абый күптән түгел, хатыны вафат булгач, Фатыйха исемле ялгыз апага өйләнгән иде. (Безнең авылда Фатыйханы «Патыйха» диләр). Тарихны шәп белүче теге агай:

– Батый хан Киевне алган... – дип, шуннан соң ул чорда ниләр булганын кыскача аңлатып, тәмәкесен авызына капкач, Хәсән абый, барысы да ишетелерлек итеп:

– Батый хан Киевне алган, ә мин Патыйханы алдым, – дип куйды.

## Бәләкәй...

Авылыбызга читтән килгән тарих укытучысы, мәктәп складыннан чыгып килүче завхозны туктатып:

– Карале, Әбүзәр, мин кышлаган бозау сатып алган идем, суйгач ите аз чыкты, –



дип зарланырга тотынды. – Бер яшьлек тана шулай бәләкәй була микәнни?

Әбүзәр абый:

– Мин бит ул бозауны күрмәдем, әйтә алмыйм, – дип җавап бирде.

Бу вакытта мин (бишенче класста укый идем бугай) икенче сменага укырга барышлый, туктап, мәктәп атын караучы Фаиз абыйның ат җиккәнен карап тора идем.

Завхоз сүзне бозау темасыннан читкәрәк борып, дөнья хәлләрен сөйләргә тели, ләкин шикчел укытучыда бер генә кайгы – торымнан-торымга кышлаган бозау дип кышламаганны сатмадылар микән дигән шиген кабатлый. Ул, шәһәр кешесе буларак, бозауның ничә айлык яки ничә яшьлек икәнен аера белмәгәндер инде, күрәсең.

Фаиз абый боларның әңгәмәсен тыңлый-тыңлый ат җигә, мин исә ат җигү алымнарын отып калырга тырышып күзәтеп торам. Ә читтән килгән укытучы Әбүзәр абыйга инде әллә ничәнче кат җанын ашаган бер үк сорауны бирә:

– Кышлаган дип саттылар бозауны, бик бәләкәй булды бит ул, ите аз чыкты, алдамадылар микән мине? Кышлаган бозау шулай бәләкәй була микәнни?

Бу вакытта мәктәп бакчасын каравыллаучы Бибиҗамал карчык үтеп бара иде. Тәбәнәк буйлы, тыр-тыр атлап йөргәнгә күрә ул әбине «Пырлыйн карчык» диләр иде.

Фаиз абый атны җигеп бетергәч, башындагы бүреген калкытып куйды да тарих укытучысына:

– Син кайчаннан бирле инде Әбүзәрнең теңкәсенә тиясең: «Кышлаган микән, ите аз, алдамадылар микән, бәләкәй булып чыкты...» – Фаиз абый үтеп баручы Бибиҗамал карчыкка ишарәләде. – Әнә, Бибиҗамал ничә кыш кышлаган, ну бәләкәй инде, нишләтәсең аны!

## Көзге урман

Беренче класска укырга кергән елның алтын көзендә малайлар белән җыелышып урманга бардык. Кәрәкә урманы дип атала иде ул, нигә алай атаганнарын белмим. Урманга килеп керү белән уң якта имәнлек (анда җәй көне җир җиләге бик шәп уңа), ә сул яктагы калкулыкны өрәңгелек биләп алган. Өрәңге яфракларын көз көне күргәнегез бар бит инде. Нинди матурлык! Нинди генә төсләр юк! Ул хуш исләр аңкуын әйтеп бетергесез! Шул өрәңгелеккә кереп, алтын диңгезендә йөздек. Минем сулышым капты, таң калдым, әле мондый матурлыкны моңарчы күргәнем юк иде. «Ничек инде шундый матурлык булырга мөмкин? – дигән сәер сорау туды шулчак башымда. – Кеше кулы белән ясалмаган бит, ничек мөмкин бу?!» Чыннан да, төш кебек иде ул күренеш.

Хәзер ел саен диярлек урманга барып шул матурлыкны, шул хозурлыкны эзлим, ләкин табалмыйм. Үзгәрсә дә, шул ук урман, шул ук көз бит югыйсә...

Матурлыкны күрергә дип максат куеп, чын гүзәллекне күрү, аның асылына төшенү мөмкин түгелдер. Ә менә бер мәлне ниндидер серле көчләр тәэсирендә аңның төксе тарафлары яктырып китә дә, ләззәт-кинәнү белән көтелгән гайре табигый әверелеш урынына инде меңәр-меңәр мәртәбә кабатланган һәм киләчәктә гел кабатланачак гап-гади вакыйга урын ала; әмма шул ук вакытта сәер бер сиземләү белән мизгел эчендә могҗиза барлыкка килгәнне аңлыйсың, ә инде шунда син багланышка кергән чынбарлыкның чынлап та могҗиза икәнлегенә ышана башлыйсың, гомереңнең шушы өзегендә сиңа күрергә язган вакыйганың асылына төшенгәндә, тирә-яктагы яшәешнең һәр тамчы-мизгеле, һәр хәрәкәте, һәрбер авазы тылсымлы дип кабул кыласың һәм ригаяңне[1] җәлеп итеп сине әсир төшергән күренеш исә бөек могҗизаның куенындагы кечкенә бер могҗиза икәненә инанасың.

Мин моны хәзер аңлыйм. Илле ел элек өрәңгелек кочагында гүзәллектән сулышым кабып тик тордым, бу өндәге төшем гел кабатланыр дип ышандым...

[1] Ригая — игътибар.

Җиде яшемдәге «мин» түгел шул инде үзем. Тормышымда иң гүзәл күренеш ул, минем беркайчан да бүтән андый илаһи матурлыкны таба алганым юк. Һәм гомерем буе күз күрмәс сукмактан шул урманга, өрәңге яфракларының алтынында коенырга барам. Кеше барыбер үзенең асылындагы бер гүзәллеккә мәңге бара торгандыр инде ул. Мин дә шул бердәнбер гүзәл күренешемә юл тотам.

## Сырган чалбар

Чүпрәк, сөяк, төсле металл җыючы Кыям абыйны «Заготовитель Кыям» диләр иде авылда. Сугыш ветераны, неместә әсирлектә булган Кыям абый бала-чага өчен бигрәк тә серле, затлы, бай кеше санала иде. Бер чиләк сөяк тапшырсаң, төрле төстәге өч-дүрт шар бирә, бер капчык чүпрәккә берничә пачка пистон аласың, чүпрәгең күбрәк булса, хәтта шул пистонны кыстырып ата торган пистолет алу бәхетенә дә ирешергә мөмкин.

Авылыбыз уртасыннан аккан инешнең сул ягындагы урамнар барысы бергә Аръяк дип атала. Кыям абый Аръякта яши, урамнары берничә йорттан гына тора, тыныч, аулак урын. Сарык йоны тапшырган өчен хәйран гына акча түли торган булгандыр инде – Аръяк малайлары Кыям абый лапасыннан тапшырылган һәм калага озатырга әзерләп куелган сарык йонын урлап, берничә көн узгач, яңадан шул йонны Кыям абыйга тапшырып акча эшләгәннәрен хәтерлим. Озак бәйрәм итә алмадылар ул малайлар, беркөнне  тоттылар аларны. Шуннан соң аның лапасыннан әйбер урлаучы булмады.

Бәләкәй чакта шартлый, яна торган нәрсәләргә нык кызыгасың бит инде ул. Сөяк, чүпрәк, иске самавырлар тапшырып, пистолет-пистонга ия булган малайларны күргәч, мин нәрсә илтә алам икән дип баш ватарга тотындым. Әбиемнең өй түбәсендә сакланган борынгы җиз самавырны Кыям абыйга илтеп бирсәм, пистолет кына түгел, өстәп тагын әллә нәрсәләр бирер сыман иде. Әмма әбием самавырны Кыям абыйга илтеп бирергә теләвемне хупламады, чөнки самавыр, иске булса да, затлы әйбер бит инде ул, аннары, әби өчен истәлекле нәрсә дә булгандыр – ул самавыр чынлап та бик борынгы иде. Самавырны бирмәгәне өчен үпкәләмәдем әбиемә, аның әйткән сүзенә хәтерем калды. Сорап теңкәсенә тигәч, ул миңа: «Кит, селәгәй банкрут!» – диде. Әбиемнең миңа әйткән авыр сүзе гел шул «селәгәй банкрут» иде, шуннан да катырагын әйткәне булмады. Банкрот сүзенең мәгънәсен аңламагач һәм әбием ачуы килгән чакларда гына әйткәч, бик начар сүз булып тоела иде ул миңа.

Чиләк тотып бакчаларда, бакча артларында йөреп карадым, чиләк төбен күмәрлек кенә сөяк җыелды, ләкин моның өчен кызыл яки сары төстәге бер шардан артыгын бирми иде Кыям абый.

Бөтен өмет чүпрәк-чапракта хәзер. Әнидән иске чүпрәкләрне бирүен үтендем. Әни миңа мунча өйалдындагы почмакта яткан иске күлмәкләр, тастымаллар, оекбашлар арасыннан иң аламаларын сайлап алырга рөхсәт итте. Арыш капчыгына дыңгычлап чүпрәк тутыргач, әни, шикләнеп, капчыкны бушатты да тикшерергә тотынды. Капчыктан иске-москы әйберләр белән бергә өр-яңа тастымал, апаның әле төсе дә уңмаган җәйге күлмәге, әтинең ике пар эш бияләе һәм үземнең әле күптән түгел алынган фуражкам чыккач, әни, орышып, аларны «конфисковать» итте һәм мин авырлыгы белән ике килога да тулмаган берничә чүпрәк кисәге белән калдым.

Мәхрүм булдым пистолет белән пистоннан. Ә бит Кыям абый үзе ясап ятмый ул пистолетларны, пистоннарны, берәр көнне бетәчәк бит алар, авылыбызда малайлар күп – ул заманда ел саен беренче класска утыз-утыз биш бала укырга керә иде.

Әтинең эш кораллары, иң кирәкле әйберләре саклана торган агач келәтне ачып кердем. Килеп керү белән үк түрдә кадакка элеп куелган сырган чалбарга күзем төште. Әти кышка гел яңа сырган чалбар алып кайта иде. Чалбарны алдым. Эчендә мамык булса да, сырган чалбарның авырлыгы пистолетка тарта иде. Кышка әле ерак, әти чалбар юклыгын тиз генә сизмәс дип, капчыкка сырган чалбарны дүрткә бөкләп тыктым да Аръякка киттем.

Кыям абый сырган чалбарны әйләндергәләп карады да, шуннан соң шактый вакыт миңа карап торды. Минем йөрәгем жу итте – әзсенде инде әллә? Юк, ул аны үлчәп тә тормады, өеннән пистолет белән ике пачка пистон алып чыгып бирде.

Урам буйлап, пистолеттан пистон белән чәлт-челт ата-ата, өйгә кайттым. Капкадан кергәч, келәтнең ишеге ачык икәнне абайладым, әти анда балта кайрый иде. Тиз генә

пистолетны чалбар кесәмә тыгып, өйгә кереп шылмакчы идем, әти миңа эндәште. Эләгә хәзер әтидән дип, курка-курка гына келәт янына килдем.

– Минем монда сырган чалбар эленеп тора иде, кая икән ул? – ди әти.

– Белмим, – дидем, ә үзем шундук барыбер әйтергә кирәк икәнне аңладым.

– Син алып берәр җиргә куймадыңмы? – дип сорады әти.

– Мин аны Кыям абыйга сдавать иттем, – дидем мин, башымны аска иеп.

– Ничә сум бирде? – дип кызыксынды әти.

– Пистолет белән ике пачка пистон бирде.

– Кая, күрсәт әле пистолетыңны.

Әти пистолетны миннән алып әйләндергәләп карады да, көлемсерәп:

– Һи, өр-яңа җылы сырган чалбар өчен Кыям сиңа автомат бирергә тиеш бит, шушы наганны гына бирдеме?! – диде. – Ул сырган чалбарны, кыш җиткәч, Кыям үзе киеп йөрер инде.

Әти миңа пистолетымны бирде дә балта кайравын дәвам итте.

Әйбер югалтсам да, берәр эш коралын ватсам да, акчасын чәлдерсәм дә, әти мине беркайчан ачуланмады – матди нәрсәгә, акчага һәрвакыт фәлсәфи күзлектән карый белә торган кеше булды ул, яшәү кыйммәтен байлыкта, малда эзләмәде, ә булган нәрсәсен чын хуҗаларча кадерләп саклый һәм куллана белә торган кеше иде. Хәзер аңа сиксән биш яшь, ул һаман да әле, җәй җиткәч, утыз ике ел элек Ижаудан сатып алып кайткан мотороллерына утырып йөри, 1970 елгы «Дружба» пычкысын кабызып утын кисә. Аллага шөкер!

## Гайфуллин Рәис

Һәр кешенең гомер буе саклана торган хатирәләре була. Хәтердә, күңелдә мәңгегә уелып калган вакыйгалар миндә дә бар.

Дүртенче классны тәмамлаганда, Алабуга шәһәренә Шишкин музеен карарга экскурсиягә алып бардылар. Классыбызның җитәкчесе – читтән килгән олы яшьтәге укытучы Сара Закировна 35 балага эстетик тәрбия бирү ниятеннән мәшһүр рәссамның шедеврларын күрсәтергә теләгәндер инде. Бөтен класс мәктәп ишегалдында җыелгач, Сара апа: «Гайфуллин Рәис бармый!» – дип игълан итте.

Әйе, шук, тиктормас малайлар классыбызда шактый иде, шуларның берсе мин үзем идем, әмма Гайфуллин Рәис, дөрестән дә, арабызда иң «йөгәнсезе» булгандыр, мөгаен. Укытучы апаның сүз тыңламый торган, көтелмәгән матавыклар чыгаручы малайны шактый ерак сәфәргә алырга теләмәвен, бер яктан караганда, аңларга да була. Икенче яктан караганда, ул бит Алабуга шәһәрендә янгын чыгармас иде инде, музейдагы картиналарны да бозмас иде. Никтер, Сара апа нык каныккан иде ул малайга. Рәис, үҗәтләнеп: «Барам, барам!» – дип кабатлады. Сара Закировна исә: «Иярсәң, бөтен класс бармый, экскурсияне отменять итәм!» – диде.

Рәис минем иң якын дустым иде дияргә була. Төрле урамнарда яшәсәк тә, мәктәпкә кадәр бер-беребезне күрми үссәк тә, без аның белән нык дуслаштык. Аның әтисе Зәй буендагы җәйләүдә көтү көтә иде, шуңа күрә Рәис бәләкәйдән үк кармакка оста балык тотучы иде. Мине ул өйрәтте кармакны көйләргә: кармак сабы нинди булырга тиеш, кыл нинди озынлыкта кирәк, калкавыч белән батыргыч арасы никадәр куела, суалчан кармакка ничек кигертелә. Билсәпитләргә атланып, иртүк Зәйгә төшеп китә идек тә караңгы төшкәч кенә кайта торган идек. Безгә эре балык эләкми иде, Рәис бик оста булса да, вак йомычка зурлыгындагы шыртлака, алабуга, бәртәс, кечкенә табан балыкларын тота идек. Балык түгел, табигать үзе кызыктырган безне. Без анда иректә дип хис итә идек үзебезне. Тәмәке тарта идек, учак ягып, көлдә бәрәңге пешерә идек, тирә-якны яңгыратып җырлый идек. Рәис бик матур җырлый иде. Һәм һәрбер җырны үзенчә үзгәртеп, шаян якка бозып, сүгенү сүзләре кушып җырлый торган иде.

Укытучылар өчен «җайсыз бала» булса да, кызык, талантлы, юмарт кеше иде Рәис.

Сара Закировна аның берүзен класстан аерып калдыруы мине тетрәндерде. Класс җитәкчесенең беләгенә ябышып: «Апа, барсын инде Рәис тә!» – дип ялвардым. Миңа кушылып тагын берничә бала Рәисне яклап сүз әйтте. Әмма: «Синең аркада экскурсиягә бармый калабыз, бар, кайтып кит!» – диючеләр күбрәк булганны хәтерлим. Ул вакытта

ундүрт-унбиш яшьтә булсам, һичшиксез, укытучыга протест йөзеннән, мин дә Алабугага барудан баш тартып, дустым белән янәшә калган булыр идем. Ул чакта миңа ун яшь кенә, экскурсиягә бик барасы килде шул.

Рәис ап-ак күлмәк киеп килгән иде. Без класс белән автобус тукталышына киттек, Рәис берүзе безнең арттан карап калды. Аны кызганудан мин елар дәрәҗәгә җиттем. Безне Кама буендагы Кызыл Чишмә посёлогына илтеп куярга тиешле мәктәп машинасы килеп туктагач, экскурсиягә әллә бармыйм микән дигән уй да килде үзе башыма. Класс мәктәп машинасының арбасына төялгәндә дә, Рәис әле һаман кымшанмыйча басып тора иде.

Ошамады миңа Алабуга шәһәре дә, музейдагы картиналарга да исем китмәде, гомумән, бу сәяхәттә мин бер шаккатырлык нәрсә тапмадым. Көне буе күз алдымда укытучыга үпкәләп, безгә ачуы килеп кайгыга баткан ап-ак күлмәкле дустым Рәис торды. Сара Закировнага да шуннан соң мөнәсәбәтем үзгәрде.

Күп еллар үтте, ә бу вакыйга, әле кичә генә булган кебек, аермачык күз алдымда тора. «Ун яшьлек малайны класс алдында шулай кимсеткәч, музейга баруның ник кирәге бар?» – дигән сорау тынгылык бирми дә бирми. Ун яшьлек баланы рәнҗеткәч, Шишкин музеена барудан ни мәгънә?!

Хәзер инде Рәис бу дөньяда юк (кырык яшендә вафат булды), Сара Закировна да бакый дөньядадыр инде (ул безне укытканда ук пенсия яшендә иде), теге вакыйга исә һаман яши миндә – без җыелышып китеп барабыз, ә Рәис, ап-ак күлмәктән, безгә карап тора...

Утыз яшьләр тирәсендә Рәис бавырын җәрәхәтли – «Беларусь» тракторына печән төяр алдыннан арбадагы ломны алып җиргә сикерә дә лом очлы башы белән аның бавырына кадала. Исән кала калуын, ләкин шуннан соң торымнан-торымга бавыры авыртып бимазалана. 2000 елны мин Казаннан авылга әти-әнигә печән чабышырга кайттым. Яңгыр килә иде, ашыга-ашыга чабам. Шунда әрәмә эченнән Рәис килеп чыкты, алар да шул тирәдә чабалар икән. Озак сөйләшеп торырга вакыт юк иде, исәнләштек тә, мин чабуымны дәвам иттем, ә ул, мине аңлап, китеп барды. Соңгы тапкыр очрашуыбыз булган икән. Шул җәйне, үзенең туган көнендә – нәкъ кырык яше тулган көнне үлеп киткән. Шуннан соң үземне гел битәрлим – кадалып китсен иде печәне, рәхәтләнеп сөйләшәсе калган, сәламәтлеге турында да сорамадым бит.

2006 елны минем «Телсез күке» исемле спектаклем белән Бөекбритания башкаласы Лондонга бардык.

Без анда 11 көн булдык. Алтынчымы, җиденчеме көнне мин бер төш күрдем. Классташым, дустым Гайфуллин Рәис керде төшемә. Бернинди хәрәкәтсез, сүзсез миңа тик карап тора, йөзе аермачык якты.

Мин берничә көн бу төш турында уйлап йөрдем – нишләп Рәис керде соң әле төшемә, нindидер хикмәте бар бу төшнең, ни әйтергә теләде икән ул миңа? Вафат булган кешенең төшкә тикмәгә генә кермәгәнен һәркем белә бит.

Ниһаять, башыма бер «ачыш» китереп сукты – аңладым мин нишләп Зәй буйларында туып үскән Рәиснең әллә ничә мең чакрым ераклыктагы Темза буенда төшемә кергәнен.

Лондонның Милли галереясына ике көн рәттән барып, бөтен дөньяга танылган сәнгать шедеврларын карап йөрдем. Нәкъ шул көннәрнең берсендә күрдем бит сине төшемдә, Рәис туган! Аңладым, аңладым! Мәшһүр рәссамнарның мирасын күзәтеп йөргән көннәремдә синең миңа эндәшәсең килгәндер, 1971 елны булган хәлне онытмады микән дип уйлагансыңдыр. Юк, Рәис туган, онытмадым, хәтеремдә ул вакыйга.

Әйе, дөньяда югары сәнгать бар. Күз явын алырдай бөек картиналар бихисап. Яңалары да туа тора. Әмма барлык музейларны, галереяларны, күргәзмәләрне карап чыккан сурәттә дә, аларда иң бөек бер картина-күренеш җитми, дөнья галереясы аннан башка тулы түгел. Алабугадагы Шишкин музеенда да бушлык бар, хәтта Лондондагы Милли галереяда да җитенкерәмәгән нәрсә бар!

Минем өчен иң кирәкле бер картина җитми галереяларда, музейларда, күргәзмәләрдә. Ул мондый картина: кешеләр төркеме каядыр китеп бара, аларның артыннан ап-ак күлмәкле ун яшьлек малай үпкәләп карап кала.

**Зөлфәт ХӘКИМ**

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Бәхетсез иткән сугыш...

**Әлеге вакыйга инде онытыла да башлаган иде. Тик менә бүгенге хәл аны барсының да янәдән исенә төшерде.** Әминә әбидән интервью алырга килгән мәктәп укучылары аны яңадан яшьлек елларына, сугыш чорына әйләнеп кайтырга һәм саф мәхәббәтен исенә төшерергә мәҗбүр итте. Өйдә тынлык урнашты, барсы да Әминә әбине тыңларга утырдылар, һәрбер сүзен язып барырга керештеләр. Ак яулыклы, ап-ак кардай ак чәчле Әминә әби үзенең тормыш йомгагын яшь хәбәрче балаларга сүтеп җибәрде.

– Хәлле генә бер гаиләдә без ике матур кыз үстек. Исемнәребез дә бигрәк матур. Беребез – Әминә, икенчебез – Җәмилә. Әти-әниебез исем кушканда, бәхетле булсыннар дип уйлаганнардыр да соң...

Әтиебез Зиннур авылда зур булмаган кибет тота. Безне дә гел матурдан киендереп йөртә.

Мактанып әйтүем түгел, матурлыгыбыз, гүзәллегебез, нәфислегебез авыл егетләренең күз яуларын алырлык була. Кич җиткәч, бергәләшеп уенга чыгабыз. «Чума үрдәк, чума каз» уены вакытында авылның баһадир егете Хәтмулланың зәңгәр күзле, озын чем-кара чәчле кызга, миңа күзе төшә. Мин дә инде егетне игътибарсыз калдырмыйм. Әкренләп очраша башлыйбыз, арабызда мәхәббәт уты кабына, көз җиткәч өйләнешергә дип вәгъдәләр бирешәбез. Янымда яраткан кешем булуы белән үземне бик тә бәхетле тоя идем, – дип сөйләвен дәвам итте Әминә әби. – Алдагы тормыш турында уйланып, хыял диңгезендә йөзеп йөргәндә, Хәтмуллага армиягә чакыру кәгазе килде. Мин инде көтәргә вәгъдәләр биреп озатып калдым.

Күп тә үтми әти-әнием мине, димләп, икенче бер авылга, үземнән өлкәнрәк Хәсәнҗанга кияүгә бирделәр. Ничек инде олылар сүзеннән чыгасың, буйсынырга мәҗбүр булдым. Бирелгән вәгъдә җепләре шул минутта өзелде... Төннәрне елыйелый Хәтмулламны сагынып үткәрәм. Тормыш йомгагы алга таба тәгәри дә тәгәри. 16 яшь кенә иде әле ул вакытта миңа. Чибәр, акыллы, тәрбияле, зыялы Хәсәнҗанны яратырга өйрәнә башладым, көннән-көн аңа ияләштем. Гаиләмне бәхетле итеп, бер-бер артлы ике матур кызыбыз, ике улыбыз дөньяга килде.

1941 ел... Көтмәгәндә Бөек Ватан сугышы башланды. Сугышка барлык авыл ирләрен чакыра башладылар. Хәсәнҗанга да чакыру кәгазе килде, мин дә иремне елый-елый озатып калдым. Сугыш еллары һәрбер гаиләгә ачы күз яшьләре алып килде, күпме гаиләләр ятим, ач-ялангач калды. Сугыш дисәң, йөрәкләр тетрәнә. Бу сүзләрне һич кенә дә тыныч күңел белән әйтеп булмый.

Хәсәнҗан Полтава өлкәсенә эләкте, пулемётчы булып хезмәт итте. Безгә булдыра алган кадәр хатлар җибәреп торды.

1943 ел. Август ае. Гаиләбезгә сугыш кырыннан «кара кәгазь» салдылар. Мин үземнең тормыш таянычымны югалттым. Ул вакытта төрле авырулардан, ачлык-ялангачлыктан бер генә кызым исән калды.

Көн артыннан көн үтте, Бөек Җиңү көне дә якынлашты. Бик күп кеше өчен бу бәхетле минутлар булса, минем өчен тол хатын тормышы, ялгызлык вәгъдә иткән көн иде...

Авылыма әти-әнием янына кунакка баргач, юлыма көтмәгәндә Хәтмулла килеп чыкты. Мин каушап, уңайсызланып калдым, сугыштан кайткан ир алдында башымны аска идем. Бу минутларда үземне бик гаепле тойдым, вәгъдәмне үти алмаганым өчен газап утларында яндым. Хәтмулла сугыштан исән-имин кайткан, яу кырларында алган медальләре түшен бизәп тора. Авылда аны яратып, «безнең майор абзый», дип йөртәләр.

Шул очрашу вакытында Хәтмулла мине һаман да яратуын, мине генә сөюен белдерде, яңадан кушылу теләген әйтте. Тик мин ризалыгымны бирмәдем. Ир-ат чит кеше балалары белән кабул итә алмас төсле тоелды, бәлки, кабат ялгышуым булгандыр бу… Без инде бүтән очрашмадык.

Тормыш йомгагым акрын гына алга таба сүтелде. Сугыш еллары бик авыр иде. Куш йөрәкле хатын булганмындыр инде ул заманнарда, өемә килеп кергән ач, бетле башлы кызны – Назыйманы да үз куеныма алдым. Соңрак, тол хатын тормышыннан тәмам туеп, гомеремне башка кеше белән бәйләдем, йортыбыз янә балалар тавышы белән тулды.

…Сугыш еллары инде күптән артта калса да, мин һаман да күземне басу капкасыннан алмыйм, үземнең Хәсәнҗанымны көтәм. Басу капкасыннан авылга кергән һәрбер кеше миңа яраткан иремне хәтерләтә сыман тоела.

Әминә әбинең сөйләгәннәре сугыш вакытының ачы, ялангач хәлләрен барыбызның да күз алдына китереп бастырды…

**Алёна ФӘХРЕТДИНОВА,**
*Казан шәһәре 37нче гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Җиңү парадында катнашкан бабам

**Ул дерт итеп уянып китте. «Онытканмын бит!»** Укытучы апасына Бөек Җиңүнең 71 еллыгына багышланган сыйныф сәгатендә үзенең Кызыл мәйданда Җиңү парадында катнашкан ерак бабасы турында чыгыш ясарга сүз биргән иде бит.

Берничә ай элек, кышкы салкын көннәрнең берсендә, Казанга Ильясның әбисе килде. Ильяс аның килүен түземсезлек белән көтте. Оныгы дәресләрен әзерләп бетерүгә, әбисе аңа һәр кич төрле-төрле маҗаралар, әкиятләр сөйли. Нинди матур итеп сөйли ул аларны… Тыңлап туйгысыз!

Беркөнне әбисе аңа Абзалетдин бабасы турында сөйләрмен дигән иде. Ильяс, бер минутын да әрәм итмичә, оныгы торышка чәй кайнатып, коймаклар пешереп йөргән әбисе янына чыкты.

— Мин сугыш турында китаплардан укып, кинолардан карап кына беләм, – дип сүз башлады дәү әнисе, – җирдә сугыш булмасын, бары тик тынычлык кына хөкем сөрсен иде. Сугыш ветераннарының сафлары да елдан-ел сирәгәя. Без аларны һич тә онытырга тиеш түгел. Без ветераннар алдында түләп бетермәслек бурычлы.

Минем әтием, синең Абзалетдин бабаң да Бөек Ватан сугышында катнашкан. Ул 1926 елның 24 мартында Чувашстан Республикасының Чкалов районы Чкалов авылында дөньяга килә. Шушы авылның җидееллык мәктәбен «5»ле билгеләренә генә тәмамлап, Батыр район үзәгендә укуын дәвам итә. 1944 елда Абзалетдин Шәйхелислам улы бик күп яшьтәшләре белән бергә армиягә алына. Хәрби хезмәтен тутырып тиз генә өйгә кайту насыйп булмый аңа. Тиз арада танк училищесын тәмамлап, бабаңа беренче көннәрдән үк бик каты сугышларда катнашырга туры килә. Танкистлар иң кайнар нокталарда мөһим бурычларны үтәгәннәр. Нинди генә канлы юллардан үтми, нинди генә куркыныч орышларны күрми ул. Күп кенә орден, медальләр белән бүләкләнә.

Ниһаять, зарыгып көткән Бөек Җиңү көне килеп җитә. Әтием 1945 елның 24 июнендә Кызыл мәйданда Җиңү парадында катнашу бәхетенә ирешә. Парадны Георгий Жуков үзе кабул итә. Туплар гөрселди, дошман байраклары җиргә ыргытыла, салют була. Бабаңның күңелендә бу көн онытылмас бер вакыйга булып саклана. Парадтан соң да үз хәрби частенда хезмәтен дәвам итә, туган авылына 1951 елда гына әйләнеп кайта. Шул ук елны авылның чибәр кызларының берсе – Камәрия әбиең белән өйләнешеп, матур гаилә корып җибәрәләр.

Сугыш кырларында чыныккан, фронт михнәтләрен күп татыган әтиебезне партиянең район комитеты финанслар бүлегенә бухгалтер-ревизор итеп чакыралар. Сугыштан соңгы иң авыр елларда бу җаваплы постта эшләү җиңел булмый. Әмма Абзалетдин Шәйхелислам улы үзен тырыш, булдыклы хезмәткәр итеп таныта. Язмыш җилләре бабаңны 1954 елда Иркутск шәһәренә алып килә. Ул егерме елдан артык алтын приискаларында шахтёрлар бригадиры булып эшли. «Хезмәт ветераны» исеменә лаек була, рәсеме «Мактау тактасы»н бизи.

Әбисе сөйләгәннәрдән ерак бабасы Ильясның күз алдына җанлы булып килеп басты. «Мин ерак бабамны күреп белмим. Ләкин мин аның барлыгын тоям. Сыйныф сәгатендә иптәшләремә Абзалетдин бабамның тормышын ничек тасвирларга икәнен беләм мин хәзер», дип уйлады ул.

– Сез түккән каннар, ерак әбиләребезнең күз яшьләре юкка булмаган икән. Алар бәрабәренә без рәхәт яшибез. Шуны онытмыйча, сезнең батырлыклар турында үзебездән соңгы буыннарга да җиткереп, тынычлыкның кадерен белеп яшәргә өйрәнсәк иде. Ә син, бабаем, тыныч йокла. Мин синең исемеңә тап төшермәм…

**Ильяс РӘХМӘТОВ,**
*Казандагы 4нче гимназиянең*
*3 «А» сыйныф укучысы*

---

# БАКА-БАКЫЛДЫК

ӘКИЯТ

Борын-борын заманда яшәгән ди бер симез бака. Ул күп сөйләшә торган булган. Шуңа күрә аңа Бака-бакылдык дип исем кушканнар. Ул ишегалдындагы бөтен йорт хайваннарын һәм кош-кортларны үзенең туктаусыз бакылдавы белән тәмам туйдырып бетергән. Барлык йорт хайваннары күмәкләшеп эш эшләгәндә, ул бармакка бармак та ормый ди. Алар көне буе эшләп, кич белән арып йокларга ятса, Бака-бакылдык көне буе йоклап, кич җиткәч тамак киереп бакылдарга керешә икән. Моның әлеге гадәтенә түземлеге калмаган хайваннар, бака белән бер-бер хәл кылырга уйлашканнар. Көндәлек эшләрен тәмамлагач, ишегалдында җыелыш җыйганнар. Җыелышта сүзне, беренчеләрдән булып, горур әтәч алган. Ул, күкрәкләрен киереп, канатларын җилпеп, койма башына менеп баскан да: «Җәмәгать, Бака-бакылдыкның тәртибе бер дә канәгатьләнерлек түгел. Без иртә таңнан торып эшкә чыгып китәбез, ә ул көне буе күләгәдә йоклап ята, без йокларга яткач, бар дөньяны яңгыратып бакылдый башлый, беркемгә дә йокларга ирек бирми. Шуңа күрә аны хуҗалыктан куарга тәкъдим итәм!» – дигән.

Әтәчнең бу фикере белән барлык йорт хайваннары да килешкәннәр һәм баканы хуҗалыктан шактый ерак урнашкан камышлы күлгә куып җибәрергә карар кылганнар.

— Бака-бакылдыкның ялкаулыгын беләбез, — дип сүзгә кушылган Энҗеле үрдәк, — ул ярты юлдан кире борылып кайтырга мөмкин. Мин аны күлгә чаклы үзем озатып куям.

Һәм Энҗеле үрдәк Бака-бакылдыкны камышлы күлгә озата киткән. Бик тиз әйләнеп кайткан үзе… Әмма шул көннән бирле Бака-бакылдыкның тавышын ишеткән кеше юк ди…

**Роза КӘЛИМУЛЛИНА,**
*Алабуга шәһәре 9нчы урта мәктәбенең*
*10нчы сыйныф укучысы*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Сибгат ХӘКИМ**

## Блокнотлар

Мунчада… Иң матур җыр, иң матур арияләрне шунда ишеттем. Берсе җырлый, берсе сызгырып кушыла. Күрәсең, җан йомшый, җан эри…

Кайсы шунда Глинканы көйли,
Кайсы Сәйдәш, кайсы Шубертны.
Җырның биек ноктасына җиткәч
Кычкыралар: «Кайнар су бетте…»

***

Илле яшь тулгач, мәҗлестә
Эчик, дуслар, «Цинандали»;
Илле – ир уртасы, дип, ул
Миналдалый, синалдалый.

***

Дуслар сорый: «Борның күккә чөеп
Йөргән чагың синең кайда?» – дип.
Үтте инде, үтте ул вакытлар,
Төште борын… Миндә – гайморит.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Харис абый фәлсәфәсе

Авыл картлары сарык абзары төзәтәләр. Ял итәргә туктадылар. Яннарына барып чүгәләдем.

Исәнлек-саулык сорашкач, китте сүз.

— Карале, Туфан, син үзең уйлап чыгарасыңмы, әллә күргәнеңне, ишеткәнеңне генә язасыңмы? — ди берсе.

— Әкиятне генә уйлап чыгаралар, — дип җавап бирә Касыйм абый, — ә ул тыңлап-тыңлап йөри дә сезнең ишеләрнең сүзен, төзәткәләп, яза да куя.

— Акча түлиләрме инде ул синең язганыңа, Туфан?

Касыйм абый бирешми, тагын минем өчен җавап бирә:

— Түләмәскә син әллә теге… Кәчтүнен нинди акчага сатып алган дип беләсең? Ул бит синең шикелле колхоз люцерен урлап сыер асрамый.

Көлешәләр. Сүзгә Бәдретдин абый кушыла.

— Менә син зур кеше инде, Туфан, Мәскәүдә укыдың, радиодан сөйләтәләр, телевизордан күрәбез… Менә син ничек алай булдың да, нигә минекеләр синең кебек була алмый? Алар да шул синең кебек Салтык мәктәбенә йөрделәр бит. Син укыган китаптан укыганнардыр.

— Малайларыңны хурлама, Бәдретдин абый, — дим. — Үз эшен җиренә җиткереп эшләгән һәр кеше дә зур кеше. Менә дигән итеп эшлиләр ич малайларың.

— Эшләвен эшлиләр дә бит, укымадылар… Сигездән ары китә алмадылар.

Әңгәмәгә бик аз катыша торган Харис абый түзмәде:

— Башын катырма Туфанның, Бәрттин. Уку нәселдән килә ул, — диде.

— Минем нәсел Туфан нәселеннән кай ягы белән ким?— диде Бәдретдин абый.

— Кимме, артыкмы, сезнең нәселдән укыган кеше чыкмаячак, Бәрттин, — дип Харис абый үз теориясен исбатларга кереште, — бабаң, атаң көтүче булган. Үзең көтүче, малайларың көтүче, аларның малайлары да көтүче булачак. Ә Туфанның әтисе Гаптул язу-сызу тирәсендә кайнашты, Туфан да шунда, аның да балалары язу белән тамак туйдырачак. Ник дисеңме? Менә тыңлап кара. Туфанның малае туды ди, аякка йөри башлады ди. Идән буйлап кылтыйн-мылтыйн атлап барганда, ул абынып егыла. Абынып егылган нәрсәсе — китап. Шуннан, үсә төшкәч, Туфанның малае сорый әтисеннән, әти, нәрсә бу, ди. Туфан әйтә, китап, ди. Нигә ул китап, ди малае. Туфан аңлата башлый, малай күте белән шуышып йөргәндә үк хәреф танырга өйрәнә. Синең малаеңның малае туды ди. Кылтыйн-мылтыйн атлап әтисе янына килде ди. Әтисе чыбыркы ишеп утыра ди. Әти, нишлисең, дип сорый малае. Чыбыркы ишәм, улым, ди әтисе. Нәрсәгә ул чыбыркы, дип сорый малае. Әтисе аңлата, чыбыркыны шартлатып күрсәтә, малаен да чыбыркы шартлатырга өйрәтә. Менә шул: көтүчедән — көтүче, укыганнан укыган туа, Бәрттин.

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

## Сорауга сорау

– Ни өчен Мәскәү Кремеле кызыл төстә дә, Казан Кремеле ак төстә? – дип сораганнар Минтимер Шәймиевтән.

– Кем әйтмешли, Казан Кремеле ни өчен кызарырга тиеш әле? – дип, сорауга сорау белән җавап биргән ил агасы.

## Кул чабу

Композитор Александр Ключарёвның 100 еллыгы. Шагыйрь Ренат Харис шигырен укыгач, сәхнәдән төшеп бара. Халык тыйнак кына кул чаба башлап, куе алкышларга күчә. Харисның урынына барып утыруы була, халык тагын да көчлерәк кул чабарга тотына. Харис торып баса да, уңлы-суллы борылып, рәхмәтен белдереп, тамашачыларга баш ия.

Баксаң, Ренат Харис төшеп барганда ук, сәхнәгә Илһам Шакиров чыгып баскан булган икән.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Акыллылар арасында

Марсель Гали, шаулатып, Академия театрында юбилей кичәсе уздырган. Берничә көннән аңа Мөслимнән Фоат Садриев шылтырата икән:

– Соңлап булса да котлыйм. Ничек үтте юбилей кичәң?

– Зал шыгрым. Казанның бөтен акыллы кешесе җыелган иде.

Фоат Садриев, көрсенеп, әйтеп куя:

– Ул кадәр акыллы арасында берүзеңә кыен булгандыр…

**Гәрәй РӘХИМ**

## Урман суы шәп ага…

Мәскәүдә РСФСР Язучылар Союзында Сергей Михалков кул астында эшләгән чагым.

СССР язучыларының чираттагы съездыннан соң безнең Татарстан делегациясе, Мәскәү–Казан поезды иртәрәк китү сәбәпле, банкетта катнаша алмады. Мәҗлес, гадәттәгечә, Кремльнең Съездлар сараенда булды. Оста тамада буларак, Михалков һәр мәҗлескә үзенчә яңалык кертергә ярата иде. Бу банкетта ул шундый тәкъдим кертте

– тост әйтергә тиешле язучы сүз әйтеп тормый, ә үз халкының милли көен башкара. Шулай итеп, бөтен илдән җыелган танылган язучылар бер-бер артлы рус, грузин, әрмән, украин, казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, молдован, беларус һәм башка халыкларның җырларын яңгыраттылар. Мин тост әйтәчәк төрки телле язучыларның төгәл исемнәрен Михалков колагына пышылдап тордым.

Инде тостлар бетеп килә, зал шактый кәефләнгән иде, шунда Михалков миңа борылды да, гадәтенчә, тотлыгыбрак: «Та…та…рин, а у татар песни есть?» – дип сорады. Мин инде бик җитди булырга тырышып, аңа: «А как же, Сергей Владимирович, татары очень певучий народ. Их мелодии очень задушевные, у них даже есть слово «моң», которое не переводится на русский язык», – дип җавап бирдем.

– Тогда спой! – диде Михалков. Минем икеләнебрәк калуымны күреп: «Та…та…рин, – диде, кырыслана төшеп, – я твой начальник, ты должен делать то, что я скажу, иначе уволю!»

Минем инде, әлбәттә, Мәскәүдәге эшемнән колак кагасым килми иде, кинәт батыраеп: «Һәй, ни булса, шул булыр», – дип, туган авылым Федотовкада тыңлап үскән «Урман суы шәп ага»ны бар тавышыма сузып җибәрдем. Аннары кушымтага күчеп:

*Әйдә, әйдә, кайда, кайда,*
*Әйдә барыйк урманга.*
*Урман буйлары абага,*
*Урман суы шәп ага!*
*Авылыбызда бер чибәр бар –*
*Әйдә салыйк шобага! –*

дип җырны тәмамладым.

Бәхетемә, зал гөрләтеп кул чапты. Михалков, кулын иңбашыма куеп: «Молодец, та…та…тарин! Оказывается и у татар есть песни, мелодия нам всем понравилась», – диде. Мин шатлыгымнан аның артындагы урындыгыма сеңдем. Ул да булмады, Михалков тагын миңа табан борылды да: «Эй, та…та…рин…, мелодия замечательная, но нам не понятно, о чём говорится в песне. Давай, переведи на русский язык», – диде. Мин югалып калдым һәм Михалковка: «Сез, бөек шагыйрь буларак, тәрҗемә эшенең четерекле икәнен, аңа вакыт кирәген яхшы беләсез», – дип акланырга тотындым.

Михалков тагын кырысланып: «Та…та…рин…, я твой начальник, ты должен делать то, что я скажу, иначе уволю!» – дип кабатлады. Мин инде тәмам бөгелеп төштем, һәм кинәт башыма бер хәйләкәр уй килде: «бу залда бит татарча белүче берәү дә юк, урысча ничек җырласам да, аны баягы җырның тәрҗемәсе дип аңлаячаклар. Бу уй миңа дәрт бирде һәм мин, ни булса, шул булыр, дип, җырлап җибәрдем.

Кушымтасы болай булып чыкты:

*Айда, айда! Куда, куда?*
*Пойдём-ка на сеновал.*
*Я с такими девчонками*
*Сеновал не миновал!*
*Эх, девчонка, не ломайся,*
*Пойдём-ка на сеновал!*

Җыр бетүгә, зал баягыдан да кызыбрак кул чапты. Авызы колагына җиткән Сергей Михалков, мине мактап: «Молодец, та…та…тарин, и мелодия, и слова песни очень хорошие. Талантливый же татарский народ», – дип соклануын белдерде.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстан халкына мөрәҗәгать итте. «Үлемсез шигърият даһие татар халкының рухи үсеш юлын һәрчак яктыртып барсын, безне игелекле гамәлләргә һәм олы казанышларга илһамландырсын!» — диелә әлеге мөрәҗәгатьтә.

***

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Туган тел көненә һәм Г.Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган бәйрәм булды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов чыгыш ясап: «Бездә бүген өч зур бәйрәм – Туган тел көнен, Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуны билгеләп үтәбез һәм Тукай исемендәге премияләр тапшырабыз. Без һәммәбез дә телебезне һәм гореф-гадәтләрне саклауга үзебезнең өлешебезне кертергә тырышабыз. Киләчәктә дә телебез үсеше өчен көрәшербез дип ышанам», – диде ул. Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең 2016 елгы лауреатлары игълан ителде. Менә алар – рәссам, гарәп шрифты белән текстлар язылган картиналар авторы, гарәп каллиграфиясе остасы Исмәгыйлев Нәҗип Фәйзрахман улы (Нәҗип Нәккаш), шагыйрь Моратов Газинур Васикъ улы (Газинур Морат), «Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкларга сузылган юл» сәнгать-пространство экспозиция инсталляциясен иҗат иткән авторлар төркеме. Рөстәм Миңнеханов аларны ихластан котлады, диплом һәм күкрәк билгесе тапшырды. Тантанада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Президент аппараты вәкилләре, ТР Дәүләт Советы депутатлары, хөкүмәт әгъзалары, муниципаль шәһәр һәм район башлыклары, әдәбият, сәнгать әһелләре, чит илләрдән кунаклар катнашты.

***

Г.Тукайның туган көнендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Казандагы Тукай мәйданында шагыйрьнең һәйкәленә чәчәк салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы депутатлары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, республикабызның әдәбият, сәнгать әһелләре, Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы делегатлары, чит илләрдән кунаклар катнашты.

***

Г.Тукайның Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәле каршында Шигырь бәйрәме үткәрелде. Ул шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр салу белән башланып китте. Шигъри митингны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов ачты. ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова котлау сүзе белән чыкты. Бәйрәмгә җыелган халык алдында шагыйрьләр Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мирза, Газинур Морат, Айдар Хәлим, Эльмира Шәрифуллина, Флёра Тарханова, Шәмсия Җиһангирова, Фәйрүзә Мөслимова, Нәҗибә Сафина, Илсөяр Иксанова, Луиза Янсуар, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рифат Сәлах, Фәнил Гыйләҗев, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, олуг юбилей чараларының кунаклары Играннан галим Араз Мөхәммәт Сарлы, Кабарды-Балкар Язучылар берлеге рәисе Моталлип Беппаев, Казакъстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галим Җайлыбай, Азәрбайҗаннан шагыйрь, тәрҗемәче Акбар Гошалы, Кырымнан шагыйрь Диләвер Осман, Тувадан шагыйрә, галимә Сайлыкма Комба һ.б. чыгыш ясады.

***

Казандагы Островский урамындагы Яшь тамашачы театры бинасына куелган истәлек тактасын ачуга багышланган митинг булды. Тактага «Бу бинада 1908 елның 14 октябрендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукай беренче тапкыр «Печән базары, яһуд Яңа Кисекбаш» поэмасын укыган» дип язылган. Митингта ТР Премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев чыгыш ясады, актёр Илдус Әхмәтҗанов ошбу поэмадан өзек укыды. Истәлек тактасын ачуда ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты.

***

Г.Тукайның юбилеен Мәскәүдә дә зурлап билгеләп үттеләр. Шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салынды. Бәйрәмдә ТРның РФдәге Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Азат Әхтәриев, Мәскәү төбәк татар милли-мәдәни автономиясе рәисе вазифаларын башкаручы Фәрит Фарисов, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Рәмис Аймәт, Татарстаннан Социалистик Хезмәт Ге-

ройлары Любовь Смирнова, Николай Фролов һ.б. чыгыш ясады. Ул көнне Мәскәүнең Татар мәдәни үзәгендә бәйрәм концерты булды.

***

Казанда «Корстон» мәдәният-күңел ачу үзәгендә «Габдулла Тукай һәм төрки дөнья» дигән темага халыкара конференция үткәрелде. ТР Фәннәр академиясе, Халыкара Төрки академия, ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган бу чарада Америка, Иран, Казакъстан, Азәрбайҗан, Төрекмәнстан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән галимнәр катнашты. Конференцияне ТР Фәннәр академиясе президенты М.Сәлахов ачты. ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Ратникова ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлавын ирештерде. Конференциядә катнашучыларны ТР мәдәният министры урынбасары Г.Шәрипова, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты А.Гаязов та котлады. Пленар утырышта докладлар белән Халыкара төрки академия президенты Д.Кыдырали, ТР Фәннәр академиясенең гыйльми сәркатибе Д.Заһидуллина, Мәхмүткολы исемендәге Тел һәм әдәбият институты (Төрекмәнстан) директоры Г.Киясова, Висконсин университеты (АКШ) профессоры Ш.Юлай, Г.Цадаса исемендәге Тел һәм әдәбият институты (Дагыстан) директоры М.Магамедов, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.Миңнуллин чыкты. Аннары конференция эшен секцияләрдә дәвам иттерде.

***

Г.Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан аның туган ягы – Арча районында да күп кенә чаралар уздырылды, игелекле эш-гамәлләр башкарылды. Яңа Кырлай авылында шагыйрьнең үги әтисе Сәгъди абзый яшәгән нигездә әдәби парк ачылды. Ул «Таттелеком» компаниясенең генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин инициативасы белән булдырылды. Паркны ачу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты. Башта алар Г.Тукайның мемориаль музей комплексын карады. Аннары шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр китерделәр. Мәртәбәле кунаклар авыл зиратында булып, Сәгъди абзыйның каберен зиярәт кылды.

Әдәби паркта Сәгъди абзый белән кечкенә Апушның, Су анасы, Шүрәле, Былтырның сыннары урнаштырылган. Алар заманча технология нигезендә тимердән эшләнгән. Болардан тыш монда Г.Тукайның әсәрләреннән өзекләр, шагыйрь турында танылган шәхесләрнең сүзләре язылган китап-панно урнаштырылган. Шунда ук гасыр буена үскән нарат та бар. Аны 1893 елның язында Сәгъди абзый Апуш белән утырткан булган. Инеш буенда – Апуш коесы. Ул төзекләндерелгән, тирә-юнендә ял мәйданчыгы булдырылган. Ул көнне әдәби паркны Казаннан кайткан бер төркем язучылар да карады, шунда урнаштырылган ачык сәхнәдә халык алдында чыгыш ясады. Каләм ияләре Тукайның туган авылы Кушлавычта булды, шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салды, әтисе Мөхәммәтгариф каберен зиярәт кылды. Мәрхүмнең рухына дога багышланды.

«Әдәби җәүһәрләр» дип аталган I Бөтенроссия татар әдәбиятын сөючеләр бәйгесенең финалы да Арча районы Кушлавыч авылында үтте. Бәйгенең иң югары бүләге – Гран-прига Казандагы 5нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гүзәлия Шәйдуллина лаек булды.

Г.Тукайның туган көне алдыннан Арчада «Йөрәкләрдә Тукай эзләре, күңелләрдә Тукай сүзләре» дип аталган әдәби марафон үткәрелде. Ул көнне Арчага кайткан бер төркем якташ язучылар һәм журналистлар шәһәрнең барлык мәктәпләрендә һәм педагогика көллиятендә булып, укучыларның Тукай әсәрләрен ничек өйрәнүләрен, шагыйрь иҗатын яратуларын үз күзләре белән күрделәр. Марафон каланың үзәк мәйданында йөгерешчеләргә старт бирү, концерт, флеш-моб белән тәмамланды.

***

Г.Тукайның туган көне алдыннан бер төркем язучылар Балтач районына барып, Сасна Пүчинкәсе авылы зиратында шагыйрьнең әнисе Бибимәмдүдә каберен зиярәт кылды. Монда аның рухына Коръән сүрәләре укылды. Кунаклар район укучыларының ел буена барган иҗат бәйгеләрендә җиңүчеләрне һәм иң күп китап укучыларны бүләкләү тантанасында катнашты, чыгыш ясады.

***

Казандагы М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында татар теле һәм әдәбияты буенча IV халыкара олимпиадада җиңүчеләрне бүләкләделәр. Быелгы олимпиадада 12500 дән артык бала катнашты. Шуларның 500е финалга чыкты. Бәйгедә 12 чит илдән катнаштылар. Гран-прига Финляндиядән — Хакен исемендәге мәктәптән Наил Бәдретдин, Казандагы 27нче татар гимназиясенең 11нче сыйныф укучысы Зилә Мөбарәкшина лаек булды. Тантанада ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев һ.б. катнашты.

***

Казандагы «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Илһам» Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесендә җиңүчеләрне бүләкләү

тантанасы булды. Быел бу бәйгедә 2877 мең яшь иҗатчы катнашты. Эшләр шигърият, проза, драматургия, 1-4нче сыйныфларда укучылар өчен «Өметле киләчәк» махсус номинациясендә билгеләп үтелде. Гран-при Актаныш районы Пучы мәктәбеннән Гөлинә Нигъмәтуллинага тапшырылды. Тантанада ТР Премьер-министр урынбасары — мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

***

Татарстан Язучылар берлегенең химаячелегендә Анкарадагы «Бәнгү» нәшриятында тууына 130 ел тулу уңае белән Тукайның төрекчәгә тәрҗемә ителгән 130 шигыреннән торган китап дөнья күргән. Әлеге хезмәтне Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы тәрҗемәче Фатих Кутлу белән төрек шагыйре Али Акбаш башкарган.

***

Төркиядәге Евразия Язучылар берлегенең «Кардәш каләмнәр» журналының апрель саны тулысы белән Габдулла Тукайга багышлап чыгарылган. Барлык материалларны туплап тәрҗемә итү эшен идея авторы Фатих Кутлу башкарган.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Казан дәүләт федераль университетының Актлар залында ТРның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташка 75 яшь тулу уңаеннан әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә котлаулар шигырь, җыр белән үрелеп барды. Бәйрәмдарга ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды, ТР Мәдәният министрлыгы бүләкләре тапшырылды. Юбилярны КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), каләмдәшләре Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Хатыйп Миңнегулов, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, Мөдәррис Вәлиев, Шәмсия Җиһангирова, Әлфия Ситдыйкова, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Эльмира Җәлилова һ.б. котлады. Олуг юбилей уңаеннан Г.Камал театрының кече залында «Одиссея: Рәдиф Гаташ диңгезләренә сәяхәт» дип аталган шигъри спектакль дә күрсәтелде.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында һәм Иске Әлмәт мәдәният йортында шагыйрә, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, С.Сөләйманова, Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләкләр иясе Клара Булатовага 80 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде. Шигърият һәм җыр бәйрәменә әверелгән бу кичәләрдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов бәйрәмдарга ТР мәдәният министрының һәм Берлекнең Рәхмәт хатларын тапшырды. Бәйрәмдарны «Татнефть» ААҖнең «Рухият» рухи яңарыш фонды җитәкчесе Рөстәм Мөхәммәдиев, Әлмәт шәһәре башкарма комитеты рәисе Марат Гирфанов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җитәкчесе Рифкать Шаһиев, каләмдәшләре шагыйрь Рәдиф Гаташ, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов, прозаик, галим Фәрит Яхин, республикабызның сәнгать осталары, укучылары һ.б. котлады.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрь, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәшит Әхмәтҗановның тууына 75 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды. Кичәдә чыгыш ясаган каләмдәшләре Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев, Газинур Морат, Хәлим Җәләй иҗатында милләт, тел язмышы өчен борчылган, көрәш рухы белән янган шагыйрьне сагынуларын белдерделәр. Татарстан сәнгать осталары, шул исәптән Гөлзадә Сафиуллина, Риф Гатауллин, Казан филармониясе солистлары, музыка училищесы студентлары җырларын җырлады, бертуган энесе Илдус Әхмәтҗанов әдипнең шигырьләрен укыды. Искә алу кичәсендә Р.Әхмәтҗановның якташлары – Баулы муниципаль районы хакимияте аппараты җитәкчесе Ринат Хәмидуллин, хезмәт ветераны Сәгыйть Әхмәтҗанов, Сания Әхмәтҗанова, хатыны Луиза ханым, кызы Ләйлә белән улы Айдар, оныклары чыгыш ясады.

### СЕМИНАР

Казандагы Ф.Аитова исемендәге 12нче гимназиядә татар телендә белем бирү мәсьәләләренә багышланган фәнни-методик семинар булды. Әлеге чара ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгы, Милли китапханә ярдәмендә уздырылды. «Түгәрәк өстәл» утырышында язучылар Рабит Батулла, Камил Кәримов һәм Гөлзадә Бәйрәмова катнашты.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен фронтовик-язучы Хисам Камал «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

2016 елның 19 апрелендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Миңнеруй Хәбибуллина-Гайфуллина** 57нче яшендә вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть Ф.САДРИЕВА «Жаворонок»; повесть В.НУРИЕВА «Как поживаешь, сынок?»; рассказ Р.НИЗАМИ «Блокадные воспоминания»; стихи Р.ХАРИСА, ИДЕЛБИКЭ, М.САДЫКОВА, Г.БАТТАЛОВОЙ, Г.АФЗАЛА, Р.АХМЕТЗЯНОВА.*
*«100-я страница»: Х.МИННЕГУЛОВ. «Да будет вечно с нами наше духовное наследство».*
*«Наши юбиляры»: Ф.ГАЛИМУЛЛИН. «Воин-писатель и ныне в строю»; Л.ШАЕХ. «Я — нержавеющий золотой лемех!»; С.ХАФИЗОВ. «С пылающим углём на ладони»; М.МИРЗА. «Вечная забота»; статья М.ВАЛИЕВА, посвящённая 75-летию Р.Ахметзянова; Т.ГАЛИУЛЛИН, Р.ГАЛИУЛЛИН. «Человека ведёт судьба» .*
*«Литературная критика»: Ф.ХАТИПОВ. «Лжетрагедия».*
*«Публицистика»: Г.ДАУТОВ. «К великой цели — через просвещение»; И.ТАГИРОВ. «Святая святых».*
*«XVIII съезд писателей Татарстана»: Р.КУРБАНОВ. «Отчитываясь за прошлое».*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Из сокровищницы татарских рассказов»: А.ШАМОВ. «У могилы друга».*
*«Искусство»: Г.БАЙРАМОВА. «Уходить любя».*
*Страницы из «Татарской энциклопедии».*
*«Встречая юбилей»: Г.АБСАЛЯМОВ. «Из дневниковых записей».*
*«Белый парус»: З.ХАКИМ. «Маленький Зульфат»; рассказы А.ФАХРУТДИНОВОЙ, И.РАХМАТОВА; сказка Р.КАЛИМУЛЛИНОЙ.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Яблони цветут...»; река Вятка.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by F.SADRIEV «Skylark»; novel by V.NURIEV «How are you, son?»; stoty by R.NIZAMI «Blockade memoirs»; poems by R.HARIS, IDELBIKA, M.SADYKOV, G.BATTALOVA, G.AFZAL, R.AHMETZYANOV.*
*«100th Page «: H.MINNEGULOV. «Let it be forever with us, our spiritual heritage».*
*«Our anniversaries»: F.GALIMULLIN. «The warrior-writer is still in the ranks»; L.SHAEH. «I am a rustproof golden ploughshare!»; S.HAFIZOV. «With glowing coal in the palm of the hand»; M.MIRZA. «Eternal Care»; article by M.VALIEV dedicated to the 75th anniversary of R.Ahmetzyanov; T.GALIULLIN, R.GALIULLIN. «Destiny leads the human».*
*«Literary Criticism»: F.HATIPOV. «False tragedy».*
*«Publicism»: G.DAUTOV. «To the great goal through education»; I.TAGIROV. «Holy of holies».*
*«18th Congress of Writers of Tatarstan»: R.KURBANOV. «Reporting for the past».*
*«Tukay and Tatar literature»: section is led by R.RAHMAN.*
*«From treasury of Tatar stories»: A.SHAMOV. «At the friend's grave».*
*«Art»: G.BAYRAMOVA. «Leave loving».*
*«Meeting the anniversary»: G.ABSALYAMOV. «From the diary».*
*«White Sail»: Z.HAKIM. «Little Zulfat»; stories by A.FAHRUTDINOVA, I.RAHMATOV; tale by R.KALIMULLINA.*
*«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: «Apple tree in bloom...»; the Vyatka river.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Алмагачлар чәчәк ата».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Нократ елгасы.